# казан утлары

6
ИЮНЬ·1971

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

6
ИЮНЬ
1971

## Бу санда:

РОМАН, ХИКӘЯ, ПЬЕСА, ШИГЫРЬЛӘР

Ш. ГАЛИЕВ. Бәрәңге турында. Тормыш тозы. Кайчак... Үсә дә китә... Күнегелгән... Кара юллар була... Борчулар йөрәкне таласа... Артык имин көн... Әмер булсын иде... Тизрәк җитсен... Җәй әле... Җәйнең соңгы көне... Язын... Елмайдың да киттең... Үкенмәскә... Таныш түгел... Текәлеп карыйм... Мин омтылган максат... Күңелем... Шигырьләр . . . . . . . . 3
С. СӨЛӘЙМАНОВА. Йолдызларга йодрык. Хикәя 8
Ә. ШӘМИН. Өметле шайтан. Хикәя . . . . . 18
Г. СӘГЫЙРОВ. Минутлар... Ашыгам сиңа. Кайсыгыз анда... Син миңа яхшылык эшләдең... Элегия. Ишәк. Шигырьләр . . . . . . . . . 22
С. РАФИКОВ. Тын елга буенда. Роман . . . . 25
Т. МИҢНУЛЛИН. Кем сызган! Пьеса . . . . . 90

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Ф. САФИН. Музей ачтым. Юлда. Һаман шулай... Бер елганың ике ярында. Карт атменәр. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 96

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

К. Фәсәхов. Сүзе алтын, эше ялкын. Очерк . 99

ЯЗУЧЫ КӨНДӘЛЕГЕННӘН

Ш. Маннур. Һаман да истә . . . . . . . . . 107

ХАЛЫК ИҖАТЫ

М. ГОСМАНОВ. Шәкерт дәфтәре — җырлар биштәре . . . . . . . . . . . . . . . 131

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

К. ДӨҮЛӘТШИН. Чорлар аша . . . . . . . . 140
Ш. АБИЛОВ. Мәүла Колый хикмәтләренең яңа кульязмасы . . . . . . . . . . . . 147

ТӨРЛЕСЕННӘН

Й. ГӘРӘЙ. Нинчә «кара» бар! . . . . . . . . 152
Ә. БУЛАТОВ. Сәйфелгабит Мәҗитов . . . . . 154
М. ҺАДИ. Китабеннас фи хаккылхавас . . . . . 155

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Ф. УРМАНЧЕЕВ.** Халыкның күңел көзгесе . . . 158

Бәләкәй рецензияләр . . . . . . . . . . . . 168

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

**Ф. ЯРУЛЛИН.** Бәйрәмдә. Шигырьләр сөйли Марат. Искәндәрнең киңәше. Шигырьләр . . . . . 175
**М. ГАЗИЗОВ.** Балан. Тап әле. Шигырьләр . . . . 176

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

**Р. ХАННАНОВ.** Инсафлы килен. Гыйльми нәтиҗә. Хикәяләр . . . . . . . . . . . . . 177
**Ә. ФАЗЫЛҖАНОВ.** Без кемнән ким! Юмореска . 181
**ЮЗИЛ.** Сонет турында сонет. Илһам килгәндә һәм киткәндә. Яңа җырчы. Төкле аягың белән! Мәсәл геройларының сөенече. Ариозо. «Идел»гә. Вера Минкинага. Шигырьләр . . . 183
**И. ТУКТАР.** Җөмләләр . . . . . . . . . . 185
**З. НАСЫЙБУЛЛИН.** Йомычка. Озынборын. Карачкы. Турылык. Мин-минлек. Ике килми. Саран. Бала «гаебе». Ике фикер. Бүкән. Алтын сүз. Битараф. Шигырьләр . . . . . . . . . . . 186

УКУЧЫ СҮЗЕ

**Ш. ШӘЯХМӘТОВ.** Уңышлы әсәр . . . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

**Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый**

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Техник редакторы Р. Нәбиуллина.
Корректорлары Р. Сулейманова, К. Корбангалиева.

Производствога бирелде 1/II-1971 ел. Басарга кул куелды 29/IV-1971 ел. ПФ 09036. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 81946 экз. Заказ И-121. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды, Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1971 ел.

# Шәүкәт Галиев

## Бәрәңге турында

*Александр Георгиевич Лорхка*

Бер карасаң — сугыш чоры
Сагынырлык еллармы,
Бигрәк тә мәзәккә урын
Табылырлык еллармы?

Хәвеф-хәтәрне ул көннәр,
Әйе, аз китермәде,
Әмма иңне иңдерсә дә,
Башларны идермәде!

Кайгылар кара булсалар,
Өметләр якты иде,
Үткәннәр юк та, киләчәк
Гел безнең яклы иде!

Ипи әләкмәгән икән,
Бәрәңге тиде әзрәк,
Бәрәңге беткән чакта да
Бетмәде бездә мәзәк!

«Бу дөньяны авыр диләр,
Кем күтәреп караган!..»
Шулай дидек, ә бәрәңге,
Имеш, болай җырлаган:

«Иртә дә мин,
Кич тә мин,
Учакта мин,
Мичтә мин,
Чыдый алмыйм
Һич тә мин...»

Мәзәк иде бу, ә чыны
Башкача килеп чыкты —
Дошманнар әлмәккә керде,
Бәрәңге җиңеп чыкты!

...Яз иде, көннәр җылынган,
Юрганны илтеп саттык...
Һәм ниндидер бер «лорх»
дигән
Бәрәңге алып кайттык.

(Юрганга карап аякны
Сузасылар калмады!
Аякларны суза идек —
Шул бәрәңге ялгады...)

Җир тулып уңды яңа сорт,
Бик тиз таралды даны.
Соңрак белдем: мәгълүм галим
Лорх тапкан икән аны.

Лорх бабайның иҗатына
Бик күбебез бурычлы.
Шул җимешкә тоташкан бит
Шигъремнең дә бер очы.

Гадилектә ул да шуның
Кебегрәк булсын иде,
Халыкка шул бәрәңгедәй
Гел кирәк булсын иде!

## Тормыш тозы

Гадәти күк тоелса да
Болай карап торышка —
Ансыз яшәп булмый торган
Нәрсәләр бар тормышта.

— Икмәк! — диярләр хатыннар,
— Су! — диярләр яшь кызлар.
— Икмәк белән су... — диярләр
Дуадаклар-ярсызлар.

Өйләнгәннәр:—Хатын, — дияр,
Бездәйләр: — Кыз! — диярләр.
Башкалар ни диярләрдер,
Бабайлар: — Тоз... — диярләр.

Тормыш әйбәт, имин була
Һәрвакыт ул барында.
Күрдек аның юк чагын да
Без сугыш елларында.

Тормыш тозы нидәлеген
Белдек шул вакытларда,
Тоздан агарды аркалар
Тылда һәм окопларда.

Сез күрмәдегез, димим мин,
Бик җиткән без күргән дә,
Тик әчесен онытмагыз
Тәмнәр татып йөргәндә.

Аңла син ул заманны да,
Тозсыз сүздән арала,
Кайчагында тозсыз сүз дә
Тоз сала бит ярага...

Һәр кешенең тозы була,
Була, ягъни, мәгънәсе,
Сер түгел, тозсыз да була
Кайбер хода бәндәсе...

Ә тормыш — тозлы тир түккән
Җир уллары кулында.
Җирдә иң кирәк тә шулар —
Сүземнең тозы шунда!

●

Кайчак шигырь
Кинәт күктән
Иңгән төсле —
Карыйм, минем
Катнаш бармы
Дигән төсле...

Ачу җиле,
Моң җилендә
Кайчак килә;
Тешне кысып
Үкси кайчак...
Кайчак көлә.

Ә кайчакта
Буй җитмәслек
Биек тора.
Миңа чаклы
Үсәсең бар,
Диеп тора.

●

Үсә дә китә
Бала дигәнең —
Быелга кысан
Былтыр кигәне.

Тормышка шигырь
Өлгесе кисәм,
Үскән дә киткән
Киертим дисәм!

Тагын соңардык,
Ах, колак кактык;
Кинәнеп йөри
Ялангач хаклык...

●

Күнегелгән, белгән танышлардан,
Кабатланып беткән сүзләрдән
Аерылып мин сәфәргә чыгам —
Күңел офыкларын үзгәртәм.

Яна жирләр күзгә тансык була,
Яна кешеләр тансык күңелгә.
Яңага бит текәп карала да,
Яңалата ачык күренә...

Гомердә бер әле очрашсак та,
Гомерлеккә танып китәбез,
Йөрәкләрдә яңа карашларның
Кояшларын алып китәбез.

●

Кара юллар була, ак юллар,
Кара еллар була, ак еллар.
Туры юллар, туры еллардан
Әйдәп бара кыю акыллар.

Туры еллар, туры юллардан
Себереп түгеп барлык ваклыкны,
Күтәрәләр ялкын-байрактай
Гасырларда янар хаклыкны!

●

Борчулар йөрәкне таласа,
Күңелне шом үртәп торганда,
Тынычлык табам мин урамда,
Үзгәрәм дә куям мин анда.

Күтәрәм күземне түбәннән,
Текәләм наратлар башына;
Югала минутлык йомшаклык
Йөз еллык сабырлык каршында...

●

Артык имин көн кичермим микән? —
Булды шулай уйлап пошканым,
Кагылмый күк чорның тыгыз җиле,
Юк та бугай хәтта дошманым?..

Туры сүзне ярып әйткән идем,
Җайланды да китте тормышлар —
Минем дә бар шәхси дошманнарым,
Явып кына тора орышлар!

●

Әмер булсын иде, шигырьне тик
Ташка гына чокып язарга...
Буш сүз тезүчеләр бетәр иде!
Һай, бер шуны сынап карарга!

●

Тизрәк житсен иде, диеп,
Ял артыннан ялны көтеп,
Яшибез без көннәр санап,
Кыш артыннан язны көтеп.

Ашыктырабыз елларны,
Шулай көтеп ала-ала.
Ә үзебез офтанабыз:
Гомерләр бит үтеп бара!..

●

Җәй әле, җәй кебек, кай ара
Изрәткән эсселек сүрелде?
Офыкта — тасмадай,
Урманда тәңкәдәй
Сары төс күренде.

Җәй әле, җәй дисең, көннәр бар!..
Ә үзең сагаеп күзлисең.
Кинәттән күңелдә тоясың —
Көз төсен, көз исен, көз хисен...

●

Җәйнең соңгы көне... Кояш, җылы.
Гап-гадәти бер көн күк тыштан, —
Көтмәгәндә яулап алыр өчен
Сары яфракларга көз поскан...

Күбәләкләр, наян күбәләкләр
Сөенә-сөенә уйнап очалар.
Үзләренең соңгы бәйрәмнәре
Икәнлеген белми ич алар...

●

Язын сирень, шомырт чәчәге,
Көзен әгәр миләш очраса,
Ах-вах килеп кеше ташлана,
Сындыра да төйи кочакка.

Ботарланып, бик тиз таланып,
Әрәм була, күпме ямь бетә.
...Яратмаса кеше читләп үтә,
Яратканын күбрәк рәнҗетә...

●

Елмайдың да киттең һәм оныттың —
Күңелеңдә синең калмамын.
Шуңа күрә гамьсез булырга да
Тырышып мин шактый карадым.

Кабат-кабат төшмә исләремә,
Кузгатырга мине ярамый;
Син яшеңдәй тиз сүнәсең дә бит,
Әкрен кабынып озак янам мин...

●

Үкенмәскә инде өйрәндем мин,
Үкенүләрнең бармы файдасы?
Тик икәүләп үткән урыннарны
Күрергә бер килә кайтасы...

Ул чакларда тетрәндергән хисне
Кичереп карыйм, диеп талпынам:
Әмма шушы соңгы очрашуны
Киләчәккә һаман калдырам...

●

Таныш түгел якка киләсең дә
Таныш түгел кызлар күрәсең.
Шулкадәрле нигә үз икән, дип,
Сискәнәсең очрап берәрсе.

Сәерсенмәс кебек әйтсәң әгәр:
«Кил, якынрак килеп күрен... Дәш!»
Карашларны көчкә аерып алам,
Кала таныш түгел күңелдәш...

●

Текәлеп карыйм — көткәнем
Юлымда күренер күк,
Мәхәббәт тулы күңелем
Чайкалып түгелер күк.

Ах, яшен оныткан йөрәк,
Йөри үзен юатып...
Кызларны бүген яшьлегем —
Улым кайтыр озатып.

●

Мин омтылган максат ерак иде,
Гомергә дә барып житмәслек.
...Ирештем дә дисәм, бурычы бар —
Бер гомергә үтеп бетмәслек.

●

Күңелем ачык сиңа, дустым,— дидем,—
Я, кер.
Бактың исә, урмәләгән икән —
М ә к е р...

Сажидә Сөләйманова

# ЙОЛДЫЗЛАРГА ЙОДРЫК

ХИКӘЯ



Инде караңгы да төште.

— Әйдәгез, кызлар, үзәккә алып барам,— диде кемнедер кунак өенә китергән такси шоферы. Ишек төбендә аптырабрак торган Сәгадәт белән Чулпан, бу тәкъдимгә артык сөенеч белдерми генә, яшел күзле җиңел машинага кереп утырдылар.

«Кызлар», «кызлар» дип, шофер төрлечә сүз катып карый. Аның сөйләшәсе килә. Ул инде эшен тәмамлаган, кәефе күтәренке. Кызларның сөйләшәселәре килми. Аларның әле эшләре башланмаган да. Башланырмы, юкмы — анысы да билгеле түгел. Башка чак булса, унҗиде яшьлек кызы Чулпан белән бер рәттән Сәгадәтнең «кызлар» булып йөрүенә, мөгаен, кәефе килер иде. Бүген Сәгадәт ул сүзләрне гүя ишетми.

Такси тәрәзәсенә кунган вак тамчылар салкын пыяла буйлап тәгәрәп-тәгәрәп төшәләр. Асфальтка җәелгән яңгыр суларын чәчрәтә-чәчрәтә тәгәрмәчләр алга тәгәри. Шофер күңелле көй сызгыра. Ә менә Сәгадәтнең тормыш күчәре көрчеккә килеп төртелде. Ничек кузгатып җибәрергә аны, кайсы ягыннан тотынырга? Бар өмет Чулпанның вузга керүендә иде. Ул да, көмеш балдагын суга төшергән кәләштәй, буш бидрәләрен шалтыратып кайтып керде. Сәгадәтнең нишләтергә белми йөргән башына таш булып төште бу хәл. Тагын бер омтылыш ясап карарга кирәк. Кичке факультетларда имтиханнар башлана. Казандагы иске танышлары ярдәмендә эшкә урнаштырып булса кызны...

Администраторның күңелен Сәгадәтнең үтә талчыккан йөзе йомшарттымы — үзәк гостиницаларның берсендә бер урын тәкъдим иттеләр. Анысы да ярап торыр. Кызы белән икесе бер караватта ничек тә төн уздырырлар.

Сәгадәтләр кергәндә бүлмәдә ике хатын-кыз бар иде. Алар яңа гына каяндыр кайтып кергәннәр булса кирәк, урындык аркасына эленгән җиңел плащлары дымлы күренә, каш-керфекләрендә яңгыр тамчылары җемелди. Маңгай чәче яшьләрчә кыска киселгән түгәрәк йөзле мөлаем хатын арыган кыяфәттә өстәлгә терсәкләнеп утыра. Кара

костюм түшендә алтын йолдыз... Озын буйлы, какчарак гәүдәлесе йолдызлы костюмын салып, бик пөхтәләп элгечкә элеп маташа. Геройлар... Мондый данлыклы кешеләр белән очрашу-сөйләшү булыр дип һич уйламаган иде Сәгадәт. Тегеләр дә, Сәгадәтнең уен аңлагандай, гадәттә әйтелә торган сәламләү сүзләре әйттеләр дә үз эшләрендә булдылар.

— Рәшидә, өсләреңне алмаштыр, чәй эчеп алырбыз, — диде озын буйлысы кыска чәчлегә. Үзе ситсы халат киеп алды, юка конгырт чәчен тарак белән бер-ике сыпырып, артка төенләп куйды.— Хәзер кайнар чәй алып керәм, Федотовка күчтәнәче белән чәйләп алырбыз.

Какча хатын чемоданыннан төргәкләр чыгарып, өстәлгә тезә башлады. Ул арада Рәшидә дигәне дә, урыныннан җәһәт кенә кузгалып, костюмын салды, чәчәкле халат киеп куйды, чәйнекне алып чыга да башлады.

— Өстәлне әзерли тор, Настя, авыл күчтәнәчләре миндә дә бар.

Геройларны, нигәдер, кәперенке итеп күз алдына китерә иде Сәгадәт. Бу хатыннарның шулай гап-гади нәрсәләр турында сөйләшуләреннән Сәгадәтнең җанына җылы йөгергәндәй булды. Авылга, түтәкәйләренә кунакка кайткан сыман хис итте ул үзен. Кайнар чәй, күчтәнәчләр... Гаилә җылылыгы бөркелеп торган мондый сүзләр Сәгадәт өчен сәер дә, тансык та...

Рәшидә ялтыравыклы чәйнек белән кайнар су алып кергәндә Сәгадәтләр өс-башларын, аяк киемнәрен алыштырган, юл сумкаларын урнаштырганнар иде.

— Әйдәгез, балалар, чәй эчәбез, — диде Рәшидә, ишек төбендәге карават янында нишләргә белмирәк басып торган ана белән кызга.— Юлдан килгән кешегә кайнар чәй бик кулай булыр. Менә монысы һиндстан күчтәнәче. Рәшидә ханым сумкасыннан бәләкәй генә кәгазь төргәк чыгарды. — Ә монысы безнең Иркәнәш күчтәнәче дип белерсез. — Сумкадан банка белән бал чыкты.

«Һиндстан күчтәнәче» дигәч, Сәгадәт белән Чулпан да, әдәплелек дигән нәрсәне бер читкә куеп, төргәкне ачып маташучы хатын кулына күз төшерделәр. Ул да булса гомер-гомергә эчә торган «индийский» чәй икән. Күңелле генә көлешеп алдылар. Өстәл тирәсенә утырышканда бер-берсен ят итү шактый кимегән иде. Ни көйсез Чулпан, ул да чәйдән баш тартмады. Танышу-белешүнең язылмаган кагыйдәләрен үтәү йөзеннән, хатыннар яңа кунаклардан җиңелчә генә сорашып алдылар: юлчылар кайсы якныкы, Казанга эш беләнме, озаккамы? Сорауларына җавап ишетсәләр дә, ана белән кызның җәелеп китәргә исәпләре югын күреп, хатыннар артык төпченмәделәр. Ул арада Чулпан, аны-моны капмый гына бер стакан чәен эчеп бетерде дә, рәхмәтен әйтеп, өстәл яныннан китеп тә барды.

— Шундый зур кызыгыз бар, үзегез бик яшь күренәсез, — диде Настя, Сәгадәткә сокланып карап.

Бер-берсенең яшьләрен сорашу-белешү китте. Сәгадәткә гадәттә биш-алты яшь ким бирәләр. Биюле-җырлы бәйрәм кичәләрендә ун елны ук киметеп ташлыйлар. Аның яшьлеге — юка, сылу гәүдәсендә, җиңел хәрәкәтләрендә. Ә менә Рәшидә ханым бер ел да киметмәде.

— Алай да утыз сигез яшь булыр, — диде. Аның аз гына кысынкы конгырт күзләре кешене үтәли күрәләр кебек иде. «Алай» да диюе, «яшь күренсәгез дә» диюе инде. Рәшидәгә җавап итеп Сәгадәт тә нәкъ уйлаганын әйтте:

— Сезгә утыз тугыз-кырык яшьләр...

Дөрес әйткән, Рәшидәгә кырыгынчы яшь икән. Настя олырак күренсә дә, Рәшидә белән алар бер яшьтә булып чыктылар. Сүз бүген концертта җырлаган популяр артисткага күчте. Тавышының сафлыгы, үзенең сылулыгы! Рәшидәдән дә олы булырга тиеш инде ул, ә ничек яшь саклана! Узган ел гына кияүгә чыккан ди, дөрес микән? Дөрес ди.

белгән кешеләр сөйләгән. Яшь кенә хатынын аертып, баласын ташлаттырып, үзенең баянчысына чыккан ди.

— Партиядә түгел микәнни соң алар?

— Бер-берсенә мәхәббәтләре төшкәндер. Партиядәге кешеләрнең дә йөрәкләре таш түгелдер бит? — Сәгадәт үз фикерен хуплауны да, кире кагуны да көтмәстән, урыныннан кузгалды.— Арылган, ял итәргә кирәк.

— Таш түгелен анысын таш түгел дә...— диде Рәшидә, беркемгә дә карамый гына, үз алдына сөйләнгәндәй итеп. — Әмма анда нәфескә баш булырга өйрәтәләр. Бала өчен кем җавап бирә?

Сәгадәтнең кайнар чәй, якты йөздән бераз ачылып киткән күңелен гүя тимер капка белән авырттырып ябып куйдылар. Нинди кырыслар авыл кешеләре!..

Чулпан стенага карап яткан, әллә йоклый, әллә йокламый. Сәгадәтнең карашы урам яктысы төшкән түшәмгә төбәлгән. Хатыннар йокларга яткач та сөйләшеп туялмыйлар. Аларның караватлары янәшә. Сәгадәтнең буталчык уйлары арасына ара-тирә тегеләрнең пышылдаган тавышлары килеп керә.

— Бер туйганчы йокларга кирәк әле. Авылда иртәнге икедән торам мин. Дүрткә чаклы сыерым савылган, мал-туарым каралган, мичем ягылган була.

Боларны Рәшидә сөйли. Колхозда бригадир булып эшли икән ул. Сәгадәтнең күңеленнән генә гаҗәпләнүен Настя сүз белән әйтә: нигә Рәшидә сыер асрап үзен җәфалый, ферма сөтен яратмыймы? Балачагасы да булмагач...

— Мал асрамый да яшәп карадым, малай. Хатыннар хәзер усал бит. Эш буенча азрак тәнкыйть сүзе әйтә башласаң, «и, синең эш беткән лә ул, мал-туарың юк, фермада сөтең әзер» дип, авызны томалыйлар.

Барысыннан да күбрәк эшләп, һәммәсеннән иртәрәк өлгерергә кирәк икән Рәшидәгә. «Әмма анда нәфескә баш булырга өйрәтәләр...» Ничек кырыс итеп фикер йөртә ул үзе дә. Сәгадәтнең менә ике ел инде, төнлә йокысын, көндез зиһенен алган нәфес ашкынуы гынамы? Үз күңеле өчен бер дә яшәми микәнни соң бу үткен карашлы чая хатын? Әһә, әнә, яшь чакларын исенә төшерә. Күгәрчен гөрләгән кебек, әкрен генә сөйли Рәшидә.

— Мәк чәчәге кебек янып торган чагым иде. Үзем укытучы, үземне бригадир итеп куйдылар. Ике эшне дә алып барам, сугыш беткән яз, егетләр, ирләр кайта башлады. Кич белән күрше авылга клубка баралыйбыз. Берсенең күзе төштө бит миңа. Капитан. Киң җилкәле, түгәрәк йөзле чибәр егет. Җәй клубка йөрергә вакыт юк. Караңгы төшәртөшмәс тулган ай кебек балкып килеп җитә үзе. Хат язышып торган егетләрем дә бар. Бергә укып, бергә уйнап үскән. Берсен яшертен генә көтә идем. Өзелеп-өзелеп хатлар яза иде. Хәзер, әнә, райком секретаре. Кемнең ничек буласын яшь чакта каян уйлап бетерәсең? Аем балкып торганда — йолдызларга йодрык дигән бит. Аннары, үзем авылда җитәкче кеше, күз өстендә каш кебек. Очрашып, сайланып йөрү килешми. Бер озаттыргансың икән, кире борылу юк инде. Көзгә туй ясадык.

Рәшидәнең хикәятен урамда әледән-әле выжлап узган машиналар тавышы күмә. Ул арада Сәгадәтнең күз алдына үз капитаны килеп баса. Ак күбәләктәй чак. Сәгадәт дүрт туган арасында иң кечесе, аның үз юлы юл, үз көе көй. Сугыш беткән ел иде. Унны тәмамлап укырга Мәскәүгә китте, керә алмады. Ах алла, киләсе елга Ленинградка барыр. Дус-дошманнан хурланмыйча, Казанга керәсе юк. Эшләп алыр. Өс-башын карар. Хәер, Сәгадәтнең өс-башы болай да коеп

куйган кебек. Атасы чит илдән посылкалар җибәреп торды. Посылкалары килде, үзенә кайту насыйп булмады. Әнисенә ялгыз кыен, бер ел булса да янында торып Сәгадәт. Укырга кермәве әйбәт тә булды әле. Әнисе өчен кайтты да инде ул. Таныш-белешкә әнисе шулай диде бит. Әни кеше белми сөйләмәс. Әйе, әтисе кайгысыннан ВУЗга керә алмады бит Сәгадәт. Әтисенең танышлары әйбәт кенә эшкә урнаштырдылар. Хәрби оешмага. Андагы танцылар! Буе камыш, биле балдак капитан... Вася-Василек, Василичек... Аларның бер-берсе өчен яратылган икәнлекләрен бөтен кеше аңлады. Тиздән булачак туйны көттеләр. Сәгадәтнең сылулыгына табынучылар бер ул гына да түгел иде. Бигрәк тә берсе күбәләктәй кызны үзенеке итәргә теләде. Авыл егете. Хәрби училищены тәмамлап фронтка китүгә, сугышны бетереп кайтканнар. Казанга, Сәгадәтләр оешмасына эшкә кайтты лейтенант. Бер вальстан ук башы-күзе әйләнде егетнең, Сәгадәтнең артыннан калмас булды. Сәгадәт бии, көлә, аңа күңелле. Җиңелчә ирештереп бераз йөртте Сәгадәт лейтенантны. «Тиздән үзеңне туйга чакырам» дип, шаркылдап көлгәч, егетнең бер сүнеп, бер кабынган кара күзләре...

Туй булмады. Дөресрәге, булуын булды ул. Ләкин билгеләнгән вакыттан шактый соңгарып һәм бөтенләй башка кеше белән. Әлеге кара күзле авыл егете белән. Ул чакларны искә төшермәү яхшырак.

Хатыннар һаман сөйләшәләр. Настя тыңларга, Рәшидә сөйләргә ярата икән.

— Эчәргә сабышты. Сельпо мөдире булгач, җае да чыгып тора. Ирләр хатын-кызның дәрәҗәсен күтәрә алмыйлар бит. Аерылсаң, авыл халкы алдында кыен. Борының күтәрде диярләр. Председательлектән төшеп калуым шуннан булды. Как раз колхозларны эреләндергән чакка туры килде. Гаиләң таркалып барсын, үзең олы хуҗалык белән идарә иткән бул.... Район хуҗалары белән киңәштек тә, бригадирлыкта калырга булдым.

— Хәзерге бригадир элекке председатель белән бер дәрәҗәдә инде ул, — ди Настя, Рәшидәне юаткандай итеп. — Минем дә гаиләмнең сүтеләм-сүтеләм дигән чаклары бар иде. Балалар яшь... Әле ярый, картым түзем булды.

Сабый чагындагы сыман, Сәгадәтнең кулбашына борынын төртеп, Чулпан мыс-мыс йоклый. Баласының шушындый якынлыгын күптән тойганы юк иде инде Сәгадәтнең... Имчәк баласы сыман итеп, кысып сөясе иде дә... Уянуы мөмкин...

Түшәмгә урам фонарьларының шәүләсе төшә. Тәрәзәгә җилле янгыр бәрә. Әле алсу, әле кара шәүләләр хәрәкәткә килә. Кинодагы сыман тагын үткән күренешләр...

Өйләнешкән чорда лейтенант Сәгадәткә үлеп гашыйк иде. Һәрхәлдә, Сәгадәткә шулай тоелды. Шундый гашыйк булганы өчен дә чыкты аңа Сәгадәт. Алданган мәхәббәтеннән, ачынуыннан, гарьлегеннән кияүгә чыгып котылмакчы булды ул. Егетнең исеме Васил булуы да шактый роль уйнады. Тегесе Василий иде бит. «Без Вася белән», «Минем Василек»... дип, кызларга күп тәтелдәгән иде Сәгадәт. Белгәннәр бар, белмәгәннәр бар. Шул ук Вася дип уйлаучылары да булыр. Тора-бара барысы да онытылыр. Чыннан да, тора-бара капитанны телгә алмый башладылар. Ни булмас яшьләр арасында? Тик менә Васил генә онытырга теләми. Оныта алмый. Их, нигә ичмасам исеме шундый булды! Сәгадәт тора-бара иренә исеме белән дәшәргә курка башлады. Нигәдер ул бу исемне йомшак итеп әйтә алмый, катырак итеп әйтә. Бигрәк тә иркәләгән, иркәләнгән вакытларда бу исемне ишетүгә ире кинәт үзгәреп китә. Сәгадәте беренче мәхәббәтен сагынадыр, аңа дәшәдер төсле... Сәгадәттә исә, ул беренчегә күңел җәберлә-

нуеннән башка бер нәрсә калмаган, бөтен барлыгын иренә тапшырырга әзер Сәгадәт. Янәшә барганда горурланырлык буй-сыны, хатынын бәла-казадан каплый алырлык киң күкрәге, нәни кулларың белән кереп адашырлык дулкын-дулкын кара чәчләре бар Василнең. Сәгадәт гомер буе шулай ире белән горурланып, аңа аркаланып яшәр иде. Тик менә Васил генә... Вася белән булган хәлләрне ул белә. Сәгадәт аңа үзе дә сөйләгән иде. Туй алдыннан гына тегенең фронттагы хатыны килеп төшүен... Капитанның әле үзе дә белмәгән-күрмәгән баласын күтәреп... Сәгадәт нишләп балалы кеше белән язмышын бәйләсен? Бәхет күбәләген дошманнардан тартып алган кебек хис иткән иде үзен Васил ул чакта. Шат иде, горур иде. Кинәт аны алыштырып куйгандай булды. Бүтәннәргә кирәкмәгән өчен генә тигән итеп күрә башлады ул Сәгадәтне. Кеше сүзе кимерә иде бугай Василнең йөрәген.

Кызлары тугач аралар тагын да катлаулана төште. Бала гел атасына охшаган: алкаланып торган кара чәч, кара-кучкыл йөз, ияк уртасында сөйкемле чокыр. Бала җанлы Васил кызын бик ярата, күкрәгенә кысып күтәреп йөртә. Ул да булмый, нидер исенә төшеп, кинәт үзгәрә, баланы тиз генә урынына сала. Китап яки газетага каплана да, кич буе аннан бер сүз алалмыйсың. Исерткечкә һәвәсләнеп китте. Кызмача кайтып, хатынына кул күтәрүгә чаклы барып җитте. Сәгадәтнең әнисе моңа түзеп тора алмады, киявенең эш урынына барып жалу ясады. Шуннан әйләнеп китте дөнья каруселе!.. Әниләренең квартираларында түгел, Казанда калу-калмау мәсьәләсе килеп басты яшь гаилә алдына. Нигә шул чакта аерылып калмаган Сәгадәт? «Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас» дия иде әнисе мәрхүм. Балаң атасын белә башлаганчы, үзең яшь чакта аерылып кал, барыбер игелек күрсәтмәс дигән иде. Тыңламады. Ире артыннан яшь нефть шәһәренә күченеп китте. Безне белмәгән кешеләр арасында сүз-күз булмас, тынычрак булыр дип уйлады.

Башта шулай булды да. Тормышны өр-яңадан кору дәрте белән янып йөргәндә, булып узган зилзиләләр онытылды. Васил институтка читтән торып укырга керде, хәрби кешедән укытучы булып китте. Сәгадәт өйдә генә торды, Чулпан мәктәпкә кергәнче бала тәрбияләү белән мәшгуль булды. Ул үзен күп нәрсәгә сәләтле дип уйласа да, кулында диплом юк. Юк-бар эш хакына вакыт уздырып йөргәнче, өйдә тору файдалырак булыр дип карар кылынды. Квартира ялт итеп тора, баласының, әтисенең өс-башы чиста, ашарларына әзер. Әнисе янында үскән кыз буларак Сәгадәтнең кулы һәрнәрсәгә ятып тора. Тик менә Василнең эше чамадан тыш күп булса да, айлыгы азрак. Нефтьчеләр ягына йөз тоту кирәк булыр. Иң перспективалы эш.

Байтак әзерлектән соң бу план да тормышка ашты. Ләкин моның өчен Сәгадәткә соңыннан үкенергә туры килде. Васил яңа эшкә күчкәч, бик басынкыланып китте, сөйләшмәс булды. Яңаны үзләштерү җинел түгел, узар дип уйлады Сәгадәт. Күрә, ире эчкәләп кайта, ирлеген күрсәтеп, кулын да уйната башлады. Әкренләп тормыш Казандагы эзенә килеп төште. Тагын Сәгадәт гаепле. Ул Василне яраткан эшеннән аерган, аңа акча гына булсын! Китәргә иде теге шома... егет белән! Кинәндерер иде уңга-сулга алимент таратып! Я ходай, тагынниләр ишетәсе бар икән Сәгадәтнең? Нигә соң Васил Сәгадәтне тыңлап башка эшкә күчкән? Сәгадәт аның нинди эш яратканын каян белсен? Булмады бәхет, булмады. Әтисе мәрхүм «Сәгадәтем-бәхетем» дип сөя иде аны. Бәхет дигән нәрсәнең исемен ишетә йөреп, үзен күрмә икән. Кимсетелү гарьлегеннән ачынып елаган чаклары аз булмады Сәгадәтнең. Кеше кулларында кагылып-сугылып яшәр өчен үстемени сылу кыз? Аның белән бер сөйләшүне бәхеткә санаучылар бар иде бит заманында. Үзен бәйсез итеп, көчле итеп, күпләрдән өстен итеп саный иде бит ул. Нишләп җебеп төште әле?

Язу-сызу эшенә хезмәткә керде Сәгадәт. Эшләмәгән кешене бигрәк санга санамыйлар. Эштә Сәгадәтне пөхтәлеге, житезлеге өчен ярата-лар. Кайбер дипломлы һөнәр ияләреннән остарак башкара ул эшне. Шул югары белемле мактанчыкларга бераз ирония белән карый Сәга-дәт. Ромбик тагып киләләр дә, түшләрен киереп, хокуклар таләп итә башлыйлар. Үзләре бит баштa ук шушы дипломсыз-нисез Сәгадәт кулына килеп эләгәләр. Аларның бөтен документлары Сәгадәт кулын-нан уза. Берничә елдан Сәгадәтне танымаска әйләнә кайберсе.

Сәгадәт үзен шулай һәрьяклап язмыш тарафыннан рәнҗетелгән итеп сизә. Василнең җене алмашынган чакларда, һич кичектерми аерылам дигән карарга килә. Ике-өч көн сөйләшми йөргәннән соң, тор-мыш тагын үз җаена төшә. Бала бар бит. Ике арадагы өзелгән кылны ялгаучы ул. Васил Чулпанны бик ярата. Аның бөтен куанычы да кызы булса кирәк. Укый башлагач, Чулпан әллә нишләп әтисенә якынаеп китте. Сәгадәт кухня тирәсендә маташканда, алар бер-берсенә әкият-ләр сөйлиләр. Кызы авылда күреп кайткан каз бәбкәләрен, кәҗә бәрән-нәрен әкияткә әйләндерә. Әтисе әкиятләрендә Алып батыр комбайн-нар давыл пәриләренә каршы көрәшәләр. Җәй көне балыкка да кызы белән йөри Васил. Шушы баланы атасыннан аерып ничек алып китә-сең? Китәргә теләрме әле Чулпан? Шулай бер дулкынланып, бер тын-ган гаилә тормышына күнегеп тә килә бугай Сәгадәт. Яхшыга да күнегә кеше, яманга да. Тагын көчлерәк давылга сәбәп чыкмаса, бәлки шулай дәвам иткән булыр иде тормыш. Хәзер алай дәвам итә алмый. Ә Сәгадәт бер чарасын таба, янсә... Бу хакта уйласаң, баш чатный. Уй-исәпнең чигенә чыгып булмас. Йокларга тырышырга кирәк.

Үз уйларыннан арынуга Сәгадәт бүлмәдәшләренең мөңгер-мөңгер сөйләшүләренә колак сала. Ничек булып бетте икән Рәшидәнең гаилә хәлләре?

— Яшьләр калмый авылда, яшьләр... Шәһәрчә итеп культура йорты да салдык. Шәһәр артистлары даими килеп тора. Әнә минем карт өч стенасын үтә күренмәле итеп яшьләр кафесы салдырып ята. Юк, тотып булмый яшьләрне. Үземнекеләр өчесе берьюлы институтта укыйлар әнә. Тәмамлагач авылга кайтабыз диләр инде. Минекеләр дә кайтмаса, бүтәннекеләргә сүз дә юк.

Рәшидә тавышы бу. Малайларча кырысрак сөйләшә ул. Настяның тавышы иркә кызларныкы сыман.

— Бездә дә шул хәл. Әле дә машина бар, кем эшләр иде?

— Синең эш көйле, Настук. Кнопкага басасың да дуңгызларың симерә. Эшеңнән дә уңгансың, иреңнән дә. Молодчина!

— Эшем шул картым аркасында җайга салынды. Механизмнарны ул эшләде. Яшь балалар чорында гына кыенга килә. Машинага ыша-нып булмый аларны.

Гаилә хәсрәте күрмәгән икән Настя. Сөйләшүеннән үк иркә хатын икәне күренеп тора. Әнә бит, ире ничек кадерли икән аны!

Сәгадәт тагын йокыга китә алмады. Ул ирексездән үз язмышын шушы хатыннар тормышы белән чагыштыра. Герой исемен юкка бирмәгәннәр аларга. Үз хакларыннан бигрәк ил хакын хаклыйлар. Алар кирәкле кешеләр. Алардан башка җирдә яшәү юк. Сәгадәтнең эшендә кәгазьләр дә папкалар, өйгә кайтса, үпкәләш тә тарткалаш. Ничек көйләде икән Рәшидә үз гаиләсен?

Сәгадәтнең караваг сиртмәсе шыгырдаудан хатыннар тынып кал-дылар, кешене уяттык дип уйладылар, ахрысы. Бер-ике сүз пышыл-дашып алдылар да бүтән сөйләшмәс булдылар.

Күз алдында тагын хатирә хәрабәләре. Үткән тормыш җеп очыннан тартып сүткән бәйләм сыман алга өелә тора. Башта соңгыраклары, аннары арырак калганнары, онытылып беткәннәре...

Ире белән соңгы сөйләшү... Сөйләшүме соң! Бергә яшәгән бөтен тормышны астын өскә китереп ташлау булды бу. Вәсил кычкырды, Сәгадәт ярсыды. Соңгы вакытта сүзләр сайлап тору гадәте беткән иде алар арасында. Сәгадәт тә эреплэшергә өйрәнеп китте. Ниләр генә әйтмәделәр бер-берсенә! Үз сүзләрен Сәгадәт хәтерләми инде, ә иренең ямьсез тавышы әле дә колакны ярып тора. «Иснәшеп өлгергәнсез, табышкансыз, командировкага дип йөрүләрең шуның өчен икән!..» Тагын әллә нәрсәләр... Василий белән очрашу хакында бу. Көтмәгәндә Казанда Василий белән очрашу Сәгадәт өчен бер афәт булды. Чираттагы командировкасына килгән иде Сәгадәт. Әнисенең туганнары яшәгән элекке квартирына кереп чыкмакчы булды. Гомумән, анда кереп йөрергә бик яратмый ул. Вакыт та кысан була, үткәннәрне искә төшерәсе дә килми. Бу юлы керәсе итте.

Иске бакча. Көзге яфракларны җил очыра. Таныш таш койма. Вася белән соңгы тапкыр шушында очрашкан, шушында аерылганнар иде. Туй алды ыгы-зыгысы. Вася сулышына кабынып килгән. Сәгадәтне өйдән чакырып чыгарды. Ашыгып-ашыгып нидер сөйли башлады. Сәгадәт башта берни дә аңламады. Вася кат-кат бер үк нәрсәне кабатлагач кына кызның аңына барып җитте: туй булмый. Сәгадәтне алдаганнар. Васяның хатыны, баласы бар икән. Вася тукталырга курыккандай һаман сөйли: «Син бераз сабыр ит, Сәгадәт, мин Мәскәүгә китәргә, аларны урнаштырырга тиеш. Без, һичшиксез, синең белән булырбыз. Мин сине генә... Коточкыч ялгышлык булган ул...» Зиһене ачыла башлаган Сәгадәттә ярсу ташып килә иде.

— Югал күземнән!..

Сәгадәтнең бәхилләшү сүзе шул булды. Мондый кара нияттән соң бергә булу мөмкинлеге турында башына да китермәде ул чакта Сәгадәт. Хатыны, баласы була торып... Ничек җир упмый үзен!.. Ул чакта шулай уйлады Сәгадәт. Яшь чакта шулай уйлау тиешле дә. Хәзерге ачы тәҗрибәсе булса, башкача уйлаган булыр иде, бәлки. Кай тарафларда йөри икән хәзер Сәгадәтнең яшьлек мәхәббәте? Һәм... менә Сәгадәт алдында, күктән иңгәндәй, Василий басып тора! Аны уйлап кына килгәндә... Бер-берсен уйлаган кешеләр арасында биотоклар йөри диләр, дөрес, дөрес икән!

Бер-берсенә карашып сүзсез тордылар. Олыгайган Вася, калынайган, штатский киемнән, чит-ят кеше булган. Гади танышлар сыман гына хәл-әхвәл сораштылар. Арадан күпме салкын җилләр исеп үткән бит. Икесе дә элеккеге түгелләр. Сәгадәт үзен горур, бәйсез тотарга тырышты. Моңа ирешүе дә бугай ул, Вася бераз югалып калды. Ул Казанга эш белән килгән, бүген китә. Поездга чаклы күпмедер вакыт бар икән. Иске дуслар турында кайбер нәрсәләр белеп булмасмы дип, монда килгән. Теге чакта аерылышканнан соң өченче килүе икән. Менә бит, өченче тапкырында гына Сәгадәтне очрату бәхетенә ирешкән.

Сәгадәт Васяны көзге бакча буйлап озата барганда шуларны белде. Фән юлыннан киткән икән Вася, галим булган. Гаилә турында берни сорашмадылар. Бәхеткә аркылы сызык салган кешенең дөньяда барын-югын да беләсе килми иде Сәгадәтнең. Василий исә Сәгадәтнең гаиләсе хакында белә бугай. Сөйләшүне я шунда туктатырга, я бик тирәннән кубып сөйләшә башларга кирәк иде. Сәгадәт үзенең хәзерге тормышыннан бик канәгать сыман кыланды. Үткәннәре өчен үкенмәвенә ишарә ясады. Нигә иске җәрәхәтләрне кузгатырга? Хәзер Вася төзәтә алмый бит аларны. Үзалдына шулай сөйләнде Сәгадәт һәм ашыгыч эше бар сыман хушлаша башлады. Василийның болай гына

бөтенләйгә аерылышасы килми иде, ахрысы. Мәскәүдәге телефон номерын бирде, барган чакта шалтыратмый калма, диде. Менә шул. Бу очрашуның бөтен мәгънәсенә соңыннан гына төшенде Сәгадәт. Вася әйткән һәр сүзне, аның һәр күз карашын кабат-кабат күңеленнән кичерде. Сиздә бит Вася Сәгадәтнең бик үк бәхетле түгел икәнен. Югыйсә, хушлашканда Сәгадәтнең кулын шулай озак җибәрми тормас иде, телефон номерын язып, кечкенә блокнотын Сәгадәтнең кесәсенә салмас иде. Озак, бик озак арына алмады Сәгадәт очрашу күренешләреннән. Василий үзе дә бәхетле түгелдер. Югыйсә, нигә дип Сәгадәт белән очрашу эзләп йөрер иде икән?

Бер кичне Сәгадәт Василийны Казанда очратуын иренә сөйләп бирде. Нигә сөйләгәндер, үзе дә белми. Ире белән ике арадагы томанны сыпырып ташларга да мөнәсәбәтләрне ачыкларга теләптер, бәлки. Чыннан да, үткәннәргә кайту юклыгын аңлашкандай булганнар иде. Ачуын соңыннан чыгара башлады Вәсил. Теге гөнаһ шомлыгы очрашуны ул да озаклап уйлап йөреп, аның һәр ваклыгын, хәтта булмаганнарын да күз алдына китерә иде бугай. Икесенең исемен бергә кушып, шелтә сүзләре ишетә торгач, Сәгадәт чынлап торып Василий белән очрашуны тели башлады. Юк, бу юлы ул барын да сөйләп бирер, барын да сорашыр, бер күләгәле төш тә калдырмас иде. Хатынының башка берәү белән саташып, үзеннән бөтенләй читләшүе Вәсилнең җенен тагын да ныграк котырта. Алар бер-берсен аңламас хәлгә житәләр, сүздә булсын, эштә булсын, бер-берсенә юл куймый башлыйлар. Юк, болай яшәп булмый, аерылырга кирәк. Бер-береңне газапламый яшәүнең бердәнбер чарасы шул. Менә, Чулпан гына укырга керсен.

Ә Чулпан кире кайтты. Гаиләдәге орыш-талаш балага тәэсир итми каламы соң? Бик көйсезгә әйләнде кызый, бер ничек тә аның җаена килеп булмый. Тиргәүне дә кабул итми, иркәләүне дә. Әнисенә ул чыраен сытып карый башлады. Өзек-өзек ишетеп калган сүзләр буенча чит ирләр белән очрашып йөрүче дип белә торгандыр. И, бала, бала, ничек итеп сине ялгыш адымнардан саклап, әниең язмышыннан йолып калырга? Укытырга иде, югары белемле итәргә. Ромбик тагып йөрүчеләргә тыштан ачуы килсә дә, эчтән аларга кызыгып карый иде Сәгадәт. Зирәк булса да, гыйлем акылы житмәде, ахрысы, Сәгадәткә. Чулпан мәктәптә беренчеләрдән саналды. Укуда да, җәмәгать эшендә дә. Тагын бер омтылыш ясап карарга кирәк.

Чулпан исә әнисенең кулбашына курнос борынын төрткән дә мыш-мыш йоклый. «Минем Чулпан йолдызым...» Сәгадәт күңеленнән генә бишек җыры көйли.

Күк йөзен тутырып җемелдәшкән йолдызлар арасыннан балкып ай чыкты. Йолдызлар тоныкланып калды. Сәгадәтнең янәшәсендә алтын шар сыман тәгәрәп баручы ай гына. Сәгадәт йөгерә, ай тәгәри. Сәгадәт атлый, ай бара. Сәгадәтне бер адым ялгыз калдырмый, югары булса да янәшә. Үзе шомлы, үзе серле. Үзе куркыныч, үзе рәхәт. Ике йолдыз айның алдына төшеп, Сәгадәткә чекерәеп карап тора башладылар. Сәгадәт аларга йодрык күрсәтә дә кире якка йөгерә. Ай үз юлыннан китә. Йолдызлар, әйтерсең, чатларын йомарлыйлар да йодрыкка әйләнеп, Сәгадәтнең башына суга башлыйлар. «Йодрыгың үз башыңа, үз башыңа...»

Сәгадәт башы чатнаудан уянып китте. Ишек шакыйлар икән. Сәгадәт үзенең кайдалыгын абайларга тырышып яткан арада, берсе ишек ачты. Настя икән. Керүчесе сөйләнә-сөйләнә керә:

— Әле һаман йоклыйсызмыни? Бу шәһәр кешеләре бер минут бикләнми тормыйлар, үзләрен урлап китәрләр дип куркалармы?

Шәһәр хатыннарын әрләүчесе Рәшидә икән. Сәгать әле иртәнге җиде генә, ул инде әллә каян урап кайтырга өлгергән. Ишекне кем бикләгәнен йокы аралаш күреп калган иде Сәгадәт. Көн яктыргач, бер кызкай шым гына кайтып, эчке бүлмәгә узды. (Ачык капкага охшашлы ишек артында тагын өч карават бар.) Рәшидә аңа чаклы чыгып киткән, күрәсең.

— Авылдан өч кыз ФАШка керделәр. Тулай торак мәсьәләсендә йөргән идем кичә, урнаштырырбыз дигәннәр иде. Шуларның хәлен белеп килдем әле, урнашканнар. Түлке тәртип юк торакларында. Комендантларын күреп сөйләштем.

Рәшидә йоклап ятканнарның тынычлыгын бозмау турында уйламый да. Киресенчә, шушы гомер урында аунап яту үтә гаҗәп тоела иде бугай аңа. Эшчән хатын алдында уңайсызлык сизеп, Сәгадәт торды, аның артыннан Чулпан да кузгалды.

— Настук, син Казанда кала torгансындыр әле. Театрларын, музыкаларын карап кайт. Яшь балалар чоры түгел, дуңгызларыңа берни булмас.

Сәгадәт оек кияргә иелгән җиреннән тубыгына таянып туктап калды. Ул үзенә әле генә бер яңалык ачты. «Яшь балалар» дип Настя күп сөйләгәч, аның үз балалары күптер дип белә иде Сәгадәт. Баксаң, алар әнә нинди... балалар икән. Кызганыргамы дуңгыз караучы Настяны, сокланыргамы аның фидакарьлегенә? Сәгадәт кешеләргә катгый бәя бирергә гадәтләнгән. Аптырашта калыбрак утыра ул караватында. Рәшидә җил-җил генә әйберләрен җыя.

— Мин китәм. Бүген үк. Көн ачылып тора. Саламнарны нишләтәләр икән анда. Яуды да яуды бит. Быел печән хәлләрен үзең беләсең, малдан салам да артмас. Кая, берәр чынаяк чәй эчеп алыйк та, самолетка чаклы бер-ике йомышымны үтисем бар.

— Нинди йомыш? — Настя Рәшидәнең кабалануына ризасызлык күрсәтә.

— Туңмаңгай сельхозтехниканы үзем йөрми кузгатып булмас. Яңа комбайн кирәк. Әйдәгез, балалар, чәй янына! — Бусын Сәгадәтләргә карап дәшә Рәшидә, үзе стаканнарга чәй агыза, үзе Настяга гүя отчет бирә.— Аннары, картым ашханә салдырып йөри дигән идем бит. Зур итеп, ямьле итеп салдыра. Комсомол туйлары уздырырлык булсын, ди. Шуның финанс яклары төртелеп тора әле. Аны да кузгатып җибәрергә иде.

Рәшидә өстәл янында маташкан Настяга гаепле сыман бер караш ташлады да әкрен генә:

— Карт үзе больницада ята бит,— диде. Бер мәлгә хәрәкәтсез калган Настяның сорашуын көтмәстән, белгәч белсеннәр инде дигәндәй, өстәп куйды:

— Шул... зәм-зәм суыннан инде. Әле генә янынннан кайттым. Өченче тапкыр керүе...

Хатыннар дәшми генә чәй эчә башладылар. Дүрт стаканга чәй ясап куелган иде, Сәгадәт утырса да утырды, утырмаса да утырды. Әле ишеткән хәбәрдән аның бөтен тәне чымырдап китте. Әнә бит ничек тә була икән тормышта. Рәшидәгә озак кына карап торды ул. Хәсрәтләре өчен ихтирам итеп, ныклыгына сокланып. Шундый нык кешегә нинди йомшак характерлы ир эләккән. Аерылып кына котылырга уйламаган, кеше итәргә тырыша ирен. Бөтен авыл белән идарә итә, ирен кулында тоталмаган. Мөгаен, эш аркасындадыр. Рәшидәнең кичәге кырыс сүзләре... «Анда нәфескә баш булырга өйрәтәләр...» Әллә эш кенә түгел микән, бүтән сәбәпләре дә бар микән?

Чулпан да Сәгадәтне гаҗәпләндерде әле: кичәдән бирле өстәл янына кыстатмый гына килеп утыра. Әнисе дәшсә, кырык әйттерер иде.

Дәшми-тынмый гына чәй эчәләр. Күңелсез тынлыктан чыгар өчен Рәшидәгә ягымлы сүз әйтәсе килә Сәгадәтнең.

— Прическагыз үзегезгә бик килешә, яшәртә, шәһәр модасыннан калышмыйсыз.

Рәшидәнең караңгы чырае чыннан да ачылып киткәндәй булды. Гөрелдәп кенә көлеп тә куйды.

— Гөнаһларымны яндырып ясадым мин бу прическаны. Кар астында кышлаган саламнарны яндырып йөри идек, маңгай чәчемә ут капты. Көйгән чәч белән йөреп булмый бит инде, кыркыттым. Шулай яңа мода чыкты авылда.

Хатыннар гөрелдәшеп көлешкәндә, Чулпан тамак кырып алды. Кичәдән бирле бер авыз сүз әйтмәгән кешенең бу өненә бар да игътибар итте. Кыз нидер әйтергә җыена иде бугай. Мода турындамы, салам яндыру турындамы.

— Рәшидә апа, алып китегез әле мине авылга эшкә...

Көтмәгәнчәрәк чыкты Чулпанның сүзе. Сәгадәтнең башына китереп суккандай булды, ул гүя аңгыраеп калды.

— Нигә, рәхим ит, әйдә. Укырга керә алмадың исә... Бездә эш җитәрлек. Башта карап кайтырсың.

— Керә алмадым инде. Эшкә барам.— Чулпан кискен хәрәкәтләр белән урыныннан кузгалды. Рәшидә апасы кыз йөрәгенә һаман ялкын өсти тора. Сәгадәтләрнең гаиләсендә дә, кызның эчке дөньясында да ал-гөл түгел икәнлеген тәгаен белеп сөйләшә ул. Кыю сөйләшә.

— Бер-ике ел эшләрсең. Сәләтең, теләгең булса, укырга җибәрербез. Агрономлыккамы анда, врачлыккамы.

— Ни кылануың бу, Чулпан? Эшлим дисәң, үзебездә эш беткәнме? Нишләрсең авылда, кайда торырсың? Өчебезгә өч бүлмә...

Сәгадәтнең бер дәлиле дә кызга тәэсир итмәде. Әнисенә ул көйдергеч караш ташлап алды.

— Ул өч бүлмәгә сез икегез дә сыеша алмыйсыз!

Яннарында кеше булмаса, Чулпан шулай дигән булыр иде. Аның өттергеч карашын Сәгадәт шулай аңлады. Аңлады һәм тынып калды. Чулпан барыбер үз сүзен сүз итәчәк.

Чулпанны Рәшидә белән озаткач, ни уйларга, ни кылырга белмичә, ишек төбендәге караватында озак утырды Сәгадәт. Кинәт аның хәтеренә иртән күргән төш килде. Менә Сәгадәт йолдызларга йодрык күрсәтеп, ай белән янәшә йөгерә. Йолдызлар чатларын йомарлыйлар да Сәгадәтнең башына төшәләр. «Йодрыгың үз башыңа, үз башыңа!..» Кинәт айнып китә Сәгадәт, зиһененә ачыклык килә. Әйе, йолдызын югалткан ул. Якында ялтыраганга алданып, алдагысын күрмәгән. Рәшидәләрнең йолдызлары бар. Алар шуңа җирдә кыю йөриләр. Васил белән Сәгадәт тормышта юнәлеш бирүче йолдызларын җуйганнар. Һәр иртә, һәр кич бер-берсенең җаннарында казынып, югарыга күтәрелеп карарга бер-берсенә ирек бирмәгәннәр. Василгә моны әйтергә кирәк. Аңлатырга кирәк. Бүген үк.

Әбрар Шәмин

# ӨМЕТЛЕ ШАЙТАН

хикәя



Ярабби! Кемне күрәм мин, кемне?! — диде Бикчәнтәй, Шәрифне очраткач.— Карале, кара! Син дә биредә икән, ял итәсеңме?

— Әйе,— диде Шәриф һәм Бикбулатов белән кул биреп күреште.

— Кайчан килдең?

— Атна тула инде, ә син?

— Бүген генә әле.

Алар аллея буйлап киттеләр.

Каршы якта сирәк кенә нарат урманы. Аның бирге читендә матур-матур верандалы агач өйләр. Уңда — фонтан. Ак, кызыл, алсу, зәңгәр чәчәкләр белән уратып алынган. Аннары гүзәл Кама ярлары башланып китә.

Кайчандыр Шәриф белән Бикчәнтәй икесе бер идарәдә хезмәт иттеләр. Дөрес, бу идарә зур түгел иде. Шулай да Бикчәнтәй башлык иде анда. Шәриф исә — аның ярдәмчесе. Аннары, идарәләрне кыскартулар башлангач, юллары аерылды аларның. Ә хәзер...

— Торып тор! Мин хәзер чыгам,— диде Бикчәнтәй, ял йортының челтәрле капкасы каршына килеп җиткәч һәм капка янындагы таш кибеткә кереп китте. Бер тиенне учыннан кысып кына чыгара торган кеше искитәрлек юмартланды бу юлы. «Урманда куш тирәк, дөньяда дус кирәк».

Бераз уйланып торгач, Бикбулатов артыннан Шәриф тә кибеткә атлады. Ләкин Бикчәнтәй аңа авыз ачарга да бирмәде.

— Юк, юк, үзем түлим, үзем алам.

Һәм алды. Күп итеп.

— Очрашмаганга биш былтыр,— диде Бикчәнтәй, кибеттән чыгып, аллея буйлап киткәч.— Үзең беләсең: синең кебек начальникларны эштә борчу уңайсыз.

— Юкны сөйләмә!— диде Шәриф, елмаеп.

Ашханә янындагы ике катлы агач өйнең аерым бер бүлмәсенә килеп кергәч, гаҗәпкә калды ул:

— Ай-һай, ничек синең бер үзеңә аерым бүлмә бирделәр! Җитмәсә мебеле дә шәп тагын!

— Дуслар ярдәме, дуслар! — диде Бикчәнтәй һәм аскы иренен гадәттәгечә кыйшайтып елмайды да табын әзерләргә керешге.

— Урынына күрә сые, гаеп итмәссең. Иртәгә уха әзерләтербез. Гамьсез чакларны хәтергә алыйк әле!

Ниһаять, утырдылар.

— Кайсыннан салыйм! — диде Бикчәнтәй, ачык чырай белән — корысыннанмы, юешеннәнме дигәндәй? Очрашу хөрмәтенә!

— Ярый безгә кайсы да,— дигән булды Шәриф, шаяртып,— ләкин аз гына!

Эчтеләр.

— Ашханә берсез ачылмый, капкалыйк! — диде Бикчәнтәй. Менә сыр авыз ит! Колбаса, консерва ал! Теләсәң, чәй дә куярмын. Син яраткан кара икра табылса, тагын да шәбрәк буласы икән дә. Но...

Бикчәнтәй тагын нәрсәдер әйтмәкче иде, ләкин аны Шәриф бүлдерде.

— Сабыр иткән морадына җиткән, диләр бит.

— Әйе, шулай дигәннәр. Әмма... Эчик әле, Шәриф, эчик! Рюмкаларыбыз уймак кебек кенә ич. Йөргәли торсыннар.

Тагын эчтеләр. Бикчәнтәй аннан-моннан гына капкалады да папирос кабызып җибәрде. Шәриф исә тәмәкене ташлаган икән.

— Шәп эшләгәнсең! — диде Бикчәнтәй.— Менә бераз тынычлангач, мин дә ташларга уйлыйм.

— Ә нигә тынычсызланасың син? Нинди кайгың бар?

Бикчәнтәй бер елмайды, бер янә җитди төс алды. Һәм, күзләрен бер читкә текәп, юмакай тавыш белән:

— Синнән яшерен-пошырын берни дә юк, Шәриф,— диде.— Син мине яхшы беләсең. Шуның өчен дә турыдан-туры әйтәм: кыен миңа, бик кыен! Ярый ла син үстең, ә мин тегеннән киткәннән бирле эштән тәм тапмыйм. Үзеңнән бер ягы белән дә артык булмаган бүлек мөдиренә буйсынып эшлә әле? Җилкәгә иләр генә өймиләр, билләһи! Әйтерсең йомышчы малай... Идарәнең башлыгы Фәйзиев тә әллә кем түгел бит, ачуым килмәгәе! Әйе, мин тәки рәтсез эштә утырып калдым. Нишлисең бит, шулай була икән ул, кирәгеи беткәч дуслар да оныта икән... Дөресме, Шәриф?

— Юк, дөрес түгел,— диде Шәриф, чыраен бозып.— Вакыты җиткәч, сине дә искә алырлар.

Бикбулатов елмаеп куйды һәм:

— Сыныйк алайса! — диде.— Минем шеф, әлеге Фәйзиев пенсиягә җыена. Димәк...

— Ләкин,— диде Шәриф, Бикчәнтәйне бүлдереп,— андый эшләрне мин хәл итмим ич!

— Итәсең, туган! — диде Бикчәнтәй, тавышын йотып,— үзең генә аңларга теләмисеңдер: хәзер инде шәһәрдә абруйлы кеше син! Телең һәр җирдә үтә... Синең тәкъдимне безнең башлыклар кырын кагырлармыни?

Шәриф уңайсыз хәлдә калды һәм, иске дусыннан ничек котылырга белмичә, аптырап утырды. «Шайтанны өметсез диләр, ә бу өметле шайтан икән!»

Бикчәнтәйнең тулы битендә тир бөртекләре ялтырый иде. Сөртенергә уйлады, күрәсең, чалбар кесәсенә тыгылды, ләкин аннан кулъяулык белән хатын-кыз тарагы чыгып идәнгә төшмәсенме?

— Аңлашыла: иске сырхаудан һаман котылмагансың,— диде Шәриф, елмаеп.

Бикчәнтәй кызармады. Таракны алып яңадан кесәсенә салды да кеткелдәп:

— Кичәге хәтирә,— диде.

Шәриф җитди төс алды.

— Сорамадым да, семья исәнме?

Бикчәнтәй, матур төш күреп, тирән йокыдан уянып киткәндәй булды һәм хах-хах-ха... дип көлеп җибәрде. Аннары:

— Исән,— диде,— хатын малай белән авылга китте. Бер айга, ә мин монда ычкындым. Үзең беләсең, гомер дигәнең ике килми...

— Сәгать бер тула. Әйдә, ашханәдә югалтмасыннар безне,— диде Шәриф һәм урыныннан торды. Нәкъ шул вакыт ишек шакыдылар. Ул да түгел, бүлмәгә яшь кенә бер кыз атылып керде һәм, Бикбулатовка ниндидер кәгазь сузып:

— Менә сезгә ашыгыч телеграмма,— диде. Шулай диде дә бүлмәдән чыгып та китте.

«Көмеш тау. Ял йорты.

Бикбулатов Бикчәнтәй Бикбулатовичка.

Котлыйм. Минем урынга билгеләндең. Эшләрне кабул итеп алу өчен тиз кайтып җит.

Фәйзиев».

Бикчәнтәй, шатлыктан нишләргә белми, югалып калды. Һәм, кош тоткан кешедәй, кулын югары күтәреп:

— Аһ-һ,— дип кычкырды.

Шәриф сискәнеп китте.

— Ни булды, ни?!

Телеграмманы кулына алып, күз йөгертеп чыгуга, тынычланды ул.

— Но вот! Ә син Фәйзиевкә үпкәләгән буласың тагын.

— Әйе шул, ялгышканмын,— диде Бикчәнтәй һәм тиз генә юлга әзерләнә башлады. Файдаланмый бүленгән ял, бирелә каласы танышбелешләр, кояшлы көннәр, гүзәл Кама буйлары, әрәмәлекләр йөрәген чеметеп алды аның. Ләкин ике бәхет бергә килми, китмичә ярамый иде. Шәрифне исә бөтенләйгә онытты ул. Әмма өстәлдәге нәрсәләр истән чыкмады. «Чемоданга салырга кирәк. Акчасы түләнгән, кирәге булыр».

«Бирәм дигән колына, чыгарып салыр юлына», дигәндәй, Бикчәнтәй ике сәгать тулар-тулмаста самолетта иде инде. Күңелле иде аңа. Тәрәзә аша җиргә караштыргалый, авызын ера, учларын уып куя. Самолеттагы пассажирлар да гадәттән тыш әйбәт булып тоела аңа. Гүя: «Менә бу кеше зур кеше, кәттә начальник булып күренә!» дип сокланып баралар алар. Әйдә, дисеннәр! Буй-сын килешкән, корсак әле артык зурдан түгел, чәч урынында, хәтта бөдрә дә әле. Тик каралтып кына торырга кирәк. Дөрес, борын дигәнең кечкенәрәк кечкенәсен, әмма кайбер ханымнар «сөйкемле борын» диләр ич аны! Менә шундый идарәнең башлыгы да булгач, кемнәр генә баш имәс әле аңа! «Бикчәнтәй дустым, гомер буе онытмам: биш мең кирпеч, бер тонна калайга рөхсәт бир әле!», «Бикчәнтәй Бикбулатович! Бер вагон такта, ике тонна цемент бирмәссезме икән?» Әйе, монысы да бик кирәк: кош канаты белән, кеше дус-иш белән дигәннәр.

Бикчәнтәй шулай уйланды. Уйланды да куанды, куанды да янә уйланды.

Шәһәргә кайтып җиткәч, туп-туры Фәйзиев кабинетына омтылды ул. Кыяфәте кукырайган ата казны хәтерләтә. Коридорда очраучыларның бирсенә дә сәлам бирмәде. Ләкин...

— Ни булды, нигә болай иртә кайттың? — диде аңа Фәйзиев, гаҗәпләнеп.

Бикчәнтәй аптырап калды.

— Шаяртмагыз! Менә телеграмма.

Фәйзиев аңа тиз генә күз салды да җилкәсен җыерып куйды һәм:

— Аңлашылмый. Минем мондый телеграмманы биргәнем юк,— диде.

Әйтерсең лә аяз көнне яшен сукты мескенем Бикчәнтәйне! Шулай да ул һушын югалтмаска тырышты. Өйгә ашыкты. Өйгә!

Юлның юл буе:

— Я рабби! — дип көенде ул. Кавын дип үстер дә кабак булып чыксын! Бу гарьлеккә ничек чыдарга? Ничек? Кем соң, кем биргән аңа шундый ялган хәбәрне? Әйе, берәр дошман, әлбәттә... Әллә Фәйзиев үземе? Яки башка берәү рәхәтләнеп көләргә уйлаганмы? Юк, болай гына калдырырга ярамый моны! Ярамый, ярамый!

Шундый уйлар белән кабынган килеш, бусагадан керүгә, Бикчәнтәй катты да калды.

— Син... Син кайттыңмени?

— Кайттым шул, егет,— диде хатыны, иреннәрен җыерып. Нигә канатың салынды? Ял йортында күңелсез булдымы әллә? Яки начальник итмәделәрме? Күптән көтә идең ич! Ник дәшмисең?!

Бикчәнтәйнең күзләре шар булып түгәрәкләнде.

— Әллә син... Син кайтардыңмы мине?

Хатын ирексездән шаркылдап көлеп җибәрде. Бикчәнтәй исә лап итеп урындыкка утырды.

...Ярый, хәер-хуш, калганын үзләре аңлашсыннар!

## Гакыйль Сәгыйров

### Минутлар...

Сорашып йөрмиләр тукталып:
Эшлисе эшләрең беткәнме? —
Минутлар үтәләр.
Минутлар
Көтмиләр син куып җиткәнне.

Замана үрләре бик текә,
Бик кыен үтәсе юллары,
Үтәләр,
Меңәләр үрләргә
Илемнең гап-гади уллары.

«Калмыйммы, дип, артка дуслардан?» —
Ашкынам, ярсынам көн дә мин.
Уч итеп тавына, ташына,
Барсына! —
Үрмәлим югары, үрмәлим.

Йөрәгем,
Көнләш син барысыннан,
Ашкын да гел алга алып бар.
Китмәсен,
Үтмәсен заяга
Минутлар,
Кадерле вакытлар!..

### Ашыгам сиңа

I

Сине күргән көннән бирле,
Иркәм,
Аллаларга ышана башладым,—
Һаман саен
Фәрештәләр белән
Әйләнә бит газиз башларым.

Ожмахтагы
Кәүсәр чишмәсеннән
Авыз иткәнсендер син дә бер.
Фәрештәләр җирдә йөри алгач,
Валлаһи дим,
Алласы да аның җирдәдер!..

2

Кич җиттеме,
Ашыгам синең янга,
Шуклык көтеп синнән, шаяннан.
Тәрәзәгез селкә ал яулыгын
Мине танып
Әллә каяннан.

Качма әле төннең кочагына
Үзең белән алып серләрең,
Барыбер табам — компас угы сыман
Йөрәгемне тарта йөрәгең.

●

...Кайсыгыз анда туйган яшәүдән?—
Тыгыз уйлардан, мәшәкатьләрдән,
Тынгысызлыктан, кыен эшләрдән,
Һәм тирләп-пешеп, янып эшләүдән?

Кайсыгыз анда туйган сөюдән,
Башкалар өчен янып-көюдән,
Мәхәббәт хисен туң-кырау алган,
Һәм йөрәкләре гел бушап калган?..

Кайсыгыз анда туйган барысыннан:
Кошлар җырыннан, чишмә тавышыннан,
Якын дустыннан, елмаюлардан,
Җил-давыллардан, ерак юллардан?..

Килегез әле минем яныма!..
Килегез әле минем яныма,
Ятыгыз әле минем урыныма,
Бирегез миңа аяк-кул гына! —

Сөю ташыган йөрәге белән,
Һәр җанга изге теләге белән,
Эшкә сусаган беләге белән
Бу Кеше торып чыксын дөньяга:

Ул гына ачар серләр бар җирдә,
Ул гына чәчәр гөлләр бар җирдә,—
Серләрен ачсын, гөлләрен чәчсен,—
Кайсыгыз анда туйган яшәүдән?..

Син миңа яхшылык эшләдең бер заман.
Ник шуны яңартып сөйлисең син һаман? —

Күңлемдә шаулаган рәхмәт хисләрем
Инде бит югалта башлады төсләрен.

Афәтнең иң зурын җиңештең — мин беләм,
Тик шушы ярдәмең алганга үкенәм...

## Элегия

Сагышларым — сары яфрак,
Төште җиргә.
Кайгыларым — кара яфрак,
Очты җилгә.
Шатлык дигән яшел яфрак
Күренмәсә,
Нишләр йөрәк — шәрә ботак,
Шәрә кәүсә?..

## Ишәк

Ишәк беркөнне мактанган ди Кәҗәгә:
— Поэзиядә кем тиң минем дәрәҗәгә —
Алардан башка да яшим мин үлгәнче,
Ә минсез вәт яшәсен ник бер мәсәлче...

Сөббух Рафиков

# ТЫН ЕЛГА БУЕНДА

РОМАН[1]

## 2

Яртты төн күптән узган иде инде. Икенче бүлмәдә балалары белән яткан Хәмидә ничә тапкыр йокыга китеп уянды, аннары тагы күзләрен йомды. Ләкин ул ничек кенә йоклап китәргә теләмәсен, олы яктагы әкрен генә сөйләшү авазлары аның кәефен боза, йокысын качыра иде. Ул үзләренә кеше килүен башта тансыклап каршы алса да, бара-тора кәефе киткәннән китте. Ничә тапкыр әйләнеп ятты, ничә тапкыр йөткергән булып тавыш бирде. Әмма күрше бүлмәдә өстәл артында утыручы Зиннур белән Игнат моны сизмәделәр, һаман үзләренең мавыгып сөйләшүләрендә булдылар. Ләкин көндезге ару барыбер үзенекен итте, бер мәлне Хәмидә басылып татлы йокыга талды һәм ир-атның үзара гәпләшүе аңа ишетелми башлады.

Озак утырдылар тегеләр. Әле Зиннур сөйләде, әле кашларын бер җыерып, бер язып, кай ара маңгаена тирән-тирән сырлар чыгарып Игнат сөйләде. Зиннурның үз хисләре, үз уйлары белән кирәгеннән артык мавыгудан булса кирәк, күрше бүлмәдә йоклаучыларны бөтенләй онытып, кычкырып сөйләвен абайлаган Игнат каршы төште:

— Син ул хәтле кычкырма әле,— дип, ым кагып күрше бүлмәне күрсәтте.

Зиннур тавышын әкренәйтә төште:

— Барып чыгарга тиеш бу.

— Монда, башта әйткәнемчә, төп хикмәт тигезлек саклауга кайтып кала,— диде Игнат. Муенын бер кулы белән кашып алгач, сүзен дәвам иттерде: — Мәскәүдә урамнарны киңәйтергә кирәк булгач, бик күп иске йортларны күчерергә туры килгән. Ә ул йортлар үзләре менә дигән торырлык әле. Күчереп сала башласаң, бу эш дөнья хәтле чыгым белән бәйләнгән. Шуннан соң, табыла йомры башлы кешеләр. Нишлиләр дисеңме? Күчереләчәк йортларга алдан урын әзерлиләр дә, астан туннель казып көчле рычаглар белән әкрен генә икенче урынга шудыралар

[1] Ахыры. Башы 2, 3, 4, 5 нче саннарда.

йортларны. Шул ысул белән ни хәтле йортларны күчерделәр. Бу икенче, өченче бишьеллыкларда. Безнеке исә андый ук катлаулы эш түгел.

— Бер акыл ярты акыл, ике акыл бөтен акыл дип ишеткәнем бар, Игнат Данилович. Хәзер инде минем күнелдә ышаныч ныгып бара,— диде Зиннур.

— Мин әле генә артык катлаулы эш түгел, дидем. Сүземне кире алырга туры килә. Бу да бик катлаулы эш.

— Ничек кенә әле! Ләкин бер урында катып калып булмый бит инде. Яңа әмәлләр эзләргә тормыш үзе куша, үзе мәҗбүр итә.

— Дөрес,— диде Игнат,— сез тәкъдим итә торган юл белән эш иткәндә темп кимендә ике тапкырга артачак. Бу — факт. Ләкин менә начальство ничек карар? Төп эш хәзер шуңа кайтып кала.

— Картлар: хәрәкәттә — бәрәкәт, дигәннәр. Әйдә, без дә хәрәкәт итеп торыйк әле. Синең белән сөйләшкәч ничектер менә күнелгә рәхәт булып китте,— диде Зиннур.

— Васил Закирович белән сөйләшеп бакмадыгызмы әле бу турыда?

— Юк.

— Димәк, беренче минем белән сөйләшәсез?

— Сезгә хәтле Фиргали абзый белән киңәшкән идем.

— Ул бик зур практик бит инде. Кайта-кайта әллә ничә тапкыр сөйләштек. Баш ваттык. Фиргали абзый куәтли минем фикерне. Ул инде уйлаганны һич кичекмәстән гамәлгә ашыру ягында.

— Ин элек Васил Закирович белән килешергә кирәк. Ул яңалыкка юл ачучыларны һәрвакыт яклый һәм ярдәм итә,— диде Игнат. Үзе бары шунда гына кулындагы сәгатенә карап гаҗәпсенә куйды, урыныннан торды: — О, бик соң икән инде. Миңа китәргә вакыт.

Игнат саубуллашып китеп баргач, Зиннур, кухняга чыгып, ярты стакан гына чәй эчте дә тиз генә чишенеп урынга ятты. Сизгер йокылы Хәмидә күзләрен ачты, ләкин бу хәлгә ачуланмады. Ире Зиннурның соңгы көннәрдә нинди планнар, нинди исәпләр белән йөрүен бик яхшы белә иде ул.

— Синең уйны ничек таба соң Игнат Данилович? — дип сорады хатын.

— Хуп күрә, әйбәт нәтиҗә килеп чыгар, ди.

— Басынкы гына булса да, болай бик төпле кешегә охшый үзе,— диде Хәмидә.

Зиннурның күзләренә йокы үрмәләмәгән кебек, Хәмидә дә ярты йокысын туйдырган иде инде. Хатынның башына әллә нинди ят уйлар килгәли торды. Бер мәлне ул әйтеп куйды:

— Игнат дигәннән, ничә яшьләрдә бар инде ул?

— Утызның теге ягында бугай.

— Үзе һаман өйләнмәгәнме?

— Ул хакта бер сүз дә ишеткәнем юк аның авызыннан. Дөньяда төрле кеше була бит... Берәүләр иртә өйләнәләр, берәүләр каграс вакытында гына, берәүләр сазап беткәч...

— Үзләре торган шул Партизан урамының теге башындагы бер бик чибәр тол хатынга иялəнгән ди ул...

— Булмас ла. Гайбәт сүзедер.

— Бер дә гайбәт түгел. Чын. Ул хатынның исемен дә әйткәннәр иде. Менә тел очымда гына тора. Оныттым. Шул яшь кенә хатынны бер баласы белән ире ташлап киткән. Шунда барып кунып кайта, ди...

— «Дыр» белән «бугай»га бик ышанып булмый, бер теле кычытканы юрамалый сөйли торгандыр.

— Чын. Чынны сөйлиләр,— дип үз әйткәнендә калды Хәмидә.

Автобуста шундый тыгын: шырпы тыгарлык та урын юк. Ярый әле, Зиннур белән Хәмидә, алданрак килгәнгәдер инде, урынга эләктеләр. Монда шау-шу, уен-көлке, әрләшү — һәммәсе бергә бутала. Эш кием-

нәре кигән кешеләрне асфальт юлдан зур-зур автобуслар эшкә ташый. Зиннур беренче килгәч тә тар, сазлы сукмаклардан эшкә баруларын исенә төшерде. «Әх, ул чагында бот төбеннән саз ерулар. Аннары төзелеш мәйданында бүрәнәдән салынган вакытлы юллар... Ә хәзер! Нинди зур үзгәреш!» Ул автобус тәрәзәсеннән күзләрен алмады. Яна төзелеп яткан зур йортлар, яңа урамнарга каравы күңелле, куанычлы иде.

Беренче пар казанын ярты елдан артык җыйдылар, монтажладылар. Барлык эшләр дүрт стена эчендә, шактый тар урында башкарылды. Бер блок бетү белән икенчесенә тотындылар. Анысы инде әлеге эше тәмам булган блок өстендә алып барылды. Беренче блокларны монтажлаганда эш әйбәт кенә барса да, бара-тора хәтсез тоткарлыклар килеп чыга торды. Кешеләргә ут өертеп эшләү урынына күбесенчә әле бу, әле теге детальне ташып, тар баскычлар буенча өскә күтәрелергә, гел йөреп торырга кирәк. Техникадан файдалану дигәч тә, төп корпус бинасы эчендәге күтәрү кранын гел бушка куып булмый бит инде. Аның төп вазифасы да авыр механизмнарны күтәрү, аларны өске катка урнаштыру. Монтажчылар, Зиннурның башлап йөрүе белән, эшне тизләтергә, срокларны ашыктырырга, моның өчен индустриаль ысуллар кулланырга булдылар. Ләкин бу җиңел эш түгел иде. Соңгы көннәрдә бөтен уен, бөтен акылын шуңа туплаган Зиннур Гафиятуллин үзенә теләктәшләр тапты. Иң элек тәҗрибәле төзүче-монтажчы Фиргали Гатин аның фикерен хуплады. Бүтән монтажчы, җыючы слесарьлар да аның тәкъдимен ике куллап күтәреп алдылар. Зиннур исәбенчә, уйлаганны гамәлгә ашыру өчен барлык мөмкинлекләр аларның кул астында. Мотовоз. Куәтле краннар. Тагы китереп, иң кирәклесе, иң мөһиме — җыю, монтажлау эшләрен тоткарсыз алып бару өчен киң урын — промышленность мәйданы бар. Кирәкле торбалар, детальләр, материаллар шунда тупланган. Эшне тиешенчә оештырып җибәргән чагында материал ташып та, тегесе-бусы өчен дә анда-монда чабып вакыт үткәрәсе юк.

Бүген иртән эшкә килеп, беркадәр кыймылдаганнан соң, чираттагы тәнәфес вакытында Зиннурның барлык сүзе әнә шул хакта булды. Фиргали абыйсы һәм бригададагы башка монтажчы-слесарьлар, электриклар, тимерчеләр һәм эретеп ябыштыручылар һәммәсе дә аның фикерен бик кулай күрделәр. Чөнки бу һәр яктан бары тик файда гына бирәчәк, аннары вакыт ягыннан ни кадәре оту. Кешеләргә бары шул гына кирәк, алар өчен иң кыйммәтлесе шул иде.

Ул көнне көндезге тәнәфес вакытында Зиннур бригадасы кешеләре башка көннәрдәге кебек ашханәгә дә бармадылар. Фиргали абыйлары һәммәсе өчен дә котлетлар, бутербродлар алып килде. Аның өстенә тагы бер чиләккә якын компот та китерде. Бу игътибарлы кеше стакан нар алырга да онытмаган булып чыкты. Егетләрдән кайсыдыр шаяртып та алды:

— Мөгаен, Фиргали абзыйның кухняда блат бардыр?

— Блат түгел, анда минем авылдаш эшли,— диде Фиргали.— Җитмәсә, чыбык очы кадәр генә булса да, туган-тумача да санала әле ул миңа, беләсегез килсә, апайларым.

— Туган-тумача, кода-кодагыйлык та ярап куя кай чакта,— дип көлде Зиннур.

— Ничек кенә әле! — диде баягы карлыкканрак тавыш.

Бөтен проммәйданда көндезге унбердән алып уникегә кадәр тәгәл бер сәгать тәнәфес ясыйлар. Шул вакыт эчендә ашап-эчеп, хәтта берәз ял итеп тә өлгерә иде. Зиннурныкылар да унике тулу белән эшкә тотындылар. Кайда ни эшләү, урынны ничегрәк әзерләү турында алар тәнәфес вакытында ук сүз куешканнар иде инде. Шуны күздә тотып булса кирәк, Зиннур кисәтеп куйды:

— Мәйданны әзерләп бетерми торып өйгә кайту юк, егетләр. Ачык-сак кухняда — блат,— диде.

Кешеләр үзләренә эш урыны әзерләргә тотындылар. Берсенә икенчесе куәт-көч биргән кешеләр авазына металл чыңнары кушылды:

— Айда, взяли!

— Еще взяли!

— Бәреләсең, читкәрәк каерт!

Тимер-томыр, торбалар һәм башка материаллар тәртипсез рәвештә тулып яткан зур мәйданны барлык артык әйберләрдән арындыру белән генә чикләнеп калмадылар, бетон җәелгән бу мәйданны ялт иттереп себереп тә куйдылар. Эшләр өчен бигрәк тә уңайлы иде. Каршы як тимер юл буенда да тимер кисү һәм детальләрне эретеп ябыштыру өчен иркен генә урын әзерләделәр.

Вакытның ничек үтүе бүген бигрәк тә сизелмәде. Сусаклагыч ягыннан тымызык кына исеп торган дымлы җил рәхәтлеген тоеп һәркем эшли, хәрәкәт итә иде. Зиннурныкылар кичке смена килгәнен дә чамаламый калдылар. Сәгатьтән артык бергәләшеп эшләделәр. Башкалар киткәч тә Зиннур белән Фиргали һаман үз урыннарында калдылар.

...Алар проммәйданнан кайтырга чыкканда машиналар йөрми иде инде. Бу араны күптән җәяү йөргәннәре юк иде. Кайчандыр үзләре беренче булып салган сукмактан поселокка таба юнәлделәр. Ләкин әле җир-су кибеп бетмәгәнлектән, калкурак урыннардан баруы җиңел булса да, уйсулыкларда тездән саз, ерып йөри алмаслык былчырак иде. Зиннур белән Фиргали кире борылырга мәҗбүр булдылар, киң асфальт юлга чыктылар. Монда инде коп-коры, машиналар күп йөрүдән юлның кайбер урыннары көзге шикелле ялтырап күренә иде. Тимер юл калкулыгын үткәч, Зиннур кинәт телгә килде:

— Ничек эшләячәгебезне әлегә беркемгә дә сиздермик. Берәр атна тын гына кыймылдый торыйк.

Бу көннәрдә шактый ябыгып, шадралары тирәнәеп киткән Фиргали дустының сүзенә шикләнеп карады.

— Безнең эш бит ап-ачык, һәркемнең күз алдында. Барыбер кайсы да булса килеп чыкмый калмас. Монда мең күз. Күрерләр...

— Күрсәләр! Безнең ният изгедә. Тик шуны аңласыннар,— диде Зиннур.

— Кәкже аңламасыннар, аңларлар,— диде Фиргали...

### 3

Көннәр кояшлы, матур.

Язгы җилләр исеп торган саф һавада эшләве ничектер үзенә күрә бер рәхәт, үзенә күрә бер яңа ашкынулар уята. Яңа көн туган саен, күптән түгел генә җыела, монтажлана башлаган пар казанының бер блогы һаман үсә, һаман калка барды. Бер атнадан соң инде ул җыелып та бетте.

Васил Сафин гадәти көннәргә караганда бүген иртәрәк торды, хезмәтенә килү белән Никитинга шалтыратты, үзенең проммәйданда буласын әйтте. Очраштылар.

Никитинга Зиннур бригадасының керткән яңалыгы Васил Сафинның сөйләве буенча билгеле иде инде. Ул өй хәтле зур тимер блок эчендәге санап бетергесез күп нечкә һәм юан трубаларга — булачак пар казанының бер буынына шактый озак карап торды. Шушы хәтле пәһлеванның бер атна эчендә монтажланып бетүенә исе китеп гаҗәпкә калды. Башлыкның күзләре көләч, чыраенда ниндидер тантана, ниндидер елмаю нурлары балкый иде. Җыелышларда, киңәшмәләрдә чыгыш ясарга туры килгәндә аның: «Бу беренче чираттагы эш...» — дип санап китәргә яратуын һәм икенче чиратка бер эшне дә калдырмавын исенә

төшереп, Зиннур елмаеп куйды. Никитин аның киң җилкәсенә дусларча кул салды, калын тавышы белән гөрләтеп әйтте:

— Нинди зур «өй». Рәхим итеп түбәсен яп та тора бир... Бу бит безнең беренче чираттагы бурыч...

— Әйе, Андрей Акимович, «өй»нең тик ишеге юк, тәрәзәләр дә тишәсе бар...— диде Зиннур.

— Ну, молодцы, ребята, молодцы,— дип кабатлады башлык. Ул Зиннурның тынычсызлыгын зур булып ачылган күзләреннән сизде.

Зиннур читкәрәк китте дә кулын күтәрде:

— Ну, башлыйбыз, егетләр!

Шундук өстәге кранчы челтерр иттереп звонок шалтыратты. Әле яңа гына Никитин тирәсенә җыелган, өсләренә соры брезент комбинезон кигән яшь чырайлы, җиңел сөякле кешеләр сибелешеп, таралышып та беттеләр. Аларның һәркайсы үз урынын белә, һәркайсы әзер иде. Менә җыю-монтажлау мәйданына, гүя судан шуып килгән шикелле, тавышсыз-тынсыз гына мотовоз да килеп җитте.

Зиннур кулын күтәрүгә кранчы тагы кыңгырау чыңлатты. Ул арада янәшә тимер юлдан икенче куәтле кран да килеп туктады. Җиргә ябышып үскән «тимер өй»не як-ягыннан корыч арканнар белән уратып алдылар. Зиннур мотовозның алдында, Фиргали артында тора. Зиннур кирәк вакытта салмак кына кулын күтәрә һәм монтажчылар шуннан аның ни әйткәнен аңлап алалар. Ул да түгел, блок — «тимер өй» — җирдәге бетон мәйданнан күтәрелә башлый. Ике яктан ике пәһлеван кран нинди тигез һәм чайкалусыз күтәрәләр аны. Күп тә үтми, авыр блок, йомшак мендәргә утырган сыман, киң мотовозның бөтен мәйданын билән урын ала. Краннарны ычкындырганчы, Зиннур мотовозны әйләнеп чыга, кай урыннарын тотып-тотып карый да тагы кулын күтәрә:

— Тигез, тип-тигез. Расчет дөрес!

Краннар, юан тимер ыргакларны корыч арканнардан ычкындырып, үз урыннарында калалар. Мотовоз авыр йөге — булачак пар казанының бер өлеше белән киң тимер юлдан төп корпус бинасына таба юл тота. Проммәйданның төрле төшеннән, машина частьлары, торбалар һәм тимерләр арасыннан бер-бер артлы кешеләр калкып чыгалар һәм киң тимер юлдан салмак кына барган мотовозны төп корпуска озатып калалар.

Никитин белән Сафин, гүяки Зиннур Гафиятуллинның тылсымлы командасына буйсынып, мондагы һәр хәрәкәтне, һәр адымны үтә бер кызыксынып белән күзәтеп торалар... Төп корпуста көчле звонок чыңнары. Ул да булмый, төп корпусның түшәм биеклегеннән үтә торган куәтле кран мотовоздагы блокны як-ягындагы «колаклары»ннан эләктереп ала да өскә күтәрә... Озакламый бу блок үзе өчен алдан хәзерләнеп куелган ояга менеп утыра. Аннан инде мотовоз да китеп бара. Өстәге күперле кран да баштагы салмаклык белән үз урынына кайта.

Култыксалы тар баскычтан өскә күтәрелгән Зиннур инде күренми, «тимер өй»гә кереп югалган. Бераздан Никитин белән Сафин да әлеге баскычтан өскә менәләр. Алар блокның үз урынында нык һәм ипле, җайлы утыруын күргәч, бик канәгать булып, янә аска төшәләр. Өстә металл чыңлый, металл шаулый... Монтажчы егетләр эретеп ябыштыру юлы белән буыннарны ялгыйлар, почмакларны беркетергә керешәләр. Әллә ничә урында һич туктамастан, берсеннән-берсе уздырырга тырышкан шикелле, ут көлтәләре чәчри, көчле очкыннар өермәсе уйный. Бер карасаң — яшен уклары сызыла, икенче карасаң — дөньяны каплап күк күкри кебек.

Никитин белән Сафин хәтсез вакыт төрле участокларда икесе бергәләп йөрделәр. Никитин китәргә җыенып, җиңел машинага утырган-

да, Васил Сафинның күзләренә туры карап, аталарча җылылык белән әйтте:

— Зиннур Гафиятуллин бригадасы башлаган эш безнең төзелеш өчен зур вакыйга! Ләкин ничек кенә булмасын, хөрмәтле Васил Закирович, эшнең сыйфаты беренче дәрәҗәдәге бурыч. Прорабларга, мастерларга ышанып кына калмассыз, үзегез күзәтеп торырсыз дип ышанам.

— Һичшиксез, Андрей Акимович,— диде Васил.

Никитин, инде машинага утыргач, башта әйткәннәренә өстәде:

— Да, Васил Закирович, сез бу индустриаль метод турында приказ проекты әзерләсәгез шәп булыр иде.

— Яхшы. Язармын,— диде Васил.

Көннәр берсен икенчесе ашыктыра торды.

Республика газетасының үз хәбәрчесе, урта буйлы, тар җилкәле, бераз бөкерәебрәк йөри торган кеше, төзелешнең баш конторасына килеп, башлыкның үзе белән очрашырга теләгән иде. Ләкин туры китерә алмады. Баш инженер кабинетына сугылса, анысы да өйдә булып чыкмады. Хәбәрче кем белән булса да очрашырга теләп тә, ул кешене туры китерә алмау кебек хәлләргә күптән күнегеп беткән иде инде. Үзе әйтмешли, кош теле кадәр информация артыннан әллә ничә километрлар йөрергә туры килә аңа. Күп чагында машинасы да очрамый. Юл чатларында узучы машиналарны көтә-көтә яхшы ук туңган чаклары да булгалый. Кай чагында аның планнарын тамырыннан җимереп ташлый торган хәлләр дә очрый. Әйтик, ул редакциядән бирелгән задание буенча берәр колхозга яки төзелешкә кимчелекләрне бик хәтәр ачып салу, гаепләләрне фаш итү максаты белән бара. Ә тикшереп, күзәтеп йөри торгач, кимчелекләр ягын уңышлар ягы баса да, тәнкыйтьләп язарлык җирлек тә калмый. Шулай итеп, аның үзенчә әйтсәк, минус урынына плюс килеп чыга. Һәм хезмәт кешеләре турында күңел җылылыгы салынган очерк яисә репортаж язарга туры килә. Мондый хәлләр әледән-әле булып тора иде. Ләкин көннең әһәмиятле вакыйгалары, яңалыклар күбрәк кызыксындыра аны. Редакциянең куйган таләбе дә гел яңалык эзләү, гел «яңа мөгез чыгару»га кайтып кала иде. Болай тыштан карап торуга эшендә әллә ни кыенлык күренмәгән хәбәрче теге яки бу турыда яңача, үзенчә материал оештыру, үзенчә язу, һәр вакыйгага карата үзенчә яңа яктан килеп бәя бирү өчен көенә, тирән уйларга күмелеп йөри.

Һәр нәрсәгә игътибарлы хәбәрче биредәге приказлар тактасын да читләтеп үтмәде. Ул якты, киң коридор стенасына эленгән бер приказ белән аеруча кызыксынды. Төзелеш башлыгы Никитин тарафыннан кул куелган әлеге приказда Зиннур Гафиятуллин бригадасының индустриаль ысуллар белән икенче пар казанын монтажлавы турында гаять күтәренке, гаять оптимистик бер тонда язылган иде. Хәбәрче приказда язылганнарны күңеленә беркетеп, китәргә торганда аның күзе якындагы стена газетасына төште. Күрәсең, бу приказның көче зур булса кирәк, стена газетасында да индустриаль ысул турында бик хуплап, җылы хисләр белән мәкалә язылган иде. Шуларны укып, булган хәлне уйларыннан кичергәч, хәбәрченең үзенең дә хисләре ташып китте. Ул тышы таушалып беткән блокнотына ниләрдер язып куйды, каядыр бик ашыккан сыман тиз-тиз генә баш конторадан чыкты.

Җир-су кипкән, аяк асты коры, асфальт юллардан төрле участокларга изма һәм материаллар ташучы үзбушаткычлар узып киткәндә артларында куе тузан болыты калдыралар. Хәбәрче, өстенә аварга килгән тузан болытыннан качып, уңгарак борылды да төзү-монтаж идарәсе конторасына таба атлады. Конторага барып җиткәч, ул эзләгән Васил Сафинның үз кабинетында булмавына пошынып куйды. «Ни-

чек әле бу, кемне генә эзләмим, берсе дә туры килми»,— дип үз алдына, авыз эченнән генә зарланып алды. Секретарь-машинистка Сафинның бу көннәрдә күбесенчә төп корпус бинасында булуын әйткәч кенә беркадәр тынычлана төште. Өченче кат биеклегенә куелган озынча вагоннарда монтажчылар прораблыгы урнашкан. Васил Сафинны хәбәрче шундый вагоннарның берсендә очратты. Алар бер-берсен яхшы ук беләләр иде инде. Хәбәрче бу төзелешкә әледән-әле килә, төрле материаллар оештыра, участокларда да аны күргәлиләр иде. Моннан тыш аларның район күләмендә уздырыла торган төрле киңәшмәләрдә, хуҗалык активлары киңәшмәләрендә дә очрашканнары бар. Өстәл каршында төрле сызмалар карап утырган Васил Сафин хәбәрчене якты чырай белән каршы алды.

— Минем үз күзләрем белән күрәсем килә,— диде хәбәрче.

— Мөмкин,— диде Васил Сафин.— Иртәгә иртән бер блок монтажланып бетә. Рәхим итеп килегез. Менә шунда үз күзегез белән күрерсез. Ә хәзергә минем сезне бу ысулның киләчәге бик зур булуы белән таныштырасым килә...

Алар шактый озак утырдылар. Аннары, иртәгә күрешергә булып, хәбәрче таушалган блокнотын кесәсенә тыкты да кунак өенә китеп барды.

Бер тирәдәге өч районга хезмәт күрсәтүче хәбәрче үзе дә шушы якныкы булып, аның туган авылы бу тирәләрдән ерак түгел иде. Ләкин ул, бик яшьләй матбугатта эшли башласа да, үзенең яшь чакларын ерак төньякта уздырды. Аннан ул, тормыш тәҗрибәсе туплап, күтәренке күңел белән дәртләнеп үзенең туган туфрагына кайтты.

Хәбәрче төнен ятып, берәр сәгать ял итеп алгач, ничектер үзеннән-үзе йокысы ачылып китте. Яшьлек еллары, узган гомере күз алдыннан үтте. Ул яшүсмер чакта бу Яңа Наратлы тирәләреннән җәяүләп тә, атка утырып та узгалаган иде. Салам түбәле өйләр, баткак юллар, өсләренә тирес җәелгән җимерек күперләр мәңге чыкмаслык булып аның хәтеренә сеңеп калганнар. Хәзер шушы урыннарда гигант адымнар белән барган үзгәрешләргә чын күңеленнән куанучыларның берсе иде ул. Мондагы кешеләр турында ул күп язды һәм һаман яза, моның һич очы-кырые күренми иде.

Менә тагы керфекләреннән якты нурлар чәчеп, көн туар. Менә тагы кешеләр, кырмыскалардай кайнашып, хезмәткә китәрләр. Ул бу көннәрдә төзелешнең төп сулышы, төп тормышы булып әверелгән яңалыкларны үз күзе белән күрер. Зиннур Гафиятуллин бригадасы кешеләре белән ныклап танышыр. Танышыр да яңа буяулар табып, яңа очерк язар. Ә очерк язганчы кечкенә, тешле генә информация оештырыр. Башында шундый уйлар кайнаган хәлдә, хәбәрченең күзләренә йокы үрмәләде...

Гадәти көн.

Гадәти тормыш.

Беренче блокны пар казаны корылмасында урнаштыруга ун көнләп кенә вакыт узган иде әле. Проммәйданда җыелган икенче блок әзер. Хәбәрче килгәндә, бригада шул әзер блокны төп корпуска алып китү мәшәкатьләре белән мәшгуль иде. Ул Васил Сафинны да Зиннур Гафиятуллин бригадасы монтажчылары арасында очратты. Васил Сафинга таныш эш, таныш мәшәкатьләр, ә хәбәрчегә һәркайсы яңа, һәркайсы җиңү! Хәбәрченең Зиннур белән бик сөйләшәсе, бик танышасы, аны бик нык беләсе килә. Әмма әлегә кайнар дәрт ташкыны ургылып торган җаваплы эш башкарыла. Ул гадәтенчә бөтен күңеле белән бирелеп, йотылып күзәтә, тыңлый. Гадәтенчә блокноты кулында, вакыт-вакыт анда ул үзе генә танырлык яңа сүзләр языла тора.

Звонок. Блокның ике ягыннан ике кран ыргагы тәлләрен сузуга, хәбәрче сорамыйча түзмәде:

— Васил туган, блокның авырлыгы күпме тарта?

— Йөз тонна чамасы,— диде Васил Сафин сүз гади генә бер әйбер турында барган кебек.

— Йөз тонна!

— Әйе, иптәш хәбәрче.

— Ай-яй-яй,— дип гаҗәпләнеп башын селкеп торды хәбәрче. Бу вакытта ике кран шул авыр блокны мотовозга күтәреп куялар иде. Блок тирәсендә монтажчылар кайнашалар. Корыч арканнарны блокның «колагы»на беркетәләр. Бригадир әле монда, әле тегендә тыз да быз йөгерә, кулларын изи... Ә хәбәрченең йөрәге түземи, анда ашкыну хисләре дә, ашыгу да бар. Кинәт ул Василга тагы сорау куя:

— Ә краннар күпме күтәрә ала?

— Берсе-берсе иллешәр тонна, дөресрәге, илле бишәр,— ди Васил. Хәбәрче ашыга. Аның яр буе насосныена барып киләсе бар. Монтажчыларның күлмәкләре шактый озакка тартылыр кебек. Аныңча әле бәлки алар ике-өч сәгать яки артыграк та маташырлардыр. Ул сул беләгендәге сәгатенә карап ала да китәргә була.

Яр буе насосныенда йөргәндә хәбәрче сәгатенә караса, җыю мәйданыннан киткәненә ни бары утыз минут үткән иде. Аннары ул «стакан» дип атала торган станция корылмасына төште. Шунда кешеләр белән очрашкач, сәгатенә карарга да исенә китермәде. Инде әңгәмә бетә дигәндә тагы сүз чыга торды һәм хәбәрчене яңа хәлләр, яңа вакыйгалар кызыксындыра барды. Шулай итеп, ул сәгатенә күз салырга кирәклеген бөтенләйгә исеннән чыгарды. Алай да ничектер хәтеренә килде. Насоснийда эше бетмәүгә карамастан, икенче тапкыр килергә булып, тиз-тиз генә китеп барды. Проммәйданның пар казаны җыю урынына килеп җитсә, анда мотовоз да, блок та, бригада да юк иде инде. Хәбәрче бу хәлгә тәмам аптырашка калды һәм кулларын җәеп җибәрде: «Неужели шундый аз гына вакыт эчендә китеп тә бардылар. Әй, агаем, китмәгән генә булсам...» Ул шулай таралган уйларын җыеп ала алмыйча аптырап торганда, өстән тавыш ишетелде:

— Абый, нәрсә югалттың? Төшеп эзләшимме әллә?

Хәбәрче җавап кайтармады. Дөресрәге, ул ни дип әйтергә дә белми, тәмам аптырап калган иде. Өскә карады. Кимендә өч кат йорт биеклегендәге кран будкасы тәрәзәсеннән кызыл косынкалы хатын-кыз, тешләрен агартып, аңа карап тора иде. Алай да хәбәрче түземсезләнеп сорый куйды:

— Мотовоз китте дәмени инде, сеңелем?

— Инде ул моннан биш былтыр эзен суытты, абый кеше. Әллә кайчан төп корпуста инде алар.

— Әй, җитешә алмадым бит, шайтан! — диде хәбәрче.

— Алай җитешәсе булгач, китмиләр аны баштук,— диде кранчы.

Хәбәрчегә калса, бу ягымлы тавышлы кранчының да катнашы бар ич бу зур эшкә. Аңа монтажчылар бригадасы турында барыбер язарга туры киләчәк. Шунда бер урынга бу кранчы хакында да матур гына штрих кертергә мөмкин ич. Ул каерылып өскә, кранчыга караган көе, сораштыра бирде:

— Сез күптән эшлисезме кранчы булып?

— Күптән...

— Шулай да ничә ел?

— Алтынчы елым.

— Монда кайдан килдегез?

— Ерактан...

— Төгәлрәк итеп әйтә алмассызмы?

— Ул ни өчен кирәк сезгә, абый кеше?

Хәбәрченең соңгы соравына каршы үзе сорау куйды кранчы. Чөнки ул мыеклы кешенең блокнот сыман нәрсәгә нидер язып баруын күреп сагая калды. Кранчының бу шигәюен һич тә чамалый алмаган хәбәрче үз сүзендә булды:

— Сезнең исемегез ничек, фамилиягез?

Эш инде бу тиклегә җиткәч, кранчы каушыйрак калды һәм җавап кайтару урынына үзе сорады:

— Минем исемем ник кирәк сезгә, абый кеше? Танышырга уйлаган булсагыз, сез инде бик соңга калдыгыз: минем ирем бар...

Менә сиңа кранчы кыз! Шаяртып әйтәме ул, ачуланыпмы? Бер карагавда, һич белмәгән, күрмәгән кешегә беренче очрашу белән «анкета тутырту» хәбәрченең үз уйлавынча да бик ятышып бетми иде кебек. Әллә ник менә онытып җибәрә дә, хатыны әйтмешли, тозсызланыбрак китә ул кай чагында. Ул инде үзенең кем икәнен һәм кайда эшләвен әйткәч тә әле кранчы алай ансат кына «сул унаена» йөзмәде.

— Газетка язасызмыни? — дип сорады ул.— Сез яманлап язып, исемемне дөньяга таратмассызмы соң, абый?

— Юк, сеңелем, юк! Сез тагы әллә ниләр сөйли башладыгыз!

Кранчы теләр-теләмәс кенә исемен әйтте. Ул арада каяндыр бик зур йөк машинасы килеп туктады. Кранчы авыр деталь күтәртеп салырга тиешлеген аңлатып сүздән туктады һәм звонок шалтыратты.

Күңеленә каушау, куану һәм көенү хисләре туплаган хәбәрче, киң тимер юл шпалларына басып, алда текә кыя тау кебек мәһабәт булып күренгән төп корпус бинасы ягына таба юнәлде.



## 4

Ни булса — шул, ул алар белән килешә алмый.

Юлдашев шактый вакытлар командировкада йөреп кайткач, булася урыннарда булды. Ул киткән дип, чыннан да эш тукталып тормаган иде. Аңа калса, турбогенератор бүлегендә эш нормаль бара, монтажчылар, энә күзеннән җеп үткәргән шикелле, җентекләп эшлиләр. Монда бер дә инструкцияне бозу фактлары күзенә чагылмады аның. Хәер, анда нинди «уйлап чыгару» булырга мөмкин — барысы да күптән уйланган. Тик төгәллек, зур игътибар гына кирәк. Пар казаннары цехындагы ашыгу, ыгы-зыгы, «каш ясыйм дип күз чыгару»га юнәлеш алган эшләр аны каушатканнан-каушата барды. Үзенең күңелендәге шикне әйтеп, ул ышанычлы кеше, әйбәт инженер, үзәк лаборатория начальнигы Касаткин белән сөйләшеп карады. Тегесе «индустриаль метод»ны яклап та, кире кагып та ачык кына бер сүз дә әйтә алмады. «Эксперимент. Беренче омтылыш. Ничек әйтергә?» — дип, әллә нинди каршылыклы фикер йөртте ул. Тагы кем белән киңәшергә? Баш инженер була торып, Кукушкин белән киңәшмәс бит инде? Тәҗрибә. Акыл. Белем. Боларның һәркайсына да ия бит ул. Хәзер аңа кем белән киңәшергә, кем белән бу тупиктан чыгу юлларын эзләргә? Юлдашев үзенең бу соравына җавап таба алмады. «Никитин белән бу турыда телгә килү бер нәрсә дә бирмәс». Ул инде, көрешү белән, әлеге дә баягы индустриаль метод турында шатланып сөйләде. Приказ да язып өлгергән. Ә менә Сафин... Сафин аның урынбасары... Ул әллә нинди юллар табып, өстенлекне һаман үз кулына туплый бара, дилбегәне үзенә ала бара түгелме соң? Никитинны да үз ягына тарта бара. Неужели мин бу кешене үземә буйсындыра алмам. Әйтик, үлчәүнең ике башында икебез утырабыз аның белән. Хәлбуки, Сафин утырган үлчәү ягы торган саен авырракка тарта бара бит. Болай барганда, мин утырган як бөтенләй җиңеләеп, иртәме, соңмы, мин үлчәүдән төшеп тә калачакмын. Әйе, шулай булгач, минем алда башкача юл юк. Я ул, я мин...

Юлдашевның башына берсеннән-берсе томанлырак авыр уйлар килә торды.

Ул рәтләп йоклый да алмады. Иртәгесен эшкә килү белән секретарьга Сафинны чакырырга кушты. Элегрәк Юлдашевның урынбасары Брагинский кайчан карама үз урынында була торган иде. Әмма Сафин, бәлки, берьюлы «ике камыт» кигәнгәдер, бу кабинетта сирәк була, күбрәк төзелештә һәм төзү-монтаж идарәсендә кайнаша иде. Хәзер дә секретарь аның кабинетында юклыгын әйтте. Юлдашев аны, ничек кенә булмасын, табарга кушты. Секретарьның ярты сәгать буе шалтыратмаган җире калмагандыр. Алай да төп корпустагы вагон-конторадан тапты ул аны.

Сафин, кабинетка кереп күрешү белән, юка, җиңел плащын салып, почмактагы әйләнмә элгечкә элде. Аннары гафу үтенгән сыман үзе сүз башлады:

— Мин бүген иртүк сезнең янга килмәкче идем. Ләкин бишминутлык озаккарак сузылды. Шуның аркасында...

— Зарар юк, ярый,— дип, аны сүзеннән бүлдерде Юлдашев.— Димәк, хәрәкәт итеп яткан көнегез, Васил Закирович?

— Һичшиксез,— дип басым ясап җавап кайтарды Сафин.

Икесе дә папирос кабыздылар. Кабинет эченә «Казбек» папиросыннан тәмле ис таралды. Ләкин, тарта-тарта, төтен үзенең төтен икәнлеген сиздерми калмады. Юлдашев тәрәзә җиллеген ачып җибәрде.

Баш инженер командировкада чагында, үз эшләрен алып бару өстенә, аның вазифасын да үтәгән Сафин Юлдашевның проммәйданда булуын ишеткән һәм кайбер эшләрне хуп күреп бетермәгәнен дә колактан-колакка йөргән кайбер сүзләр аша белә иде инде. Үзе өйдә юк чагында башкарылган эшләр, бигрәк тә күңеленә ошаганнары хакында сөйләшкәндә Юлдашев гел баш иеп, раслап һәм куанып утырган сыман күренде. «Гаҗәп... төп мәсьәләләрнең берсенә җитәм хәзер. Ничек карар? Хуплармы, юкмы?» — дип уйлады Сафин. Пар казаннарын монтажлаучыларның яңа ысул белән эшләүләре турында аеруча куанып һәм җанланып сөйләде. Юлдашев аны тыңлаганда вакыт-вакыт карандашы белән кәгазьгә нидер төртеп-төртеп куйгалады. Ул Сафинга текәп карап сорады:

— Никитин приказында «индустриаль метод» дип аталган бу хикмәткә сез ышанасызмы?

— Ничек ышанмаска! Ышанам, әлбәттә! — Васил җилкәләрен сикертеп куйды. Юлдашев дәвам итте:

— Аның өстенлеге нәрсәдә соң?

— Минемчә, ул тиклесе сезгә дә билгеле инде: тизлектә, монтажлау өчен киң мәйдан ачылуда, вакытка да, акчага да экономия ясауда. Саный китсәң күп инде аның өстен яклары...

Юлдашев, сынаган шикелле, Васил Сафинга текәп-текәп карап алды да бөтенләй ул көтмәгән яктан эләктереп алып китте:

— Сез яшь белгеч. Энергияле. Һәр эшкә ясканып торасыз. Бу сыйфатларыгыз миңа да, бүтәннәргә дә бик ошый. Тик менә сез күп вакыт ашыгасыз. Бу ашыгуның әллә нинди көтелмәгән күңелсезлекләр китереп чыгаруы бар. Сезнең әнә шул турыда уйлап караганыгыз бармы, Васил Закирович?

Бу нилектән болай сөйли әле? Бер яктан, мактый, икенче яктан, ниндидер бәхетсезлек буласын алдан сизгән кебек, сагаерга куша. Васил Сафинның уйлары әнә шул турыда чуалды.

— Минемчә, без сезнең белән беренче көн генә эшләмибез, Зариф абый,— диде Васил бу юлы гадәттәге «Зариф Салихович» урынына,— без бергә эшлибез, бергә җавап бирәбез. Ул гына да түгел, һәркем үз эшендә үзе җаваплы. Әгәр дә сүз минем турыда бара икән, мин барын-

нан элек эшнең җәмгыятькә нихәтле файдалырак булачагын күздә тотып эш итәм. Теге яки бу адымымны шуңарга карап атлыйм.

— Беләм, мин сезне аңлыйм,— дип дәвам итте Юлдашев.— Сез хәзер генә әйткәннәрнең күбесен мин дә кул чабып каршы алам. Ләкин бит әле хикмәт анда гына түгел. Без хәзер сезнең белән беренче блокны худка җибәрү өчен зур эш алып барабыз. Әле безнең бер генә блокны да җибәргәнебез юк. Ә алар алда алты, әйе, алты блок бит. Тагы да конкретрак итеп әйткәндә, мине иң борчыганы пар казаннары цехы. Бу гигант пар казаннары утыз дүрт метр биеклектә булса да, аны кирпеч өйгән кебек кенә өеп булмый һәм алай ярамый да. Катлаулы механизмнарны монтажлау — ул җансыз тимер өеме өеп кую гына түгел. Сез мин югында менә шул кагыйдәне бозгансыз. Бу хәл белән артык килешеп торып булмый. Кабатлап әйтәм: төзелешнең техник ягы өчен иң беренче чиратта мин җавап бирәм, миннән сораячаклар. Шуның өчен бу тупас хатаны кичекмәстән төзәтергә кирәк булыр...

Бу минутларда Васил Сафин гүя төш күргән бер хәлдә иде. Аныңча, баш инженер иң матур башлангычларга тап төшерергә тели, алга ясканып бару урынына иплән кенә, сагаеп кына атларга куша кебек. Әллә хәзер үк төзелештән дә, эшеннән дә баш тартып, моннан киту турында гариза язсын микән? Ул бу төзелештә эшли башлаганнан бирле Юлдашев тарафыннан ничә тапкыр каршылык очратты инде. Әлегәчә тартышып-тырмашып җинеп килде. Хәзер нишләргә аңа? Чыннан да, бүгенге көн белән генә эш бетми. Әле аларның бергәләп күп еллар эшлиселәре, бу гигантны тәмам аякка бастырганчы эшлиселәре бар. Бу тиклесе дөрес. Ләкин бергә эшли алырмы алар? Васил Сафин бу сорауга җавап таба алмый иза чикте. Башында шундый уйлар кайнаган хәлдә, ул әйтә куйды:

— Сез нинди хата турында сөйли торгансыздыр, Зариф Салихович, бу минем өчен караңгы. Бу — бер. Аннары сез кешегә үз башыннан эшләргә юл куймыйсыз. Бу — ике. Сез һаман, яшь, теге-бу дип, кире чигендерергә телисез. Мин төзелештә беренче көн түгел. Сез мине малайга санамагыз.

Юлдашев көчәнеп елмаерга тырышты, болай да тәртипле яткан сирәк чәчләрен рәтләп куйган итте:

— Сүзнең ни турында барганын сез дә, мин дә бик яхшы беләбез. Җиде тапкыр үлчә, бер кат кис, дип бабайлар бик дөрес әйткәннәр. Бу пар казаннары монтажлаудагы сез керткән «индустриаль метод» киләчәктә әллә нинди куркыныч, хәтта мин әйтер идем, коточкыч аварияләргә китерергә мөмкин. Ә сез берничә буынны уңышлы салу белән ашыгыч нәтиҗәләр ясагансыз. Мин моңа каршы.

— Ә нигә каршы?

— Ашыгыч нәтиҗәләр беркайчан да уңышка китерми,— дип дәвам итте Юлдашев,— һәр нәрсәнең үз тәртибе бар. Аны бозарга берәүнең дә хакы юк. Минемчә, авырны күтәрүгә караганда, җиңелне күтәрү файдалырак...

— Без нормаль эшлибез ич.

— Һич юк! Без монда ике коллега... Бер-беребезне аңларга тиешбез. Син уступкага килергә тиешсең, минемчә.

— Ничек итеп?

— Бик гади. Никитинның «индустриаль метод» турындагы приказын юкка чыгарырга кирәк. Бу турыда, менә хәзер үзара аңлашкач, мин дә, сез дә басым ясарга тиеш булырбыз.

— Андрей Акимович үз приказын үзе һич тә үзгәртәчәк түгел!

— Үзгәртер! Ул төп җитәкче булса да, аның башлыча эше — оештыру эше, кадрлар... Ә без техник яктан җитәкчеләр. Техник яктан ул бездән узып эш итә алмый.

Юлдашев, сүзеннән туктап, чырае кызарган, чигә тамырлары бүртеп чыккан, күзләре төссезләнеп зур ачылган хәлдә, җавап көтеп Василга текәлде. Ләкин Васил ашыкмады. Тупас сүз әйтеп, Юлдашевның хәтерен калдырудан курка иде ул. Васил Сафин урыныннан торды.

— Юк, Зариф Салихович, мин сез әйткән тәкъдимне кабул итә алмыйм. Мөмкин түгел бу! Мин яхшы башлангычны бууга юл куйдырмау ягында!..

— Мин үз фикеремне яклаучыларны табармын! Ә сезгә соң булыр, үкенерсез. Уйлагыз,— диде Юлдашев.

Шуннан ары инде аларның гәпләре алга тәгәри алмады. Кабинетта авыр тынлык урнашты. Бу тиклесен икесе дә сизенделәр һәм бер-берсенә салкын караш ташлап алдылар.

Авыр, бик авыр адымнар белән кабинеттан чыкты Васил Сафин.

Вакытны әрәм итмәстән, Юлдашев үзен тынычландырыр өчен партком секретаре Солтан Сабировның кылларын тартып карады. Аның баш-аягы белән «яңалык» тарафдары булганын абайлап алгач, бу турыдагы сүзне тиз туктатты. «Политика кешесе. Техника мәсьәләләрендә компетентлы түгел»,— дип уйлады Юлдашев.

Кешенең кем икәнен белү өчен аның белән бер пот тоз ашарга кирәк, дигән мәкальне ничәмә-ничә ишеткәне бар аның. Ләкин әле моңарчы бу мәкальне үзенә кулланырга туры килгәне юк иде. Юлдашев белән соңгы очрашудан соң, әлеге шул мәкальне кат-кат исенә төшерде Никитин. «Ләкин «бер пот тоз ашау» гына җитми икән. Югыйсә, бу Юлдашев белән байтак гомерләр бергә эшлибез. Бу көнгәчә мин аның кем икәнен белмәгәнмен»,— дип уйлады Андрей Акимович. Ул баш инженерның производствода, кешеләр арасында сирәк булуына башта бик пошынса да, бара-тора күнегеп килә иде инде. Юлдашевның кәгазьгә язылганга, өстән килгән техник чараларга чат ябышып ятуы һәм гадәттән тыш сакланып эш итүе дә аңа билгеле иде. Ә шулай да, ничек кенә булмасын, аның әле бу хәтле үз кулагәсеннән үзе шикләнеп йөрүе турында уена да китергәне юк иде. Караса, төзелештәге иң зур, иң кайгыртучан булырга тиешле кеше — аның баш инженеры — бик сай йөзә торган кеше булып чыкмыймы соң әле? Бу соң, «контора яза, эшләп бара» дип, читтән генә күзәтеп йөрүче түгелме?

Никитин, Юлдашевның «индустриаль ысул» турында үзе белән сөйләшүеннән соң, шулайрак уй йөртте.

Юлдашев һаман да үзен хаклы, башкаларны хаксыз дип санап йөрде. «Берсе яшьлек дуамаллыгына бара. Аңа дан кирәк! Берсе техник мәсьәләләрне аңламый. Болар белән уртак тел тапканчы «көймәңә су тулуы» мөмкин. Аннан инде батуыңны көт тә тор. Сездән олыраклары да бар. Анда ак белән караны гына аерырлык кешеләр табылыр...» — дип уйлады ул һәм төзелештәге хәлләр турында, үзенчә төп комачаулаучы куркыныч сәбәпләрне инженер күзлегеннән нык кичереп, Мәскәүгә шикаять, хат язарга ныклы карар кылды.

## 5

Әле күптән түгел генә поселокның көнчыгыш ягында больница шәһәрчегеннән башка йортлар юк иде. Шунда янәшә яткан, кайчандыр кар булган урыннарда, күп дигәндә бер атна эчендә, вагоннарга охшашлы йөзләгән өйләрдән торган яңа бистә үсеп чыкты.

Васил Сафинга таныш иде инде мондый өйләр. Үзе белән бергә шул вакытлы күчмә торакларда йөргән Гәрәевнең гаҗәпләнгән, исе киткән төсле сөйләвенә артык әһәмият бирмәде ул. Гәрәев бер сүзе бетүгә икенчесен ялгады:

— Ну, эшли хәзерге әдәмнең башы, Васил Закирович. Отопленнесе үзендә. Пажалысты, бер-ике чиләк күмереңне як та чыжлат батариен.

Булмәләре иркен. Ә җәйлек өчен бигрәк тә уңайлы. Дачада яшәгән кебек яшиләр.

— Билгеле, шулай,— дип аның сүзен раслады Васил.

Бу күчмә өйләр коммуналь хуҗалык бүлеге хезмәткәрләренең эшләрен бермә-бер җиңеләйткәнгә, Гәрәев сөенечен ничек әйтеп бетерергә белмичә сайравында булды.

— Прәме иркен сулыш алдык шушы өйләр аркасында. Упшежитиеләрдә тыңгысызлык бетте. Кызыл почмаклар бушап калды. Пажалысты, культурни эшләрне теләгәнчә җәелдерсеннәр комсомоллар и, китереп, тәрбиячеләр... Андрей Акимовичка, Зариф Салиховичка и, алар белән бергә, сезгә, Васил Закирович, зур рәхмәт инде. Коммунальникларны кысрыклыктан коткардыгыз, чынын әйткәндә...

— Коммунальникларны түгел, безгә килеп эшләүче монтажчыларны,— дип төзәтте Васил Сафин.

Алар берничә өйгә кереп чыктылар. Өйләргә инде күпләр күчеп, урнашкан кебек, әле яңарак күченеп йөрүчеләр дә бар иде. Бер вагон-өйдә караваты һәм урындыкларның булмавын күреп, Гәрәев пошына калды. Ул Василга, үзен гаепле санаган кебек, ялт кына карап алды:

— Борчылмагыз, Васил Закирович, һәркайда тәртип булыр. Момент китереп җиткерерләр барсын да...— Үзе комендантка күзләрен акайтып карарга да җитеште.

Күрәсең, кешеләр бу өйләрдән канәгать калганнар иде. Төрле ризасызлыклар белән мөрәҗәгать итүче булмады. Гәрәевнең иң сөймәгәне дә жалу-шикаятьләр иде. Өйләргә кереп, анда-монда ялт-йолт карангач, әлеге шул ризасыз авазлар ишетелүдән сакланып, аның чыгарга ашыгуын Васил абайлый алмады.

— Бу өйләр бездә гел торып калмаслардыр бит, Васил Закирович?

— Калмаслар. Ә шулай да берничә ел үтәр әле. Үзегез әйтмешли, ни өчен дисәгез: кешеләргә тору өчен капиталь йортлар салып өлгертә алмыйбыз.

— Шулай шул,— дип ризалашты Гәрәев.— Эшчеләрнең яңалары килә тора. Бары да яшьләр. Өйләнешәләр, үрчиләр. Җиткереп кара син аларга торак мәйданы?

Күчмә өйләр берничә урам булып, билгеле бер тәртип белән урнаштырылганнар. Урамнар бик аз тапталган, һәркайсында яшел чирәм хәтфәләнеп ята. Торак мәсьәләсе төзелеш җитәкчеләрен бик нык борчый иде. Күчмә өйләр бу зур китеклекне, бик нык кирәк чагында, менә дигән итеп ямап куйды.

Бик куанган, күңеле күтәренке Гәрәевне Васил искәртеп куярга кирәк тапты:

— Гадәттә җир тунгач астан салкын йөрүчән була. Авыл өйләренең нигезенә туфрак өеп җылыталар ич. Боларның нигезенә дә пычкы чүбе салырга кирәк булыр.

— Тагы мәшәкать,— диде Гәрәев.

Алар инде китәргә ниятләп торганда кулына зәңгәр конверт тоткан яшь кенә, мөлаем гына бер хатын каршыларына чыкты:

— Начальник абыйлар, әйтегез әле, адресны ничек язарга?

Гәрәев аптырый калды. Бу сорау турыдан-туры аңарга кагыла иде. Ул ык-мык килеп торган арада Васил Сафин җавап бирде:

— Әлегә эшли торган урыныгызның адресын күрсәтеп язылыгыз. Тиздән урамнарның да исеме булыр, өйләргә номерлар да сугылыр.

«Менә баш дисәң баш, ичмасам. Нинди сорау алдында да каушап калмый. Тик ник соң әле мин әйтәсене ул әйтеп өлгерде?» — дип уйлады Гәрәев. Үзе кесәсеннән кечкенә блокнот чыгарып язып куйган иттә.

— Дөрес, Васил Закирович, момент эшлибез аны. Поссовет белән сөйләшеп килешербез мәсьәләне...

Күчмә өйләр урнашкан шактый киң урынга төбәп исем кушучы булмаса да, аның турында сүз чыкканда берәүләр: «Вагон-городок», икенчеләр: «Монтажчылар поселогы», өченчеләр: «Шанхай-городок» дип, телгә алалар иде. Шуны истә тотып һәм «Монтажчылар поселогын» барыннан да дөрес һәм мәгъкуль санап, Васил бу турыдагы үз фикерен Гәрәевкә җиткерде. Теге исә ризалашып башын селки-селки: «Момент була ул»,— дип, тагы кесәсеннән блокнотын чыгарды.

...Кызык кына бу балалар: тиз иләнәләр, тиз оныталар, тиз күнәләр, тиз елыйлар — гомумән, һәртөрле зур үзгәрешләрне дә, тормыштагы башка хәлләрне дә җиңел кичерәләр. Йөзләре әле генә кояш кебек якты, шунда ук караңгыланып та китә. Ләкин болар берсе дә озакка бармый. Кечкенә Ринатны балалар бакчасыннан алып кайтышлый, Васил шулай уйлады. Авыл һавасы, иркен һәм тыныч тормыш малайга яхшы тәэсир ясый. Аның йөзе-тәне коңгыртланып тутланды, күзләрендә тереклек нуры артты һәм гәүдәсе дә калкулана бара. Өстенә кыска җиңле блуза, кыска ыштан, башына матроска кигән «кара чутыр»ны җитәкләп, яшь агачлары матураеп яшәргән поселок урамыннан салмак кына атлап кайта Васил.

Малайның әнисеннән аерылганына ничә айлар үтте инде. Дөрес, баштарак ул әнисе турында: «Әни, кулуттан касан кайта?» — дип сораштыргалады. Васил бу сорауга, аны-моны уйлап тормастан, турыдан ярып җавап бирде: «Ул күптән кайткан инде. Әниең безнең янга килми. Ул анда тора. Синең белән мин, әбиең монда торабыз»,— диде. Ринат, шул җаваптан канәгать калган сыман, башкача ләм-мим әйтмәде. Көннәр үтә торды. Васил малайның әнисен юксыначагын уйлап көенеп йөрде. Әмма, бәхеткә каршы, малайда юксыну, сагыну хисләре, әнисен искә алу сизелмәде. Ринат бакчада үзенә менә дигән дуслар да тапты. Ул бакчага шул хәтле иләнде, ял көннәрендә дә бик иртә йокысыннан уяна һәм бакчага китәргә ашыга. Тик ял көне икәнен әйткәч кенә бераз моңайган сыман тынып кала. Бакчага кызыгырлык та шул! Ринат йөри торган балалар бакчасы — зур тәрәзләре белән көньякка караган ике катлы озынча йорт. Аның ишек алды челтәрле тимер коймалар белән әйләндереп алынган. Киң ул. Верандалары, уен мәйданнары, озынча түтәлләрендәге янып торган чәчәкләре үткән-сүткән олырак кешеләрне дә кызыктырырлык. Ринатны алырга килгән Васил да сокланып карап торды. Гәрәевнең: «Кешеләр үрчи»,— дигән сүзе исенә төште аның. Мәзәгрәк һәм тупасрак кеше булса да, үрчү турында дөрес әйтә. Булган ясләләр, бакчаларга өстәп, узган ел тагы ике йөз кырык урынлы бина җиткерделәр. Әле һаман барлык сабыйларны да бакча-ясләләргә урнаштырып бетерә алмыйлар. Тагы да «балалар комбинаты» дип исемләнгән зур бина салырга керештеләр.

Кызык кына балалар дигәнең. Язгы гөрләвекләр, кар сулары шаулап аккан көннәрнең берсендә, бакчадан кайтканда, Ринат юл уртасыннан килгән җигүле атны күреп туктап калды. Күрәсең, шәһәрдә торганда малайның йорт хайваннары күргәне булмагандыр. Ул бик кызыксынып атка карап торды да әтисеннән сорап куйды:

— Әти, нигә аның туфлие пысылак?

— Туфли түгел, тояк,— дип төзәтте әтисе.

— Юк! Туфли. Үзләле тишек, ямасы бар.

Чыннан да, атның тояклары, ихтимал, гомергә дә киселмәгәндер, бик тупас һәм әллә ничә урыннан кителеп-кителеп тора иде.

Нихәтле бәхәсләшсәләр дә, малай үз сүзеннән кайтмады. Васил үзенең дә кечкенә чакларын хәтерләде. Ул заманда малайларның иң кызыкканы ат иде. Авылда, әйтик, төпсез ыштанлы малай атка атлануны зур мәртәбә һәм батырлык дип саный иде. Шулай бер вакыт ул,

эле гомерендә беренче тапкыр бугай, инеш буена ат эчерергә төшә иде. Кайсыдыр берсе мактый-мактый канатландырып җибәрде үзен. Аннары кинәт әйтә салды: «Әле син үсеп җитмәгәнсең икән. Малай кеше атын чаптыра ул. Ә син атлатып кына барасың...» — дигән булды. Васил атның корсагына аяклары белән тибеп, малга тезген очы белән суккалый торгач, тауга түбән төшеп баручы ат теләмәсә дә юртып китте. Һәм... безнең «батырыбыз» мәтәлчек атып ат өстеннән егылып төште. Акыллы ат туктап аны көтеп торды. Башта котырткан теге шаян кеше аны янә атка күтәреп атландырды да: «Менә үстең инде»,— дип, көлә-көлә үз юлы белән китеп барды. Шул беренче чыныгудан, шул чирканчык алудан соң, Васил инде башкача ат өстеннән егылып төшмәде.

Васил, улын җитәкләп, өенә кайтып кергәч, әнисе карчык аңа хат китереп тоттырды. Ачты. Хат судтан иде.

Василга ашыгыч рәвештә җыенып шәһәргә китәргә туры килде. Нурзиләнең үзенең уй-фикерләрен әйтеп кайчандыр аңа хат салмакчы булган иде бит. Нигәдер Васил аннан хат көтмәде, үзе дә язмады. Хатынына карата аның күңеле яңадан эремәслек булып бозланып өлгергән иде инде. Аерылышу турында аның искәртми-нитми судта эш кузгатуын ул бары тик күңеленнән хуплады гына. Гадәттә халык судьялары аерылышучы тарафдарларны чакырып үгетлиләр. Судья Васил белән алай сөйләшмәде. Күрәсең, Нурзилә һәммәсе турында да кайгырткан, судьяга сөйләгән һәм аны ышандырган булса кирәк.

Кирәгеннән артык юка иякле, озын борынлы, матур, көр тавышлы судья баланы кем ягында калдыру турында баштарак аптырап калды. Иң элек Нурзиләгә сорау куйды. Ана тиешле кеше нигәдер, сыгылабөгелә генә, калтыраулы бер тавыш белән сөйләде. Алай да ул баланы үзендә калдыруларын үтенде. Судья як-ягында утыручы халык утырышчыларына карап алды. Халык утырышчыларыннан берсе хәзерге көндә баланың кем тәрбиясендә, кем янында торуын сорауга Нурзилә, телен йоткандай, тып-тын калды. Василга сорау куелды. «Ул ничек уйлый?» «Улым үз янымда, үз канатым астында,— диде ул,— мин аны әнисенә бирмим. Үз янымнан беркая җибәрмим. Аның әнисенә бала кирәк түгел...» Шул турыда судьяның сорауларына җавап биргәндә, ул бозлы тар сукмактан, менә егылам, менә тәгәрим, дип барган кеше сыман ышанычсыз һәм салкын бер тонда сөйләде. «Хөрмәтле судья һәм хөрмәтле халык утырышчылары, баланы миндә калдыруыгызны бик нык үтенеп сорыйм»,— диде. Бала турында судьяның икенче мәртәбә үзенә сорау куюына каршы Нурзилә: «Һәр анага бала якын, бик якын. Ләкин мин, тормышыбыз шулай уңышсыз чыккач, ни дип әйтергә дә уңайсызланам. Шулай булгач, суд нинди карар чыгара — миңа шуның белән ризалашырга туры килә»,— диде.

Суд баланы әтисе тәрбиясендә калдырды.

Васил судтан чыккач, кая барырга дип уйланып торганда, Василның күзенә тротуарга килеп туктаган җиңел машинада кайчандыр күргән, таныш кебек бер кеше чалынды. Озак та тормый, Нурзилә шул кеше янына янәшә утырды һәм җиңел машина, артыннан сыек төтен калдырып, китеп тә барды. Әйе, моннан элек килүендә Василга очраган болоний плащлы, эшләпәле кеше иде бу. Нурзилә курортта төркем белән төшкән фотокарточкада да бар иде ул кеше. Шул үзе.

Суд вакытында Васил кайчандыр үзе ихтирам иткән, бергәләп матур тормыш кору турында хыялланган, хәзер инде бөтенләй чит-ят булган Нурзиләгә карамаска тырышса да, барыбер күзләре төшеп-төшеп алды. Аңа калса, элекке Нурзилә түгел иде инде бу. Хатынның күз төпләрендә ниндидер җыерчыклар хасил булган, яңаклары сулып, күзләре зураеп калган, борыны да үсеп киткән сыман. Барыннан битрәк, аның күз карашы салкын һәм нурсыз, гүя бер яшькелт пыяла кисәге иде...

Гашүрә карчыкка баштарак, бирегә күчеп килгән көннәрендә, бер кадәр күңелсез иде, тора-бара ияләнде, күнекте. «Ризык кайда — бәндә шунда»,— дисәләр дә, ул әллә кайда түгел, үз улы янында лабаса. Тагы әле менә оныгы: нәкъ коеп куйган улы төсле. Гомер-гомергә авылда яшәгән, шәһәр дигәнендә әллә нидә бер булган бу карчык Яңа Наратлыга килгәч тә, кая барса да гел яшьләрне генә күреп, баштагы көннәрдә шактый хәвефләнә калган иде. Ни әйтсәң дә һәркемгә үз ише белән күңелле бит инде ул. Ә менә Гашүрә карчык үзе әйтмешли: аллага шөкер, тора-бара аның үзе кебек карчык-корчыгы да табылды. Аның иң якын сердәше — Варвара карчык. Һәрвакыт якты чырайлы, миһербанлы бу илгәзәк карчык әледән-әле аның янына килә тора. Хәтта кибеткә йомышы төшкәндә дә сугылмыйча үтми. Рәхәтләнеп сөйләшәләр, дөньяил хәлләрен уртаклашалар, самоварның суы беткәнче чәй эчәләр.

Соңгы арада Гашүрә карчыкның кәефе китеп торуын ишеткәч, Варвара карчык тагы килеп чыкты. Ул ахирәтенең баш өянәге кузгалуын һәм аяклары сызлап торуын белгәч, көннәрнең тиздән явымнарга керәсен юрады. Аннары сырхауны кайтару, бетерү өчен үзенчә әмәлләр эзләде. «Минем чормада, акыйрәт, узган елгы кипкән мәтрүшкә бар. Балан кагым да бар, кодайга шөкер. Менә шуларны китерермен дә әммәсе дә узар. Мәтрүшкә кайнатып эчсәң, баш сыркавын юып алгандай итә. Кагы, май өстендә бал дигәндәй, буыннарны йомшартып җибәрә. Казер шулай итим әле, апкилим әле...» — дип сөйләнде.

— Картлык дигәннәре итәктән тарта инде,— дип зарланды Гашүрә эби.— Алты дистәнең теге ягына чыккач, әллә ни алдырып булмый. Шакыр-шокыррак итеп йөрергә туры килә.

Варвара ахирәтенең хәлләрен сорашкач ук китеп барырга һәм аңа үлән дәваларны китерергә ниятләсә дә, сүз бозау имезә дигән кебек, сүзе һаман чыга торды. Бер арада ул Гашүрәгә шундый сорау куйды:

— Катыны белән арасы ничек соң улыңның, апкайтмыймы?

Бу сорауны ишеткәч, Гашүрә карчык тагы да куырылып киткән кебек булды:

— Юк, Барбара туган. Ул инде Куйбышевка барып, араларын бөтенләй өзеп кайтты.

— Суд беләнме?

— Әйе, судлашып.

— Малай кем ягында калды соң?

— Әтисе ягында,— диде Гашүрә, тавышын күтәрәрәк төшеп.— Бирәме соң ул аны хатыны кулына. Теше-тырнагы белән ябышкан малаена.

— Шулай шул инде, колык-адәтләре килешмәгәч, дөньяны бергәләп тәгәрәтә алмаганнардыр, дигәндәй... Син теге, бала дип, мәкапәтләре булмагачтын, этле-мәчеле торуның ни кирәге бар.

Гашүрә карчык аңа каршы кайтарып бер сүз дә әйтмәде. Шуны сизенепме яки үз көе беләнме, Варвара карчык сөйләнүендә дәвам итте:

— Минем дә төпчек әллә ничегрәк булып чыкты әле, менәтерәк... Алмадай-хөрмәдәй кызлар тулып ятканда үзебезнең урамдагы түбән оч якның берәүгә ияләнде. Кем дисәң тагы: ирдән аерылган бер балалы катын. Каян тапкандыр инде мәнсез, безнең «бозау»ны әйтәм. Югалып-югалып тора, төннәрен шуның янында куныл-куныл кайта. Әйттем. Колагына да алмый. Син теге катын күрмәгән кешенең... Илимин-фәлән түләрлек хәлгә генә җитмәсә ярарие инде, кодаем. Мәгәр шул «колынлы бия»не ихатама кертәсем юк...

Карчыкларның берсенә, ахирәте килгәч, җиңелрәк булып китте, икенчесе эчен бушатып, иркенрәк сулыш алды. Варвара карчык шул көнне үк телгә алган дәваларын да китереп бирде.

Ике-өч көн гомер сизелми генә үтеп тә китте. Гашүрә карчыкның хәле әллә ни әйбәтләнмәде. Һаман башы авыртты, аз гына йөрергә туры килсә дә, аяклары сызлап, үзәгенә үтте. Бер көнне улы Васил, җыелыш булу сәбәпле, эшеннән соңга калып кайтасын телефоннан шалтыратып әйтте. Гашүрә карчык оныгы Ринатны алып кайтырга үзе китте. Бераз баргач, аяклары авыртуга чыдый алмыйча, урам читендәге эскәмиягә утырды. Шул вакыт аның янына чибәр генә бер кыз тукталды. Иң элек ул карчык белән исәнләште. Гашүрә карчык күтәрелеп карады: таныш йөз, таныш төс. Бу кызны кибеттә очраткалаганы бар иде аның. Карчык белән гел исәнләшеп, баш иеп китә иде ул. Бу нинди кыз икән? Ул тиклесен Гашүрә карчык белми, тик аның турында: «Итагатьле ата-ана баласыдыр»,— дип кенә уйлый иде.

Моңарчы очрашканда җылы гына сәламләшеп узудан башка танышлыгы булмаган әлеге шул кыз бу юлы ничектер көтелмәгән бер миһербанлык күрсәтте. Кинәт кенә карчыктан:

— Әллә авырыйсызмы, әби, төсегез бик киткән? — дип сорады.

— Әйе, кызым, сырхау тотты, кәефем китебрәк тора әле,— диде Гашүрә карчык, җылы сүзгә күңеле булып.

— Ял итеп утырасызмыни?

— Юк, кызым. Менә детсадка барышым иде, бераз хәл алыйм дип утыруым. Сәламәтлегең китә башласа, бик яман икән ул.

Гөлзаданең шул секундта: «Гашүрә әби, әйдәгез, мин сезне җитәкләп урыныгызга илтеп яткырыйм да Ринатны үзем алып кайтам. Хафаланмагыз, таныйм мин ул малайны, күргәнем бар. Ә сез тыныч булыгыз»,— диясе килде. Ләкин ничек әйтергә моны? Кыз каушый калды. Карчык аякларын көч-хәл белән кузгатып, урыныннан торгач кына, Гөлзадә телгә килде:

— Гашүрә әби, әйдәгез, Ринатны бакчадан үзем генә алып кайтыйм. Сез кереп ятыгыз. Сезгә кыен...

Кызның бу каләр үз итеп, якын итеп эндәшүенә карчык бөтенләй гаҗәпләнә калды. Аңа ничектер бик рәхәт булып китте. Ул кызга күтәрелеп карады да:

— Соң син аны, кызым, таныйсыңмы? — дип сорады.

— Таныйм, бәй, танымыйча...

Шуннан соң Гөлзадә балалар бакчасына китте. Карчык, шундый шәфкатьле кыз очрауга куанып: «Савaплы бул! Бәхетле бул!» дия-дия өенә кереп китте.

Икенче көнне, әнисенең хәле рәтләнмәгәч, Васил өенә врач чакыртты. Ияк очында зур борчак хәтле миңе булган, бер нечкә, бер калын тавыш белән сөйләшә торган урта яшьләрдәге врач хатын карчыкны әйбәтләп карады да хәле әллә ни куркыныч түгел икәнен әйтеп, бер кочак рецепт калдырып китеп барды. Васил көндезге ашка кайта алмады. Аннары бераздан әнисенең авырып торуы ничектер исеннән дә чыгып китте. Васил кичке якта, соңга калып кына эшеннән кайтырга чыкты. Менә шунда инде аның йөрәге «җу» итеп китте. Әнисен дарусыз калдырды бит. Ичмаса, күршеләренең берәрсенә әйтеп куйган булса... Вакыт соң, аптека ябык иде инде. Ул, эченнән үзен тирги-тирги, өенә кайтты.

Бүген инде, бүтән көннәрдәге кебек, әнисе аның кайтуына урын өстендә ятмый иде. Гашүрә карчык, берни булмаган кебек, улына табын әзерләде. Васил сабырсызланып сорый куйды:

— Әни, хәлләрең ничек?

— Рәтләнә хәлләр, арулана, улым. Аякка торып басуым шушы булса кирәк. Баш та ул хәтле чәнчешми.

— Мин дарулар алып кайтырга да оныткаңмын бит эшкә күмелеп.— Василның чыраена сизелер-сизелмәс кенә булып кызыллык йөгерде.
— Әнә, дарулар камутта,— диде энисе.
— Ничек? Үзең бардыңмыни?
— Кая үзем бару? Иртәнге якта кәефем әллә кем түгел ие. Шул инде теге көнне әйттем бит: миңа бер шәфкатьле кыз очрады дип. Шул кыз апкайтып бирде.— Карчыкның түсе яктырып, күзләре нурланып китте кебек.
— Кем соң ул?
— Исемен үзе әйтмәде, мин сорарга кыймадым. Анысы башыма да кереп чыкмаган, хәерсез. Карт кешенең хәтере — тишек иләк инде ул...
— Ринатны үзең барып алдыңмы?
— Юк, улым... Теге чибәр апасы китереп куйды минем улымны.
Васил гаҗәпләнүдән кулларын тез өстенә салды:
— Ул кем булыр икән?
Шул сорауны гына көткән кебек, моңарчы олыларның сүзенә һич тә колак салмагандай, үз шөгыле, үз уенчыклары арасында кайнашкан Ринат кинәт сүзгә кушылды:
— Кичә дә, белсе көнгә дә тетя Галя белән кайттым мин садиктан.
— Аның тетя Галя икәнен каян белдең, улым?
Әбисенең бу сүзенә каршы:
— Ул минем исемемне солады, мин аныкын,— диде малай.
Көлештеләр.
«Кем булыр бу»,— дип уй йөртте Васил. Гөлзадә түгел микән? Энисе дә теге кызның исемен белми. Бу ничегрәк килеп чыга соң әле? Васил әнә шул сорауларга җавап эзләде. Дөрес, хәзер инде Гөлзадә белән аның мөнәсәбәте томанлы бер билгесезлектән узган, ачыкланган иде. Ләкин аларга бик сирәк очрашырга туры килә, ә соңгы көннәрдә бөтенләй күрешкәннәре юк. Гөлзадә төнге сменада эшли, Василның эше бик күп иде.
Берничә көн үткәч, алар урамда очраштылар. Васил, эштән кайтып килгәндә, ни күзе белән күрсен: Ринатны житәкләгән Гөлзадә салмак кына атлап тротуардан кайтып килә иде. Күрәсең, «тетя Галя», эшкә барганчы, ашый-эчә дә һәр көн малайны барып ала. Кызның өстендә жинсез зәңгәр ефәк күлмәк, аягында капрон оек, заманча очлы башлы, яссы үкчәле кара туфли. Ул матур куе коңгырт чәчләрен баш түбәсенә күпертеп җыеп куйган. Күлмәге нечкә биленә сыланып тора. Василны күргәч, Гөлзадәнең янаклары алсу чәчкә төсенә керде.
— Исәнме, «тетя Галя»? — диде Васил.
— Исәнме, Васил абый? — диде Гөлзадә.
— Ул миңа гына тетя, сиңа алай түгел, эти,— диде Ринат.
Малайның әле моны, әле тегене такылдавын искә алмаганда, икесе дә тын бардылар. Василның күңеле йомшарып китте. Кызның малайны шулай житәкләп баруы, аның турында кайгыртуы аны мең-мең сөендерде. «Әни ялгышмый торгандыр, чыннан да, нинди сөйкемле. Малайга — «тетя». Мин «тетя»га «абый». Кызлар шулай инде: көндезен «абый», кичен исә «җаныем» диләр. Халык белми әйтмәгәндер». Василның башыннан әнә шундый уйлар үтте.

## 7

Һич көтелмәгән хәл булды бит әле бу. Василның күз аллары караңгыланып китте.
Ул бүген барлык бригадаларны да диярлек йөреп чыкты. Йөреп кенә чыкмады, һәркайсында тукталып, озак-озак сөйләште, киңәшләр бирде, кешеләрне тыңлады. Һәрнәрсә диярлек үз урынында, кешеләр ясканып

эшли иде. Болай барса, яңа ел тирәләрендә яки аннан элегрәк энергия гигантының эшли башлавы күз алдына килеп басты аның. Шуңа күрә ул эштән кутәренке күңел, менә дигән кәеф белән кайтты.

Кич йокларга яткач, Василның уйлары Гөлзадә тирәсендә уралды. «...Күзне йомасы да тәвәккәллисе. Бәлки ул риза булмас. Бәлки... Хәер, Гөлзадә белән минем яшь аерымлыгы әллә ни зур түгел. Подумаешь, мин аннан тугыз яшькә олы. Моның бит бернинди куркынычы юк». Васил үз-үзе белән шулай сөйләшеп ятты. Ләкин һаман да күзләренә йокы кермәде. Кайдадыр этәчләр кычкыруы ишетелде. Аннары этләр өрешкән аваз килде. Инде болары тынып җитмәгәндер, малай чакларда үз авылларында ишеткән бер моңлы гади авыл көен уйный башладылар. Василның исенә җырның сүзләре дә кайдандыр күңел түреннән актарылып килеп чыктылар. Аның бу көйне күптәннән бирле ишеткәне юк иде. Гармун тавышы әкренләп ерагая барган саен, ул да оеган шикелле бер рәхәтлеккә тала барды, күзләре үзләреннән-үзләре йомылды.

Челтер-р итеп әче тавыш белән телефон шалтырауга уянып, Васил тиз генә йөгереп барып, трубканы алды.

— Тыңлыйм. Әйе, Сафин. Нәрсә, нәрсә?

— Бәхетсезлек. Травма,— диде баш диспетчер Дина Гурская.

— Нинди травма? Кайда?

— Төп корпуста. Хәзер сезгә машина килеп җитәр.

— Киенәм.

Диспетчер әйткәнчә, машина тиз килде. Беркадәр каушап калган Васил Сафин төннең салкынчалыгын да, яңгыр тамчылары төшкәләп торуын да сизмәде. Ул төп корпус бинасына килеп җиткәндә, анда халык кайнаша иде инде. Төнге сменаларда эшләүчеләр, прорабларстена буендагы бер почмакны әйләндереп алганнар да аптырашып карап торалар иде. Милициядән дә кешеләр бар. Бетон идәндә эш киемнәреннән дә төсен аеруы кыен булган берәү кан эчендә ята иде.

— Фарукшин,— диде Дина.

— Фарук Фарукшин? — дип кабатлады Васил Сафин.

Ак халатлы дежурный врач бәхетсезлеккә очраучының пульсен капшады. Бер сүз дә әйтмичә, башын гына селкеде. Фарукшинның гәүдәсен носилка белән ашыгыч ярдәм күрсәтү машинасына салдылар да китеп бардылар. Тикшерүче шунда ук протокол язды һәм машинасына таба атлады. Ләкин ул китеп бармады. Тиз генә борылып тагы килде.

Прорабтан сорашып, Васил Сафин Фарук Фарукшинның өстә, егерме биш метр биеклектә пар казанын утка һәм эссегә чыдам махсус кирпечләр белән тышлауда эшләгәнен белде. Бу — обмуровщик эше дип атала. Култыксалы металл баскычлардан өскә менделәр. Обмуровщиклар белән турыдан-туры җитәкчелек итүче прораб, битен санап бетергесез күп мең баскан бөкрерәк кеше, өскә менеп җиткәч, кулларын җәеп салды:

— Менә күрәсез, безнең монда куркынычсызлык ягыннан барсы да эшләнгән...

Тикшерүче дүрткел рәвешендәге озынча тимер идәннәренең ничек беркетелүләрен карады. Һәрберсе шөрепләр белән ныгытып утыртылган иде — бәйләнерлек урын таба алмады. Ул, булган хәтле фактларны кәгазьгә теркәп, мәсьәләне ачыклау өчен төнге сменада эшләгән кешеләрне чакыртып сөйләшергә булып, китеп барды.

Әмма бу хәл, бу зур күңелсезлек Василның болай да югалган күңел тынычсызлыгын үстерә генә барды. Ул тәмам китәргә җыенып, аска төшкәч, беркадәр вакыт арлы-бирле йөренде дә тагы пар казанын кирпечләр белән тышлаучы звено кешеләре янына өскә күтәрелде.

Ул кешеләрдән сораштырып кына бернинди нәтиҗәгә килә алмады. Фарук Карчыга белән бергә эшләгән. Карчыгадан сораштырырга исәпләгәч, анысы күренмәде. Аның әле күптән түгел генә төп корпуста булганлыгын әйттеләр. Нихәтле эзләп тә Васил аны таба алмады. Булган хәл турында ул төрлечә уй йөртте. «Аның ничек һәлак булуын тикшерү оешмалары ачыкларлар, белерләр. Әмма ничек кенә булмасын, төзелеш өчен, бигрәк тә минем житәкчелектәге участок өчен бу бигрәк тә күңелсез хәл»,— дип уйлады Васил.

Иртәгәсен Сафинны баш инженер Юлдашев чакыртты. Юлдашевның төсе күңелсез, күз карашы тонык һәм төксе иде. Күрәсең, төнге травма аңа да авыр тәэсир иткән. Нигәдер Юлдашев үзен бик сәер тоткан шикелле күренде. Кая да булса барырга ашыккан кебек, беләгендәге сәгатенә күз төшереп алды.

— Бу көтелмәгән бәла ничек килеп чыкты әле? — дип сорау куеп сүз башлады ул.— Прораб, мастерлар кайда булган? Сез ни карадыгыз?

Ничектер Василның: «Шушындый ук сорауны сезнең үзегезгә дә биреп була бит»,— дип әйтәсе килде. Ләкин ул тыелып калды.

— Әйе, зур бәхетсезлек. Кешенең гомере өзелде.

Юлдашев гасабиланудан өстәлдәге калын пыялага чиртеп-чиртеп ала иде. Ләкин ни сәбәптән аның бу кадәр кәефе киткән: Василгамы, әллә производствода кеше һәлак булгангамы?

Юлдашев алдында яткан язуга карап алды:

— Фарукшин. Кырык биш яшендә. Әле ир уртасы чагы гына.— Ул иреннәрен тешләп бераз уйлангандай утырды да сүз катты: — Сез аны белә идегезме?

— Белә идем. Хәер, бик яхшы ук түгел.

— Бик сала торган кеше булган, дип сөйлиләр.

— Соңгы вакытларда әллә ни сизелми иде.

— Салмыш белән дус кешене өстә эшләргә куймаска кирәк иде. Менә хәзер җавап бир аның өчен. Хәзер бит, үзегез беләсез, производство травмасы өчен «кылдан нечкә, кылычтан үткен» сират күпере аша чыгаралар. Травма үлем белән бәйле булса бигрәк тә. Шома гына узмас бу. Моның өчен кайбер кешеләргә каты гына эләгер...

Бераздан Юлдашев өстәленең бер читендәге ак төймәгә басты. Бусагада купшы киенгән секретарь-машинистка күренде. Кабинет хуҗасы аңа карамыйча гына сорады.

— Шалтыраттыгызмы?

— Озакламый килеп җитәргә тиеш, Зариф Салихович.

Кабинетта тәмле хушбуй исе калдырып секретарь чыгып китүгә, озак та тормастан, врач-хирург килеп керде. Юлдашев аңа урын күрсәтте. Теге утырды.

— Ну, ничек? Эчкәнме?

Хирург, гадәтенчә, чиста күлъяулыгы белән күзлеген сөртте дә, кашларын җыера-җыера, кемгәдер ачуланган шикелле җавап кайтарды:

— Аның эчкәнме-эчмәгәнме икәнен ачыкларга мөмкин булмады. Чөнки бөтен гәүдәсе изелгән, сынмаган сөяге калмагандыр. Ашказаны да тишелгән. Анда бары канлы төерләр генә...

Бу җавапны ишеткәч, Юлдашев врачка коры гына:

— Борчыганым өчен гафу итегез, минем сезгә башка соравым юк,— диде.

Хирург тагы бер-ике сүз алышкач, китеп барды. Юлдашев тынгысыз күзләре белән сынаулы һәм шикле бер төстә Сафинга карады:

— Күрәсез, эш катлаулана, Васил Закирович! Фарукшинның эчкән-эчмәгәнлеген медицина әһелләре ачыклый алмаганнар. Димәк, гаеп... прораблар, сезнең өскә төшә.

— Мин сезне аңламыйм, Зариф Салихович.

— Ничек аңламыйсыз! Күрәсең, анда техника куркынычсызлыгын саклау кагыйдәләре тиешле югарылыкта булмагандыр. Шуның аркасында бәхетсезлек килеп чыккан...

Василның, бер яктан, ачуы да килеп китте: нигә ул читтән килгән бер кеше шикелле кылтым-мылтым сөйләшә? Үзе дә күктән төшмәгән, шушындагы кеше ләбаса. Ләкин Юлдашев белән бәхәсләшеп маташу әллә ни бирмәс кебек тоелды. Шулай да хәлнең ничек торганлыгын әйтмичә дә ярамый иде.

— Пар казаннары цехында техника куркынычсызлыгын саклауны начар куелган дип булмый. Карадым, булдым.

— Анда ул яктан эш әйбәт куелган икән, ни өчен кеше тикле кеше шул хәтле биеклектән егылып төшкән соң? Ул аннан үзе ташланмагандыр бит инде?

— Әйтүе кыен. Алай да...

— Ничек, ничек? — дип сорады Юлдашев.

— Кем белә: бәлки ул барьердан аска карагандыр. Шунда башы әйләнеп-нитеп егылуы да мөмкин, минемчә. Азмы тормышта андый хәлләр.

Юлдашев аны тыңладымы, юкмы, әмма чырае һаман саен кырыслана барган кебек тоелды. Ул ниндидер ачулы һәм ризасыз тавыш белән сүзен дәвам иттерде:

— Шушы травма аркасында нихәтле премиядән колак кагабыз. Кешеләрнең инициативаларына бөтенләй кире яктан китереп сугачак бу. Аннары Главка приказында бу хәл турында электр станцияләре төзелеше барган бүтән җирләргә дә җиткерәчәкләр. Менә мәсьәләнең иң кыен ягы кайда!

— Мәсьәләнең иң кыен ягы кешенең гомере вакытсыз өзелүдә,— диде Васил Сафин.

— Анысы үзеннән-үзе билгеле,— диде Юлдашев салкын гына тонда.— Өстән килеп тикшерә башлаганчы, үзебезгә чаралар күрми ярамастыр.

— Нинди чаралар?

— Иң элек төп гаеплеләрне табарга кирәк.

— Ул тиклесе белән тикшерү органнары шөгыльләнә ич,— диде Васил.

— Тикшерү органнары безнең булышлыктан башка берни дә эшли алмыйлар монда. Исегездә нык тотыгыз: киләчәктә мондый хәлләр кабатланырлык булмасын. Техника хәвефсезлеген ныгыту буенча кулыгыздан килгәннең һәммәсен дә эшләргә тырышыгыз.

— Анысы, әлбәттә, кирәкле эш,— дип килеште Васил.— Инструкцияләрне тагы да аңлата төшәргә кирәк булыр. Журналларны тикшереп чыгарга...

Бу нигә болай?

Юлдашев белән очрашкан, сөйләшкән саен Василның күңеленә юшкын утырып кала. Гомуми эш, гомуми бурычлар уртак булганлыктан, аның белән теләмәсәң дә очрашырга туры килә. Бу юлы да шулай булды. Бигрәк тә Юлдашевның төзелештә эшләүче җитәкчеләренең берсе буларак түгел, бәлки читтән, каяндыр ерактан килгән вәкил сыман гәпләшүе ошамады. «Шундый коры кеше, шундый коры... Күрәсең, ул үз өстендә бернинди җаваплылык булуын теләми. Башкалар теләсә нишләсеннәр, ә ул «манара»дан гына карап торырга, шуннан гына хөкем итәргә тиеш. Күпмегә хәтле дәвам итәр бу хәл?» — дип борчылып уйлады Сафин.

## 8

«Күпме түзеп торырга, күпме көтәргә мөмкин? Тынлыкны бозып, һөҗүмгә күчәргә вакыт! Хәзер моның өчен иң уңайлы чак...» Шушы уй-исәп, шушы теләк Юлдашевның күңелендә көчәйгәннән-көчәя барды.

Фарук Фарукшинның аянычлы үлеменнән соң озак та үтмәде, барлык участокларда техника хәвефсезлеген ныгыту турында баш инженерның приказы чыкты. Ул, үзе башлап, тикшерү оешмаларына гаепле кешеләрне каты җавапка тарту турында гел искәртеп, исләренә төшереп торды. Ләкин тикшерү оешмалары әлегәчә берәүне дә конкрет гаепләргә нигез таба алмадылар, җентекләп тикшерүләрен дәвам иттерделәр. Аларның эшенә төп уңайсызлаган сәбәп — дәлилләр, ачык фактлар булмауда иде. Фарук Фарукшин белән бергә эшләгән, аның әшнәсе Карчыганың кинәт юкка чыгуы тикшерү оешмаларына мәсьәләне ачыкларга юлны бикләп тора кебек иде. Сорыйлар, тикшерәләр, Карчыганы эзлиләр иде...

Ә Юлдашевның үз уе, үз карашы, үз планнары. Ул махсус приказ белән төзелештә техника хәвефсезлегенең торышын тикшерү турында комиссия төзеде. Комиссиягә үзәк лаборатория начальнигы Касаткинны, аның урынбасары Кукушкин һәм баш диспетчер Гурскаяларны кертте. Комиссия эшкә керешер алдыннан ул алар белән аерым-аерым сөйләшеп чыкты. Касаткин белән Кукушкин Юлдашевның күптәнге дуслары, иярченнәре булганлыктан, ул аларга турыдан-туры әйтте:

— Башка участокларда артык төпченмәгез. Прицельдә Сафин җитәкчелегендәге объектларны тотыгыз. Пар казаннары цехында техника куркынычсызлыгын саклау аеруча начар хәлдә булса кирәк...

Дина белән ул икенчерәк тонда сөйләште. Хәер, аларның якынлыклары булса да, Юлдашев хатын-кыз алдында саграк кыланырга кирәклеген уйлап эш итте. Аны, барыннан да бигрәк, шул чибәр, сылу хатынның да барыбер «чәчләре озынлыгы» уйландыра иде. Аннары Динаның Сафинга карата уңай фикердә булуын да белә иде Юлдашев. «Әмма, ничек кенә булмасын, үз кеше. Динаны баш диспетчер итүче мин бит. Ул аны гына аңлый торган хатындыр ла...»

Берничә көннән соң Касаткин комиссия исеменнән язылган тикшерү нәтиҗәләре белән Юлдашев кабинетына килде. Эссе көн иде. Баш инженерның өстәлендә, очып китәргә талпынган кош шикелле, выжылдап вентилятор әйләнеп утыра. Касаткин эшләпәсен салып өстәлгә кую белән аңа рәхәт җиләслек килеп бәрелде.

— Ну, кыздыра, Зариф Салихович.

— Яңгыр булыр. Эссе көндә, болытлар куерып, яңгыр ява торган була.— Юлдашев, гадәти сүзләрне бер якка куеп, турыдан-туры тикшерү нәтиҗәләре белән кызыксынды. Ул, Касаткин язмаларын укыгач, чыраена житдилек чыгарып беравык уйланып торган итте дә кәгазьләрне кире үзенә кайтарып бирде:

— СМУ буенча күп җитешсезлекләр тапкансыз. Бу хәтлесе бик әһәмиятле. Тик миңа пар казаннары цехына сез тиешенчә «үтеп керә» алмагансыз. Һич ышанмыйм, анда барысы да ал да гөл булуы мөмкин түгел. Тагын бер кат инәсеннән җебенә кадәр җентекләп тикшерегез. Анда техника куркынычсызлыгын саклау ике аяклап аксый: минем кулда сигналлар бар. Теге кеше дә — фамилиясен онытканмын да инде — шул техника куркынычсызлыгы кагыйдәләренең үтәлмәве аркасында һәлак булды. Яңадан андый хәл кабатланмасын өчен бик кечкенә кимчелекне дә күрә белергә кирәк. Һич тә озакка сузмастан, тагы бер кат тикшерергә туры килер сезгә...

Касаткин Юлдашев кабинетыннан шактый авыр уйлар белән чыкты. Нишләсен, иң олы урындагы түрә кушканны кире кагып булмый. Ул Кукушкин белән киңәште. Анысы аптырап калмады. Ниндидер бик хикмәтле нәрсәне онытып кигкан сыман, иң элек, ике кулы белән кавын шикелле озынча башын тотты:

— Беләсезме, без нәрсәне оныткнбыз?

— Нәрсәне?

— Өстә бер буын тимер идән бик начар беркетелгән иде. Анда, хәтерем ялгышмаса, уналты шөреп урынына биш-алты гына шөреп борылган. Калганнары әллә төшеп беткән, әллә башта ук шулай килделекиттеле генә беркетелгән. Анысын белүче, ай-һай, булыр микән?..

Касаткин үзенең урынбасарына шикләнеп карады. Кукушкин: «Кирәк икән, акны кара дип тә әйтергә мөмкин ич!..» — дип уйлап алды. Һәм башлыгына:

— Ул турыда киметеп түгел, артыгы белән язарга кирәк...— диде.

Касаткин аның тәкъдиме белән килешмәде:

— Ул идән нык тора. Син...

— Нык тора, нык тора,— дип кабатлады Кукушкин.— Башта ул бөтенләй беркетелмәгән дә булса һәм әлеге Фарукшин шуннан егылып төшеп һәлак булган булса, ни әйтерсез...

— Ничек инде, ул идән нык тора ич,— дип кабатлады Касаткин.

— Бер дә нык тормый. Төптәнрәк уйласаң, именно травманың төп сәбәбе шул идәндә булып калырга тиеш. Идәнне соңыннан беркеткәннәрдер.

— Булмас, булмас,— дип каршы килүендә булды Касаткин.

Ләкин Кукушкин бу карашыннан бер карыш та чигенмәде, киресенчә, әйткәннәрен чынга чыгару өчен, анда эшләүче прорабның бик хәйләкәр адәм икәнен, андый-мондый авырлык алдында калган сурәттә «судан коры чыга» торган кеше икәнен әйтте. Касаткин Кукушкинны тыңлый-тыңлый икеләнә калды. Ахырында пар казаннары цехын яңадан барып тикшерергә сүз куештылар. Комиссия члены Гурскаяны да үзләреннән калдырмадылар. Тимер баскычлардан өскә менделәр. Комиссия членнары теге «аз шөрепле» идәнне бу килүләрендә таба алмадылар. Аның барлык уентыкларына да шөрепләр беркетеп «куелган» иде. Прорабтан шул турыда сорагач, ул бер дә гаҗәпләнмичә җавап кайтарды:

— Әйе, сезнең искәртүләрне искә алып, тагы да ныгытып чыктык.

— Ә комиссия килгәнче нишләп ныгытмадыгыз? — дип сорады Касаткин.

Прораб иңбашларын сикертте:

— Шөрепләр башта ук бар иде. Ныгыттык...

— Сез һәммәсенә дә күз-колак булып торырга тиешсез,— диде Касаткин.

— Кая барың да күреп бетерәсең, кырыкмаса кырык төрле эш монда! Миңгә ярылып булмый! — дип, кулларын җәеп салды прораб.

Прораб: «Ай, таптың бәйләнер төен, шул булдымы эш?!» — дигән сыман, күзләрен зур ачып, үзенчә сөрде:

— Ул идәннең дә берниндн куркынычы юк иде. Сезнең күрсәтмәләрне тыңлап, тагы да ныгыттык. Бер ул идәндә генә түгел, күрәсез, башкаларында да яңа шөрепләр бар,— диде.

Уйлый торгач, Касаткин, Кукушкин сүзләрендә хаклык булмый калмаска тиеш, дигән карарга килде.

Менә, бераз җил искәндә сыгылырга торган озын чандыр гәүдәле Касаткин яңадан Юлдашев кабинетында. Юлдашев аны тыңлап тормады, тикшерү нәтиҗәләре язылган кәгазьне кулыннан җәһәт кенә алып укый башлады. Касаткинның йөрәге леп-леп типте: «Тагы кай ягы ярамас, тагы ниләр әйтер икән?»

Укыган саен Юлдашевның чырае яктыра, иреп читләрендә һәм күз кырыйларында якты сызыклар арта барды.

— Булган бу. Шәп! Баштагы приказны алып ташлап, хәзер шушы безнең хөрмәтле комиссия искәрмәләре нигезендә яңа приказ язарга туры килер,— диде Юлдашев.

Ул Касаткин язмаларын тагы бер кат күздән кичерде. Касаткин

Дина Гурскаяның кәгазьгә кул куюдан баш тартуы турында әйтергә өлгергәнче, Юлдашев үзе сорады:

— Ярый, бик ярый. Диспетчер Динага кул куйдырыгыз да сезнең нәтиҗәләр аннан соң үз юлы белән хәрәкәт итәр. Вәкаләтегез уңышлы тәмамланды.

— Гурская белән, бәлки, сез үзегез сөйләшерсез, Зариф Салихович.

— Ә именно нигә мин?

— Ул актка кул куюдан баш тартты.

— Баш тартты? Нигә?

— Ул әйтә: акт тенденциоз төстә язылган, ди. Безнең нәтиҗәләр белән килешми.

Юлдашевның чырае караңгыланып китте. Ирен читләрендә һәм күз кырыйларындагы якты сызыклар сүнеп калган кебек булды. Ул күзләрен кәгазь өстендә тагы бер кат йөгертте: «Пар казаннары цехында техника куркынычсызлыгын саклау аеруча канәгатьләнмәслек хәлдә тора. Югарыда эшләүчеләр өчен куелган мәйданда тимер идәннәрнең бик начар ныгытылган урыннары бар. Без тикшерү үткәргәндә бер идән (шөрепләре булмау яки бик аз булу сәбәпле) шундый куркыныч хәлдә иде. Башта ныгытылмаган шул идән шуып китеп, обмуровщик Фаруктшин шуннан егылып төшеп һәлак булган дигән нәтиҗә ясарга тулы нигез бар. Идәнне бәхетсезлек булгач кына ныгытып куйганнар. Бу, бер яктан, турыдан-туры прораб гаебе булса...»

Хәзер инде Юлдашев өчен хәл ачыкланды. «Менә ул нәрсәдән өреккән. Комиссия составына аны кертеп ялгыш иттем. Бәлки, Дина кул куярлык итеп, актны икенче редакциядәрәк язарга кирәктер...»

Юлдашев бу уйларын Касаткинга җәеп салмады, артык шәрәләнү дә ярамый. Ләкин, ничек кенә булмасын, комиссия файдалы эш башкарган кебек тоелды аңа. Ул Касаткинга тик бер генә сүз әйтте:

— Диспетчерның кул кую-куймавы әллә ни әһәмиятле түгел. Ярый, актларны миндә калдырыгыз, кул куючы аннан башка да табылыр...

Касаткин чыгып киткәч, Юлдашев беркадәр вакыт ишекле-түрле киләп сарып йөрде. Ничегрәк булып чыга соң әле бу? Соңгы вакытларда Дина үзгәрә бара түгелме? Бәлки, аңа яшь ир кирәктер. Бәлки, ул Сафинга гашыйктыр... Юлдашев авыз эченнән: «Хатын-кызга ышану — суга таяну кебегрәк шул ул»,— дип куйды.

Динаның актка кул куймавы Юлдашевны нихәтле борчымасын, аңа карап кына күтәрелеп бәрелеп булмый бит инде. Алар болай да сирәк очрашалар... Ә хәзер аның иң ышанычлы кешеләреннән берсенең «читкә тайпылуы», ни әйтсәң дә, күңелле хәл түгел. Мәгәр Динаны кул куярга өндәү, аңа ялыну яки аның алдында тез чүгү баш инженер эше түгел! Юлдашев бу яшь һәм кайнар хатынның холкын азмы-күпме белә, аны башта ук ваз кичкән эшенә кире күндерү, бердән, бик кыен булачагын, икенчедән, Юлдашевка карата хатынның карашы үзгәрәчәген уена китереп, ул бу турыда сүз ачмаска булды. Инде актка кул куярга өченче кеше табылмаса, ике имза җитмәгәнмени? Юлдашев әнә шулай уй йөртте. Һәм аның Дина белән күрешеп, бу турыда сөйләшү теләге башкача уянмады.

## 9

Кинәттән генә Никитинның саулыгы начарланып китте. Врачлар аңа, ревматизмының көчәюе сәбәпле, санаторийга барып дәваланырга киңәш иттеләр. Гомумән, ул соңгы вакытта, авыруым болай да узар әле дип уйлап, үз-үзе белән бик нык тартышып йөрде. Эш ул дигәнчә барып чыкмаслыгын аңлагач, врачлар тәкъдиме белән ризалашырга мәҗбүр булды. Төзелеш башлыгы эшләре вакытлыча Юлдашевка йөкләтелде. Никитинны озаткан чакта, Юлдашев бик җылы сүзләр белән аның тиз-

рәк савыгып кайтуын теләп калды. Инде ул киткәч, өстеннән тау төшкән кебек җиңел сулап куйды. Менә хәзер ана «бөтен фронт буйлап һөҗүм» итәр өчен юллар ачылды кебек. Иң элек ул партком секретареның «кыллярын» тартып карады. Аның белән читләтеп кенә, дипломатик төстә гәпләште. Бигрәк тә соңгы көннәрдә Сабиров аңа ошамый, читләшкәннән-читләшә бара иде. Барыннан да элек ул аны Сафинның дусты, аның белән бергә ашап-эчеп йөрүче итеп карый иде.

Җәйге талгын җил исеп торган, күктә зәңгәр болытлар йөзгән көннәрнең берсендә райүзәктәге ике катлы ак таш йорт алдына ялтырап торган яңа кара җиңел машина килеп туктады. Юлдашев, гадәтендә булмаганча, машинадан җиңел генә төште дә шул бинага таба юнәлде. Телефоннан сөйләшенгәнчә, аны райкомның икенче секретаре Гусев көтеп утыра иде инде. Җылы гына кул биреп исәнләштеләр. Юлдашев өстәл каршындагы йомшак креслога барып утырды. Кабинет эче салкынча. Тәрәзә каршындагы бакчадан ачык җилләткеч аша саф һава, яфраклар исе кереп тора. Иң элек бер-берсенең исәнлеген, гаилә, бала-чагалары турында сораштылар.

Юлдашев, райкомның пленум члены буларак, теге-бу мәсьәлә белән йомышы төшкәндә күбрәк икенче секретарьга мөрәҗәгать итәргә ярата, аларның ничектер характерлары да бер-берсенә якын кебек. Аннары, икенче секретарьның промышленность мәсьәләләре буенча турыдантуры җитәкчелек итүе аңа бик тә ошый. Җитмәсә, берничә мәртәбә бер-берсен кунакка чакырышкан чаклары булды. Алдагы көннәрдә аларның гади танышлар гына булып калмыйча, чын-чыннан дусланып китүләре дә бик ихтимал кебек. Гусев Юлдашевның Сафинга карашы бик шәп булмавын да үзенең сөйләве буенча азмы-күпме белә иде. Ләкин Юлдашев ни өчен килүе турында шундук әйтергә ашыкмады. Кирәгеннән артык калын иякле, калын җилкәле, тыныч карашлы бу кеше Юлдашевка беренче караштук ошаган иде. Һәм шуннан соң ул үзе башлап хатыны белән икесен парлап кунакка чакырды. Болай якыннан танышкач, тагы да күңеллерәк булып китте. Сүзләре дә килеште, фикерләре дә бер яккарак ятты, хәтта яраткан җырлары да бер үк төсле булып чыкты. Юлдашев, шуларны уеннан кичереп, теге-бу турыда сөйләшкәли торды. Ә үзе: «Бу дус кеше бер вакытта да артык төпченмәс, төзелешкә килсә дә, кайберәүләр кебек үзен артык белдекле итеп күрсәтергә тырышмас, юкка-барга тылкышмас, башын кыңгыр салыр да тыңлый бирер. Син әйткәннәргә каршы төшмәс. Моның белән килешерге була. Менә дигән кеше, менә дигән җитәкче...» Ул аңа әйтергә күптән җыенып та моңарчы ничектер форсат тапмый йөрде. Җәйнен матурлана баруы турында гәп кузгатты, киләсе ял көнен бергә-бергә уздырырга кирәклеген әйтте. Гусев, аның бу тәкъдиме белән алдан ук килешеп, үз чиратында сүз кушты:

— Кама буена дисез, Зариф Салихович, мин ике куллап риза. Табигать кочагы... Наратлар...

— Китәргә җыенмыйсыздыр бит? — дип, иңбашларын селкетеп алды Юлдашев.

— Юк,— диде Гусев.— Кая китү! Мин дә, сезнең кебек, бу якларда яңа кеше бит әле. Китү дигәннән,— Гусев беренче секретарь кабинеты ягына ияге белән ымлап күрсәтте: — Ул китәр, ахры.

— Беренче секретарьмы?

— Әйе.— Гусев, күзләрен кыса төшеп, ишек ягына карап алды да пышылдап диярлек әйтте: — Аны күтәрергә уйлыйлар шикелле, обкомның үзенә эшкә кодалыйлар.

— Нинди эшкә?

— Бүлек мөдиренмә дә кем түгелдер, аннан югарырак та куюлары мөмкин. Тик аның үзенең бик китәсе килми бугай.

— Ә монда беренче булып сез калачаксызмы, Федор Кузьмич? — дип сорады Юлдашев.

Гусев җавап кайтарырга ашыкмады. Беравык, уйга бирелгән кебек, тын утырды.

— Хәзергә әйтүе кыен. Беренчедән, ул әле китмәгән, икенчедән, кемне сайлыйлар бит. Ә үземә килгәндә, минем өчен барыбер...

Моңа каршы Юлдашевның: «Беренче беренче инде ул. Сез аның урынына калсагыз, төзелеш өчен шәбрәк булыр иде»,— дип әйтәсе килде. Ләкин, «тумаган колынның билен сындырудан куркып», уен тышка чыгармады.

Юлдашев секретарьның кылларын тагы да нуграк тартып карарга уйлады. Беренче секретарь районда юк. Ә мәнә күпкәме? Шул турыда Гусевка сорау бирүгә, тегесе елмаеп куйды:

— Аны ничек тә яңа эшкә күчәргә ризалатырлар сыман. Обком агайлары көндерми калмаслар, әлбәттә. Монда кайтса да, әле тиз кайтмас. Кайткан сурәттә дә эш тапшырырга гына кайтыр дип уйлыйм. Пленум җыярга туры килер...

Гусев сүзләре нигәдер алдан ук Юлдашев күңелендә ниндидер яшерен тантана уятты, хәтта төсе дә яктырып китте. Ул шунда кайнарланып сорап куйды:

— Вакытыгызны күп алмаммы? Минем бер чуалчыграк мәсьәлә турында сөйләшәсем бар иде...

Гусев урындыгына җайлабрак утырды, нигәдер беләгендәге сәгатенә күз салды һәм тупланыбрак Юлдашевка карады:

— Вакыт бар. Әле үзем дә сезнең якка барып чыгарга ниятләп тора идем. Болай үзегез килгәч, минем баруның кирәге калмыйдыр. Я, сөйләгез, Зариф Салихович.

Юлдашев йомшак креслога бөтенләй күмелеп утырган җиреннән аз гына калкынып куйды. Яшел плюш җәелгән өстәлгә терсәкләре белән таянды, күптән әйтергә теләгәнен башлап җибәрде:

— Сүз Сафин турында бара.

— Сезнең урынбасарыгыз, төзү-монтаж идарәсе начальнигы?

— Әйе, Федор Кузьмич. Аның тупас чатаклыклары турында сез азмы-күпме беләсез инде... Ә минем үземә килгәндә, Никитинны узып булмый бит... Ярый, мин бүгенгесе көндә вакытлыча төзелеш начальнигы эшен дә алып барам икән, Сафинга карата партия сызыгы буенча каты чара күрелергә тиеш дип уйлыйм.

— Катырак бәрелмисезме икән? Фактлар?.. Нигез?..

— Фактлар бар! — дип катгый рәвештә каршы төште Юлдашев.— Менә алар.— Ул язу машинасында басылган унбиш-егерме бит чамасындагы документны дерматин папкадан алып Гусевка тапшырды. Гусев язуларның баштагы берничә битен укыгач та, калганын Юлдашевның сөйләп бирүен үтенде. Юлдашев, яхшы әзерләнгән гаепләүче кебек, бер-бер артлы тезеп китте:

— Пар казаннары цехында кеше үлгән өчен кем җавап бирергә тиеш? Бу цех төзелеше белән турыдан-туры җитәкчелек итүче Сафин, минемчә. Техника хәвефсезлеген саклау кагыйдәләренең тупас рәвештә бозылуына кем юл куйган? Шул ук Сафин. Аннан ары, үз хатынын ташлап, яшь кызлар артыннан чабып йөрүче кеше — кем дип беләсез? Шул ук Сафин. Тупаслык... Үз кул астында эшләүчеләргә кул күтәрү...

Юлдашев, бу юлы ни өчендер, баштагы дерматин тышлы папканы ачмады. Күен кесәсеннән яхшы ук таушалган конверт чыгарды, Гусевка шунын эчтәлеген генә сөйләде. Аннары: «Үзегез нәтиҗә ясый аласыз хәзер»,— дип сораулы күзләре белән секретарьга карады.

Гусев, кинәт кенә урындыгыннан торып, кабинет буйлап йөренеп килде. Юлдашев, аның бу йөрешеннән ниндирәк нәтиҗә ясарга белмичә, аптырап калды. Гусев көтелмәгәндә сорый куйды:

— Мин сезне дикъкать белән тыңладым, Зариф Салихович, ләкин... Ләкин сезнең бит партоешма бар, аның секретаре бар. Бу мәсьәләләрне иң башлап партком секретаре иптәш Сабиров күтәреп чыгарга тиеш бит. Сез райкомга килгәнче аның белән сөйләшмәдегезме?

Мәсьәләнең катлаулана барачагына шиге уянып, Юлдашев, җепнең очын югалтмаска тырышып, болай диде:

— Партком секретаре белән сөйләшеп тә торасы юк!

— Нигә?

— Алар әшнәләр.

— Сабиров белән Сафин?

— Әйе, Федор Кузьмич. Партком секретаре аның һәр адымын хуплый.

Юлдашев та торып басты:

— Минемчә, Сафин, пленум члены буларак, үзенең һәр хәрәкәте, һәр адымы өчен иң элек райком алдында җавап бирергә тиеш буладыр.

— Анысы шулай,— дип килеште Гусев.— Аның турындагы мәсьәлә каралганда партком секретаре барыбер читтә кала алмый. Бу чаклысы да бәхәссез. Безгә аның фикерен белергә кирәк.

— Ул чаклысы сезнең эш,— дип килеште Юлдашев.— Ләкин миңа шунысы бик ачык: Сабиров аңа каршы бер генә сүз дә әйтмәс дисәм дә хата булмастыр. Алар икесе бер багана төбен таптыйлар. Безнең партком секретаре шәхси дуслыкны өстенрәк куярга ярата, Федор Кузьмич...

Гусев, уйланган кебек, бер ноктага карап торды да, кашларын җыерып, янә телгә килде:

— Коллективта шундый зур күңелсезлекләр булгач, билгеле, түзеп торып булмый. Сизгерлек күрсәткән өчен сезгә рәхмәт, Зариф Салихович. Мәсьәләне җитди рәвештә тикшерергә кирәк булыр...

Гусев кайнар эздән эшкә тотынды. Иң элек ул төзелеш парткомы секретаре Сабировны чакыртып сөйләште. Билгеле, Сабиров Юлдашевның райкомда булганын белми иде. Ләкин партком секретареның һәр хәл, һәр вакыйга турында үз фикере бар иде. Гусев әйткәннәрне ул әкрен генә кире кага торды. Гусев сүз барышында: «Сез шәхси дуслык мөнәсәбәтләрен гомуми эш, гомуми бурыч максатларыннан өстен куясыз»,— дип әйтергә никтер җөрьәт итмәде. Әмма шул мәгънәне читләтебрәк әйтми калмады.

Икенче секретарь белән сөйләшкәндә Солтан Сабировның кашлары җыерылды, тез буыннары калтырап китте, гасабилыгы һәм киеренкелеге артты. Ул, Васил Сафинның гаять зур, җаваплы эш алып барганын, төзелештә иң кайнар, хәлиткеч көннәр җиткәнен уеннан кичереп, Гусевка ашыкмаска, бик үлчәп эш итәргә кирәклеге турында киңәш итеп әйтте. Мондый тәкъдимне ишеткәч, Гусев, алай бик күтәрелеп бәрелмәсә дә, шактый кайнарлана төште. Алай да гадәти тактны саклаган хәлдә, үз фикерен һаман куерта барды:

— Мин сезне аңламыйм, иптәш Сабиров. Сез ниндидер сәбәпләр табасыз. Шундый җитди мәсьәләгә объективрак карарга кирәк, минемчә. Райком кулында җитди сигналлар бар икән, безнең аны читләтеп үтәргә яки томалап калдырырга хакыбыз юк. Кешенең олы урында утыруына карап кына аңа барысын да гафу итеп булмый ич. Һәр нәрсәнең чиге бар...

— Алайса, бик гадел тикшерергә кирәк,— диде Сабиров.

Гусевның чырае аз гына яктыра төшкәч кебек булды.

— Ниһаять, уртак тел таптык. Мин дә шул турыда сөйлим ләбаса. Димәк, безгә сигнал килгән икән, тикшерергә кирәк. Аннан күз күрер.— Ул уйланыбрак туктап торды, иягең сыпырып алды да бүленгән уйларын ялгап китте: — Моның өстенә тагы башка мәсьәләләр дә бар бит әле. Әйтик, техника куркынычсызлыгы кагыйдәләрен саклау ничек? Бу турыда югары партия оешмалары әледән-әле кисәтеп торалар безне. Аннан,

житәкченең эшчеләр арасында үз-үзен тотуы ничек? Ул мораль яктан ниндирәк кеше?..

Секретарь янынннан авыр уйлар, начар кәеф белән чыкты Сабиров. Чөнки ул ыргытылган ташның кемгә төбәлгәнен бик ачык төшенә иде.

Гусев төзелеш парткомы секретарен чакыртып сөйләшү белән генә чикләнеп калмады, үзе әйтмешли, хәрәкәтне киң җәелдерде. Ул өстәлнең бер читендәге ак төймәгә бармагы белән басуга, пөхтә киенгән, чәчен артка яткырып тараган бүлек мөдире һәм һәрвакыт диярлек чыраенда елмаю сүнми торган инструктор кабинетка керделәр.

Күрсәтмәләр. Таләпләр. Пошыну хисләре...

## 10

Ә тормыш дигәненнең үз юлы, үз кануннары...

Көннәрдән бер көнне Главкадан ике кеше килеп төште...

Юлдашев бу араларда, әллә ничек, бөтенләй танымаслык булып үзгәреп китте. Хәзер инде, күпкәме, азгамы, төзелеш «дилбегә»се аның үз кулында. Ул озатканда Никитинның саргылт йөзенә, хәлсез янган күзләренә теләктәшлек белән караган иде. Ул минутларда күңелендә ничектер аны кызгану хисләре дә кузгалган булды. Әмма, башлык китеп берничә көн узуга, мондый хисләр иртәнге томан кебек таралып та бетте. Никитин Юлдашевка аның көнен каплап торган кара болыт кебек тоела башлады. Бу «болыт»ны узып ул эш итә алмый шул әлегә. Бәлки киләчәк аның ягыннан торып елмаер. Вакытлыча башлык урынында калгач, мондый уй-тойгылар бик еш баш калкыта башлады аның күңелендә.

Юлдашев Гусев кабинетында булганнан бирле әле артык күп вакыт узмаган иде. Әмма ул кузгаткан «хәзерлек» бер туктамый барды. Юлдашев, юк йомышны бар итеп булса да, райкомга шалтырата торды, һәм икенче секретарьның йомшак, ягымлы тавыш белән сөйләшүе аның күңеленә сары май кебек йомшак ятты.

Ишектән ят кешеләр килеп кергәндә Юлдашев шундыйрак уйлар кичереп утыра иде. Алдан кергәне — озын гәүдәле, чәчләре агара башлаган бер кеше. Калын күзлекләре өстәл артыннан чыккан Юлдашевка текәлеп, сөзеп карады.

— Исәнмесез, Геннадий Антонович,— дип, кулын сузды аңа каршы Юлдашев.— Кайчан килдегез?

— Әле килеп төшеп урнашу гына, иптәш Юлдашев.

— Бик вакытлы килдегез, бик вакытлы,— дип кабатлады Юлдашев.

Баш инженер белән күрешкәннән соң, тып-тын торганы, гәүдәгә Геннадий Антоновичтан шактый кайтыш, ачрак яңаклы, әмма күзләре ниндидер бер үткенлек белән янып торганы, тәрәзә буенарак барып утырды да, әле үзенең аяк очларына карап, әле болай да бик тәртипле булган чәчләрен рәтләп, ике танышның сөйләшүләрен тынлый бирде.

Юлдашев Фирсовның Главкада зур һәм җаваплы бүлектә өлкән инженер икәнен белә, төзелеш йомышлары белән аңа берничә мәртәбә мөрәҗәгать итәргә туры килгәне дә бар иде. Аңа калса, бу кеше ул күрми торган ике-өч ел эчендә хәтсез олыгайган, беркадәр төс ташлаган сыман күренде. Бу картаю дигәнне берәү дә читләтеп уза алмый, күрәсең. Фирсовның битендә күз читләрендәге җыерчыклар элеккерәк күрешүләрдә юк иде кебек.

Фирсов Юлдашевны теге какчарак иптәше белән дә таныштырырга житеште:

— Безнең бүлекнең төп йөкне тартучы яшь инженерларыннан Зотовны бәлки белмисездер дә әле. Хәзер һәммәбезгә бергәләп эшләргә туры килер.

Зотов Юлдашевка тагы бер кат баш иеп күрешкәндәй итте. Ул сызылып киткән куе кара мыеклы иптәш иде. Ләкин анда-санда: «Әйе.

Шулай. Да»,—дип раслаудан башка, ул кеше сүзгә катнашмады диярлек.

Фирсов сүз уңаеннанмы яки башка сәбәп беләнме, Никитин турында сорашкач, Юлдашев әсәренә калды. Ул аның саулыгы бик үк яхшы булмау сәбәпле дәваланырга киткәнен әйтте.

Шуннан соң Главка инженеры төзелеш хәлләре белән кызыксынып сораша башлады. Сүз уңаенда Юлдашев Главка вәкилләре төзелешкә бик тиз китәргә килмәгәннәрдер дип уйлап алды. Тик ул һаман да аларның нинди максат белән килүләрен төшенеп җиткерә алмады. Кем белә... Бәлки беренче блок эшли башлаганчы биредә калырлар, бәлки ул җибәргән шикаятьне тикшерергә килгәннәрдер. Бәлки һәр икесен дә бергә эшләрләр...

Сүз капчыгы бушабрак калган бер арада Юлдашев Мәскәү кунакларының ничек урнашуларын сорашты. Фирсов, бик канәгать төс белән, ике кешелек уңайлы, әйбәт бүлмәгә урнашуларын әйтте. Кунаклар гостиница белән әле рәтләп танышырга да өлгермәгәннәр икән. Электр станциясенең беренче чиратын тапшыруга хәзерләү уңае белән, шефлар, төрле шәһәрләрдән төзелешкә электр җиһазлары, катлаулы механизмнар җибәргән төрле завод-фабрикаларның вәкилләре киләчәген күздә тотып, биш катлы гостиницаны бик тиз вакыт эчендә өлгерттеләр. Бары тик зур шәһәрләрдә генә очрый торган мондый тизлеккә Фирсов, таң калгандай, башын чайкап куйды. Аннары ул гостиницаны Мәскәү йортларына ошатуын да әйтте.

— ВДНХ га килүчеләр Ярославский урамындагы гостиницаларны бик яратып китәләр. Анда бит, беләсездер, ике дистәдән артык бина бер гостиница тәшкил итә. Әсрма шунда — алар лифтлы. Биредә лифт юк. Сезнеке шул гостиница биналарына бик охшаган. Яхшы җигештергәнсез. Беркадәр бизәкләре дә бар.

Фирсов, гостиницада буфет барын белгәч, бигрәк куанды. Салкын, җылы сулары үзендә, ваннасы бар. Тагы ни кирәк? Үзәк шәһәрләр белән провинция арасында аерма кими баруын һәр адымда күрү куандыра иде аны.

Юлдашев, алай-болай кирәк булыр дип, кунаклар тукталган бүлмәнең номерын да язып алды. Фирсовка диспетчерлыкның телефон номерын да әйтте. Кирәк булганда шунда шалтыратып, машина сорарга мөмкин икәнен искәртеп куйды. Кунаклар чыгып киткәч, ул берничә тапкыр ишекле-түрле әйләнеп килде дә янә үзенең йомшак урындыгына чумды. Ул иң әлек диспетчерлыкка шалтыратты. Мәскәүдән бик зур кешеләр килгәнен һәм алар сорагганда һәркайчан җиңел машина җибәрергә кирәк икәнен боерып әйтте. Аннары үзенең чираттагы эшләренә керешге. Тик нигәдер килүчеләр аның күңел тынычлыгын качырган кебек булдылар. Нигә соң алар, дөресрәге, Геннадий Антонович Фирсов, үзәккә ул җибәргән шикаять турында ләм-мим кузгатмады?

Хәер, вакытлыча гына булса да, үзе хуҗа булып калгач, «индустриаль ысул»ны юкка чыгару уе аның башында бертуктаусыз әйләнеп торды. Тик мәсьәләгә кай почмактан, кай яклабрак һәм кайчан тотынырга гына җөрьәт итәрлек куәт-көч тапмады үзендә. Юлдашев көн-төн эш кайнаган пар казаннары цехына ике-өч тапкыр сугылды. Чыннан да, эш җырлап-гөжләп бара иде. Ә аның нәтиҗәсе ничек булыр? Мастерларга, бригадирларга ул үзенең каршылыклы фикерләрен ничек ачып салсын? Ул күп уйлады, күп баш ватты. Ул үзенең исәпләрен гамәлгә ашыру өчен җирлек, нигез эзләп интекте. Әгәр ул, аның уенча, шул нигезсез индустриаль ысулны туктатуны көн тәртибенә куйса... Кыскасы, Никитин приказын юкка чыгарса?.. «Юк, булмый, булмый,— дип кулларын селтәде Юлдашев.— Менә беркем дә тыңламаячак. Ахмак хәлендә калачакмын ул чагында. Ә сынаулар...» Алда торган гидравлик сынаулар аның котын ала иде. Җитмәсә, республика газетасының үз

хәбәрчесе шул ысул, аны гамәлгә ашыручылар турында гел язгалап тора. Татарчадан күчереп, үзәк газеталар да бу турыда материаллар урнаштыра. Юлдашев, шуларның һәммәсен дә исәпкә алып, әлегә тын гына йөрергә, аңа-моңа борын тыкмаска карар кылды. Әле Мәскәү бар. Мәскәү үзенә кергән сигналга колак салмый калмас. Дөреслек аның ягында булырга тиеш.

Гостиница бинасының вакытыннан алда житкерелүе үзен бик тиз аклады. Атна-ун көн эчендә шефлар, күзәтүчеләр бер-бер артлы килеп төштеләр һәм күп бүлмәләрдә шау-гөр килеп яши башладылар. Главка вәкиле Фирсовның килүе Юлдашевны бер яктан куандырса, икенче яктан шактый куркуга салды. Куандырганы — Фирсовның тәэмннат буенча да, башка техник яктан авырлык килеп туганда да кыенлыкны тиз җиңеп, ерып чыгуы иде. Ул, үзәк учреждение вәкиле буларак, кирәкле шәһәргә, тиешле оешмага телеграмма суга яки телефоннан шалтырата. Фирсов сөйләшкәннән соң күп тә үтми, кирәкле детальләр махсус контейнерлар белән килеп тә төшә...

Әле шушы көннәрдә Фирсов Юлдашев кабинетыннан Мәскәү белән сөйләште. Бик зур бер мәсьәләне хәл итәргә кирәк иде. Фирсов бу мәсьәләне бүтәннәр белән хәл кыла алмагач, министр урынбасарына шалтыратты. Аны туры китерә алмаса да, тугарылып, каушап калмады, төн уртасында (бу вакытта телефоннан сөйләшүчеләр азая) министр урынбасарының квартирына шалтыратты. Һәм бик кыен мәсьәләне уңышлы хәл итәргә ачкыч тапты...

Үзенең туып килүен сәгатьләп сиздергән яшь гигантны тизрәк аякка бастыру өчен кайнар тартыш, тынгысыз хезмәт ташкыны кайнап торган көннәр сизелми генә үтә бирә. Төп эшләренең оясы булган пар казаннары цехында, машиналар залында һәм идарә иту биналарында хезмәт белән көннәр төнгә ялгана, эш һәммәсен кызулый, куа, ашыктыра иде. Шундый көннәрнең берсендә, эш бетәр алдыннан, Фирсов, гадәтенчә, салмак кына адымнар белән Юлдашев кабинетына килеп керде. Производствога кагылышлы байтак кына мәсьәләләр турында гәпләштеләр дә беразга тынып калдылар. Әмма Фирсов үзенең эшчеләргә соклануын эчендә генә биклəп кала алмады:

— Алтын кешеләр эшли сездә! — дип башлап китте ул.— Зиннур Гафиятуллин, Фиргали Гатин кебекләр белән таулар актарырга була. Шәп кешеләр!

Аның сүзләрен Юлдашев рыясыз гына елмаеп җөпләп торган иттe. Бакса, Фирсов әлеге дә баягы «индустриаль ысул»ны мактарга күчте. Юлдашевның чәчләре үрә торды.

— Инженер акылы, шунарга өстәп, батырлар колачы бар сезнең ул кешеләрдә! Пар казаннарын җыю һәм монтажлау срогын өч тапкыр кыскарту — бу бит здорово!

Шуларны ишеткәч инде, Юлдашев аның сүзен куәтләп тә, каршы килеп тә берни әйтә алмады, шулай да үзенең шикләнүен сиздереп куйды:

— Хәзергә җырлап бара кебек тә бит, Геннадий Антонович, соңгарак нишләр? Чебешне көз көне генә саныйлар...

— Мин сезне аңламыйм, Зариф Салихович,— диде Фирсов.

Башын бер якка кыйгайта төшеп утырган Юлдашев сүзенә ачыклык кертергә тырышты:

— Гидравлик сынаулар ничек үтәр бит әле!

— Анда да хәвеф булмас! Эшнең сыйфат якларын Сафин бик нык тикшереп тора. Шундый ярдәмчеләрегез барында сезгә ике кулны кесәгә тыгып кына йөрерлек,— дип көлде Фирсов.

Юлдашев җавап кайтармады. Аның бөтен тәне буйлап ниндидер бер салкын, бер кайнар дулкын бәргән калтырау йөгереп үтте, йөрәге чәнчеп куйды.

## II

Июль — җәйнең егет чагы, сафлыкка күмелгән чагы. Бу рәхәтлекне берәүләр туйганчы татыйлар, икенче берәүләр күреп кенә калалар...

Васил, кичтән озак кына йокыга китә алмыйча, шундыйрак уйларга күмелеп яткан иде. Аннары күзләре бер йомылгач, берсен дә белмәде, басылып, изрәп йокыга талды. Иртәгесен керфекләре ачылу белән, гадәтенчә, урыныннан сикереп торды да тиз генә радиоалгычның ак төймәсенә басты һәм физзарядка ясарга кереште. Җәйнен рәхәте! Ачык тәрәзәдән зәңгәр күзле июль иртәсе карый. Аны күреп тә, карап та туярлык түгел. Тик менә... Гөлзадәне очрата алырмы? Нигә кичтән хәбәрләшеп куймады да нигә алданрак кайгыртмады. Менә хәзер үз-үзенне алдап йөр инде: я очрар, я юк... Иртәнге чәйдән соң, Васил шундыйрак уйлар белән телефон трубкасына үрелде. Ләкин трубканы алыр-алмас янә кире чигенде... Бераздан ул кызлар торагына китте. Василның баштагы пошынуы нигезле булып чыкты: өч катлы ак йорт тып-тын; коридорларда әрле-бирле йөрүчеләр дә күренми. Бары тик таныш вахтер хатын гына ялкау бер кыяфәттә көнбагыш ярып утыра иде. Ул Василның соравына каршы:

— Мондый вакытта тотарсың кызларны булмәдә...— дип, авыз читен кыйшайтып кына җавап кайтарды. Ул инде Василның кем янына килүен сизенә иде, мөгаен. Вахтер хатын аңа мәзәгрәк итеп тагын бер карап алды да әлеге шул көнбагыш яруын белде. Тик Васил борылып китеп барганда гына:

— Җиләккә китмәгән булсалар, кичтән шулай сүләнгәннәр ие,— дип әйтеп калды.

Бүген поселок ял итә. Урамнар тын. Бакчалар матур яшеллеккә күмелгән, куаклыклар тигез булып калкынып киләләр! Берән-сәрән дә, гаиләләре һәм танышлары белән дә су буйларына, табигать кочагына сәфәр кылучылар әледән-әле очрый торды. Шундый төркемнәрнең берсе белән ул да елга буена юнәлде. Җәйге күкнең иртәнге зәңгәрлеге аз гына да кимеми, әйтерсең, сафлыкка сафлык өстәлә генә бара. Ләкин, эзләгән кешесе күренмәгәч, тирә-яктагы матурлык та, яшь авазлар да тоныклана, сүрелә барган кебек тоелды аңа. Бүтән чакларда Тын елга буеның ямьлелегенә сокланып бетә алмаган Васил ничектер бу күренешләр эчендә югалыбрак калган кебек булды.

Су коену урыннары тулысынча җиһазланып бетмәгән әле, шулай да кешеләр ял итсен өчен байтагы эшләнгән инде: яр буйларына ак ком җәелгән, яшел таллыклар арасында сәүдә лареклары тезелеп киткән, урыны-урыны белән ак палаткалар да күренә. Ләкин, кирәкле кешесе күренмәгәч, Василның берсенә дә күңеле бармады, берсенә дә аягы тартмады. Яр буйларында һәммәсе буталган диярсең — ир-аты, хатын-кызы баштан-аяк чишенеп ташлаганнар да, трусиклардан, коену костюмнарыннан һәм лифчикләрдән генә калып, кайсы кояшта кызына, кайсы зонтик белән күләгә ясап ял итә, ә күпләр су коеналар. Әйтерсең, бер атауга җыелган кошлар. Василның күзләре бер төркемнән икенчесенә күчте.

Кайда булыр икән ул?

Бая вахтер апа дөрес әйткәндер бәлки — иптәшләре белән җиләккә киткәндер.

Васил таныш дежурныйдан өр-яңа көймә алды да сулыкның аргы ягына ашыкты. Күптән көймәгә утырганы да, ишкәк ишкәне дә юк иде. Бер хәтле бизелгән икән, шулай да ишкәкләр чапыл-чопыл суга тигән саен катырак һәм куәтлерәк каералар иде. Бу каршы як ярда җиләкчеләрнең үз сукмаклары бар. Васил, шуны күздә тотып, яр буйлатып тагы да берәр километр чамасы өскә күтәрелде. Су бөтенләй акмый кебек.

Тын. Су өсте биниһая зур көзгемени — ичмасам бер генә җыерчык булса икән!

Нигә әле бу болай? Гөлзадә турында аның беркайчан да бу кадәр якын итеп, үз итеп уйлаганы юк иде шикелле. Баксаң, аны күрмичә тора алмый булып чыга түгелме соң? «Юксыну... Нигә соң күзгә ак-кара күренми башлады әле минем? Әллә берәрсе «сихерләдеме» югыйсә?» Васил йөрәгенә тынгы бирми торган уйларыннан арынырга тырышты. Ул шунда әле күптән түгел генә кечкенә Ринаты әйткән сүзләрне исенә төшерде. Ни диде әле «усал малай»? «Әти, тетя Галя минем әни булсын»,— диде. Нигә әле ул әтисенең күзенә карап шулай дип әйтте? Әллә берәр төрле эчке сиземләү бармы сабыйның күңелендә?

Уйларыннан арына алмаган хәлдә, Васил аргы якка да чыгып житте. Шунда гына ул Гөлзадә белән бергә эшләүче Лиза исемле кызны күреп, күз аллары яктырып киткән төсле булды. Көймәдә урын житмәү сәбәпле, Гөлзадә бу якка чыга алмаган икән. Шуннан соң Васил, алдынаартына карамастан, кире яктагы ярга ашыкты. Бу якка чыгып житканче үк ул, баш түбәсенә көлтәләндереп куйган чәчләреннән һәм сыек зәңгәр күлмәгеннән Гөлзадәне танып алды. Аның янында үзе белән бер бүлмәдә торучы дуслары Диләрә, Людалар да бар иде. Васил көймәне яр буендагы басмага кадәр китереп туктатты да үзе сикереп ярга чыкты. Көймә чылбырын басма казыгына урарга өлгермәде, төрле яктан тавышлар ишетелде:

— Васил Закирович, теге якка чыкмыйсызмы? Безне дә алсагыз икән.

— Була ул. Сыйган хәтле утырырсыз.

Гөлзадәнең тавышы ишетелмәсә дә, төсендәге елмаю яктысы, ирен читләрендә уйнап торган нурлар, күзләрендәге терелек аның да Василга таныш хисләр белән янганын күрсәтә иде шикелле. Утырыштылар. Көлешә-шаулаша, җырлаша-җырлаша аръякка чыгып житүләрен дә сизми калдылар.

Шактый киң юл аларны эчкәрәк алып керде. Усаклар. Каенлык. Урман эчендә көн эссесе сизелми, таманча бер рәхәтлек. Сулышлар үз алдына киңәеп китте, тәннәргә җылылык йөгерде. Аланлыкка чыккач, бер-бер артлы жиргә иелделәр. Гөлзадә башкалардан алгарак киткән Диләрәгә кычкырып әйтте:

— Җиләк бармы?

— Бар! — дип кычкырып җавап кайтарды тегесе.

— Күпме?

— Бик күп. Тик табып кына булмый...

Берничә минуттан соң, аланлыкка килеп тоташкан таррак куентыкка житкәч, җиләкчеләр таралышып-сибелешеп тә беттеләр. Баштарак көлешкән, шаярышып сүз алышкан авазлар ишетелеп торды. Соңра алар да тынычланды һәм бер мәлне бөтенләй тынып калды. Гөлзадә Василга бер якынаеп, бер ерагаеп, уртача зурлыктагы яшькелт мискигә җиләк сала иде. Ниһаять, ул Василны үз янына чакырды:

— Оясына килеп чыктым җиләкнең, күзенә. Бирегә килегез, Васил абый, зерә дә күп...

Кыз, чыннан да, дөресен әйткән икән. Хуш ис бөркеп торган сырлы яфраклар арасыннан кызарып торган җиләкләр күрде Васил. Башта ул учына җыйган җиләкләрне авызына озата барган иде. Гөлзадәнең яртылаш җиләк белән тулган мискиен күргәч, бераз уңайсызлана калды. Аннары кызарып пешкән жир җиләкләрен газетадан өчпочмаклап ясаган савытка жыя башлады. Ул да булмады, Васил бер тумгәккә абынып, азмы-күпме җыйган җиләген дә түкте. Яшел яфраклар арасына «посып» өлгерә алмаган җиләкләрне авызына алып капты. Ә Гөлзадәгә нәрсә? Кычкырып көлүен генә белде ул... Икесенә дә бил язарга, утырып ял итәргә кирәк иде. Аланлыкта черки, озынборын күренми, матур көн-

нея күркен бизәргә теләгәндәй, төрле төстәге күбәләкләр генә оча иде. Кырмыскаларга килгәндә, алар әллә кайлардан сиздермичә генә килеп чыгалар да әче итеп тешләп тә алалар, тәнне кытыклыйлар. Васил утырыр урын эзләп тирә-якка каранды. Аланлыкның аргы башындагы берсеннән-берсе зифа каеннарны күргәч, куанып куйды. Ул төштә тоташ күләгә, мөгаен, салкынчарак, талгынрак тадыр. Гөлзаданең дә карашы шул зифа каеннар, ефәк шәлләрен әкрен генә селкеп утырган табигать иркәләре ягында иде. Икесе дә сүзсез генә каенлыкка таба атладылар. Берничә адым үткәч, бер төптән өч мәһабәт каен үсеп чыккан ак кәүсәләр янында туктап калдылар. Бу каеннарның ябалдашлары, өстә бергә тотышып, гаять дәү челтәр шикелле күренә. Югарыда җил булса кирәк, бу чачаклар, бу ефәк чуклар талгын гына тирбәләләр. Шулай тирбәлеп, гүя кемнедер чакыралар, кемнедер озаталар, кемгәдер бәхет телиләр кебек... Өстән карашларын алуга, күзләр әкрен-әкрен аска төштеләр. Шушы кушкаеннар төбендә эскәмия күргәч, алар бер-берсенә карап елмаештылар да рәхәтләнеп килеп утырдылар. Күрәсең, кемдер каен төбенә эскәмия ясауны кирәк тапкан. Васил җентекләбрәк карый башласа, имән такталарның өрәңге казыкка беркетеп эшләнгәнлеген абайлап алды. «Бу каеннар төбендә ни хәтле гашыйклар, ни хәтле парлылар булгандыр... Бәхетлеләре дә, бәхетсезләре дә булгандыр аларның...»

Менә татлы мәхәббәт газабы кичерүчеләрнең гомерлек юлдашы булган ак каеннар аларны да үз чуклары астына алды... Бер-берсенә терәлердәй якын утырдылар. Васил сакланып кына як-якка каранып алды, кызның иңбашларыннан кочты...

Нигәдер аларның сүзләре оешып җитә алмады. Күңелләре нинди дер татлы уйлар, татлы хисләр белән тулышкан иде.

— Ни дә булса сөйләгез әле, Васил абый,— диде Гөлзадә, аның күкрәгенә сыенып.

— Ни сөйлим?..

— Ни булса да...

— Үзең дә сизенә торгансыңдыр. Безгә уйларга кирәк.

— Нәрсә турында уйларга?

— Киләчәк тормыш турында,— диде Васил.

Аннары, бер мизгел тын калып, янә иреннәрен кыймылдатты:

— Мин сине...

— Әй, сөйләмәгез, сөйләмәгез,— дип кырт кисте шундук Гөлзадә. Кызның тән кайнарлыгы һәм аның дерелдәве Василга да сизелә иде. Ул гына булмады, Гөлзадә аның күкрәгеннән башын алды да, юка ефәк кулъяулыгы белән йөзен каплап, елап та җибәрде. Васил, ни әйтергә белмичә, аптырабрак калды:

— Сиңа ни булды, Гөлзадә? Нигә...

Кыз шундук җавап кайтара алмады, бераздан соң гына:

— Миңа берни дә булмады, болай гына...— диде.

Васил бу очрашуда «мәсьәләне тәмам хәл иткәнче» сөйләшмәкче иде. Инде аның шактый вакытлардан бирле әзерләп куйган сүзләре дә бар: «Гөлзадә, чәчләрне чәчләргә бәйләргә вакыт җиткәндер. Ничек? Син ризамы? Бөтенесе дә синнән тора». Ләкин бу сүзләр һаман да эчтән борынлап чыга алмадылар. Василның күз карашлары, йөз хәрәкәтләре андый тойгыларны аңлата алдымы, юкмы — бу тиклесен дә әйтүе кыен иде.

— Иптәш кызлар ник килмиләр, кайларга таралышып беттеләр икән? — дип куйды Гөлзадә.

— Килерләр әле,— диде Васил.

Кушкаен төбеннән кузгалып киттеләр. Аланлыкта мендәргә басып барган шикелле йомшак булса, урман юлына чыккач, такыр, каты иде инде.

— Ишлибез? — диде Васил.

— Көймәдә йөрик,— диде төртелә-уңайсызлана Гөлзадә.

Алар көймәдә яр буйлап кына бара башладылар. Нинди күңелле! Су төбеннән күк зәңгәрлеге карый! Каршы яктагы электр станциясе төзелеше, аннан өстәрәк поселок күренешләре нинди дә зур шәһәрнең бер өлешен хәтерләтсә, алар көймәдә бара торган яр буенда күз күреме җитмәслек урынны бөдрә урман ямьләндереп тора. Яр буйлап беркадәр киткәч, су салкынчалыгын кырлар исе, басу исе алмаштырды. Ул да булмады, яр буеннан агарып килгән арыш басуын күрделәр. Сулык өстеннән акчарлаклар очып үткәли. Ә арыш кыры ягыннан бытбылдык сайравы ишетелә, ул бер ерагая, бер якыная кебек, ә үзе күренми. Җитеп килгән арышларга карап Васил бер минутка кулында ишкәк барын да онытты, тынып калды. Икесе дә арышларга сокланып карап тордылар.

— Нинди күңелле,— диде Васил,— авыл урамына җырлатып индустрия килеп керде. Нинди зур безнең бу якларның киләчәге!

— Әйтәсе дә юк, Васил абый,— дип аның белән килеште Гөлзадә.

Кыз, нигәдер томрап торган тулы иреннәрен бөрештергәндәй, үзалдына моңсуланып калган шикелле булды. Ул карашын кырдан алды, алдына туры карады да шул ук минутта кисәк борылып, нигәдер тынып калган Василның бераз моңсурак күзләренә йотылып, текәп карады.

— Нинди иркен, нинди рәхәт монда! Шулаймы? — диде Васил, сөенечле бер төс белән. Ул да күзләрен тутырып кызга карады.

Үз алдына бәхет һәм шатлык шәрабы эчкән бу ике ярсу йөрәк, сүзсез генә, көймәдән ярга чыктылар. Җитәкләшкән килеш, тар гына басу юлыннан өскә таба менделәр. Бу басу юлыннан әле узган ел гына йөриләр иде. Юл... Алда болынлык һәм тар гына Тын елга, күпер иде... Ә хәзер боларның берсе дә юк. Әллә нинди авыллар ягыннан килә торган юл гүя зур сулыкка килеп җитә дә өзелеп кала. Гөлзадә бәләкәй чакта иптәш кызлары белән арыш басуларыннан күк чәчәкләр җыеп кайткан елларны исенә төшерде. Бу юлы арыш арасында күк чәчәкләр күренми иде. Бары шунда гына хәзер орлыкны агулап чәчүләрен, иген арасында чүп үлән булмаска тиешлеген исенә төшерде ул. Шактый баргач, тагы урман итәге күренде. Агачлар куенындагы ак палаткаларга карап, Гөлзадә кычкырып җибәрде:

— Анда чегәннәрдер, мөгаен...

— Әй, булмас ла.

— Мин әйтәм, чегәннәр, дим. Әйдә, Васил абый, кире борылыйк.

— Кирәкми, барыйк әле. Кемнәр булса да, безне тотып ашамаслар бит. Әллә курыктыңмы?

— Курыкмадым да, анда барасым килми...

— Күрик әле, нинди кешеләр икән?

Барып җитсәләр, ни күрсеннәр — Зиннур Гафиятуллин, аның хатыны Хәмидә һәм аларның балалары яшел чирәм өстендә бик тәмләп балык шулпасы ашап утыралар. Безнең дусларны да кыстый-кыстый табынга утырттылар. Василның беренче кашык шулпа кабуга ук күзләре якында гына күксел төтен чыгып торган учакка төште. Учак өстенә аркылы таякка чиләк эленгән һәм аннан пар күтәрелә иде. Менә озакламый, җирдән тишелеп чыккан шикелле, учак тирәсендә ике кеше күренде. Болары — яшь пар, яшь оя корган Рафис белән Мәдинә иде. Кычкырып сәламләштеләр, бер-ике шаян сүз әйтештеләр. «Менә семьялы кешеләр, палаткалар корып, күңелле ял итәләр. Гөлзадә белән без кайчан шулай тормыш көтә башларбыз икән?»

Васил бөтен барлыгыннан нур, сафлык һәм яшьлек кайнарлыгы бөркелгән Гөлзадәгә карады. Авызына шулпасыз буш кашык капканын бары шунда гына абайлады.

Җәйге озын көннең ничек узганы сизелми дә калды.

Көн аларныкы булган кебек, төн дә аларныкы иде...

## 12

Тикшерү органнары да шактый кыен хәлдә калдылар. Фарукшинның үлеме белән бәйләнешле мәсьәләне ачыклый алмый йөдәделәр. Карчыга да, ничәмә-ничә чакыру булуга карамастан, тикшерүче янына килмәде. Ахырында, аның, беркемгә бер сүз әйтмичә, поселоктан качып китүе турында хәбәр таралды. Бу хәтлесе яңа шик, яңа шөбһә тудырды. Имештер, Фарукшин белән Карчыга арасында ниндидер дошманлык булган һәм вакытын, җаен туры китереп, Карчыга аннан үч алган. Ләкин моның чынмы яки ялганмы икәнен берәү дә өзеп әйтә алмый иде. Тикшерү органнары тагы бер бик кирәкле терәкне тапсалар да, анысы да хәзергә аларны тынычландыра алмады. Бер хатын Фарукшиннар белән пар казаны янында эшләгән булган. Тик ул шул хәл булган көннәрне авырып киткәч, аны район больницасына салганнар. Анда аңына килмәгәч, Казанга ук җибәргәннәр. Аны эзләп тикшерү органнары Казанга махсус кеше җибәрсәләр дә, нәтиҗә чыкмады. Теге хатын, каты авыру булу сәбәпле, аларның сорауларына җавап бирә алмаган.

Ә райкомның икенче секретаре Гусевка көненә әллә ничә тапкыр төзелештән шалтыраттылар. Анысы исә, үз чиратында, тикшерү органнарыннан гаеплеләргә карата тизрәк чара күрүне таләп итте. Бер яктан, эш шулай барса, икенче яктан, ул бюро утырышын ашыктырды. Бюро башланганчы Юлдашев белән барлык мәсьәләләр дә нигездә хәл кылынган, бик нык уйлап тикшерелгән иде.

Бюро утырышы билгеләнгән вакытында — нәкъ иртәнге тугызда башланды. Кайсыдыр колхозда сөт савып алудагы бик җитди кимчелекләрне тикшереп, тиешле карар чыгарганнан соң, көн тәртибендәге икенче мәсьәләгә күчтеләр. Райком бинасының киң коридорында йомшак диваннарга һәм урындыкларга утырышып түземсезлек белән көткән кешеләрне секретарь кабинетына чакырып алдылар. Кабинетның кайбер тәрәзәләре ачык иде. Тәрәзә алларындагы биек булып үскән агачларның куе яшел яфраклары кабинетка салкынчалык биреп тора, алар арасыннан хәтта кояш нурлары да рәтләп үтеп керә алмый, бары тик челтәрләнеп идән һәм стеналарда гына тирбәләләр. Кабинетның түрендә утырган Гусев стена буйларындагы диван, урындыкларга утырышкан кешеләргә карашын йөртеп чыкты. Көн шактый эссе булса да, ул ни өчендер кара ефәк галстук таккан, костюм кигән. Ә кабинеттагы бик күпләр күлмәкчән генә, байтагы якаларын ачып ук җибәргәннәр иде. Гусев болай да әйбәт яткан, беркадәр сыеклана башлаган чәчләрен тагы бер кат сыпыргалап, якасын һәм галстугын төзәткәләп алды. Аннары озынча өстәл каршында утырган куе кара чәчле, нечкә мыеклы, очлырак борынлы кешегә — бүлек мөдиренә сүз бирде.

— Төзелеш идарәсенең баш инженер урынбасары, шул ук вакытта беренче төзү-монтаж идарәсе начальнигы коммунист Васил Закирович Сафинның персональ эше турында,— дип башлап китте бүлек мөдире. Ул, бер урында да төртелеп тормастан, машинкада басылган юлларны йөгертеп укырга кереште.

Василга калса, ул мондый ук хәлне көтмәгән һәм уена да китермәгән иде. Ул, күп булса, төзелештә техника куркынычсызлыгының торышы турында гына сүз барыр дип уйлаган иде. Ничек соң әле болай кинәт кенә, шундый кызу «урак өстендә» аның башына тимер казык белән кизәнәләр? Ул, һөҗүм бик көтелмәгәнчә башланганга күрәдер инде, берничә минут үзенең кайда икәнен дә онытыбрак каушап һәм югалып калды. Ә бүлек мөдире бер дә каушамыйча, гадәти салкын канлылык белән укуында дәвам итте: «...В. З. Сафин, җитәкче буларак, коллектив фикере белән хисаплашмый. Бик күп мәсьәләләрне хәл кылганда ул мин-минлек күзлегеннән чыгып эш итә. Коллектив җитәкчелек принципларын танымый. Партия һәм халык тарафыннан гаепләнгән иске метод-

ларны куллана... Аның эш методы — кычкыру, җикерену һәм шәрә администраторлыкка кайтып кала... Мәсәлән, Сафин моннан берничә айлар элек эшендә кайбер вак-төяк төгәлсезлекләр җибәргән прораб иптәш Кукушкинны эзәрлекли. Кимчелекләре төзәтелгәч тә, аңа канығудан туктамый. Хәтта Кукушкинга кул күтәрүгә кадәр барып җитә...»

Шулай ясмыктан ястык ясап кабартылган һәм ишәя барган гаепләү сүзләрен ишеткәч, Васил, түземен югалтып, сикереп урыннан торды, ни әйткәнен дә белмәстән кычкырып җибәрде:

— Кешегә нахакка яла ягу бу!..

Гусев, кыңгырау чыңлатып, аны сүзеннән бүлдерде:

— Купчелекне ихтирам итү дигән этика кагыйдәсе бар, иптәш Сафин. Тыныч утырыгыз. Вакыты җиткәч, сезгә дә сүз бирелер.

Бүлек мөдире, аз гына вакытка тукталып торганнан соң, башта алган җаена кайтып төшеп, яңадан укый башлады: «...Коммунист Сафинның эшкә салкын каравы турыдан-туры үзе җитәкчелек итә торган пар казаннарын монтажлау урыннарында бигрәк тә ачык күренә. Анда техника куркынычсызлыгын саклау кагыйдәләре үтәлмәү-саклан- мау нәтиҗәсендә Фарукшин дигән югары квалификацияле эшче егылып төшеп һәлак була...»

Озынча өстәл артында утыручы бюро членнарыннан кайсыдыр авыр сулап алды, кайсыдыр башын селкеп куйды, берсе тамак кырды. Сафинга калса, ул тәмам тузынып, бюро утырышын ташлап чыгып китәргә ниятләде. Ниятләп кенә дә калмады, чыгарга дип урыныннан кузгалды. Ләкин нindидер эчке тавыш акыл-киңәше белән үзен кулга алды, түземен саклап калды. Аңа нинди генә гаепләр такмадылар, нинди генә тукмаклар төшермәделәр... Чөй өстенә тукмак, чүп өстенә чүмәлә, дигәндәй, кешене бер пычрак белән керендерергә керешсәләр, табыла икән ул. Шуларның һәммәсен дә тыңлап, Сафинның тәне бер эсселәнде, бер суыкланды, башы тубалдай булды. Кем белә, эшләр бу кадәргә җиткәч, аны яңадан тора алмаслык итеп хур итәргә, бөтенләй яраксыз тип итеп сафтан чыгарып ташлаулары да мөмкин. Ләкин ул әледән-әле башына килгән мондый ямьсез уйлардан арынырга тырыша иде. Ахырында бүлек мөдире сүзне төйнәргә ашыкты:

— В. З. Сафин, коммунист һәм зур җитәкче буларак, мораль яктан да бик аксый. Тотнаксызлык күрсәтә. Мәсәлән...

Бүлек мөдиренең бу рәвешчә фикер йөртүе Гусевка бик йомшак тоелды бугай. Ул, аны сүзеннән бүлдереп, мәсьәләгә юнәлеш бирде:

— Нинди тотнаксызлык? Һәр нәрсәнең үз исеме бар. Шулай булгач, әйберне үз исеме белән атарга кирәк. Үз семьясы була торып, хатын-кызлар белән йөрү, бу баткаклыктан чыгасы урында, хатынын һәм баласын ташлап, икенче берәүгә өйләнү — бу инде әхлакый тотнаксызлык кына түгел. Бу инде мораль яктан череп таркалу...

Райбашкарма комитеты председателенә — колак артларында гына биш-алты бөртек чәче тырпаеп торган, зур табак битле, киң борынлы җирән кешегә — мәсьәләнең бу кадәр кискен куелуы сәеррәк тоелды булса кирәк, ул бер Гусевка, бер бүлек мөдиренә карап:

— Минем өч соравым бар,— диде.

Икенче секретарь Гусев бик тәкәллеф белән генә аңа сүз бирде:

— Рәхим итегез.

— Сорыйсым, ачыклыйсым килгәне шул,— дип сүз башлады райбашкарма комитеты председателе.— Производстводагы травма өчен нигә Васил Закирович кына җавап бирә? Баш инженер Зариф Салихович нигә читтә кала? Тагы... Бу мәсьәлә төзелеш парткомында каралганмы? Аннары, моңа хәтле Васил Закирович Сафинның партҗәзасы бармы?

Райбашкарма председателе, кайсы җавап бирер икән дигән шикелле, бер секретарьга, бер бүлек мөдиренә карады. Бүлек мөдире исә кыза-

рынды-бүртенде. Секретарь, әйдә җавап бирә башла, дигәндәй, бүлек мөдиренә карап ым какты. Кызаруы тагы да куера төшкән мөдир әкрен генә, гүя үзенә ышанмаган бер төстә сүз башлады:

— Минемчә, баш инженер иптәш Юлдашев ул гомуми житәкче. Билгеле, житәкче буларак ул да бу мәсьәләдән читтә кала алмый. Ләкин монда төп җавапны монтаж эшләре өчен турыдан-туры җаваплы кеше иптәш Сафин бирергә тиеш.

Мөдирнең сүзләре белән килешеп, Гусев ияген какты да икенче сорауга үзе җавап кайтарды. Ул башта сүзне тартып-сузып башласа да, бераздан теле язылды, сүзләре шома акты:

— ...Без райкомда кайбер бюро члены белән киңәштек тә, мәсьәләне бирегә кую мәслихәтрәк булыр, дидек. Чөнки, иптәш Сафин, бердән, райкомның пленум члены, икенчедән... башкаларга сабак булыр...

Райбашкарма председателе моңа каршы нидер әйтергә авызын ачкач ярты юлда туктап калды. Өченче сорауга да секретарь үзе җавап бирде. Сафинның бернинди дә партия җәзасы алганы юк икән.

Һич көтелмәгәндә генә Юлдашев торып басты. Бер генә минутка шунда Сафин белән аның карашы очрашты. Ләкин бүлек мөдире сөйләгәндә күбесенчә башын селкеп яки ярым елмаеп утырган бу кешенең карашы кинәт артык җитдиләнеп китте. Тик ул нигәдер бик еш тирли һәм маңгаен әледән-әле сөртеп тора иде. Аның тигез агылышлы тавышы бюро члены һәм игътибарын үзенә тартты.

— Иптәшләр, бу мәсьәләнең бүген бюро утырышына куелуы, минемчә, бик урынлы. Яшь белгеч, яхшы ук энергияле кеше инженер иптәш Сафинны сазга батканда коткарып калу бу. Бу рәвешчә барганда аның әллә нинди көтелмәгән зур җинаятьләргә юлыгуы котылгысыз. Чир тәмам кешене егып салганчы, авыру урынга үз вакытында операция ясау файдалырак. Монда да эш шулайрак. Үз вакытында безнең коллектив һәм, баш инженер буларак, мин үзем ярдәм кулын сузарга тырыштым аңа. Производство мәсьәләләренә карата да комиссия бик дөрес бәя биргән диясе килә. Мин аларны кабатлап тормыйм. Тик авыр фаҗигале травма турында гына бер-ике сүз әйтәсем килә. Әгәр дә иптәш Сафин алдан тиешле чара күрсә, техника куркынычсызлыгын саклауга житәрлек игътибар итсә, мондый бәхетсезлек булмас иде.— Әллә уйлары чуалды, әллә бераз каушады шунда, Юлдашев таркаурак сөйли башлады. Ул, кинәт кенә юлдан чыккан шикелле, сүзен шулай дип дәвам иттерде: — Семья мәсьәләләрендә дә мин аны һаман кисәтә килдем. Хәтта аның белән генә чикләнмәдем. Иптәш Сафинның үз семьясын җимерергә йөз тотуы турында парткомны да искәрттем. Әмма иптәш Сафин һәм безнең секретарь иптәш Сабиров минем искәртүләргә колак салмадылар. Ә нәтиҗә ничек килеп чыкты? Күңелсез, бик күңелсез...

Төзелеш парткомы секретаре Сабиров, Васил Сафинның эшен һәм шәхси тормышын биш бармагы кебек белгәнгә, баш инженерның урынсыз нәтиҗәләр, дөресрәге, ялган нәтиҗәләр ясавы белән һич килешмәгәнгә күрә, түзеп тора алмады:

— Демагогия белән шөгыльләнәсез, Зариф Салихович... Һич нигезсез гаепләр такмагыз парткомга...— диде.

Ачудан төсләре үк үзгәргән Сабировка артык әйтергә туры килмәде. Секретарь Гусев аны сүзеннән туктатты:

— Иптәш Сабиров, әлегә сезгә сүз бирелмәгән. Болай килешми, тәртип белән.

Ә Юлдашев, яңадан үзен кулга алып, берни дә булмаган кебек, тыныч һәм тигез тавыш белән сүзен янә дәвам иттерде:

— Әгәр дә вакытында партком безнең тавышка колак салган булса, бүгенге күңелсезлекләрнең күбесе булмас та иде. Нигә, мәсәлән, шул чакта иптәш Сафинның семья мәсьәләләре һәм башка чатаклыклары турында партком утырышында карамаска иде? Хәтерегезгә авыр алма-

да эшләнмәде...

— Дөрес түгел!

Гусев, кечкенә кыңгырау шалтыратып, Сабировны тагы бер тапкыр тәртипкә чакырды. Юлдашев, сизгерлек һәм үз вакытында «ярдәм» күрсәткәне өчен райком хезмәткәрләренә рәхмәт әйтеп, тыныч кына урынына утырды.

Васил Сафин, мәсьәлә үзе турында, аның тормышы һәм язмышы турында барганлыктан, салкын кан белән тыныч кына утыра алмады. Аның вакыт-вакыт башы әйләнеп китә, бөтен тәне ут кебек яна, әйтерсең ул инәле урындыкта утыра, алай гына да түгел, ниндидер усал куллар аны тирән чокырга таба аягыннан сөйриләр кебек иде. Бары тик Сабиров сүз сорагач кына ул, азмы-күпме өмет баглап, рәхимле күзләре белән аңа карады.

Гусевның бер бик шәп ягы бар: сөйләүченең сүзе аңа ошыймы, юкмы, ул аны тыныч кына тыңлый. Үз фикерен соңыннан гына әйтә. Сабиров аның бу гадәтен белә иде инде. Ул сөйләп бетергәч, Гусев Сабиров адресына усал гына берничә сүз әйтте дә янә Сафин мәсьәләсенә кайтып төште. Үзенең баштагы фикерләрен беркадәр яңадан «ныгыткач», сүзне Сафинга бирде. Васил бары бер генә сүз әйтте:

— Минем сүзем юк...— диде.

— Димәк, сез үзегезне гаепле саныйсыз?

— Санамыйм! — Сафинның күз читләре тартылып-тартылып куйды.

Бу минутта Васил Сафинга караган кеше аның иреннәреннән кан качуын күрер иде.

— Нинди тәкъдимнәр бар?

— Мин монда әллә ни баш китәрлек эш күрмим,— диде райбашкарма председателе.

Бюро члennарының фикере икегә аерылуын бик яхшы төшенгән Гусев, озынча өстәл артында утырган кешеләргә карап-карап алгач, үзе сүз куертты:

— Беренче тәкъдим: югарыда саналган гаепләре өчен иптәш Сафинны партия сафларыннан чыгарырга. Икенче тәкъдим... юк. Тавышка куям. Бюро члennары гына тавыш бирәләр. Ягез, иптәшләр, кем дә кем...

Васил Сафинны партиядән чыгарырга бюро члennарыннан дүртесе тавыш бирде. Каршылар... алар да дүртәү иде.

Гусев, барыннан да битрәк, үзе уңайсыз бер хәлдә калуын сизенде. Әйтик, унбер членның икесе командировкада икән, берсе кан басымы белән больницада авырып ята икән... Нигә ул моны исәпкә алып эш итмәде? Больницада ятучы райфо мөдирен бюрога чакыртып алса? Кем белә аның ничек тавыш бирәсен? Нишләсен, бюро утырышы башланганчы уйлабрак җиткермәгән икән шул. Гусев галстугын чишеп өстәл тартмасына тыкты, изүен ачып җибәрде. Ләкин ул бөтенләй тугарылып озак тормады:

— Бу мәсьәлә көн тәртибендә кала. Берничә көннән тагы карарбыз, әйләнеп кайтырбыз бу мәсьәләгә,— диде.

Шулай итеп, Васил Закирович Сафинның язмышы әлегә җир белән күк арасында эленеп калды.

## 13

Һәркайсы үз машиналарына утырды, бер-берсенә күтәрелеп карамадылар. Васил Сафинның нинди хәлдә икәне Сабировка билгеле. Шундый зур эшләр төгәлләнеп килгәндә нигә тырнак астыннан кер эзләргә? Бу Юлдашев ни уйлый икән? Аның максаты Сабировка күптән ачык иде инде. Тик ул аны бу хәтлегә үк җитмәс дип уйлый иде. Күрәсең, ялгышкан һәм нык кына ялгышкан булып чыкты. Юлдашевның үз карьерасы

өчен, үз тиресе өчен берни алдында тукталып калмаячагын ник ул аллан ук күрә һәм бәяли алмаган?

Хәзер ана нишләргә соң?

Әнә шул уй Солтан Сабировның башыннан чыкмады, аны гел борчып торды. Бюро утырышыннан кайткач, кабинетында ишекле-түрле йөренде. Сафин мәсьәләсенең хәл ителмичә калуы аның өметен азмы-күпме яңартып җибәргәндәй булды. Әмма Гусев мәсьәләне җир белән күк арасында калдырмас. Тиздән аны яңадан куяр һәм баштагы фикереннән чигенмәс. Беренче секретарь үзе өйдә булса һәм аның алдында икенче урынга күчү кебек мәшәкатьләр тормаса, билгеле, «тырнак астыннан эзләнгән кер» бу кадәр кабартылмас, бу кадәр кискен төс алмас иде. Өлкә комитетына язып караса? Никитинга телеграмма сукса? Нишләргә соң?

Ниһаять, баш вата торгач, Сабиров кискен бер карарга килде. Ул уйлаганын гамәлгә ашырганчы министрлык вәкиле Фирсовны күреп сөйләшергә теләде. Ләкин аны тиз генә таба алмады. Аннары эш вакытында бик алай бүленәсе дә килмәде. Дөрес, ул Фирсовның күбесенчә вакытын төзелештә уздырганын белә иде. Ул үзе дә анда еш була. Ләкин ана бу махсус кешеләр, белгечләр кебек үк озак йөрергә туры килми. Тегендә-монда барасы, башлангыч партоешмаларда буласы, җыелышларга катнашасы була. Вакыты аның бик чикле. Иртән иртүк чыгып китә дә кичен соңгарып кына өенә кайта. Шул нигездә гаиләдә күңелсез генә сөйләшүләр дә баш калкыткалый. Ул бүген Фирсовны беркая да таба алмагач, аның белән ничек тә кичке якта сөйләшергә булды һәм эшеннән соңга калып кайтты.

Фирсов белән төзүчеләр клубында очраштылар.

Төзүчеләр клубының залы халык белән шыгрым тулы, инә төртер урын да калмаган иде. Ишекләр шар ачык, алай да эсселеккә һәм тынчуга чыдап булырлык түгел. Атаклы җырчылар, Ленинград филармониясе артисткалары — бер туган Федороваларның чыгышын тын да алмый тыңладылар. Рус халкының моңлы көйләре бик күпләрнең күңелләрен биләп алды. Бер-берсенә охшаган бии туган, әйтерсең лә бер сулыштан, бер тавыш белән җырлыйлар иде. Залда утыручылардан, мөгаен, Геннадий Антонович Фирсовтан башка, аларны әле барсы да диярлек беренче тапкыр гына күрәләрдер. Солтанга калса, халык җырлары аның күңел түренә үк кереп утыра инде! Залдагы һәркем кебек Солтан да Федороваларны яратып тыңлады, күңел кыллары тибрәнеп куйды. Вакытның ничек үтүе дә сизелмәде. Концерттан таралганда да кешеләр, тәнәфескә чыккан кебек, ашыкмыйча гына атладылар.

Алар клубтан өчәүләп чыктылар. Солтан беркадәр тын барды. Аннары Фирсов белән сүзләре үзеннән-үзе ялганып китте. Алар бик әкрен атлыйлар, арттанрак чыккан кешеләр дә аларны узып киттеләр. Шулай бара-бара Солтаннар квартиры турына да килеп җиттеләр. Бары тик шунда гына Солтан хатынына ягымлы гына итеп эндәште:

— Минем Геннадий Антонович белән кайбер мәсьәләләр турында сөйләшәсем бар иде. Гостиницага барсам, син каршы килмәссең бит.

Хатыны берни булмагандай әйтте:

— Геннадий Антонович кебек кеше белән төне буе сөйләшсәң дә рөхсәт миннән,— диде һәм йомшак бер тавыш белән гөлдерәп көлә көлеп алды.

Сабиров Мәскәүдән килгән ике инженерның гостиницаның унайлы гына бер бүлмәсенә урнашуларын белә иде. Бүлмәдә форточка ачык, аннан саф һава кереп тора. Икенче инженерның бүлмәдә юклыгын искәртеп, Сабиров әйтә куйды:

— Ә иптәш Зотов кайда соң?

— Ул пар казаннары цехында. Көн-төн кайтмый. Хәзер анда иң җаваплы момент, сезгә билгеле булганча,— диде Фирсов.

Икесе дә түгәрәк өстәл артына утырып, папирос кабыздылар. Сабиров, баштa беркадәр тартыныбрак торгач, фикерләрен тупларга тырышып, сүз башлады. Ул Фирсовка әле көндез генә райком бюросы утырышында каралган мәсьәлә турында әйтте дә өстәп:

— Сез әйткәндәй, хәзер шундый җаваплы момент, Геннадий Антонович, ә иң кирәкле бер җитәкчебез өстендә кара болытлар куера,— диде.

— Таратырга кирәк ул болытларны,— дип, мәгънәле генә көлемсерәде Фирсов.— Әгәр, мин сезне дөрес аңлаган булсам, Солтан Сабирович, бу буталчыкларны оештыручыларның берсе безнең хөрмәтле коллегабыз Зариф Салихович булып чыга?

— Әйе, Геннадий Антонович! Аңа нидер җитми, аңа мәйдан тар кебек кылана. Мин инде күптән сизенеп йөри идем бу хәлне. Күрәсең, беренче секретарьның икенче эшкә китәргә йөрүеннән файдаланып, вакытны үзенчә отарга чамалый. Безнең тарафтан хәзер үк тиешле чара күрелмәсә, аның отып куюы да бар...

— Отып куюы да бар...— дип, ирексездән кабатлады Фирсов.

Фирсов, бер папиросны тартып бетермәстән, төпчекне көл савытына ташлап, икенчесен алып кабызды. Уйга бирелеп, кашларын җыерды. Аннары якты күзләре белән Сабировка текәлеп:

— Димәк, сез каршылыкка каршы хәрәкәт итәргә булдыгыз? — дип сорады.

— Сез мине дөрес аңладыгыз. Әйе...

Сабиров, терсәге белән өстәлгә таянып, учын маңгаена куйды, бер мизгел уйланып торгач, сүзен дәвам иттерде:

— Каршы якның картасы ачык: Сафиннан арыну... Эш барып чыкса, ул инде барлык җаваплы позицияләрне калдырырга тиеш була. Рәхим итеп теләсәң кая кит — дүрт ягың кыйбла. Шуңа юл куелса, гомуми эшкә нихәтле зыян, нихәтле зарар килә диган сүз, Геннадий Антонович...

— Бу турыда ике сүз булырга мөмкин түгел,—дип, Фирсов партоешма секретаре фикерләре белән килеште.— Яңаны төзү авыр. Ә җимерү — ансат. Хата юлга басу да нәкъ шулай тормышны, бәхетне җимерә. Нишләргә уйлыйсыз? — дип янә сорау куйды Фирсов.

— Язарга.

— Кая?

— Өлкә комитетына...

— Ул гына җитәрме?

— Никитинга хәбәр итәргә.

— Дөрес! Ләкин тизрәк эшләргә кирәк!

Солтан таң алдыннан гына була торган серле тынлыкка чумган кин урамнан атлый. Баганаларда электр лампалары күз кысалар. Кайдандыр түбән урамнар ягыннан этләр өргән аваз колакка килеп сугыла. Ул да булмый, тальян гармунның таныш моңнары ишетелә, гармунга кушылып җырлаган тавышлар да көчәя бара.

Каядыр еракта төн каралыгын таң яктысы куып килә иде. Хатыны аңа ишек ачты да, күзенә менгән йокы авырлыгын җиңә алмыйча, янә урынына барып ятты.

Күптән яктырган иде инде. Тәрәзә пәрдәләре өстеннән, утлы сөлге шикелле, кояш нурлары уйнаганда, хатын йокыдан торды. Бу нихәл — Солтан күренми. Ул кайда булыр? Хатын гадәттә ире язу-сызу, уку белән шөгыльләнә торган кече бүлмәгә чыкты. Ни күзләре белән күрсен: Солтан, өс киемнәрен дә салмыйча, диванга кырын яткан да йоклый. Өстәлдә кәгазьләр таралып ята. Конверт... Ябыштырылмаган конверт эченнән берничә дәфтәр битеннән торган хат алды. Берничә юлын укып хатның хатын-кызларга язылмаганын белгәч, янә конвертына кире тыкты. Ул иреңең һаман эш, төзелеш турында кайгыртуын төшенеп, башын селкеп куйды һәм, аяк очларына гына басып, иртәнге чәй әзерләргә керешә.

Васил Закирович Сафин нихәлләрдә икән?

Эшкә барышлый Солтанның башына нигәдер гел шул уй килә торды. Тормышта аның үз фәлсәфәсе бар иде. Ул фәлсәфә төзүчеләр арасында кайнашып йөргәндә күзәтүләрдән туды. «Баш кешенең ниндирәк кәефтә булуы эшчеләргә тәэсир итә. Әйтик, башлыкның чырае сытык, төсе ачулы, күз карашларында шәфкать нуры чагылмый икән, ул гасабилана һәм тузып-кызып йөри икән, шул нәрсә аның кул астында эшләүчеләргә дә үзенең күләгәсен салмый калмый».

...Василга үзенең язмышын Гөлзадә белән бергә бәйләгәч, таңнар да нурлырак, көннәр дә ямьлерәк, кешеләр дә күңеллерәк һәм җанлырак күренә башлады. Гүя ул күптән, әллә кайлардагы урманнар, таулар арасыннан кочак җәеп килгән бәхетне соңгарып булса да тапты кебек. Хәзер аның кечкенә гаиләсендә дә тантана иде. Һичкем өйрәтмичә, Ринат Гөлзадәгә «әни» дигән кадерле сүзне дә әйтә башлады. Моның өчен Гөлзадәнең иңә очы кадәр дә күңеле кителмәде, киресенчә, сөенече генә артты. Тик ул үзе малайга «улым» дип кенә әйтә алмады. Әле күптән түгел генә кияүгә чыккан, кызлык хисләреннән аерылып җитмәгән бу яшь затка алай әйтүе кыен, балага ни дип әйтергә белми аптырый иде ул. Тормыш бит бу. Бер нәрсә дә бер урында тик тормый, бер әйбер дә дөньяга ничек пәйда булса, шул хәлендә калмый. Үзгәрә. Кем белә, бәлки Гөлзадә дә иртәме, соңмы ана булыр. Аның инде икәү кушылгач, өченче җан иясен көт тә тор! Шул чагында ул хәзерге кебек «Ринат» дип кенә эндәшмәс, «улым» дигән тагы да җылырак, тагы да шәфкатьлерәк сүз белән җавап кайтарыр сабыйга.

Гашүрә әбигә килгәндә, өенә килен төшкәч, аның дөньясы түгәрәкләнеп, кыйбласы нурланып китте, олыгайган гәүдәсенә «хода җиңеллек» салды кебек. Карчыкның ин интеккәне — кешегә сусавы басылды, рәхәтләнеп сөйләшерлек, киңәшерлек кешесе бар хәзер. Югыйсә, улы башлыкзле булмаса, чит-ят җирләрдә торырга теләге дә суына башлаган иде. Тегеберенче килене янында аңа килеп-килеп кунак булгалаудан гайре, алай озак торырга туры килмәде. Тик шулай да Нурзиләнең кайнанасы белән теләмичә генә, төксе сөйләшүе, үзен һавалы тотуы ошамый иде карчыкка. Гәрчә ул нихәтле гомерләр яшәп бу тиклесен үз эчендә саклады, бер чагында да ризасызлыгын тышка чыгармады. Гөлзадә турында уйлаганда кайнананың төсләре яктырып китә: «Бусы, ичмасам, үзебез кебек прастуй кеше. Дөрес, әле аның белән күп торып карамаган. Киленен мактаган кайнана, кайнанасын хөрмәт иткән килennәр ул хәтле күп очрамый. Әмма, ничек кенә булмасын, Гөлзадәнең кылтым яклары сизелми, и болай барса, гомер-гомергә әйбәт булыр төсле». Җитмәсә, яшь киленнең ни тотса шуңа кулы ябышып торуы, аш-суга осталыгы, тегү-чигүгә маһирлыгы карчыкның түбәсен бөтенләй күккә тидерде. Ә йомшак, татлы теле! Кеше арасына бит барысы да кирәк, бер генә китеклек тә, бер генә «ямау» салган җире дә булмасын.

Васил Гөлзадә алдында нихәтле сабыр һәм борчусыз күренергә тырышмасын, эчтән ул тыныч түгел, бюро утырышында аның йөрәгенә яра салган гаепләү күңелен айкап тора, әллә нинди авыр тойгылар уята иде.

Кем белән сөйләшсен, кайгы-кичерешләрен кем алдында түксен? Андрей Акимович Никитин өйдә юк. Хәзер үзе өчен бердәнбер терәк Солтан Сабиров иканен уена китерде ул. Сафин райкомнан кайткач ук, аның янына барып сөйләшергә ниятләсә дә, пар казаннары цехында ки-

чекмәс эшләре булу сәбәпле парткомга бара алмады. Ә бер эшкә чумгач... Эш барысын да оныттыра, барысын да истән чыгара, көнелдәге борчуларны куып, алар урынына үз борчуларын өсти, кеше җилкәсенә үз мәшәкатьләрен сала. Монтажчылар иң җаваплы эшләрне башкарган бу көннәрдә Васил як-ягы тимер култыксалы тар баскычлар буенча әле аска төште, әле өскә менде. Янгын сүндерүчеләр шикелле, башларына каска, өсләренә саргылт брезент чалбар һәм курткалар кигән, ут көлтәләре чәчә-чәчә торбалар тоташтыручы, металл тишүче, эретеп ябыштыручы яшь ирләр, егетләр янында кай ара ул тукталып, тегe-бу турыда киңәш-күрсәтмәләр бирә, бер үк вакытта үзе дә аларның сүзләренә колак сала иде.

Ул шулай көпә-көндез йөзләгән утлы кылычлар белән һаваны телгәли-телгәли кайнашкан кешеләр арасында әвәрә килеп йөргәндә, аның янына партком секретаре Сабиров үзе килеп чыкты. Беренче сүзләрне әйтеп күрешүгә үк Сабировның якты чырае Сафин йөрәгенә ниндидер тынычландыру шифасы салды кебек. Өстенә ак тукыма костюм кигән, ялан башлы, аксылрак чырайлы бу кешенең текә маңгае тагы да биегәйгән сыман күренде аңа. Монда — булачак пар казаннары цехында — мотор тавышлары, металл чыңнары шау-шу, гүләү тудырганлыктан, яхшы ук кычкырып сөйләшергә туры килә. Төтәсләнеп тузан бөтерелгән шушындый урынга кар кебек ак костюм киеп килгән Сабировка Васил беркадәр гаҗәпсенеп карады. «Ак кош булып килгән, моннан киткәндә кара карга кебек булуы бар»,— дип уйлап алды.

Монтажчылар партком секретаре белән, эшләреннән бүленмичә, баш кагып кына исәнләштеләр.

— Куыралар егетләр!

— Куыралар, почем зря куыралар! Зур сабан туеның бәйге көннәре якынлаша бит,— диде Васил.

— Именно шулай! Үзегезнең кәефләр ничегрәк соң, Васил Закирович?

— Кычкырып җыларлык түгел,— диде Васил беркадәр корырак төстә, һәм аның чырае алмашынган кебек булды. Бары шунда гына Сабиров бирелгән соравының бигүк урынлы булмавын, аның иң авырткан җиренә бәрелгәнлеген аңлап алды. Ләкин эш ул уйлаганча ук шигъерлек булмады, ахры, Васил дәвам итте:

— Кайгырырга вакыт юк. Хет тәүлек утыз сәгатьтән торсын, барыбер җитешә алмас идең...

Билгеле, бу аның зарланып әйтүе түгел иде. Сабиров бу тиклесен бик дөрес аңлады. «Берүк шулай булсын»,— дип юрады. Дөресен әйткәндә, бюро утырышында Васил Сафинга карата булган үчегүләрдән соң, ул аны канатлары бик салынкы, кәефләре җимерек хәлдә күрермен дип уйлаган иде. Васил Сафинның алай коелып төшмәве, җиргә иңмәге секретарьның эченә җылы салды.

Төп корпус бинасының өченче катында үзенә аерым бер рәт булып тезелгән куе яшел төстәге вагон-контораларның тәрәзәләрендә тәүлек буена ут сүнми, ишекләр ябылып тормый. Бу вагоннарга читтәнрәк карап торсаң, менә-менә кызыллы-яшелле күзләрен уйнатып поезд килеп чыгар да вагоннар дәррәү кузгалып китәр сыман. Ә алар кузгалмыйлар. Вагон-конторааларда — монтажчы-төзүчеләр штабы. Шуларның берсендә ярты вагонны Сафин кабинеты били. Сафин белән Сабиров шул кабинетка керделәр. Тәрәзә буендагы почмакта — язу өстәле. Телефон. Стена буйларына ярым йомшак урындыклар тезелгән. Стеналарга җинел, нечкә таяклар белән төрле проектлар эленгән. Сафин өстәл артына, Сабиров аның каршысына утырды. Төзелештә иң авыр йөкне тартып баручы җитәкчеләрнең берсе, тыйнак табигатьле, шау-шуны яратмый торган, ләкин бу көннәрдә язмышы үлчәү тәлинкәсенә куелган бу кешегә җылы сүзләр әйтергә теләде Сабиров. Ләкин, сүзенең бик беркатлы

килеп чыгуыннан сагаеп, бармакларын өстәл пыяласында биетеп утыра бирде. Хат турында сүз башласа ничек булыр? Ул шул рәвешчәрәк уйланып утырганда, Сафин үзе башлады:

— Беренче үзе кайчанрак кайта икән?

Бары шуны ишеткәч кенә, Сабиров кыюланып, җанланыбрак китте:

— Беренче секретарь тиз генә кайтмас әле.

— Нишләп?

— Ул чираттагы ялына киткән. Анда ким куйганда бер ай булырдыр. Аннары башка эшкә күчәргә тиеш.

— Наратлыда кем калыр? Гусевмы?

— Минемчә, аңа шул икенче секретарь булып эшләсә дә, бик житкән.

— Бюро утырышы тагы кайчанрак булыр икән? — дип сорады Сафин.

— Артык сузмаслар,— диде Сабиров.— Юлдашев та бик ашыктыра, нигә карама — машинасы гел район юлында. Алай да утырышны бу якын көннәрдә генә үткәрә алмаслардыр әле. Ни өчен дисәк, бердән, бюро членарыннан берсе һаман авырып ята. Икенчедән, районда сөт, ит планнарының үтәлеше хөртирәк тора. Өстән кыздыралар... Иртәгә колхоз председательләрен җыеп сөйләшәчәкләр икән әле.

Икесе дә урыннарыннан тордылар.

Сабиров, тимер идәннәр буенча шак-шок атлап барганда, алдына карамаган булган, күрәсең, берәү белән чак-чак кына маңгайга маңгай бәрелми калды. Күтәрелеп караса — аның каршында Гөлзадә тора иде. Кабарынкы чәчләрен зәңгәр төстәге косынка астына яшергән, соры курткалы, тар чалбарлы авылдашы үзенең бу кыяфәте белән хатын-кыздардан бигрәк, яшүсмер малайларга охшый иде. Ләкин бу беренче карауга гына — ә чынында пешеп җиткән алма кебек матур иде ул. Гөлзадә, сөрмәле керфекләрен тибрәндереп, кычкырып җибәрде:

— Солтан абый!

— Гафу ит, сеңел, минем игътибарсызлык аркасында «авария» була язды.

Гөлзадә чыркылдап көлеп җибәрде. Аның кулында кечкенә-җыйнак кына азык-төлек сумкасы күргәч, Сабиров Гөлзадәнең нигә ашыгуын, кая баруын шундук чамалап алды:

— Аның янынамы? — дип, Сафин кабинетына таба ымлап күрсәтте.

— Әйе, Солтан абый, икебезнең дә тамак ялгап аласы бар.

— Аныси капкалап алу ярый,— дип, Сабиров, гүя авылдашының күз карашына буйсынып, китә алмый торды.— Кайда эшлисез, һаман идарә пультендәме?

— Шунда эшлибез. Бу араларда безнең бригаданы оныттыгыз, Солтан абый.

— Онытмадым һич тә. Участоклар күп, кайсына житешәсең?! Сезнекеләр янына да барып чыгарга тырышырмын.

— Килегез, безнең кызлар сагынып беттеләр инде сезне.

— Бәхетле булырлар, бәхетле булырлар,— дип кабатлый-кабатлый, төп корпус бинасыннан чыкты Солтан Сабиров.

## 15

Төрле сүз йөрде.

Пар казаннары корылмасындагы кеше үлү вакыйгасыннан соң күп тә тормый Карчыганың тәзелештән китеп баруы сәбәп булды бу сүзләргә. Имештер, Фарук Фарукшин белән Карчыга арасында байтактан бирле дошманлык яшәп килгән. Карчыга үч алу өчен унайлы форсат кына карап йөргән. Тәнге сменада эшләгәндә, җай үзеннән-үзе килеп чыккан — өстә эшләүчеләр кайсы кайда тамак ялгарга, ял итәргә тарал-

гач, Фарук белән Карчыга икәү генә калганнар. Әнә шунда инде Карчыга Фарукны биш катлы йорт биеклегендәге корылмадан төртеп аска тәгәрәткән, имеш...

Бу хәбәр поселоктагы бер генә ишекне дә, бер генә капканы да читләтеп узмады. Уты сүнеп бетмәгән учак шикелле, шул имеш-мимеш пыскудан тукталып житмәгән көннәрнең берсендә партком бүлмәсенең ишеген шакыдылар.

— Рәхим итегез,— диде Сабиров.

Бүлмәгә кыюсыз гына килеп кергән озын буйлы, киң җилкәле, тузып торган очын чәчле, чигәләреннән иягенә килеп тоташкан куе сакаллы берәүне күргәч, Сабиров күзләрен челт-челт йомгалап алды. Ул бу ят кешене күзләреннән һәм башка берәүдә дә булмый торган калын тавышыннан таныды:

— Карчыга?!

— Әйе, мин, гражданин... то-есть, иптәш секретарь.

— Син бит күренми идең... Сез...

— Шулай туры килде, иптәш секретарь.— Шуларны әйткәч, Карчыга телен йоткандай тынып калды. Моннан өч айлар элек ул таза, түгәрәк битле булса, хәзер аның йөзе очлаеп тора, яңаклары суырылып эчкә баткан, болай да зур борыны кылычланып юкарган, күзләре шар кебек зурайганнар иде. Карчыганың чәч-сакаллары да бу хәтле тарау һәм озын түгел иде.

— Я, сөйләгез, мин тыңлыйм,— диде Сабиров.

Карчыга аска карады. Сабировтан папирос сорап алып кабызды да аның күзләренә туп-туры карап әйтте:

— Мин гаепсез, иптәш секретарь!

Сабиров аптырый калды, әкренләп аның гасабилыгы арта барды:

— Гафу итегез, минем сезне гаепләргә җыенганым юк ич. Эш нәрсәдә соң?

— Мин беләм: сез — яхшы кеше.

— Әйдә, мәсьәләгә якынрак килик.

— Мәсьәләгәме,— дип, авыз-борыныннан төтен чыгарып дәвам итте Карчыга.— Сез беләсездер, мин качып киткән идем...

— Эштән качарга ярамый,— дип искәртү ясады Сабиров.

Карчыга папиросын авыз тутырып берничә тапкыр суырды да төпчеген өстәлдәге көл савытына батырды. Ул, секретарьга килгәнче, төзелеш башлыгы урынына калган Юлдашевны әзли-әзли тинтерәп беткән икән. Туры китерә алмаган. Инде туры китерсә, тегесенең эше гел тыгыз икән. Кабул итмәгән моны зур начальник. Аннары ул Сафинны күрергә булган. Аның янына барырга чыгып та, ярты юлдан кире борылган.

— Нигә борылдыгыз? — дип сорады Сабиров.

— Шулай, мин аннан куркам.

— Куркасыз?

— Әйе.

— Нигә?

— Моның өчен мин үзем гаепле, билгеле. Нигә дисезме? Васил Закирович эш вакытында тик торуны, шәләй-вәләй йөрүне бер дә яратмый. Минем ишене үзегез беләсез... Перекур с дремотой, теге-бу... Миңа аннан ничә тапкырлар эләккәне бар... Мине күргә күзләрендә утлы фонарьлар кабына аның. Ә сез менә, егетләрнең сөйләвенчә, бөтенләй башка кеше...

— Салпы якка салам кыстырмыйча гына сөйләп булмыймы? — дип, аны бүлдерде Сабиров.

Карчыга, бер җайга төшеп, салмак кына сөйли бирде.

— Кыскасы, шул: кайттым, тикшерүче янында булдым. Дядя Фарукның ничек егылуын сөйләдем.

— Сез нигә качып киттегез соң?

— Курыктым, үзем дә ни эшләгәнемне белмәдем.
— Ул ничек егылды?
— Дядя Фарукмы? Ничек уена килгәндер инде, ул төнне дядя Фарук эштән тукталган арада папирос кабызды да тимер култыксага барып сөялде. Култыксага таянган килеш тарта башлады. Күп тә үтмәде, башы белән аска һап бу! Әле генә тере кеше күз ачып йомганчы юкка чыкты, агаем.— Фарукка шундый бәхетсезлек килгән чакта Карчыга аннан дүрт-биш метр читтәрәк, бер апа белә сөйләшеп торган булган.
— Ул хатынның фамилиясе ничек?
— Сәетхужина.
— Кайда соң ул хәзер?
— Казанда больницада ята, ди.
Әле генә исеме телгә алынган ханым әлеге хәл булган көнне үк бик каты авырып китеп, һушын югалткан хәлдә, санитар самолетта Казанга озатылган иде. Сәетхужинаның бөерләре авыртып, аңа катлаулы операция ясаганнар. Хатынның хәле беркадәр арулана төшкәч, Наратлы районы прокуратурасының тикшерүчесе Казанга барып, аның үз авызыннан сөйләтеп, һәммәсен беркетмәгә язып алган.
Башта үзе качып киткәч, Карчыгага карата тикшерү органнарының чыннан да шиге туган булган. Инде хәзер ике кеше бер үк сүзне сөйләп торгач, күрсәтмәләр тәңгәл килгәч, мәсьәләгә тиешле ачыклык кергән булып чыга. Сабиров, шул рәвешчәрәк уйлап, сорый куйды:
— Димәк, сезнеңчә, Фарук Фарукшинның үлемендә берәү дә гаепле түгел?
— Гаепле,— диде Карчыга әкрен генә, басынкы бер тавыш белән.
— Ә кем гаепле?
— Ул үзе.
— Үлгән кешене ничек гаеплисең? Анысы булмый,— диде Сабиров, ни өчендер авыр сулап. Аларның гел бергә йөрүләре, бергә эчүләре турында Сабиров күптән хәбәрдар иде. Аларны адәм күзенә күренерлек сыйфатларын югалткан кыяфәттә очраткалаганы да булды. Шуларны исенә төшергәч, тагы сорамый түзмәде:
— Бу хәл булыр алдыннан эчкән идегезме сез?
— Эчкән идек,— диде Карчыга, күзен дә йоммыйча.
Карчыганың сүзләре ялган булырга тиеш түгел. Димәк, Фарук култыксага таянып аска карап торганда башы әйләнеп егылган булып чыга. Сабировның хәтер тартмасында моннан җиде-сигез ел элек булган җан тетрәткеч бер хәл калкып алды. Ул югары партия мәктәбендә укыган елларда, шулай салмыш белән хәтсез дуслашып өлгергән бер студент, тулай тораклың дүртенче катындагы баскыч култыксасына таянып торганда, аска егылып төшеп һәлак булган иде. «Бик күп бәхетсезлекләрнең башы — эчүдә. Бездә эчүгә каршы лекцияләр онытылганда бер генә була. Врачлар белән ныклы элемтәгә керәсе бар. Эчүгә каршы даими төстә көрәш алып барырга...» Бу уй Сабировның күңеленә каткат килә торды.
Карчыга әйтәсен әйтеп бетергәч тә китәргә ашыкмады. Беркадәр тын калып утыргач, кинәт әйтеп ташлады:
— Ә мине япмасларны, иптәш секретарь?
— Сез бит инде прокуратурада булгансыз?
— Әйе.
— Шулай булгач? Утыртыр исәпләре булса, сез монда йөрмәс идегез...
Сөйләшү байтакка сузылды. Ахырында Карчыга үзен элекке эшенә кайтаруда секретарьның ярдәм итүен сорады. Бервакытта да, беркайчан да тәртип бозмаска, эчүне ташларга вәгъдә итте.

Сабиров аны баштарак артык житди һәм төксерәк төс белән тыңласа, бара-тора секретарьның чырае ачылды, күзләренә көләчлек бәреп чыкты. Карчыгага ул ярым шаяртып, ярым житди итеп әйтте:

— Сез инде тормышыгызда йөз сиксән градус борылыш ясыйсыз икән, бу чәчләрегезне дә адәм рәтенә кертегез. Яп-яшь килеш жирән поплардай тузынып йөрү бер дә килешми. Сакалга инде ул кадәр бәйләнеп тә булмый, теләгән кеше үстерә бирсен.

Карчыга, партком бүлмәсендә утырган арада, беренче мәртәбә рәхәтләнеп кычкырып көлде:

— Рәтләтәм чәчне, иптәш секретарь, рәтләтәм. Менә күреп торырсыз.

— Ә эш мәсьәләсендә — кайгырмагыз, мин Васил Закирович белән сөйләшермен,— дип, жылы гына озатып калды аны Сабиров.

Карчыга чыгып киткәч, ул, мәсьәләне төбенәчә ачыклау теләге белән, иң элек прокуратурага шалтыратып сөйләште. Аннары телефонын төп корпустагы вагон-контораларның берсе — Васил Сафин кабинеты белән тоташтыруны сорады. Сафин белән сөйләшкәндә, аның тавышы басынкы, күңеле шактый тыныч иде.

## 16

Гадәти бер иртә...

Самолет алтынчы яртыда кузгалып китте. Шаулы Казан каласы үзенең әллә ничәшәр катлы зур йортлары, сорылык эчендә яшел утрау булып күренгән бакчалары, өзлексез рәвештә кырмыскалар кебек троллейбуслар, трамвайлар, автомашиналар кайнашып торган урамнары, күкләргә сузылган завод торбалары һәм жемелдәп күз кыскан сулыклары белән юлчыларны, хәерле юл теләгән шикелле, озатып калды. Андрей Акимович Никитин һәммәсен йотлыгып карады, күзләрен тәрәзәдән алмады. Әллә нигә бик якын, бик сөйкемле, әллә нигә шунда аның яшьлек елларын искә төшерде бу карт һәм шул ук вакытта егетләрдәй яшь шәһәр. Шул күз карап туймаслык шәһәр күренешләре белән бергә, кояшлы иртә аларга байтак кына ияреп барды. Һава тын, жилсез булганлыктан, һава чокырларына төшереп интектермәде, йөрәкләрне жу иттермәде. Су өстеннән йөзгән метеор кебек, тын гына йөзде самолет. Кеше күп түгел, иркен иде.

Идел киңлекләрен үтүгә, куе болытларга килеп керделәр. Көн караңгылана, күңелсезләнә барды. Куе урман эчендәге сирәк-мирәк аланлыкларга охшаган ачыклыкларга да килеп чыккаладылар. Ләкин соры болыт юрганы аларны каплап алырга ашыкты. Яңа Наратлы аэропортына шул үзләрен озата барган болытлар китереп житкерделәр.

Менә тагы бәхет! Самолеттан юлчылар төшкәндә, дөньяны балкытып кояш елмайды. Никитин, күтәрелеп карагач, көнчыгыш яктан күк битенә зәңгәрсу итәгeн сузып аязлык иңләп килүен күрде. Бу аязлык арта бара, кояштан сузылган меңләгән утлы кылычлар жир өстен томалап торган соры шәүләләргә һөжүм итәләр һәм аларны чигендерә баралар иде.

Никитин көньяк санаторийларның берсендә, йомшак һәм жылы дулкынлы Кара диңгез буенда дәваланды. Монда булуның яхшы ук файдасы да тиде шикелле — буыннары ныгып, тәнендәге сызлаулары сизелерлек кими төште. Саулыгы начар чакта врачларның теге-бу киңәшләрен, кушканнарын төгәл үтәсә һәм шуның белән юанса, сихәтлеге ныгый барган саен күңеле аны тизрәк төзелешкә тартты. Аның, бернигә дә карамастан, өйгә кайтасы килә башлады. Төннәрен йокысыннан да рәте китте диярлек. Шундый кәеф-рух белән сабырсызланып йөргән көннәрнең берсендә Солтан Сабировтан килеп төшкән хат аны юлга чакырды. Врачларның дәваланырга кирәклеге турындагы киңәшен бер якка куеп торырга туры килде.

Никитин, башка вакытлардагыча, кайчан, кайсы рейс белән кайтачагын алдан хәбәр итмәгәч, аэропортта аны җиңел машина көтеп тормый иде. Ул, юлында очраган таныш-белешләре белән күптән күрешеп, исәнлек-саулык турында сүзләр алышкач, гаражга шалтыратты. Елкылдап торган кара озынча җиңел машина озак көттермичә килеп тә җитте.

— Артык кума,— диде Никитин шоферга.

Бер як битендә зур гына миңе булган урта яшьләрдәге шофер жиз чыбык кебек тырпайган мыек очларын бөтереп куйды. Андрей Акимовичның иген басуларыннан үткәндә тын гына, онытылып карап барырга яратуын ничек исеннән чыгарып җибәргән әле ул? Ара алай бик якын булмаса да, төзелеш күренешләре — зур-зур бинaлар, таш-кирпеч пулатлар ниндидер бер серле төскә манылган панорама шикелле күренәләр иде. Алдагы иңкүлекне чыккач, еpактагы төзелеш гәүдәләнә, үсә барды. Алар арасында иң беренче булып күзгә бәрелеп торганы — кошлар очар биеклеккә күтәрелгән төтен суырту торбасы иде.

— Салып бетерделәрме? — дип, шоферга мөрәҗәгать итте Никитин.

— Бетерделәр! Әле кичә генә башына байрак куйдылар.

«Бу труба ике блокка хезмәт күрсәтәчәк. Футеровканы ашыктырырга кирәк»,— дип уйлап алды башлык.

Нигезенә ком түшәп, аның өстенә вак чуер таш салынган тигез юлда былчыраклык, юешлек беленми. Тик вак ташларның машина артыннан черт-черт чиертеп калулары гына ишетелә иде. Ә ул читләрендә урыны-урыны белән күлләвекләр күз ялтыратып калалар. Юлның сул ягында арыш басуы, уң ягында ефәк шәл чукларын талгын гына селкеп утырган кукуруз кырлары китә. Дымлы, саф кыр һавасы ачык тәрәзәдән ургылып-ургылып машинага керә һәм әле мичтән генә чыккан кайнар икмәкне искә төшереп, әле бал исен хәтерләтеп, кәеф-рухларны хушландыра, күңелгә әйтеп бетергесез бер рәхәтлек сала иде.

— Бик каты яуган, ахры, бу тирәләрдә?

Шофер үзе белән янәшә утырган Никитинга таба башын янтайтыбрак җавап бирде:

— Өч көн буена туктамады яңгыр. Бер сибәләп, бер чиләкләп коеп торды. Әле менә сез кайтыр алдыннан гына болытлар тарала башлады, Андрей Акимович.

— Алайса, мин җиңел аяк белән...

— Шулайга охшый,— дип елмайды шофер.

Сагынып көтелгән кунакны каршылаган төсле җылы, иркәләгеч дулкыннар кочагында тын гына барганда, саргылт-аксыл теземнәр, аннары урылмаган кишәрлек ягасында бер-берсеннән ерак булмаган комбайннар күренде. Яңгыр яву сәбәпле хәрәкәтсез торган бу зур машиналар Никитинга ничектер кызганыч сыман тоелды. Хәтта ул аларны көзен күл буенда бер аякларын канатлары астына яшереп, сыңар аякта тын гына йокымсыраган казларга охшатып куйды. Озакламый шунда таба мотоциклга, моторлы велосипедларга утырып, басуларга килүче механизаторлар очрый башлады.

— Акъяр егетләреме?

— Әйе, Андрей Акимович.

Тиздән Иске Наратлы артта калды. Сулыкның тимер-бетон белән ныгытылган буасы өстендәге тигез юлдан әллерде. «Нинди шәп! Әйтерсең лә Кара диңгез буе»,— дип уйлап алды Никитин. Хәзер инде төзелешкә якынайгач, күк гөмбәзенә барып терәлгәндәй, мәһабәт торбаның башында кызыл байрак җилфердәвен күреп, ул рәхәт тойгыларга бирелде.

Өйдәгеләр бик сагынганнар иде аны. Хатыны Роза Павловна кочагын җәеп каршы алды, күзенә чыккан яшьләрен сөртте. Ләкин Никитин өйдә артык юанмады. Санаторийда ничек ял итүен, андагы шартлар, көньяк табигате, һаваларның торышы турында чәй эчкән арада кыска-

кыска гына итеп сөйләде дә төзелешкә китте. Роза Павловна иренең болай иртә кайтуының сәбәбен белә, партком секретаре Никитинга ашыгыч хат язуы турында аңа әйткән иде. Алай да, ай күрде, кояш алды, дигәндәй, Андрей Акимович шулай җәлт кенә чыгып киткәч, хатынына ни өчендер ямансу булып китте. Ул ашыкмый гына табын җыярга керешге.

Партком секретареннан хат алгач, Никитин Юлдашев белән бергә эшли башлаганнан бирле булган хәлләрнең һәммәсен, һәммәсен күз алдына китерергә тырышып, зиһененнән үткәрде. Юлдашевның төп проблемаларны, төп эшләрне бер читкәрәк куеп, икенче һәм өченче чираттагы — күләме ягыннан кечкенәрәк эшләр, прораб яки участок башлыклары шөгыльләнергә тиешле эшләргә кул-аягы белән чат ябышуы Никитинга электән дә ошамый, ул аны бу хакта искәрткәләп тә тора иде. Инде хәлләр бу чиккә килеп җиткәч, ягъни бу сыйфатлар янына куркаклык, эчкерлелек, вак җанлылык һәм карьеристлык хисләре дә өстәлгәч, аның алдында ул бөтенләй чит-ят кеше булып күренә башлады.

Никитин үзе ялда чакта аның кабинетында Юлдашев шөгыльләнгәнен белә иде инде. Ничектер бу минутларда кабинетка аяклары тартмады. Иң элек, Юлдашев белән очрашканчы, Никитинга башкаларны күрергә кирәк иде. Ул, конторага килеп кергәч тә, икенче каттагы үз кабинетына күтәрелмәде. Буяу исе бетеп җитмәгән, салкынча, тар коридорның бер як башына урнашкан партком бүлмәсенә керде. Солтан аның кайтканын ишеткән иде инде. Төзелеш башлыгын күргәч, ул урыныннан торып, өстәл артыннан чыкты да кочаклашып күрештеләр.

— Исән-сау гына кайттыгызмы, Андрей Акимович?

— Күрәсез, сезнең хәер-фатихагызда,— диде Никитин.

— Сездә чын көньяк төсе. Яшәргәнсез кебек.

— Комплиментыгыз өчен рәхмәт, Солтан Сабирович!

— Сезне борчырга туры килде инде,— диде Сабиров, гафу үтенгән тавыш белән.

— Зарар юк.— Никитин калын тавышы белән көлеп куйды.— Эш интересы кушкач — кая барасың? Дөньяда төрле хәлләр була, һич көтелмәгән каршылыклар килеп чыга...

Бер-ике минут сүз алышкан арада, секретарь өстәленә тоташтырылган озынча өстәл янында аларга арты белән утырган кеше, уңайсызлана калды булса кирәк, урыныннан торып, ишек катына килә башлады.

— Ник кузгалдыгыз, утырыгыз,— диде Сабиров.

— Мин бүтән вакытта килермен...

Бу кешегә Никитин да игътибар итте. Ул аңа күзләрен төбәп, җентекләп карап торды да белгеннән тотып алды:

— Болай мыеклар җибәргәч, сине танырлык та түгел, иптәш... Гафиятуллин! Син бит идарәнең Почет тактасында...

— Әйе, Андрей Акимович.

— Пар казанын күккә күтәрешәсең! — Никитин кулларын югары күтәреп өскә күрсәтте.

— Так точно, иптәш начальник!

— Ничек соң, эшләр барамы?

— Бара!

— Экскаваторыңны сагынмыйсыңмы?

— Сагынсам, кире кайтып булыр ич? Ә хәзергә көн кадагында — монтажлау.

— Әлбәттә, беренче номерлы эш, бурыч — монтажлау хәзер, Зиннур дус!

Никитин төзелештә даими эшләүчеләрнең бик күбесен белә, аларны тантаналы җыелышларда гына түгел, эшли торган урыннарында да әледән-әле күреп йөри иде. Ул, бер Сабировка, бер Гафиятуллинга карап, ярым шаяртып күз кысты:

— Нәрсә, әллә партиягә кодалыймы секретарь?
— Әйе,— дип югалыбрак калды Зиннур. Үзенең яңакларына кызыллык йөгерде.
— Инде кодаладык! Ике коммунисттан рекомендация бар,— диде Сабиров.
— Ә өченчесе?
— Сез кергәндә менә шул турыда сөйләшеп утыра идек әле,— диде Сабиров.
Никитин, куе кашларын бер кушып, бер аерып, калын тавышы белән кычкырып әйтте:
— Бу да безнең беренче номерлы бурыч бит, Зиннур дус.— Никитин аңа дустанә карап торды.— Мин сезне ике елга якын беләм ич. Төзелешкә Васил Закирович Сафин белән бергә килеп төштегез.— Никитин нәк очын кашып алды:— Өченче рекомендацияне үзем бирсәм, риза булырсызмы?
— Ник риза булмаска, әлбәттә, риза,— диде ике тавыш берьюлы.
Парткомнан Зиннур Гафиятуллин күтәренке күңел белән чыгып китте.
Никитин куанып әйтә куйды:
— Кешеләр үсә! Мондый егетләр бар чагында әллә нинди зур эшләр дә куркыныч түгел. Партиягә керәләр. Иң алдынгы сызыкта барырга телиләр һәм баралар.
— Бу айда производство алдынгыларыннан унбер кеше партиягә керергә гариза бирде,— диде Сабиров.
Никитин «Т» хәрефе рәвешендә куелган өстәлләрнең бер башына барып утырды. Сабиров та аңа якын гына икенче урындыкка күчте.
— Вакытында «кыңгырау шалтыраткан» өчен рәхмәт сезгә, Солтан Сабирович,— дип, янә ашыкмыйча гына сүз башлады Никитин.— Шулай булмаганда кайбер кайнар башлар төзәтеп булмаслык хаталар ясап ташларлар иде. Мин инде күңелемнән катгый карар кабул иттем. Ләкин кайбер ачыклыйсы детальләр, мәсьәләләр бар...
Төзелеш башлыгы, Сафинга тагыла торган барлык гаепләр турында партком секретареның әйткәннәрен игътибар белән тыңлаганнан соң, авыр сулап алды да:
— Сезнеңчә, ничек, Солтан Сабирович, бу Юлдашевка ни җитми? — дип сорады.
— Кешелек җитми, Андрей Акимович, кешелек.
— Димәк, без күреп җиткерә алмаганбыз, аның башында андый уйлар бер бүген генә тумагандыр ич? Күптән...
— Минемчә дә күптән...
— Ул башындагы мәкерле исәпләрен гамәлгә ашыру өчен уңайлы форсат кына көтеп йөргән булган. Аңа дөнья тарая башлаган.
— Бөтен хикмәт тә әнә шунда шул, Андрей Акимович. Юлдашев курка. Беренчедән, ул һәртөрле яңалыктан курка. Әзер, тапталган юлдан гына барырга күнеккән ул. Икенчедән, иртәме, соңмы, ул үзенең җитәкчелек арбасыннан төшеп калырга тиешлеген дә бик яхшы чамалый...
— Сез әйткәннәргә ике куллап кушылам, Солтан Сабирович. Баш инженер урындыгына икенче берәүнең килеп утыру ихтималыннан, һичшиксез, курка Юлдашев. Әле аның анысы бер хәл. Үзенең йомшый башлаган позициясен саклап калу өчен гаять былчырак юлга, башкаларга яла ягу юлына басуы — монысы инде, йомшак кына итеп әйткәндә — акылга сыймый торган хәл. Бу инде аның түбән тәгәрәве. Утыз җиденче еллар алымы...
Никитин да, Сабиров та Юлдашев аның төзелеш башлыгының озак авырып, сафтан чыгуын көтеп йөрүен, аннары дилбегәне үз кулына алырга өметләнүен белмиләр һәм ул турыда уйларына да китерә алмый-

лар иде әле. Шулай да үзенә уңайсызлаган кешене юлдан алып ташларга бик нык ниятләгән булуы һәм аның урынына төзелештән төзелешкә үзенә койрык шикелле тагылып йөргән берәүне куярга исәп тотуы Сабировка билгеле иде. Үзе көткән форсатның кичектерми килүе Юлдашевны яхшы ук канатландырган иде.

— Инде бер сүз чыккач, әйтим,— дип дәвам итте Сабиров.— Юлдашев үзе күерткан ботканың тәмам пешеп чыгачагына нык ышанып тотынган. Аның инде «янганнар» урынына кандидатлары әзер. Мәсәлән, ул Касаткинны баш инженер урынбасары итеп куймакчы.— Сабиров, моннан тыш та Юлдашевның житәкче эштәге байтак кешеләрне алмаштырып, үзенә тугрылыклы кайберәүләрне куярга җыенуы турында әйтергә дә онытмады.

— Аңлашылды,— диде Никитин.— Бик күп мәсьәләләр ачыкланды. Рәхмәт сезгә!

Партком бүлмәсеннән чыккач, Никитинның әле һаман үз кабинетына керәсе килмәде. Аңа, ничек кенә булмасын, Главка вәкиле Фирсовны күреп сөйләшергә кирәк иде. Бу көннәрдә, башкалар белән бергә, эш көненең күпчелек өлешен аның да төп корпуста уздыруын белә иде инде ул. Шулай, ул уйлаганча булып та чыкты. Никитин аны, Васил Сафин белән бергә, электр цехында очратты. Сөйләштеләр. Карап йөрделәр. Никитин үзе дәваланган арада төзелештә бик күп үзгәрешләр булуын, эшнең күзгә күренеп үрчүен абайлады.

Кешеләр арасында беркадәр юангач, алар өчәүләшеп вагондагы Сафин кабинетына керделәр.

## 17

Шул ук көнне, кичтән сөйләшенгәнчә, Юлдашев райүзәккә юл тотты. Гусев, кабинетында ялгызы гына, терлекчелек продуктларының үтәлешенә кагылышлы соңгы мәгълүматларны күздән кичереп утыра иде. Җылы гына күрештеләр. Юлдашев секретарь өстәле каршына куелган йомшак креслога чумды. Гусев бер алдындагы мәгълүматларга, бер Юлдашевка күз төшереп сөйләп китте:

— Сөт белән эшебез рәтләнә шикелле. Уртачалар янына бик кызу атлап барабыз. Ит белән начаррак, аксыйбыз. Йомырка планы ярыйсы гына бара.

— Председательләрне җыеп сөйләшүнең файдасы бар, димәк?

— Ничек кенә әле! Кешеләрнең исләренә төшереп, тәнбиһләп тору ул профилактика кебегрәк була.

— Мин үзем дә шул фикердә,— дип, Юлдашев Гусев әйткәннәр белән ризалашып, елмаеп куйды.

— Урак өсте дип, бүтән эшләрне дә оныту ярамый бит. Сөте дә, мае да кирәк. Әнә эшче сыйныфы үзебездә генә дә нихәтле?

— Шулай, Федор Кузьмич, шулай. Ә кайсы хуҗалыклар бик артка сөйри соң?

Гусев аңа бераз әсәренеп карап калды:

— Алай бик артта калучылар юк инде хәзер. Шулай да йөкне бик тигез үк тартмыйбыз әле.

Гусев колхозлар турында бик җәелеп тел тибрәтә башлагач, Юлдашев, житәр инде дигән сымак, тамак кырып куйды. Ләкин тегесе бу искәртүне колагына да элмәде, һаман уйларыннан аерыла алмый иде. Менә ул авыл хуҗалыгы техникасы турында сөйли башлады:

— Әле безнең хуҗалыкларда бульдозерлар житеп бетми. Сезнең көчле төзү оешмасы, бер мөмкинлек табып, минемчә, безне куандыра алыр иде.

Шулай дигәч, Гусев мәгънәле генә итеп Юлдашевка карады. Юлдашев аның төп мәсьәләгә якын килмичә, һаман читтән-чаттан уратып сүз

бертүенә борчылып утырса да, ни кылсын, бу урында һәм бу минутларда ул аннан узып эш итәр хәлдә түгел иде. Менә тагы нинди четерекле мәсьәлә куя бит әле ул аның алдына. «Бульдозерлар кирәк. Кирәктер анысы. Хәер, мондый таләптән дә баш тартып булмый инде. Бигрәк тә хәзер, менә шушы көннәрдә». Тик аның өчен яшәү белән үлем кебек җитди мәсьәләне генә хәл итсен. Әйе, бөтен җепләрнең очы Гусев кулында... Шуларны җәһәт кенә уеннан кичерә-кичерә, Юлдашев әйтеп салды:

— Ярдәм итәрбез, билгеле. Минем исемгә заявка язсыннар. Механик мастерской мөдиренә тиешле күрсәтмә бирелер.

Беразга икесе дә тын калдылар. Юлдашев түземсезлек белән секретарьның янә сүз башлавын көтте. Ул арада кемдер телефоннан шалтыратты. Гусев телефоннан сөйләшкәндә нигәдер бармаклары белән өстәлгә шакып, гасабиланып утырды. Таралган уйларын җыеп алгандай, бераз тын утыргач, ул тыныч тавышы белән сүз какты:

— Без берсекөнгә бюро утырышы үткәрмәкче булдык. Сафин эше көн тәртибендәге өченче мәсьәлә булып тора. Бу төенне чишеп, «капчык»ны бушатырга кирәк. Җитте!

Юлдашев сагая калды, күзләрен челт-челт йомып алды:

— Узган бюродагы кебек скандал булмастыр бит бу юлы?

— Булмаска тиеш, Зариф Салихович. Нигә дисәгез... Бюро членнарының берсе,— сүз ике арада гына калсын,— райфо мөдире больницадан чыкты. Ул комиссия материаллары белән таныш. Мәсьәләне дөрес аңлый сыман. Ә элекке утырышта каршы тавыш бирүчеләрдән ике иптәш өйдә юклар.

Юлдашевның чырае ачылды, күз төпләрендәге күләгәләр югалган кебек булды. Гусев белән дустанә хушлашкач, Юлдашев, икенче кат баскычтан төшеп килгәндә, Сабиров белән очрашты. Икесе дә, аяк кагып, исәнләшеп узып киттеләр.

Юлдашев, урамга чыгып, җиңел машинага утырырга барганда янә бер кешегә очрады. Озын буйлы, өстенә көрән төстәге бостон костюм кигән, күлмәк якасын ачып җибәргән, бер кулына саржа плащ, икенче кулына сары күн портфель тоткан урта яшьләрдәге бу кеше Юлдашевка таныш түгел иде. Шулай да алар бер-берсенә сәлам биреп уздылар.

Кабинетка Сабиров килеп кергәч, ниндидер кәгазьләргә күмелеп утырган Гусев башын күтәрде. Күрешкәч, ул ябылып бетмәгән ишеккә карап алды. Түзмәде. Урыныннан торып, ишекне ябып килде. Утырыштылар. Гусев, сүз башлаганчы, өстәл артында утырганда кулыннан сирәк төшә торган карандашын бармак араларында уйнаткалап алды. Зиһенен җыеп, сүзгә кереште:

— Ник чакырганымны беләсездер инде?

— Андый гыйлемем юк. Әйтсәгез — белермен, Федор Кузьмич.

Гусев һәр сүзен сузып-сузып дәвам итте.

— Алайса, әйтим: сезгә ялгыш позициягезне үзгәртергә кирәк булыр, иптәш Сабиров.

— Нинди позицияне?

— Үзегез беләсез сүз ни турыда барганны.

— Белмим. Ачыграк сөйләсәгез икән, Федор Кузьмич.

— Ярый. Тыңлагыз. Берсекөнгә бюро. Сез узганда да райком линиясенә каршы чыктыгыз. Һәрбер мәсьәләне хәл кылганда, зурмы, кечкенәме ул, шуларның берсенә дә карамастан, бердәмлек булырга тиеш. Сез, зур тәҗрибәле партком секретаре буларак, моны бигрәк тә исегездә тотарга тиеш идегез...

Сабиров мондый сүзләрне беренче секретарь урынына калган кешедән ишетүенә ышанмаска тырышты. Ләкин ышанмый мөмкин түгел иде. Гусев исә башлаганын тагы да куерта төшкәч, Сабиров та түземлеген саклап кала алмады, яхшы ук яңгыраулы аваз белән әйтте:

— Сүз коммунист Сафин турында бара икән, минем карашым үз гәрмәячәк. Райком комиссиясе бу турыда парткомның фикере белә тиешенчә исәпләшмәде әле.

— Мин сезне анламыйм,— дип дәвам итте Гусев.— Уйлагыз, иптәш Сабиров, таяк ул ике башлы. Соңыннан үкенергә туры килмәсен...

Нәкъ шул сүзләр әйтелгәндә, әле бая гына райкомнан чыгышлы Юлдашевка очраган озын буйлы, көрән костюмлы кеше кабинетк килеп керде. Сүзләр бүленеп калды. Бу иптәш — өлкә комитеты инструк торы иде. Гусев аны каршыларга өстәл артыннан торды. Өчесе дә исән ләштеләр. Аннары Сабиров, китәргә җыенып, урыныннан кузгалды Гусев аңа:

— Сезнең белән соңыннан... Үзем чакыртырмын,— диде.

Сабиров ишек катына таба берничә адым атлап өлгермәде, инструк тор бер кулын күтәреп әйтә куйды:

— Калсын. Ул кирәк безгә...

Поселок читендәге ике катлы ак таш йорттан кешеләр өзелеп тор мый. Төзелеш идарәсе урнашкан шул йорт алдында еш кына җинел машиналар, мотоциклляр туктап торганын күрәсең. Әле генә райкомнан кайтып төшкән Юлдашев күзләре күптән күнеккән мондый күренешк игътибар итмәде. Салмак кына атлап, икенче катка күтәрелде. Ишек тән керүгә, артык зур булмаган бүлмәдә, сулышка рәхәт ята торган хушбуй һәм пудра исләре аңкытып, секретарь-машинистка утыра. Шул бүлмәнең уң ягында — төзелеш башлыгы, ә сул якта — баш инженер кабинеты — аның төп эш урыны. Никитин өйдә чакта Юлдашевка ничектер күңелсез, кыенрак иде. Бусагадан атлап кергәндә аның тәненнән калтырау йөгереп үтә, маңгаена салкын тир бәреп чыга торган иде. Хәзер ул — бәлки күпкә, бәлки бөтенләйгәдер, үзе хуҗа. «Кеше бер туза башласа туза бит ул. Никитин кебекләргә хәзер иң яхшы урын — санаторий. Аннары, бәлки,— пенсия».

Юлдашев, башыннан шундыйрак уйлар кичереп, ишек тоткасына кулын салды. Ачыйм дисә, ишек ачылмады. Аны секретарь-машинистка ачты.

— Андрей Акимович кайтты.

— Кайтты? — дип сорады Юлдашев, айнып киткән кебек.

— Әйе, Зариф Салихович.

— Кайчан?

— Иртәнге якта ук, сез райкомга киткәч.

— Алай икән...— дип пошаманланган төстә сузып әйтте Юлдашев.

— Үз кабинетыгызның ачкычын алыгыз, Зариф Салихович.

Секретарь-машинистканың ни әйткәннәрен ишетмәгән кебек, шулай да ул сузган сырлы-яссы ачкычны кулына алып, Юлдашев үз кабинетына юнәлде. Аның йөрәге кысып-кысып чәнчешеп куйды. Өстәле артына барып утыргач, аның күңелен кимерә башлаган тынычсызлык тагы да катырак үч итәргә тотынды. Ул, ни эшләгәнен белмәгән төсле, өстәлендә тәртипле генә яткан папкаларны бер урыннан икенче урынга күчерде, ниндидер кәгазьләрне учына йомарлап, чүп-чар кәрзиненә ташлады. Аннары бармакларын батырып сирәк чәчләрен рәтләп куйган итте. Өстәлнең бер читендәге ак төймәгә басып, секретарь-машинистканы чакырды. Аңа башлык өстәлендә яткан үз кәгазьләрен китерергә кушты. Инде болар барысы да эшләнгәч, мөмкин кадәр тыныч күренергә тырышып сорады:

— Андрей Акимович мине сорамагандыр?

— Юк, сорамады.

— Ул хәзер кайда икән?

— Проммәйданда булса кирәк.

— Ярый, мин занят,— диде Юлдашев.

Алар арасында шуннан артык сүз булмады. Секретарь-машинистка, песи кебек кенә басып, кабинеттан чыкты һәм тыгыз итеп ишекне япты. Ул инде Юлдашевның холкын-гадәтен белә, аның янына берәүне дә кертмәс һәм телефоннан шалтыратучыларга да: «Юк!» — дип кенә җавап бирер.

Нигә болай иртә кайтып төште Никитин? Бөтен эшкә аяк чалып куймасмы?

Хәзер бу минутларда Юлдашевның күңелен әнә шундый сораулар борчый, ул аларга анык җавап бирә алмыйча иза чигә, ләкин аның Никитин белән һич кенә дә очрашасы килми иде. Шулай төрле-төрле исәпләргә күмелеп утырганда, аның каршына Дина Гурская килеп баскандай булды. Әгәр менә хәзер Диночка белән очрашса... Урманга ук китсәләр? Юк! Булмый! Дина байтактан инде, Фарук Фарукшин һәлак булгач, үзен техник куркынычсызлык саклауның торышын тикшерү комиссиясенә керткәннән бирле, аңа йөз чөереп карый. Аларның аралары өзелде. Бары тик анда-санда күрешкәндә салкын сәламләшүләр, берәр эш турында телефон аша сөйләшүләр генә калды. Берәр җаен табып, аны хезмәт нигрәсенең түбәнрәк баскычына төшерәсе булыр»,— дип уй йөртте Юлдашев.

Ул шулай үз-үзе белән сөйләшкәндә, ишектә секретарь-машинистка күренде. Юлдашев аны күрмәде, кабинетка кергәнен дә сизмәде.

— Зариф Салихович, сезне химиклар шәһәреннән Брагинский сорый,— диде секретарь.

— Искәрттем бит инде мин сезне... занят дип.

Секретарь-машинистка бүлмәнең нәкъ уртасында торса да, хатын-кызлар гына тәмен-ләззәтен белеп чәчләренә һәм киемнәренә сөртә торган әйбәт хушбуй исе Юлдашевның борынына килеп бәрелде. Машинистка, сулышы капланганддай, башлаганын әйтеп бетерергә ашыкты:

— Ул сезне бик нык үтенеп сорый. Каян булса да табарга куша...

— Сезгә әйтелгән бит инде...

— Беләм. Ләкин ТЭЦ төзелешендә шундый зур мәсьәлә килеп чыкты, аны бары Зариф Салихович кына хәл кыла ала,— ди иптәш Брагинский.

— Һы, менә сиңа,— дип, һич тә теләмичә Юлдашев телефон трубкасын алды. Хәтсез сөйләштеләр, бәхәсләштеләр дә бугай. Юлдашевның тавышы бер чыгырыннан чыгып көчәйде, бер гадәти агымга төште. Телефон трубкасын куйгач, ул өстәл читендәге ак төймәгә басты. Секретарь янә керде.

— Гаражга шалтыратыгыз.

— Ярый, Зариф Салихович.

Күп булса, ун минут вакыт үтмәгәндер, секретарь машинаның килүен хәбәр итте. Кая барса шунда үзеннән калдырмый торган кара күн тышлы папкасын кулына тоткан Юлдашев секретарь-машинисткага карамыйча гына әйтте:

— Чыннан да, бик мөһим эш икән. Мин химиклар шәһәренә киттем. Бәлки, бүген кайтмам да. Сораучы булса әйтерсез.

## 18

Ул берәр җирдән командировкадан йөреп кайтамы яки башка берәр эш белән озаграк тоткарланамы — төзелешкә кайтып төшүгә, үзен жепнең очын бераз югалткан сыман хис кыла башлый. Чөнки ул китеп торган арада азмы-күпме үзгәрешләр булмый калмый. Шул үзгәрешләрне үз күзләре белән күргәч, шуларны мәйданга китерүче кешеләр белән күреп сөйләшкәч кенә күнеле утыра аның. Никитин бүген дә, әле теге участокта, әле бусында кешеләр арасында әвәрә килеп йөри-йөри, вакытның ничек үткәнен сизми дә калды. Ут көлтәләре чәчеп эшләүче

монтажчылар янынннан киткәннән соң, турбина җыючылар янында шактый юанды. Генератор детальләренең ничек җыелуы белән кызыксынды. Аннан кала, торак йортлар, мәктәп һәм балалар бакчасы төзелешләрендә дә булырга җитеште. Ул, үзе санаторийга киткәч, торак-көнкүреш биналары салучыларның элеккечә ике сменалап эшләүләре урынына, Юлдашев приказы нигезендә, бер сменага күчүләрен белде. Уйланды. Кашларын җыерды. Юлдашев бу приказны беренче энергоблокка бәйләнышлы барлык эшләрне тизләтү теләгеннән чыгып биргән булса кирәк. Бер яктан, бу хәл белән килешмичә мөмкин дә түгел кебек. Әмма, Никитинга калса, торак төзелешендәге эшчеләрнең шактый өлешен проммәйданга күчерүдән әллә ни отыш күренми. Ул проммәйданда тәрәзәләргә пыяла кую, ишекләр утырту, түбә ябу һәм җир мәйданнарын тигезләү эшләрендә кешеләрнең кирәгеннән артык күп булуын, кай урыннарда хәтта бер-берсенә комачаулауларын үз күзе белән күрде. «Дөрес, проммәйданда — беренче чираттагы эшләр. Алай да икенче сменалардан алынган эшчеләрнең, барысын булмаса да, яртысыннан артыгын тагы үз урыннарына кайтарырга кирәк булыр. Ничек инде, бер тармак йөгерә, икенчесе аксый?» — дип уйлады.

Андрей Акимович өенә соң гына кайтты. Тәнендә талганлык, арыганлык сизмәде. Күп йөргәннән соң, тез буыннары да сызлап теңкәсенә тимәде. Күрәсең, ял итү — дәвалану тала башлаган организмга шифа салгандыр.

Ул өенә кайтып кергәндә, сәгать теле төнге унберенчегә үрмәләгән иде инде. Әле йокларга ятмаган Роза Павловна аны ят тавыш, ятрак төс белән каршылады:

— Нигә бу хәтле соңгардың?.. Бераз үзеңне саклый да белергә кирәк. Тагы бер мәртәбә лапылдап егылсаң, аннары яңадан аякка басуы читен булыр.

Андрей Акимович, хатынына сабыр гына карап:

— Хәзер егылырга исәп юк, Розочка. Ныгыдым шикелле,— диде.

— Ничә тапкыр ужин җылыттым, ничә тапкыр чәй яңарттым, син юк та юк,— диде хатыны, йомшый төшеп.

— Тынычлан, Розочка.

Ирен көтә-көтә зарыккан хатын табынны тиз әзерләде. Андрей Акимович бүтән чакларда: «Төнге якка ашказанына авыр була» дип, ужинны аз ашый торган иде. Компот яки чәйне дә аз эчә торган иде. Иренең тәлинкәгә тутырып салган гуляшны тиз генә ялтыратып куюына, берничә телем икмәктән дә җилләр исүгә, җитмәсә тагы, өченчеме-дүртенчеме стакан чәй эчүенә Роза Павловна гаҗәпләнеп иңбашларын сикертте.

— Сиңа ни булды, Андрюша, төнге якка авыр булмасмы?

— Булмас, кайгырма,— дип көлде ире.— Көне буе диярлек баш эшләде дә аяклар эшләде, ашказаны ял итте. Төнен эшләп карасын әзрәк.

Җәй кояшы шулай бит инде, үзе дә аз йоклый, кешеләргә дә, дөньяларын онытып, озак йокларга юл куймый. Соңгарып кына уятуына карамастан, җылы нурлары белән тәннәрне кытыкларга керешкән кояшның шаяртуына җиңеләеп, Андрей Акимович тиз генә урыныннан торды.

Капка төбендә аны җиңел машина көтеп тора.

Әйдә, төзелештән бер урап кайтсын әле.

Бер сәгатьтән артыкка сузылган көндәлек оператив киңәшмәне үткәргәннән соң, агымдагы эшләргә күмелә барган Никитин үз кабинетында калды.

Ул көтте...

Әллә ничә тапкыр беләгендәге сәгатенә күз төшереп алды.

Төштән соң Главка вәкиле Фирсовка Мәскәүгә шалтыратып сөйләшергә кирәк иде. Моның өчен иң җайлы урын — Никитин кабинеты. Партком секретаре Сабиров килеп кергәндә, өлкән яшьтәге бу ике кеше — Никитин белән Фирсов — стеналарга эленгән сызымнарның бер-

се турысына тукталып, гәпләшеп торалар иде. Сөйләшкән арада Никитин тагы сәгатенә карады.

Юлдашев көннең яртысы авышкач кына химиклар шәһәреннән кайтып төште. Барысы белән дә күрешеп чыккач, ул, үзен тәкәллефле генә тотып, Никитин каршына барып утырды. Аның йөрәге леп-леп тибә, кешеләргә күтәрелеп карыйсы килми, авыз ачып сүз әйтергә теле авырая сыман иде. Ул шулай гәүдәсенә, башына инә башлаган авырлык белән тартышканда, Никитин үзе башлап җибәрде:

— Анда эшләр ничек? План үтәлеше? Брагинский нихәлләрдә ята?

Бу сорау Юлдашевны уятып җибәргәндәй булды. Ул иелгән башын күтәрәрәк төшеп, креслода тураеп утырды да бер-ике сүз белән генә химиклар шәһәрендә салына торган ТЭЦ төзелешендә эшнең ничек баруы турында сөйләп бирде. Анда байтак кына техник җиһазлар килгән икән инде. Тиздән монтажчылар эшкә тотынырга тиеш булачаклар. Бу мәсьәләне Брагинский үзе ерып чыга алмый. Яна Наратлы электр станциясе үз монтажчыларының бер өлешен аларга җибәргәндә генә өзеклек тумаячак... Юлдашев та әлегә бу мәсьәләне хәл кыла алмый кайткан.

— Ярый, мөмкинлекләребезне бергә-бергә үлчәп карарбыз, уйлашырбыз,— диде Никитин. Аннары елмаеп өстәде:— Монда, брат, ничек тә рәтен табарга кирәк. Сарыклар да исән калсын, бүре дә тук булсын, дигән кебегрәк килеп чыга.

Нинди генә шартларда булмасын — баш инженер бит әле ул. Юлдашев Юлдашев булып калырга тиеш. Ул, барлык көчен җыеп, өстәл тирәли утырган Сабиров һәм Фирсовларга сөзеп карап алды, аннары башын Никитинга таба борды, кылана төшеп, сүзне икенчегә борды:

— Сез һаман да эш, эш дип борчыласыз. Ә сихәтлегегез ничек соң, Андрей Акимович? Иң мөһимен читләтеп үтмик әле.

— Болай ярыйсы сизәм үземне. Зарланырлык түгел сыман. Диңгез буе, көньяк һавасы буыннарны азмы-күпме ныгыткандыр дип уйлыйм.

«Ай-һай, бик ашыгып кайткансыз. Сезгә кимендә өч-дүрт ай ял итәсе иде әле. Аннары да эшкә тотынырга соң булмас иде. Ашыккансыз»,— дигән сүзләр әйләнде Юлдашевның күңелендә. Ләкин ул, бу тиклесен тел очында калдырып, башкачарак әйтте:

— Билгеле, сезнең кайтуыгыз яхшы. Әмма соңыннан, сихәтлек ягыннан, мин әйтәм, авыргарак килмәсә? Бу тиклесен дә онытып бетерү ярамый. Үкенерлек булмасын...

— Әгәр шундый яхшы теләкләрегез бар икән, анысы өчен рәхмәт,— диде Никитин.

Ничек ул, Юлдашев күңелендә ана карата начар теләкләр бар дип уйлыйммы икән әллә? Никитинның бу соңгы сүзе аны азмы-күпме сагаерга мәҗбүр итте.

— Димәк, сез эшли башладыгыз да инде?

— Күрәсез, тәгәрәтергә тырышам тормыш тәгәрмәчен.

Юлдашев өстәл тирәсендә утыручыларга, аларның үзләренә сиздермәскә тырышып кына тагы күз йөгертеп алды. Көтмәгәндә генә кайтып, аның барлык уйларын, планнарын юкка чыгару ихтималы булган башлыкны төзелештәге үзгәрешләр, яңалыклар белән таныштырырга кирәк санап, Юлдашев сүзен дәвам иттерде:

— Хәер, сез түзеп утыра торган җитәкче түгел шул. Кайбер объектларда үзегез дә булгансыздыр. Әйтергә теләгәнем — мондагы хәлләр белән яхшы ук танышкансыздыр, дим. Әмма мин, вакытлыча төзелеш начальнигы хезмәтләрен үтәүче һәм баш инженер буларак, сезне һәрбер объектта эшнең ничек торышы, производство планнарының ничек үтәлеше белән таныштырырга һәм алда торган бурычлар турында сезгә тулысынча информация ясарга тиешмен...— Юлдашев, ара-тирә алдындагы мәгълүматларга күз төшергәләп, тәфсилле рәвештә сөйләп чыкты.

— Рәхмәт,— диде Никитин гадәти калын тавышы белән беркадәр үгез мөгрәгәнне хәтерләтеп.— Мин инде гомуми агылышка, гомуми дулкынга кереп киттем кебек.— Ул Юлдашевка текәлеп карады.

— Шулай булсын,— дип, салкын гына бер төстә әйтеп куйды Юлдашев.

Берничә минутлар буе берәү дә сүз кушмады. Инде Юлдашев үз кабинетына чыгарга җыенганда гына, Никитин авыр карашын аңа юнәлтеп сорый куйды:

— Бүтәнчә яңалыклар юкмы тагы?

Юлдашев аптырый калды. Никитинның тел төбе кай якка тартканын шундук төшенеп алды. Ул, өстәлгә терсәкләре белән таянып, алдына туры караган килеш сөйләп китте:

— Аннары тагы бер бик мөһим мәсьәлә турында сезгә әйтергә тиешмен, Андрей Акимович.— Юлдашев Сабиров белән Фирсовка каш астыннан гына карап алды.— Бәлки, ул турыда иптәшләр сезгә сөйләгәннәрдер дә инде. Төзелештә зур һәм җаваплы эш башкаручы Васил Закирович Сафин,— хәер, миңа бу хакта сөйләве бик күңелсез булса да, бу фактка күз йомып карап булмый,— үзен акламады. Райком...

Юлдашев авызыннан мондый шомлы сүзләр ишеткәч, Никитин, түземлеген югалтып, аны бүлдерде:

— Ничек акламады? Төшенмим. Производство планнарының үтәлеше әйбәт бит. Монтаж эшләре дә җырлап бара! Төзелеш графигының үтәлеше турында әле генә үзегез сөйләп күрсәттегез. Монда сезнең үз сүзегездә каршылык килеп чыга түгелме соң?

Никитин тынып калгач, Юлдашев янә бер эзгә төшеп сөйләп китте:

— Юк, каршылык килеп чыкмый, Андрей Акимович. Әйтик, график төгәл үтәлә яки арттырылып үтәлә икән, бу — коллектив эше. Аерым кеше эше түгел.

«Ничек инде бу? Производствода житәкчелек ролен инкарь итә. Бу рәвешле аның үзе турында да әйтеп була бит»,— дип уйлап утырды Никитин. Ул бу хакта Юлдашев белән бәхәскә керергә талпынып-талпынып куйса да, әлегә түземлеген саклады. «Әйдә, сөйләсен әле, эшне нәрсәгә китереп терәр икән?»

Юлдашев тиз генә туктамады. Төзелештә райком комиссиясе булуын, шул комиссия чыгарган нәтиҗәләр нигезендә бюро утырышында Сафинның персональ эше каралырга тиешлеге турында бөртекләп сөйләп чыкты.

— Зариф Салихович, әйтсәгез икән, Сафин мәсьәләсенә сезнең карашыгыз һәм мөнәсәбәтегез ничегрәк?

Юлдашев әллә нидә бер кия торган күзлеген борынына элде, кызарынды. Үзен яхшы ук чеметеп алган бу сорауга нинди җавап кайтарырга тиеш ул? Юлдашев нинди генә сорау алдында да тугарылып калучылардан түгел иде. Монда да үзен бик салкын тотарга тырышты.

— Ничек карыйм? Беренчедән, Андрей Акимович, һәркем үзе өчен үзе җавап бирә. Шулай булгач, бу хәл безнең хөрмәтле Сафинны да читләтеп уза алмый. Икенчедән, райком тикле райком аның бик күп хаталарын, зур ялгышларын табып, аңа партлиния буенча җәза бирү ниятенә җиткән икән, бу инде — бик житди мәсьәлә. Өченчедән, аңа минем мөнәсәбәтем ничеклеге турында мин хәзер генә өзеп бер сүз дә әйтә алмыйм. Сезнең белән бергә, төзелештә төп житәкчеләр буларак, Сафинга нindирәк мөнәсәбәттә булу мәсьәләсе райком бюросыннан соң ачыкланыр. Мин шулай дип уйлыйм, Андрей Акимович.

Никитин нигәдер күңеле белән карар кылганны шушы минутта ук уртага ярып салырга ашыкмады. Юлдашевка авыр, салмак караш кына ташлады:

— Кайчандыр сез аны тѳзелешкә үзегез чакырткан идегез бит?
— Русларның: век живи, век учись... дигән мәкальләре азмы-күпме миңа да кагыла торгандыр. Шулай булмаганда...
— Сафин ничек эшли, сезнеңчә?
— Бу турыда сөйләүнең кирәге шунын хәтле генә. Сезгә мәсьәлә ачык бит инде...
— Түгел. Һич тә ачык түгел. Миңа тик мәсьәләнең томанлы икәне генә ачык.— Никитин авыр сулап куйды.— Ә бюро утырышы кайчан?
— Мин белмим. Ул тиклесен райкомнан сорарга кирәк,— диде Юлдашев.
Никитин карашын Сабировка төбәде. Шул чагында Сабиров урыныннан күтәрелеп, тыныч кына телгә килде:
— Бюро утырышы иртәгә...
Моннан соң бик кыска гына вакытка кабинетта авыр тынлык урнаша башлады. Бу арада кайсы папирос кабызды, кайсы су эчте, кайсы башын кашыды. Киеренкелек болытын беренче булып шул ук Сабиров таратты:
— Әйе, бюро утырышы иртәгә... Ләкин коммунист Сафин эше анда каралмаячак...
— Нишләп каралмасын? — дип кабынып сорау ташлады Юлдашев.
— Шулай,— диде Сабиров.— Безнең тавышка өлкә комитеты бик вакытлы колак салды. Казан вәкиле, комиссиянең нәтиҗәләре белән танышкач, безнең фикерне, ягъни тѳзелеш парткомы фикерен дә тыңлады. Аннары бюро членнарын җыеп алар белән киңәште. Иптәшләр комиссия чыгарган нәтиҗәләрне нигезсез һәм тенденциоз санап, бюро утырышына куюдан баш тарттылар. Мәсьәлә шулай, Зариф Салихович...
Юлдашевның маңгаена борчак-борчак салкын тир бәреп чыкты, борын тишекләренә кадәр киңәйде. Аңа һава житми кебек тоелды. Ул кичә райкомнан чыгышлый урамда очраткан озын буйлы, көрән костюмлы кешене күз алдына китерергә тырышты. «Шул икән. Ә кыңгырау кагучы — Сабиров»,— дип ачулы төстә уйлап алды. Сабировка күтәрелеп карарга батырчылыгы җитмәде. Тик тоныклык бер тавыш белән әйтте:
— Юкка гына гаеплисез мине, Солтан Сабирович. Мин сездән моны көтмәгән идем. Партком секретаре буларак, сезгә шулай сөйләү, йомшак кына әйткәндә, оят булырга тиеш.
— Оят турында сүз чыкса, ул, минемчә, иң элек сезгә кагыла,— диде Сабиров.
— Юк,— диде Юлдашев, аның сүзен кискен төстә кире кагып.— Сез, кәер, җаваплы партия хезмәткәре булсагыз да, шәхси дуслыкны гомуми интереслардан өстенрәк куясыз. Сафин мәсьәләсе... Сез аның чатаклыкларын күрмисез, күрергә дә теләмисез. Чѳнки дуслар...— Юлдашев өстәл тирәсендә утырганнарның һәммәсенә дә авыр бер караш белән күз йөртеп чыкты да сүзендә булды:— Мин, беләсегез килсә, иң яхшы теләкләрдән чыгып, Сафинны ялгыш адымнардан тыя килдем, тыя килдем. Гафу итегез, тѳзелештәге һәр вак нәрсә өчен дә, кимчелек яки хата өчен дә иң элек начальник белән мин җавап бирәбез. Рационализаторлык маркасы астында... Авария...— Юлдашев, сүзеннән бүленеп, су эчте.
Никитин маңгаен һәм муен тирәләрен кулъяулык белән сөртеп алды:
— Сез яңалыктан куркасыз...
— Мин тормыш сынавын үткән яңалыкка ике кулымны күтәреп тавыш бирәм.
— Яңалык ул, иң элек, кирә. Аннан тормыш сынавын үтә. Житәкченең иң төп сыйфаты шунда — ул юл ярып алдан барырга тиеш. Кайберәүләргә әнә шул сыйфат житми дә инде,— дип каршы төште Никитин Юлдашевка.
— Бәхәсләшмим, бәлки, шулайдыр да,— дип дәвам итте Юлдашев.— Ләкин иптәш Сафин кебек кайнар башларга тулысынча юл куй-

саң — бәхетсезлек көт тә тор. Әйе, мин аны һәм анын кебекләрне уйланмаган адымнардан тыя килдем. Ләкин, Андрей Акимович, кайбер очракларда сез үзегез дә аны узындырасыз. Бигрәк тә соңгы индустриаль метод...

— Сез һаман ул методка каршымыни әле? Ул бит сез әйткән тормыш сынавын үтте инде,— диде Никитин.

Хәзер инде үзенен нииндирәк хәлгә куелуын яхшы ук аңлаган һәм ни әйтергә белмичә, тарау-чирәү уйларын жыя алмый гажиз булган Юлдашев, өстәлнең икенче кырыенда үзенә каршы утырган Фирсовка карап, калтыравы арта барган ятрак тавыш белән әйтте:

— Мин, барлык уй-фикерләремне чагылдырып, вакытында Министрлык Главкасына яздым һәм алардан ярдәм көттем...

Монарчы тын утырган Фирсов Никитинга берничә бит кәгазь сузды:

— Менә иптәш Юлдашевнын докладнойлары. Без инженер Зотов белән аның һәр пунктын ныклап тикшердек. Сездә тормышка ашырылган рационализаторлык тәкъдимнәренең миллионнарча сум файда китерүләреннән тыш бернинди дә күләгәле якларын күрмәдек, очратмадык. Өлкән яшьтәге, тәжрибәле Зариф Салихович кебек техник житәкченең болай каушап, тугарылып калуы гажәпләндерә безне. Бу чиксез күнелсез хәл...

Юлдашев кинәт урыныннан сикереп торды. Аннары янә авыр гына хәрәкәт белән кире утырды да бары бер генә сүз әйтте:

— Булмый! Болай булмый...

— Булмый! — дип күтәреп алды ул әйткәнне Никитин.— Күрәбез, Зариф Салихович, берсе дә сезнен файдага сөйләми. Сез үзегез утырган ботакка үзегез балта чабасыз...

Төзелеш башлыгы тынып торган арада, ин элек Фирсов, аннары Сабиров ияк кагып кына саубуллаштылар да кабинеттан чыгып киттеләр. Юлдашевка үзенен соңгы сүзен бик каты, бик яңгырашлы итеп әйтергә жыенган Никитин, тегенен бөрешеп калуын сизенеп, ничектер аны кызганып куйды. Әмма, ничек кенә булмасын, кайчандыр төрле төзелешләрдә житәкчелек вазифасын үтәгән, ә хәзер исә ялгыша башлаган бу кешегә карата ул үзенен соңгы сүзен әйтергә тиеш иде. Һәм ул аягүрә басты:

— Сез дөрес әйттегез, Зариф Салихович. Булмый!

— Ничек булмый? Мин сезне аңлап бетермим, Андрей Акимович,— дип сүз кыстырды Юлдашев.

Никитин, күңелендә туа башлаган кызгану хисләрен бер якка куеп, кискен һәм ачык итеп әйтте:

— Сезнең белән эшләп булмый... Дөресрәге, сез хәзер безнен төзелештә эшли алмыйсыз. Үзегезнең эштән азат ителүегез турындагы приказны иртәгә сәгать унда алырсыз.

Ләкин, нәрсә, ни генә булмасын, Юлдашев мондый ук авыр чишелешне, көтмәгән иде, бер мәлгә, урындыкка кагып куйган шикелле, катып калды, чырае качты, күзләре томанланды, иреннәре кысылды, башы шаулый башлады. Шулай да ул, бөтенләй җиргә сеңеп калырга теләмәгәндәй, соңгы көчен жыеп, карлыкканрак бер тавыш белән әйтте:

— Мин Главка исемлегендә. Ничек инде сез мине алар ризалыгыннан тыш эштән аласыз?

— Барысы да тәртиптә, мәсьәлә Мәскәү белән килешенгән,— диде Никитин.

Юлдашев чыгып киткәч, Никитин, кулын артка куеп, ишекле-түрле йөренде дә, секретарь-машинистка янына чыгып, приказны ниндирәк итеп язарга кирәклеген әйтте. Үзе янә, урынына кереп утыруга, телефоннан шалтыратырга тотынды. Ләкин кирәкле кешене туры китерә алмагач, ишеккә атылып барып, секретарьга әйтте:

— Ничек тә, мөмкин кадәр тизрәк Сафинны табыгыз. Хәзер үк минем янга килсен! Бик кирәк!

Вакыт тәгәрмәче бер генә секундка да тукталып тормыйча әйләнә тора. Яшел ефәк киемле җәйне сары мыеклы көз, үз чиратында, аны ның озын ак сакалларында жил уйнаткан куян бүрекле кыш алмаштыр-ды. Ләкин табигатьнең вакытлы картлыгы — кыш — кешеләрнең хисла-рен суыта алмады. Киресенчә, төзелештә урак өстенең иң кызу чакла-рын хәтерләткән көннәр берсе икенчесенә ялганды. Кешеләр үз-үзләрен аямыйча, вакыт белән хисаплашмыйча, кирәк булганда берьюлы ике сменалап эшләделәр. Нәтиҗәдә зур электр станциясе бинасы — төп корпус — үзенең пар казаннары, турбогенератор урнашкан машина заллары, идарә пультләре һәм уртак комплексны тәшкил итә торган башка күп төрле корылмалары белән зур мәйдан биләп җиргә басты.

Батыр калкынды.

Батыр аякка басты.

Хәзер инде аңа җан кертәсе, сулыш өрәсе генә калды. Әмма бу тик-лесе иң җаваплы эшләрнең берсе иде.

Иң элек пар казаннарын ягып карадылар. Гидравлик сынаулар уңышлы үткәч, башка төрле катлаулы сынауларны башлап җибәрде-ләр. Турбиначылар, монтажчылар, югары һөнәрле электриклар, көй-ләүче слесарьлар бер агрегат янынннан икенчесе янына килделәр, ура-лып-уралып бер-берсенә ялганган, астан өскә күтәрелгән һәм өстән аска үрмәләгән хисапсыз күп юан, нечкә торбалар тирәсендә кайнашты-лар. Электр станциясен хутка җибәрү алдыннан сынаулар алып баручы энерготөзүчеләр, көйләүчеләр белән эшне кабул итүче комиссия член-нары арасында вакыт-вакыт кайнар бәхәсләр калкып чыкты. Чәбәләнеп беткән бер төенне чишүгә, «капка»ны ача алмыйча, икенчесенә барып төртелделәр.

Төп корпус дигәнебез хәрәкәт, ыгы-зыгы, машиналар һәм кешеләр шау-шуының үзәгенә әйләнде. Шушы кайнар көннәрдә, шушы авыр имтиханның соңгы капкаларын үткәндә, һичбер төрле тоткарлык булма-сын өчен, зур гына бүлмәгә урнашкан буфетка һәр сменада эшләүчеләр-гә термослар белән кайнар ашлар китерә тордылар. Хәтта төп корпус белән янәшә генә торган бер бинаның зур-зур бүлмәләрендә вакытлыча тулай торак оештырып җибәрделәр. Бик күп эшчеләр һәм техник житәк-челәр шул җылы бүлмәләрдә ял иттеләр, йоклап алдылар.

Белгечләр, консультантлар, шефлар катлаулы машиналарның һәр буынын, һәр өлешен тикшереп чыктылар, күздән кичерделәр. Карт инже-нер Фирсов җитәкчелегендәге дәүләт кабул итү комиссиясе махсус журналга язган эреле-ваклы кимчелекләр саны башта бик күп, йөз илледән артса, һәр көн, һәр смена саен ул кими бара. Инженер-техник-лар һәм башка җитәкче состав хезмәткәрләре һәр көнне эш сәгате баш-ланганчы ук оператив киңәшмәләр уздыру өчен махсус көйләнгән вагон-га җыелдылар. Гадәттә, ярты сәгатькә яки аннан артыкка сузыла торган мондый киңәшмәләрне төзелеш башлыгы Никитин һәм баш инженер Сафин чиратлашып алып бардылар. Белгечләр узган көндә табылган кимчелекләрнең күпмесе беткәнен, күпмесе калганын хәбәр иттеләр. Алдагы көнгә яңа бурычлар билгеләнде. Төзелеш башланганнан бирле әле беркайчан да башлыкның үзеннән алып барлык техник эшчеләргә хәтле төп корпуска бу кадәр тупланып, ябырылып ятканнары юк иде.

Декабрь йомгагы сүтелеп бетәргә якынлашкан көннәрнең берсендә, иртән, бик иртә гадәти киңәшмә башланып китте. Әле тышта караңгы, кышның кыска көне йокылы күзләрен ачарга да өлгермәгән иде. Озын-ча вагонда рәт-рәт тезеп куелган урындыкларның берсе дә буш түгел, басып торучылар да бар.

Вагоннарның иң түренә куелган зур өстәл артына Никитин, Сафин, Фирсовлар утырган. Киңәшмәне алып баручы Никитин, белгечләрне информацияләреннән соң, өченче көнгә һәм кичәге кимчелекләрнең бик күбесе бетерелүенә куанып, иртәгәдән башлап пар казаннарына ягарга кирәклеге турында сүз ачарга уйлап торганда, кемдер аның башын суккандай, исәнкерәп китте. Детальләрне көйләүче, җайлаучы слесарьлар прорабы сөйләвендә дәвам итеп:

— Конденсаторның вакуумнары тотмый...— диде.

— Ныклап карадыгызмы? — дип бүлдерде аны Никитин.

— Карадык. Карамаган кая!

— Конденсаторның тышлыгы герметичный булырга тиеш.

— Шулай, герметичный булырга тиеш,— дип раслады прораб.

— Алайса, ничек су үткәрә соң ул?

— Үзебез дә шуңа төшенмибез. Эзлибез. Тикшерәбез...

— Бу хикмәтнең бик зур тоткарлык ясавы мөмкин. Туйга барырга чыккач кына ат тугарылу кебек,— дип баш кагып куйды Фирсов.

Никитин бу көннәрдә аз йоклап күзләре кызарган Сафинга карашы ташлады:

— Васил Закирович, бөтен ышаныч сездә. Конденсатордагы кимчелекләрне тизрәк табып бетерергә кирәк. Тырышырсыз дип ышанам.

Оператив киңәшмәдән соң Сафин җиһазларны көйләүче-җайлаучы кешеләр арасында өзлексез бөтерелеп йөрде. Турбина астына гаять зур савыт — бак урнаштырылган. Бу — конденсатор, аның бер өлеше нигезгә яткан. Ул һәркайсын уйландырды, һәркайсының башын ватты. Пар казаннарын җыйганда бик авыр, катлаулы детальләрне төгәл урнаштырган, төгәл көйләгән Фиргали Гатин белән Зиннур Гафиятуллин да шул тирәдә әвәрә киләләр иде.

Нишләргә?

Астагы калын тимер-бетон нигез ватарлык та, сүтәрлек тә түгел. Васил шуларны хәл кыла алмыйча, аптырап кашларын җыерып торган Фиргалигә карады.

— Басым белән су тутырып карыйк.

— Мәслихәт киңәш,— дип риза булдылар көйләүчеләр.

Ләкин бу эш тә көткән нәтиҗәне бирмәде.

Васил Сафинның башында бер уй икенчесен алмаштырды.

Озак баш ваттылар.

Нишләргә?

Вакытлыча тулай торак итеп көйләнгән зур бүлмәдә бераз черем итеп алырга дип өстен чишенмичә генә караватка яткач та, Василның күзләренә йокы кермәде. Шулай да берәр сәгатьтән соң ул татлы йокыга талды. Ләкин тыныч йоклый алмады, әлеге шул конденсатор төшенә кереп йөдәтте. Йокыдан торгач, ул тиз генә битен-кулын юып, авызын чайкады да буфетка барып кайнар чәй эчте. Василның башы җиңеләеп китте.

Ул үзенең план-исәпләрен көйләүче слесарьларга әйткәч, эшкә тотындылар. Утлар уйнатып, автогенщик конденсатор стенасына кеше сыярлык тишек уйды. Башта ук сүз куешканча, конденсатор эченә өстендәге комбинезонының сарымы, сорымы төстә икәнен аеруы кыен булган Зиннур Гафиятуллин кереп китте.

— Җентекләп кара,— дип калды аның артыннан Сафин.

Зиннур, кулына фонарь тотып, бик ныклап тикшереп чыкты. Ләкин бер генә тишек-тошык та таба алмады. Аптырагач, куллары белән капшап карады. Болай итүдән дә хикмәт чыкмады.

— Ничек бара? — дип сорады Васил.

— Бернәрсә дә тапмадым, Васил Закирович.

— Алайса, чык.

Зиннур чыгуга, аның кулындагы фонарен алып, Васил үзе конденсатор эченә кереп китте. Менә ун минут, ниһаять, ярты сәгать тә вакыт үтте. Мәгәр, бәхетсезлеккә каршы, Васил Сафин да, Зиннур кебек үк, канәгатьсез һәм ачулы төстә чыкты.

Инде болай да булмагач, иң соңгы чарага керештеләр. Инженер-техниклардан кайсыларыдыр икеләнде. Андрей Акимович Никитинның ризалыгын сорарга кирәклеген әйттеләр. Кайсыдыр:

— Ул-бу була калса...— дип, шик тә белдерде.

Әмма кем генә, ни генә димәсен, нинди генә каршылык булмасын, Васил Сафинның карары кискен, аны инде кире чигендерү мөмкин түгел иде. Ул икеләнүчеләрне күргәч тә каушап калмады:

— Юк инде, дуслар, эшләр болайга киткәч, мин, төзелешнең баш инженеры буларак, сезнең һәммәгезгә әмер биреп, боерып әйтергә тиеш булам. Кушканнарымны үтәгез, жалобалар соңыннан...

Моңа каршы килеп сүз әйтүче булмады. Әмма Зиннур кинәт кенә әйтеп салды:

— Сез түгел, мин керәм!

— Ничек инде ул? — дип каршы төште Васил. Тегесе үз сүзеннән чигенмәде. Васил, Зиннурны читкәрәк алып китеп, беркадәр сөйләште дә аның җилкәсеннән дусларча кагып алды.

Зиннур өстенә су үткәрми торган комбинезон, аякларына бот төбеннән диярлек резин итек киде, кулына фонарь тотты да янадан конденсатор эченә кереп китте. Автогенщик күптән түгел генә үзе ачкан «тәрәзә»не яңадан япты. Ничә минут, ничә секунд үткәндер, алдан сүз куешканча, конденсаторга иң элек һава өрдерделәр. Һава һаман азлап-азлап булса да керә торды. Аннары эчтән ике мәртәбә доң-доң иткән аваз ишетелгәч, су җибәрделәр. Эчке яктан янә доң-доң иткән тавыш кабатлангач кына конденсаторга су җибәрүне туктатып, киеренке бер хәлдә көтә башладылар. Тышкы яктагы дистәләгән кешенең йөрәге, әйтерсең лә: «Ни булыр, ни булыр?» — дип тибә иде. Кайберәүләр калын тимер стенага колакларын куеп тыңлап торалар иде.

Шаулап су кереп тулгач, конденсатор эче кинәт тынып калды.

Зиннур фонарен сүндереп, күкрәк кесәсендәге икенче запас фонарен капшап карады. Монда шундый караңгы, әйтерсең ул икенче бер дөньяда иде. Фонарь тиз кабынды. Конденсатор эчендәге бихисап күп нечкә-юан торбалар аңа иркенләп хәрәкәт итәргә уңайсызлыйлар иде. Зиннур, үрмәли-үрмәли, корыч-тимер стеналарны бик җентекләп күзләре белән тикшерергә кереште. Эретеп ябыштырылган кыршауларны кат-кат карады. Барысы да тәртиптә сыман, һәммәсе үз урынында кебек, барлык кыршаулар да һични кермәслек һәм чыкмаслык итеп ябыштырылган төсле. Тикшерә-тикшерә тәмам башы катып бетте аның. Ул, шулай күзләре белән сөзеп, фонарь яктысында стеналарны караганда, тышкы яктан стенага сугып-сугып куялар, Зиннур да эчтән шакып җавап кайтара. Тыштагылар тагы киеренке рәвештә көтәләр.

Баштарак аллә ни кыен, җайсыз тоелмаса да, тора-бара конденсатор эче бик нык тынчуланып, бөркүләнеп китте. Зиннурның бөтен тәне манма тиргә батты, маңгаеннан, битеннән борчак-борчак тир тама башлады. «Бәлки, табылыр... Тәмам арыгач кына стена шакырмын»,— дип уй йөртте ул. Аның исәбенчә, стеналардан су чыгар, тишек-мазар булган сурәттә монда су кимергә, аның эзе калырга тиеш иде. Ләкин бу хәл дә сизелмәде. Су һаман бер урында, бер эздә торадыр кебек. Су кайдандыр, ниндидер тишекләрдән юл тапкан икән, ул туктаусыз хәрәкәтләнеп йөреп торганда, бу үзгәреш ничек сизелмәсен соң? Зиннур шул турыда

уй йөртте-йөртте дә үрмәләп барып тезләнде һәм әле бер терсәге, әле икенче терсәге белән савыт төбенә таянды. Аяк-куллары, барлык буыннары шулхәтле арыды, әйтерсең ул бер зур таш күтәреп тора. Җитмәсә, ул бер җайсызрак хәрәкәт ясап, өстәге торбаларга яхшы ук бәрелеп тә алды. Күз аллары караңгыланып китте.

Шулай хәрәкәтсез калып күзәткән чагында, аның колагына еракта̂н, бик ерактан чишмә аккан шикелле зәгыйфь бер тавыш ишетелде. Ул да булмады, тәмам тынып калган тонык су өстендә черки уйнаганны хәтерләткән ифрат вак бөрчекләр чыкканы күренде. Зиннур шул бөрчекләргә якынлашты да, күзләре белән шуларны йотарга теләгәндәй, тагы да күзәтә, карый башлады. Ул урыныннан кузгалгач, бөрчекләр күренми башласалар да, су тынып калгач, яңадан пәйда булдылар. Күрәсең, бик азлап-азлап кына саркып су чыга, аның урынына саркып һава керә булса кирәк. Инде ул барысын да ачык чамалады. Башка төшләрдә андый бөрчекләр күренми иде.

Тышкы яктан тагы шакыдылар. Зиннур, салмак кына су кайнаганны хәтерләтеп төптән күтәрелгән шул вак бөрчекләрдән карашын алмыйча, сак кына җавап кайтарды. Бик җентекләп карый, күзәтә торгач, бөрчекләрнең янәшә ике урында булуларын күрде. Эретеп ябыштырган урын кыршауны хәтерләтә. Күрәсең, шул кыршау астында тишек калгандыр. Зиннур кат-кат үлчәп, кат-кат карап, бөтенләйгә ышанычы утыргач кына, фонарьны бөрчекләр күтәрелгән кыршау өстенә куйды да конденсатор стенасына өч мәртәбә шакыды. Ул бары тик шунда гына үзенә һава җитмәвен, күкрәгенең бик нык авырттырып кысуын тойды, башы авыраеп китте һәм күз алларында бер яктырып, бер караңгыланып әллә нинди шәүләләр уйнады...

Конденсаторның үзе кергәндәге уентыгы ачылуга, Зиннур шуның авызына килеп капланды. Аның төсе күм-күк, күзләре хәлсез булуын, борын яфраклары калтыравын күреп, кешеләр шөбһәгә калдылар. Зиннурның иценнән тотып ике кеше аны люктан тартып чыгардылар. Ике яктан култыклап алдылар, гәүдәсе йомшап калуын сизенделәр.

Васил да әсәренә, каушый калды. Ләкин ул үзен бик тиз кулга алды һәм янәшәдәге дежурный өстәленә ашыкты. Телефон трубкасына үрелде.

Ашыгыч ярдәм күрсәтү машинасы бик тиз килеп җитте. Врач тапчанга яткырылган Зиннурның пульсен капшады. Аннары төсе качкан Зиннурга соры мендәрдән кислород иснәтергә кереште.

Зиннур күзләрен ачып җибәрде. Аңа берничә йотым су бирделәр. Урта яшьләрдәге, төз борынлы, уймак кебек кечкенә авызлы хатын-кыз врач аның пульсен тагы капшап карады һәм янында торган санитарга носилка алып килергә кушты.

— Ну, ничек? — дип сорады Васил.

— Больницага салырга кирәк. Алып китәбез,— диде врач.

Зиннур Гафиятуллинны носилкага салып, төп корпус бинасыннан алып чыктылар. Тышта талгын гына кар явып тора. Монда инде Зиннур чын мәгънәсендә иркен сулыш алды. Тик тиз арада тәненә, бөтен әгъзаларына баштагы ныклык, көч кайта баруын сизде ул. Ике санитар аны ашыгыч ярдәм машинасына керткәндә, Зиннур кинәт кенә носилкадан сикереп торды.

— Ярамый, ятыгыз,— диде боеручан тавыш белән врач хатын.

Ләкин Зиннур аны тыңламады.

— Илтифатыгыз өчен рәхмәт, мин үземне әйбәт хис итәм.— Ул, шулай дип, эре-эре адымнар белән яңадан төп корпус бинасына юнәлде...

Монтажчылар бригадиры Фиргали абзыйның хәрби диңгез флотында хезмәт иткән кеше булуын күпләр белмиләр иде әле. Фиргали Гатин очарга теләгәндәй талпынып, канатланып сөйләп китте:

— Безнең эсминецта шунар охшашлырак хәлләр була торган иде. Әйтик, кирәк икән, бозлы суга сикереп төшү дисеңме, пар казаннарын ремонтлаганда кайнар мичләргә керү дисеңме! Безнең Зиннурда моряклар колачы бар! Мондый кешеләр белән корабны кузгатып җибәрергә була, туганнар! Дөрес әйтәмме?

Төрле яктан:

— Дөрес!

— Дөрес!..— дигән авазлар ишетелде.

— Дөрес,— дип ялгап китте Васил Сафин да.— Икенче блок конденсаторын җыйгач, проммәйданда ук сынап карарга кирәк безгә. Ул чагында мондый интегүләр, юлда барганда туктап калулар килеп чыкмас.

— Дөрес!

— Анысында инде без акыллырак булырбыз,— диештеләр.

Оператив киңәшмә бүген башка көннәрдәгедән иртәрәк җыелды. Төп корпустагы озынча вагон халык белән шыгрым тулы, анда энә төртерлек тә урын юк иде.

Андрей Акимович Никитин, салмак кына хәрәкәт белән урыныннан торып, кемнедер эзләгән сыман, кешеләр өстенә күз йөртеп чыкты да, җинелчә генә тамак кырып, сүз башлады:

— Дәүләт комиссиясе күрсәткән төп кимчелекләр исемлектән сызылды. Станцияне хутка җибәрүнең соңгы капкасына барабыз. Төштән соң пар казанын ягарга. Аңарчы барлык эшчеләрнең, инженер-техник персоналның үз урыннарында булуларын сорыйм. Димәк, приказ бирелде дигән сүз.

Оператив киңәшмә берничә минут эчендә бетеп тә куйды.

Олуг хезмәт ташкынының соңгы агымына сынау башланды.

## 20

Икенче көнне иртәнге алтыда Бөтенсоюз радиосы сүзне илдә тагы бер гигантның сафка басуыннан башлады. Эфирда шундый сүзләр яңгырады:

— «Яңа Наратлыдагы электр станциясенең беренче чиратын төзү тәмамланды.

Бу көннәрдә, электр станциясен файдалануга тапшыру алдыннан, таүлекләр буе дәвам иткән, киеренке һәм фидакарь хезмәт нәтиҗәләре күңелләргә шатлык сала. 19 январьда иртәнге 2 сәгать 50 минутта пар казаны ягылды. Ул нормаль эшли. 8 сәгать 25 минутта бер блок турбинасына пар бирелде. Шулай итеп, турбина хәрәкәткә килде, ротор минутына 3000 тизлек белән әйләнә башлады. Көндезге сәгатьләрдә сынау нагрузкасы уңышлы алып барылды.

Монтажчылар, электр станциясе эшчеләре, илебезнең төрле шәһәрләреннән килгән белгечләр җылылык электр станциясе механизмнарының хәрәкәтен күзәтәләр».

Быелгы январь да бозлы җиле белән битләрне кисә торган зәһәрлеген кабатламый калмады. Тәрәзәләрдә шул ук кышкы бизәкләр. Алар нәрсәләргә генә охшамый! Бер карасаң, нәкъ каз канатлары алар, бер карасаң, урманнарга, тауларга, болытларга, бер карасаң, шаулап аккан ташкын елгаларга охшыйлар.

Иртәнге як...

— Василдан да иртәрәк торган кеше булдымы икән? Ул, радиода[
куанычлы хәбәрне ишеткәч, тиз-тиз генә киенеп, өйдән чыкты. Соклан[
ган бер кыяфәттә, һәр күренешне куанып күздән кичерде.

Офык читләре аксыл мамык шәлгә урангангмыни — шундый ку[
томан! Салкынча булганга, кош-кортлар да кайдадыр каралты түбәлә[
ре астына качып беткәннәр, берсе дә күренми. Көннең шундый рәхим[
сезлегенә карамастан, Яңа Наратлы поселогы урамнарында хәрәкәт-
кешеләр, автобуслар, машиналар йөреп тора.

Төп корпус бинасының түбәсенә Ильич лампаларыннан тезеп
«Яңа Наратлы электр станциясе коммунизмга эшли!» дигән лозунг язы[
ган. Васил бу утларга озак карап торды.

...Кешеләр митингка җыелалар.

Төп корпус бинасы алдында халык артканнан-арта бара. Кышны[
салкынлыгын алар сизмиләр кебек. Күпләрнең чәчләре, кашлары бә[
ләнгән, битләре кызарган. Гаять зур көч чыганагының, ифрат зур куә[
нең йөрәк тибеше тыныч кына, салмак кына тоташ гөрелте булып ишете[
леп тора. Кояш күренми. Гигантның исәпсез күп механизмнарын ка[
кыткан, аларга җан өргән кешеләр үзләре һәммәсе кояш кебек якты
кояш кебек нурлы булып күренде Василга.

Алар кызыл комач белән камалган трибуна тирәсендә һәр якла[
ишәйгәннән-ишәяләр. Безнең уртак танышларыбызның да күбесе шун[
да. Васил Сафин һәм Зиннур Гафиятуллин елкылдап торган өр-яңа
автобустан әле яңа гына килеп төшкән Гөлзадә белән Хәмидәне каршы[
ладылар. Васил Сафинның өстендә тышлы кыска тун, башында колак[
лары кайтарылып куелган йомшак пыжик бүрек, аякларында сары кү[
белән камалган ак фетр итекләр. Зиннур Гафиятуллинның өстенд[
заманча кыскарак, кондыз якалы пальто, башында очлы мех бүрек.
Гөлзадә әкиятәге кар кызы кебек матур — яңаклары нинди алсу, [
күзләре... Нихәтле тереклек, нихәтле яшәү уты ул күзләрдә... һәркайсы[
ның чырайлары якты һәм тантаналы.

Гел эш киеменнән күрергә өйрәнгән Фиргали абыйларының д[
өстендә кара доха, аякларында төньяк кешеләре кия торган уңайлы
унталар. Моны күргәч, Васил аны аюга охшатып, ихтыярсыздан көле[
куйды:

— Сезне танырлык та түгел, Фиргали абзый...

Тегесе исә, аның сүзләрен ишетмәгән кебек, Васил белән ике кулла[
күрешкәч, кычкырып тәбрикләргә ашыкты:

— Бәйрәм белән! Җиңү белән котлыйм сезне! Тәки ерып чыкты[
егетләр.

Үзәк лабораториянең яңа начальнигы Игнат Данилов, кояшка күзлә
ре чагылгандай, бүреген басыбрак кигәч, әйтә куйды:

— Иң катлаулы эшләр алда әле. Икенче блок... Өченче блоклар...

Әйтерсең лә дөньясы түгәрәкләнгән, нигәдер бүген күз төбендә[
җыерчыкларына хәтле юкка чыккан Фиргали Гатин, Игнатның сүзе[
тыңлап бетермәстән бүлдереп:

— Хәзер инде чирканчык алдык. Йөзә беләбез, иптәшкәем. Алары
да бергә-бергә кулга-кул тотынып калкытырбыз,— диде.

Һәркем шат, һәркем тантаналы минутлар кичергәндә, нигәдер әл[
бу Рафис бик уйчан күренә. Берәү белән дә сөйләшми, көлми дә. Ан[
ни булган? Яшь прораб Рафиска күзе төшкәч, Васил Сафин шулайра[
уйлап алды. Аның янына барды:

— Башыңа нинди уй төште, Рафис?

— Нинди уймы? Уй дигән нәрсә ерак йөри ул минем тирәдән...

— Шулай да сиңа нидер булган...

— Юк, Васил Закирович.

— Ник ялгызын гына, Мәдинәң кайда?

Рафис читкәрәк карап алды, кызарды:

— Мәдинә роддомда шул. Бүген иртә белән генә салдым. Шуңа минем күңел әллә нишләбрәк тора, шайтан алгыры...

— Димәк, син дә ата кеше буласың! Котлыйм! Борчылма.

— Ярый ла исән-сау котылса?

— Котылыр!

Менә «служебный» дип язылган автобустан шефтагы Акъяр колхозчылары килеп төште. Калын-калын шәл бөркәнгән хатын-кызлар, толыплы агайлар да күренде.

Алып батыр Виктор белән Карчыга кызлар арасына елыштылар. Икесенең дә башында кибән хәтле зур куян бүрекләр. Карчыга көрәктәй озын сакалын кырдырып ташлаган. Җыйнак кына мыек җибәргән. Бу тиклесе ничектер аңа килешеп тора сыман.

Торак конторасы башлыгы Гәрәевнең бүрегенең бер колагы төшкән, икенчесе күтәрелгән. Өстендә аяк йөзеннән диярлек озын пальто. Ниндидер урта яшьләрдәге бер юантык хатын аның артыннан калмый. Сүз квартир ремонтлау турында бара булса кирәк. Гәрәевнең:

— Ни өчен дисәгез... Момент эшлибез аны. Материал гына булсын,— дигән сүзләрен ишетеп калды Васил.

Төзелеш житәкчеләре, алдынгы эшчеләр кызыл комач белән төрелгән трибунага менгәч, ыгы-зыгы һәм шау-шу тынып калды. Башкалар кебек үк җылы һәм пөхтә киенгән, яңаклары күгәргәнче кырынган, күзләренә көләчлек чыккан Солтан Сабиров, кыска, әмма җылы, канатлы сүзләр белән митингны ачкач, беренче сүзне Андрей Акимович Никитинга бирде.

— Иптәшләр, беренче номерлы бурыч үтәлде! — дип башлап китте Никитин гадәттәге сүзе белән.

Төзелеш башлыгының ышанычлы калын тавышы кешеләрне үзенә тартты. Барысы да аңа карадылар.

**Туфан Миңнуллин**

# КЕМ СЫЗГАН?

КАТНАШАЛАР:

**Габсаматов** — начальник урынбасары. Кешеләргә сынаулы караш белән карарга ярата.
**Хәбибрахманова** — идарә хезмәткәре. Күпне күрүчән, күпне ишетүчән хатын.
**Нуретдинов** — хезмәткәр. Караңгы чырайлы, ләкин эшлекле кеше.
**Шәмсиев** — хезмәткәр. Бик күңелле кеше. Ике сүзнең берендә сәбәпсез-нисез кычкырып көлеп җибәрә торган гадәте дә бар.

Габсаматов кабинеты. Уртада өстәл. Өстәл артында, ике кулы белән өстәлгә таянып, кабинетның хуҗасы басып тора. Тамаша залына мөрәҗәгать итеп сүз башлый.

Габсаматов. Мин сезгә, иптәш тамашачылар, бик күңелсез бер хәбәр әйтергә тиешмен. Кичә безнең идарәдә профсоюз оешмасының отчет-сайлау җыелышы булды. Монысы әле күңелсез хәбәр түгел — факт кына. Җыелышта барлыгы егермедән артык профсоюз члены катнашты һәм яшерен тавыш белән месткомның яңа составы сайланды. Монысы да бары тик факт кына. Яшерен сайлауның нәтиҗәләре белән җыелышны таныштырганда түбәндәге хәл ачыкланды — монысы инде күңелсез хәбәр — җыелышта катнашкан профсоюз членнарыннан кемдер берәү местком составына тәкъдим ителгән бер кандидатның фамилиясен сызган. Һәм нәтиҗәдә ул кандидат бер каршы тавыш алды. Сызылган кандидатның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме: Борһан Җамалиевич Шәрифҗанов. Ә Борһан Җамалиевич Шәрифҗанов ул безнең идарәнең начальнигы! Төшендегезме инде? Бүтән беркемне сызмаганнар, ә кемдер берәү Борһан Җамалиевич Шәрифҗановны!!! — безнең начальникның!!! — фамилиясен сызган. Кем ул сызучы?! Кемнең кулы шул эшкә күтәрелгән?! Ничек кулы барган ул кешенең, ничек йөрәге калтыранмаган? Мин, иптәш тамашачылар, ул кешенең чын йөзен ачарга тиешмен. Югыйсә, Борһан Җамалиевичның әллә ни уйлавы бар. Миннән шикләнүе дә бик ихтимал. Ник дигәндә, мин Борһан Җамалиевичның урынбасары. Юк-юкта уйлар Борһан Җамалиевич, минем урынбасар Габсаматов минем фамилияне сызган, дип уйлар, миңа чокыр казып маташа, минем урыныма үрмәләргә азаплана, дип уйлар. Бардыр, соңгы вакытларда бәйләнә башлады. Ә минем үземдә андый теләк юк, миңа Борһан Җамалиевич җитәкчелеге астында эшләү дә бик җиткән. Хәтта артыгы белән җиткән. Бик хөрмәт итәм мин Борһан Җамалиевичны, һәм сезнең каршыда ант итеп әйтәм, аның фамилиясен сызучы мин түгел. Ләкин кем? Кем сызган? Менә ул Борһан Җамалиевичның фамилиясе сызылган бюллетень. Анысы минем кулыма эләкте. Димәк, тикшерүне башларга мөмкин. Ләкин ничек? *(Лупа белән бюллетеньгә карап.)* Белеп булмый, шайтан алгыры. Гап-гади сызык. Идарәдә

егермедән артык кешенең кайсысы сызганын гади сызыкка карап белер өчен криминалист булырга кирәк. Шулай да, тәвәккәллибез, иптәшләр. Һәм тикшерүне... тикшерүне *(уйланып алып)* Хәбибрахманевадан башлыйбыз. *(Телефон шалтыратып Хәбибрахманованы чакыра.)* Бәлки, сызучы ул түгелдер, әмма күпне күрүчән, күпне ишетүчән хатын — бу мәсьәләгә нинди дә булса ачыклык кертер.

Хәбибрахманова *(керә)*. Исәнмесез, Мәмдәл Харисович, хәерле иртә. Кәефләрегез ничек? Ничек йокладыгыз?

Габсаматов. Сезнең кәефләрегез ничек, сез ничек йокладыгыз, Сабира ханым?

Хәбибрахманова. Әллә нинди төшләр күреп саташып чыктым. Кичәге профсоюз җыелышы әйләнә дә керә төшемә, әйләнә дә керә.

Габсаматов. Я, я, кызык. Ничек итебрәк әйләнеп керә?

Хәбибрахманова. Хәтердә дә калмаган инде. Имеш, мине местком составына сайлыйлар икән, шунда кемдер минем фамилияне сыза да сыза, сыза да сыза, сызган өстенә сыза икән.

Габсаматов. Кызык, кызык. Кем инде ул шулай сыза да сыза? Кайсы явызы сезгә каршы?

Хәбибрахманова. Хәтердә калмаган. Төш дисәң төш.

Габсаматов. Ә бит фән раслый, Сабира ханым, өнеңдә ни турында күп уйласаң, шул төшкә керә, ди.

Хәбибрахманова. Уйлаганым да юк. Җитәр алты ел член булып тордым месткомда.

Габсаматов. Шулай, шулай. Ничек соң, месткомның яңа составыннан канәгатьме?

Хәбибрахманова. Безнең кебек эшләп күрсәтсеннәр әле.

Габсаматов. Бу юлы Борһан Җамалиевич үзе местком члены. Ул булгач...

Хәбибрахманова. Билгеле. Карагыз әле, Мәмдәл Харисович, кем сызды икән аның фамилиясен?

Габсаматов. Бик беләсегез киләмени?

Хәбибрахманов. Килми дә. Шулай да кызык.

Габсаматов. Кызык микән, Сабира ханым?

Хәбибрахманова. Ә нигә?

Габсаматов. Болай гына. Төшегездә сезнең фамилияне сызганнарын күргәнсез. Бәлки шунда беррәттән...

Хәбибрахманова. Әллә миннән шикләнәсезме, Мәмдәл Харисович? Аллам сакласын. Борһан Җамалиевич фамилиясенә кулым күтәреләме соң?

Габсаматов. Шикләнүен шикләнмим, Сабира ханым. Әмма... Әмма ул фамилиянең сызылуы сез уйлаганча ук кызык түгел. Хәтта, әйтер идем мин, кызганыч. Бүген Борһан Җамалиевичны сызалар, иртәгә бүтәннәрне. Димәк, безнең идарәгә кемдер кереп оялаган. Һәм сызуны хуҗаның үзеннән башлаган. Борһан Җамалиевичны сызганны сезне һәм башкаларны сыза да сыза инде ул. Менә фаҗига кайда ята.

Хәбибрахманова. Чыннан да бит, Мәмдәл Харисович.

Габсаматов. Чыннан да шул, Сабира ханым.

Хәбибрахманова. Кем икән ул?

Габсаматов *(бюллетеньны күрсәтеп)*. Менә, Борһан Җамалиевичны сызган, үзенең фамилиясен, кызганычка каршы, язмаган. Мин, дөресен әйткәндә, сезне шуның өчен чакырдым. Мин сезгә ышанам. Бәлки, бәлки...

Хәбибрахманова. Ягез әле, күрсәтегез *(бюллетеньне карап)*. Сызык кына шул, шариковый авторучка белән сызылган. Кемдә бар безнең шариковый авторучка?

Габсаматов. Хәзер бөтенесендә бар инде ул.

Хәбибрахманова. Туктагыз әле, туктагыз. Карасы нинди төстә? Яшел бит, Мәмдәл Харисович. Белергә кирәк, кемнең авторучкасында шундый кара.

Габсаматов. Андыйлары да җитәрлектер.

Хәбибрахманова. Түгел, Мәмдәл Харисович, яшел белән язмыйлар, күбесенчә зәңгәр белән язалар. Так, Сафинаның зәңгәр, Шварцманның кызыл, Исмәгыйловның да зәңгәр, Петрованың кара... Таптым, Мәмдәл Харисович, Нуретдиновның төрле төстәге авторучкасы бар, әйе, яшеле дә бар.

Габсаматов. Әкренрәк.

Хәбибрахманова. Шул, шул сызган. Ул һәрвакыт берни булса чәчрәп чыга, тәнкыйтьли. Ишеткәнсездер, кичә җыелышта да кычкырды. Имеш, бездә хезмәт дисциплинасы какшый, эш сәгатьләрендә кирәкмәгән эшләр белән шөгыльләнәбез, имеш, ләчтит сатабыз. Шул гына, башка беркем түгел, Мәмдәл Харисович. Хәтерегездәме, бер җыелышта Борһан Җамалиевичка да тел тидерде?

Габсаматов. Борһан Җамалиевич ул чакта аны яклады бит.

Хәбибрахманова. Яклямый нишләсен. Олы башын кече итеп Нуретдинов белән бәхәсләшсенме, нигә эт белән эт булсын.

Габсаматов. Әйе, Нуретдиновның булуы мөмкин. Ул авторучкасы кичә бар иде микән?

Хәбибрахманова. Күрүен күрмәдем. Нишләп инде авторучкасын калдырып йөрсен. Чакырып кертимме үзен, Мәмдәл Харисович?

Габсаматов. Ашыкмагыз. Капылт ярамый. Сез анда караштыргалап торыгыз әле, тагын кемдә бар икән яшел кара. Тик сездермичә генә.

Хәбибрахманова. Ярый, ярый, Мәмдәл Харисович. *(Чыга.)*

Габсаматов. Эшлексез булса да үткен хатын. Бер дә белмәгәне юк. Нуретдинов диген ә? *(Лупа белән бюллетеньгә карап.)* Булуы бик мөмкин, бик нык сызылган, болай итеп Нуретдинов кына сыза ала. *(Телефон шалтыратып.)* Иптәш Нуретдинов, кереп чыгыгыз әле. *(Трубканы куеп.)* Моның белән сөйләшүе бер бәла инде ул. Һич җайга килә торган адәм түгел.

Нуретдинов *(керә)*. Исәнмесез. Ни өчен кирәк булдым, ашыгыч эшем бар иде.

Габсаматов. Утырыгыз, иптәш Нуретдинов. Эш барыбызның да бар. Кәефләр ничек?

Нуретдинов. Ал да гөл. Өлгереп булмый. Бүлектә бер үзем.

Габсаматов. Ә башкалар кайда?

Нуретдинов. Хәбибрахманова бүлмәдән бүлмәгә тыз-быз чабып йөри. Аңа карап бүтәннәре нигә без генә эшләп утырыйк, диләр.

Габсаматов. Сез һаман зарланасыз, иптәш Нуретдинов. Идарәнең эшләре сез уйлаганча ук начар бармый бит.

Нуретдинов. Начар бармый дип әйтү үз-үзеңне юату гына. Әйбәт барырга тиеш, гөрләп.

Габсаматов. Шулай, әлбәттә. Кичәге җыелышта да сүз шул турыда барды. Шактый усал чыгыш ясадыгыз. Борһан Җамалиевичны кызганып утырдым.

Нуретдинов. Кызганырлык та шул. Берүзе диярлек. Аңа ярдәм итүчеләр юк. Күбрәк аяк чалабыз.

Габсаматов. Анысы инде бераз арттыру. Бардыр житешсезлекләр. Төзәләбез, иптәш Нуретдинов, һаман төзәләбез. Менә мин дә сезне юк нәрсә өчен эшегездән бүлдем. Ачуланыгыз. Идарә эше буенча түгел, шәхси йомышым — вак-төяк. Бер көн мин сездә шәп шариковый авторучка күргән идем, кызыгып куйдым. Кайсы магазинда бар ул, малай сорап интектерә.

Нуретдинов *(кесәсеннән авторучка чыгарып)* Шушымы?

Габсаматов *(авторучканы кулына алып)*. Нәкъ үзе. Кара, нинди! Кара, кызыл, зәңгәр, яшел. Кызык, яшеле нигә инде аның, андый төс белән язучы юктыр да.

Нуретдинов. Мин үзем шунысын яратам.

Габсаматов. Кирәк бит. Кайсы магазиннан алдыгыз?

Нуретдинов. Тулып ята. Бүген килгәндә киоскадан тагын берне алдым.

Габсаматов. Нигә икәү?

Нуретдинов. Монысын өченче көннәре югалткан идем. Бүген килгәч җыештыручы апа бирде. Тапкан. Кирәк булса, мәгез, алыгыз.

Габсаматов. Юк. Хезмәткәрләрдән бүләк алу килешә торган эш түгел.

Нуретдинов. Ә мин аны сезгә бүләк итмим. Акчасын түләгез — өч сум.

Габсаматов. Алай дисәгез инде. *(Кесәсеннән акча чыгарып бирә.)* Рәхмәт сезгә. Гафу итегез, юк нәрсә өчен эшегездән бүлдем. Кирәк бит, беләсез, бала-чага җанга тия башласа...

Нуретдинов. Китәргә мөмкиндер?

Габсаматов. Билгеле, билгеле. *(Нуретдинов чыгып киткәч, авторучканы өстәл тартмасына атып бәрә.)* «Шәп» булды, баедым. Сиздерми, планын корып куйган.

Хәбибрахманова *(керәп)*. Үземе? Коридор буйлап тузынып бара, эшләре юктан эш табалар, ди.

Габсаматов. Сез анда бүлмәгездә бераз утырып эшләгез инде. Тыз-быз чабып йөрү...

Хәбибрахманова. Сезнең өчен ич. Машинистка Халидәдә бар тагын яшел авторучка. Тик, белмим, ул сызар микән, җыелышта да йоклап утырды. Бу ничек соң, Мәмдәл Харисович?

Габсаматов. Әй, шайтан белсен. Җыештыручы хатынны күрсәгез, әйтегез әле, кереп чыксын.

Хәбибрахманова. Әллә улмы?

Габсаматов. Кем белә. Яшел каралы авторучканың кичә аның кулында булуы ихтимал. Сызгандыр. Хәзер кемнән шикләнергә дә белмәссең.

Хәбибрахманова. Ләкин мин түгел, Мәмдәл Харисович. Менә шушы баскан җиремдә...

Габсаматов. Беләм инде.

Хәбибрахманова. Аннан соң, Мәмдәл Харисович, яшел каралы авторучка план бүлегендәге Шәмсиевта бар. Үзем күрдем. Нидер сызып утыра иде, дача өенең проектын сызам ди, ә сызыклары нәкъ менә шундыйга охшаган.

Габсаматов. Әйтегез үзенә, кереп чыксын.

Хәбибрахманова. Ярый, ярый, хәзер.

Габсаматов. Карагыз аны, эшләргә дә кирәк.

Хәбибрахманова. Эшлим, эшлим, Мәмдәл Харисович. Җыештыручыны күреп әйтәм дә эшкә утырам. Шул Нуретдиновны күрсәм, кулым калтырый. *(Чыгып китә.)*

Габсаматов. Юкка бәйләндем бу хатын белән. Көн озыны бүлмәдән чыкмас инде.

Шәмсиев *(керә)*. Исәнмесез, Мәмдәл абый.

Габсаматов. Исәнме, исәнме, Шәмси дус. Син анда дача салырга йөрисең икән.

Шәмсиев. И-и, башка бәла булды әле. Мәмдәл абый, Хатынга өч сутый җир биргәннәр. Шул җирне карап кайтканнан бирле тынычлык югалды. Порт кебек нәрсә дә салырга кирәк, агачын-фәләнен дә утыртырга кирәк. Баш каткан. Ничегрәк итеп салырга инде ул йортны. Әллә

ничә төрле вариант сызып карадым. Тегеләй дә ошамый, болай да ниерәк.

Габсаматов. Мин өлкәнрәк кеше, киңәш сорарга иде. Бәлки, ярдәмем тимәсә дә...

Шәмсиев. Берәр кирәкмәгән кәгазегез юкмы, Мәмдәл абый? *(Кәгазь алып сызгалый башлый.)* Буйга дүрт метр, ингә өч метр, биеклеге ике дә кырык, монда бүлмә, монда веранда.

Габсаматов. Нигә син яшел кара белән язасың?

Шәмсиев. Женем сөйми яшелне, бүтән стерженьнәр юк кибеттә, аптырагач алдым. Димәк, веранда монда, әллә монда куйыйк микән, Мәмдәл абый?

Габсаматов. Анда да ярый. Бусы нәрсә соң?

Шәмсиев. Бәбкә инде, русча стропило.

Габсаматов. Рәтле-башлы күренми дә, ныграк итеп сыз. *(Шәмсиев сызгач.)* Менә хәзер икенче эш. Ярыйсы була бу, Шәмси дус. Бик җыйнак та була.

Шәмсиев. Менә монда мансард.

Габсаматов. Эһе, эһе. Карале, Шәмси, син сулагай икән ич.

Шәмсиев. Язганда уң белән, сызганда сулагай.

Габсаматов. Кызык.

Шәмсиев. Өйрәнелгән инде.

Габсаматов. Кызык, кызык. Бу сызымыңны миңа калдыр әле, Шәмси дус. Минем бажа да бит шул дача белән җенләнеп йөри. Курсәтим, бәлки синең вариант ошар.

Шәмсиев. Миндә алар тулып ята.

Габсаматов. Миңа монысы ошый. Шул җиткән. Ярый, уңышлар телим. Эшләр барамы? Син кара, идарәдәге эшеңне дә онытма, Шәмси.

Шәмсиев. Анысын ничек онытасың инде, Мәмдәл абый. Хезмәт хакы алабыз лабаса. Сау булып торыгыз, Мәмдәл абый. *(Чыгып китә.)*

Габсаматов *(лупа аша карап сызыкларны чагыштыра)*. Охшавын охшаган. Ләкин Шәмсиев ни өчен Борһан Җамалиевичны сызар икән. Болай да мәшәкате муеннан. Юк, ул түгел. Борһан Җамалиевич уң кул белән сызылган. Ә Шәмсиев — сулагай. Кем сызган соң алай булгач? Әллә соң җыештыручы эшеме?

Хәбибрахманова *(атылып килеп керә)*. Яңа хәбәрләр, Мәмдәл Харисович. Җыештыручы сызмаган. *(Кабаланып сөйли.)* Чөнки кичә ул җыелышта булмаган. Нуретдиновның авторучкасын чыннан да ул тапкан. Ләкин бүген түгел, өченче көннәре, бирүен бүген биргән.

Габсаматов. Бу яңа хәбәр түгел, Сабира ханым.

Хәбибрахманова. Ашыкмагыз, Мәмдәл Харисович. Яшел каралы авторучка безнең идарәдә тагын бер кешедә бар. Борһан Җамалиевичның үзендә.

Габсаматов *(коты чыгып)*. Тсс! Сез ни сөйләгәнегезне беләсезме?

Хәбибрахманова. Беләм, үзем күрдем.

Габсаматов. Күрсәң ни. Башың бармы синең? Ничек инде начальник кеше үз фамилиясен үзе сызсын. Син нәрсә, аның башына тай типкәнме?

Хәбибрахманова. Хәтерегезгә төшерегез, Мәмдәл Харисович кичә Борһан Җамалиевич самоотвод бирде.

Габсаматов. Әй-әй-әй! *(Үчекләп.)* Самоотвод! Самоотводны мин дә бирәм, син дә бирәсең, барыбыз да бирә. Самоотвод кыланып кына бирелә, тыйнак булып күренер өчен генә.

Хәбибрахманова *(ачуы чыгып)*. Кем сызган соң алайса? Әйтеп торалар бит сезгә, үзе сызган, диләр.

Габсаматов. Сез кемгә кычкырасыз?

Хәбибрахманова. Ә нигә сез бәйләнәсез?

Габсаматов. Кем сезгә бәйләнә?

Хәбибрахманова *(елап җибәреп)*. Сез бәйләнәсез. Минем нй гаебем бар. Мин ирсез хатын. Яклаучым юк. Шулай инде, йомшак агачны корт баса.

Габсаматов. Булырсыз йомшак. Сез үзегез теләсә кемнең жанын кимерә торган хатын.

Хәбибрахманова. Үзегез бик әйбәт инде. Әллә белмибезме.

Габсаматов. Нәрсә беләсез ә, нәрсә беләсез?

Хәбибрахманова. Миңа ышанмагач, бәлки үзегез сызгансыздыр.

Габсаматов. Ә?!

Хәбибрахманова. Өстәл тартмагызда нинди ручка ул?

Габсаматов. Ә?

Хәбибрахманова. Мә.

Габсаматов. Ул Нуретдинов ручкасы, тиле хатын. Мин аны сатып алдым, өч сумга.

Хәбибрахманова. Кемне сатып алганыгызны, күпмегә сатып алганыгызны беләм мин. Мине дә сатып алырга җыендыгыз. Ләкин без сатыла торганнардан түгел. Ирсез хатын булсак та үз кадеребезне беләбез. Сызучы сез. Юкса, миңа ышаныр идегез. Мин шундый хәбәр таратачакмын, бөтенесе белсеннәр.

Габсаматов *(кинәт йомшап)*. Шулай укмыни?

Хәбибрахманова *(йомшап)*. Шулай шул, Мәмдәл Харисович.

Габсаматов. Алай икән... Кхм... Гафу итегез, Сабира ханым, кызып кителде.

Хәбибрахманова. Сез дә гафу итегез, Мәмдәл Харисович.

Габсаматов. Сызучы мин түгел.

Хәбибрахманова. Мин дә түгел.

Габсаматов. Ләкин кем?

Хәбибрахманова. Үзе.

Габсаматов. Тагын үзе?!

Хәбибрахманова. Үзе дим. Сөйләп бетергәнне көтегез. Әле яңа гына яңа месткомның утырышы булган. Эш бүлешкәннәр. Шунда Борһан Җамалиевич үзе әйткән. Җитәкчене месткомга сайлау килешә торган нәрсә түгел дигән. Чөнки, местком, дигән, җәмагать оешмасы, дигән, ә мин административ җитәкче, дигән. Һәм шунда үз фамилиясен үзе сызганын ычкындырып ташлаган.

Габсаматов. Ант диегез.

Хәбибрахманова. Ант әгәр. Кичә самоотводта да шулай дигән иде бит.

Габсаматов. Шулай дигән иде. Ләкин сызам дип әйтмәгән иде.

Хәбибрахманова. Бу юлы әйткәндер.

Габсаматов. Китәргә мөмкин. Рәхмәт, Сабира ханым. (Хәбибрахманова чыгып киткәч, бюллетеньне лупа аша карап.) Дөрес бит. Валлаһи дөрес. Болай итеп бары тик Борһан Җамалиевич кына сыза ала. Ничек соң мин, ахмак, шуны... Үзен үзе сызган диген. Үзен үзе бит. Әгәр белгән булсам, сизенгән булсам, мин дә сызган булыр идем Борһан Җамалиевичны, шатырдатып сызган булыр идем.

*Пәрдә.*

◇◇◇◇◇◇◇◇◇



## Фәннур Сафин

*Туган җирем — Минзәлә районы Күзкәй авылы.*
*Дөньяга беренче соравым:*
*— Әтием кайда?*
*Һәм абыйларым мине яшел аланда сузылып яткан кара еландай бормалы сукмактан алып киттеләр. Зират юлы иде бу...*
*Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыйм.*
*Миңа 22 яшь. Әйтәсе сүзләремнең дәвамы шигырьләремдә.*

### Музей ачтым

Мин өр-яңа музей ачтым.
Анда
Фатих Кәрим язган каләм бар.
Мин өр-яңа музей ачтым.
Анда
Күтүй кайта дигән хәбәр бар.

Минем музеемда Мөҗәйләрдән,
Алишлардан яңа хатлар бар.
Анда Җәлил ярсып шигырь укый!..
Янында...
Аның башын кискән балта бар.

Музеемда канәфер чәчәкләре,
кашкарыйлар, кыргый гөләпләр,
ядрә тишеп үткән йөрәкләр бар,
үтерелгән җырлар, теләкләр...

Музеемда — каен тузы түгел,
Кеше яна торган мичләр бар,
Һәм солдатлар сөйгән хатыннарын
Соңгы тапкыр кочкан кичләр бар.
Ярсу хисләр, бетмәс үчләр бар!..

Сугыш кырын ташлап качканнар бар,—
Корбаннарны таптап чапканнар...
Шулар бит ул якын туганнарын
Мәрхәмәтсез килеш сатканнар...

Бу дөньяда һаман яши әле
Намус сатып көн итүчеләр...
...Яңа музей ачтым йөрәгемдә...
Килегез сез аңа,
Кешеләр!

## Юлда

Идел елга ул кич ачуланды,
дулкыннары бәрде түшемә...
...Ярда, төнге учак җылысында,
акчарлаклар керде төшемә...

Күзләремне ачсам:
җил басылган,
давыл тынган,
алсу таң аткан.
Юлга дәшкән кебек, акчарлаклар
тавыш бирә миңа ерактан.

Әй дулкыннар, инде пышылдашып,
ялый комда яткан ишкәкне.
Учагыма талгын җил җан өрә,
иңбашыма салам бишмәтне...

Учагыма чыбык өстим дә мин,
җан җылысы алам, хәл җыям.
Барыр юллар шундый озын әле,
җитәсе җир — ерак океан!..

## Һаман шулай...

Кызыктырып йөргән кызлар инде
хатын булган.
Тиң парлары белән атлый алар
яныбыздан...

Күрше өйдә челтәр бәйли һаман
бер тол хатын.
Ай нурын җеп иткән.
Җебе — алтын,
йөрәк — ялкын!..

Яшь кызларның кисеп бәгырьләрен
телем-телем,
гармун сөйли гашыйк егетләрнең
йөрәк серен.

Тик без сөйгән яшьтәш кызлар гына
әни булган;
нәниләре белән горур атлый
яныбыздан...

## Бер елганың ике ярында

Кайгыларым ташлыйм, диеп, ялгыш
бәхетемне суга салганмын...
Һәм күперсез елга ярында мин
көймә көтеп ялгыз калганмын.

Сак белән Сок кебек кычкырабыз
бер елганың ике ярында.
Синең якка карап искә алам
үткәннәрнең барын-барын да...

Көймә чакырып күпме сызгырсам да,
үткән көннәр кайтмый бит инде...
Әмма минем уйчан күңелемә
алар әле кайтыр шикелле!...

## Карт атменәр

Эх...
үләннәр кибә икән,
күзләр дә килә икән.
Үзәндәге яшь тайларга
инде кем менәр икән?

Пар атларның чанасында
ера-ера карларны,
ал таңнарның каршысына
чабасылар бар әле,
чабасылар бар!..

Эх...
үләннәр бетә икән —
инде күз житә икән.
Тик шунысы бик кызганыч:
гомер тиз үтә икән...

Касыйм Фәсәхов

# СҮЗЕ АЛТЫН, ЭШЕ ЯЛКЫН

Наил Касыймов Түреш елгасы буендагы җәйләүдән бик кәефсезләнеп кайтты. Ферма мөдире Әзһәм Мансуров җен ачуларын чыгарды аның. Аңламаса да аңламас икән бу бәндә дигәнең. Туксан эшең туксан якта таралып ятсын, бөтен дөньяң кырылып бетсен, ә аның уенда да юк. Соң, тәнендә җаны булган кеше мондый чакта, лаякыл исереп, әрәмәдә җырлап ята димени? Җитмәсә үзе генә дә түгел бит әле, котүчене дә «компаньон» иткән, акылсыз. Сөт өчен көрәшнең иң кызган чагында, «Сезнең колхоз сөт буенча кайчан артталыктан чыгар»,— дип, районнан теңкәгә тигән вакытта. Мөдир үзе шулай йөргәч, бүтән терлекчеләрдән нәрсә таләп итәсең инде. Фермада нинди тәртип булсын, ди.

Озак уйланды председатель. Күңеленнән тегесен дә, бусын да мөдир итеп карады, ләкин һәрьяклап уйлаган саен, барысыннан да баш тартты. Монысы ялкаурак, әрәмәдә йокы симертүдән бушамас. Бусы тырыш та, уңган да кебек, характеры йомшаграк. Кешеләрне тыңлата алмас. Сыер савучыларны бело ул — берсеннән берсе үткен. Бер сүзгә килсәләр, телләреннән чаткы чыгаралар. Әзкиясе дә, Канитәсе дә, Ритасы да, бүтәннәре дә шул. Яшь булуларына карама. Һәркайсы урта мәктәп тәмамлаган. Сөйләшеп кара син алар белән тегеләй-болай гына...

Һәр яктан килгән кандидатураны үзе генә таба алмагач, Наил партком секретаре белән киңәшергә булды.

— Кара әле, Зәйнак, бу Әзһәм урынына кемне куйыйк икән, ә? Тегесен дә, бусын да уйлаштырдым, һич кенә дә төпле фикергә килә алмадым.

— Әгәр дә... Әгәр дә,— дип кабатлады Зәйнак, әйтим микән, юк микән дигәндәй.

— Нәрсә «әгәр дә?!.» Әйбәт кандидатураң бар икән, әйт!..

— Мин Канитә турында киңәшмәкче идем,— диде Вәлиев, ниһаять.

— Ганиеваны әйтәсеңме?

— Әйе...

— Ай-һай... Барып чыгармы икән?

— Нигә? Алдынгы савучы. Коммунист. Былтыр гына «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнде. Димәк, авторитеты да бар. Үткенлек ягына килгәндә дә...

— Анысы җитәрлек,— дип елмайды председатель.— Дөресрәге, шунысыннан курка төшәм дә мин аның. Тегесе тегеләй, монысы болай, тегеләй итик, болай ярамый, дип җаныңны алыр.

Партком секретаре шаркылдап көлеп җибәрде.

— Үзәгеңә үткән икән.— Аннары җитди итеп өстәде.— Соң, иптәш Касыймов, безнең ул фермага нәкъ ут чыгара торган кеше булсын. Минемчә, Канитә нәкъ менә шундый. Авыз ачып сүзен әйтә алмаган җебегәнне куйсаң, ярты елдан тагын мөдир мәсьәләсен тикшереп хәл итәргә туры киләчәк.

— Анысы шулай инде...

— Кыскасы, Ганиева — иң кулай кандидатура,— диде секретарь, мәсьәлә хәл ителгәндәй.— Парткомның фикере шундый. Бу хакта сүз булган иде инде, хәтереңдәдер. Тик менә үзен күндереп булырмы?

— Нигә булмасын икән?

— Шундыйрак хатын ул.— Һәм Зәйнак көлеп җибәрде.— Бер хәл искә төште әле. Ире Гарифҗанны комплекслы бригадага бригадир итеп куйганда бик кызык булган иде. Бригаданың комсоргы иде бит Гарифҗан. Тәкъдим иткәч, әллә ни тарткалашмады, риза булды. «Ярар, җәмәгать белән уйлашып карыйк»,— диде дә өенә кайтып китте. Ун минут та үтмәгәндер, дулап Канитә килеп керде. Керде дә диванга капланып еларга да тотынды.

— Бу ни була инде, Зәйнак абый,— ди, елый-елый.— Нинди правагыз бар минем ирсез калдырырга, өч бала белән. Ул вакытта кече кызы юк иде әле.

— Нәрсә булды, мин әйтәм, Гарифҗанга ни булган? — Аптырап калдым үзем дә, ни уйларга да белгән юк.

— Белмәмешкә салынмагыз инде, Зәйнак абый,— ди бу,— бригадир итәсез икән бит Гарифҗанымны,— ди.

— Әйе шул,— дим,— ләкин бригадир итүнең синең ирсез калуыңа нинди бәйләнеше бар,— дим, аптырап.

— Ничек инде булмасын,— ди бу.— Бригадада күпме хатын-кыз? Ә Гарифҗан ул хатын-кыз күрсә һушсыз кала. Куштанрак хатын-кызлар да бетмәгән. Бигрәк тә нәчәльник кешегә. Честно комсомольское, аздырачаклар, мине тол, балаларымны ятим итәчәкләр.

Эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алгач, мин көләргә тотындым. Юкка көнләшәсең, мин әйтәм, Гарифҗан андый түгел ул. Үзең дә бит әлегә кадәр мактап туя алмый идең, минем Гарифҗаным беркемгә дә карамый ул, диеп.

— Карамый иде дә бит,— диде, яшьләрен сөртә-сөртә Канитә,— нәчәльник булгач, кем белсен, азып та куяр...

— Алай икән,— диде председатель дә көлә-көлә.— Бик яратышып торалар иде шул. Гарифҗаны да теленнән төшерми иде Канитәсен. Кызганычка каршы, бик вакытсыз вафат булды. Дүрт баланы тәрбияләп үстерү җиңел түгелдер хәзер аңа да. Шулай да уңган хатын Канитә. Вакытсыз килгән бәхетсезлектән сыгылып төшмәде, авыр булса да, үзен тиз кулга алды. Бирешми, эшендә дә алдынгы, үзешчәннәр концертында катнашырга да вакыт таба. Балаларын да әйбәт кенә карап үстерә.

— Әнисенә охшаган,— дип сүзгә кушылды Зәйнак.— Минҗиһан апай да бик тырыш, уңган иде бит. Бердәнбер кызын күз алмасыдай багып үстерде. Камай абзый фронтта һәлак булганда аңа егерме биш кенә иде бит әле. Яучылап йөрүчеләр дә булды бугай. Кызымны үстереп, кеше итәсем бар, дип кул гына селтәде. Канитә үсеп җиткәч, Минҗиһан апаның бар курыкканы — кызының унны бетереп укырга китүе иде. Бер китсә, кайтмый инде ул, дип офтана торган иде. Китмәде бит Канитә. Әллә әнисен бик яратканга инде, әллә авылдан китәсе килмәгәнгә. Туры килеп торуын кара син аның. Әнисе тол калган яшькә җитәр-җитмәс, Канитә дә ялгыз калды бит...

— Алайса тәвәккәллик дисең инде,— диде Касыймов, сүзнең бик озынга китүенә чик куеп.

— Канитә йөзгә кызыллык китермәс, дип ышанам мин,— диде Вәлиев, урыныннан торып.— Әлбәттә, баштарак ярдәм дә кирәк булыр. Ләкин булдырыр ул. Ферма хәлләрен яхшы белә.

— Хәл иттек, болай булгач...

* * *

Председатель белән секретарьның шикләнүләре урынсызрак булган икән. Канитә уйламаганча-көтмәгәнчә тиз ризалашты.

— Фермадагы тәртипсезлекләр күптән инде җанымны әрнетә иде. Дөресен әйтим, эх, үзем мөдир булсаммы, дип куйган чаклар да булмады түгел. Сәрхушлектән башы чыкмаган мөдир эшне рәтле алып бара аламыни ул,— дип килеште Канитә председательнең тәкъдименә каршы.— Коммунист башым белән кушкан эштән читләшә алмыйм

инде анысы. Ләкин, председатель иптәш, минем бер шартым бар. Шунсыз мөдир булмаячакмын.

— Тыңлап карыйк, нинди шарт икән ул,— диде Касыймов, партком секретарена күз кысып. Янәсе, күрдеңме, башлана...

— Минем шартым шул,— диде Ганиева,— фермадагы тәртипсезлекләрне бетерү өчен берничә кешедән, бәлки, котылырга да туры килер, әгәр дә җайга килмәсәләр дим инде. Андый чакта сезнең ярдәм кирәк булыр.

— Әт-тә-тә,— дип телен шартлатты Наил, сүзне шаяруга борырга тырышып,— әле мөдирлекне тәкъдим генә итәләр, ә ул үзенчә тәртип тә урнаштыра башлады инде. Тора-бара нишләр бу...

Канитә шаяртуны аңламады булса кирәк, әллә инде аңласа да сүзне житдилектән шаяртуга борырга теләмәдеме, кинәт кенә кабынып китте дә председательнең үзенә ябышты:

— Юк, иптәш председатель, мөдир итәсез икән, үпкәләштән булмасын, сезгә дә тыңгылык күрсәтмәм. Тәртипсезлекләрнең сәбәбен фермадан гына түгел, канцелярия тирәсеннән дә эзләргә кирәк булуы ихтимал. Әгәр андый чакта: «Әт-тә-тә, мөдир булдым дигәч тә...»,— дип торасы булсагыз, табыгыз бүтән кешене.— Канитә урыныннан торды да ишеккә үк юнәлде.

— Тукта әле, тукта, мин шаярттым гына бит,— диде председатель, житди тонга күчеп.

— Җаваплы эш турында сөйләшкәндә нинди шаярту булсын,— диде Канитә, кырт кисеп.

— Авыр булыр, билгеле,— дип сүзгә кушылды партком секретаре,— ләкин без ышанабыз, булдырырсың, Канитә. Ярдәм кирәксә, без һәрвакыт әзер. Идарә дә, партком да. Уртак эш ич. Үпкәләш булмас...

Эш чыннан да җиңел түгел иде. Иске мөдирнең барысына да күз йомуына күнеккән, ара-тирә инеш суы исәбенә савымны арттырырга өйрәнгән савымчыларның, терлекләр ризыгына кул сузгалап, «зәмзәм суы» белән җайлау тирәсендәге әрәмәлекләрдә күңел ачып утыргаларга хирессләнеп киткән терлек караучыларның кәйберләре башта яңа мөдирне бар дип белергә дә теләмәделәр, аның сүзләрен кинаяле елмаеп кына тыңладылар: кара әле, ул да мөдир булган, янәсе. Нилләр сөйләнгән була бит, өмер бирергә өйрәнеп туган диярсең. Әле кичә генә гади сыер савучы булганын оныткан, күрәсең...

* * *

Канитә идарәгә пыр тузып килеп керде. Аның аксыл-коңгырт тестәге чәчләреннән тузгыган булуыннан, болай да алсуланып торган тулы битләреннән кызу мич алдында мәшәкатьләнгәндәге кебек тагын да кызара төшүеннән һәм йөзенә чыгып торган ачуыннан ук нидидер гадәттән тыш хәл булуын аңларга мөмкин иде. Ду килеп керде дә уфылдап диванга утырды. Ачуы чиктән ашканлыктан, беравык әңгәмәне башлап җибәрер сүз таба алмый торды.

— Ни булды, Канитә,— диде Касыймов, аның бу кыяфәтеннән бераз аптырашка калып.

— Булды инде,— диде Канитә, ниһаять, сөйләшә алырдай хәлгә килеп.— Оят дигән нәрсә юк та икән үзендә. Бозаулыйсы сыерлар өлешенә кергән бит, оятсыз. Хет бүгеннән тот та төрмәгә утырт.

— Тукта әле, Канитә,— диде председатель, аны бүлдереп,— рәтләп кенә сөйлә әле. Нәрсә булды? Кемне төрмәгә утыртырга җыенасың? Нәрсә өчен?

— Шул инде, Тимергали. Буаз сыерларга ашатасы онны урлаган. Үзем тоттым. Сатмакчы икән, мәртәт. Аракыга акча кирәк бит. Барлы-юклы ризыкларын да шулай янга калдыргач, ул сыерлар бозаулагач күпме сөт бирә инде дә, бозавының рәтечираты нинди була. Юк бит, аны уйламый, аракы дигән нәмәрсә тәмам зиһенен алган, күрәсең, юньсезнең.

— Кара әле, Канитә, чынмы бу,— диде председатель, ышанып җитмичәрәк.— Кешегә зур гаеп ташлау бит бу. Алай-болай хата булып чыкса...

— Соң, үзем тоттым, утыз килограмм онын фермага китерттем, дип әйтеп торам лабаса. Тагын нинди алай-болай булсын... Кыскасы, мин аңа фермага аяк басасы

булма, дидем. Бүтән кеше бирегез. Ә үзен судка бирәсезме анда, әллә иптәшләр суды алдына бастырасызмы, үзегез хәл кылырсыз.

Шулай диде дә Канитә, председательнең ни әйткәнен дә көтмичә, чыгып та китте...

...Ире Тимергалине тоттырганы һәм бөтен кеше арасында хур иткәне өчен Әзкия мөдиргә бәйләнер җай гына эзли иде. Канитә аңа:

— Савып бетермисең сыерларыңны, җилен төбен калдырасың,— дип әйтергә өлгермәде, Әзкия эләктереп алды, пыр туздырып салды Ганиеваны.

— Я аллам, кыланышларын гына кара инде. Ул да нәчәл булган, имеш. Кичә генә сыер сауганын оныткан, гомер буе мөдир булган диярсең. Тимергали өчен бәйләнәсең син миңа. Аны хур итүең җитмәгән, тагын мине дә кудырырга телисең бугай. Бик һаваланма, дөнья куляса бу, яңадан әйләндереп басмасын. Бүген мөдир булдым дигәч тә... Иртәгә тагын сыерлар сава башлавың да бар. Мөдирлек нәселдән нәселгә күчми ул.

— Кушсалар, савармын, эшләмәгән эш түгел,— диде Канитә.— Сыер саву он урлау түгел, хурлыгы юк. Ә менә Тимергали хакында өзеп әйтә алам: фермада эшләмәячәк ул. Председатель дә яклар мине бу мәсьәләдә...

— Яклар, якламый ни,— дип мәсхәрәле көлде Әзкия,— аның күңелен син күрәсең, синекен — ул. Шулай була инде, кунак ашы — кара каршы...

Канитәнең яңагына суккандай булды. Юк, яңакка сугу гына кешене болай түбәнсетмидер, йөрәкне болай сыкратмыйдыр. Сөттәй пакь күңеленә төкерделәр аның. Әзкиянең кем бакчасына таш атуы һәркемгә аңлашыла иде... Бәлки әтисез үскәнен истә тотыптыр, бәлки яшьли дүрт бала белән тол калуның хатын кеше өчен никадәр авыр булуын аңлаптыр, ә бәлки уңганлыгы, тырышлыгы, авырлыклардан курыкмавы өчендер,— председатель бу чая, беренче карашка хәтта усал да булып күренгән хатынны чын-чынлап хөрмәт итә иде. Ә мөдир итеп куйгач, Ганиеваның фермада тәртип урнаштыра башлавын, кыска гына вакытта фермадагы эшләрнең җайга салына баруын күреп, аңа булган ихтирамы тагын да артты, тырыш мөдиргә мөмкин булган һәр ярдәмне күрсәтергә тырышты. Бу, әлбәттә, кайбер усалларның, көнчеләрнең күзеннән читтә калмады.

Дөрес, Канитәнең бу имеш-мимешләргә баштарак әллә ни исе китмәгән иде. Шулай да соңгы вакытта күңеле тынычсызлана башлады. «Касыймовның хатыны райкомга барган, имеш. Иремне бүтән җиргә күчерегез, анда ул ферма мөдире белән чуала дип сөйлиләр, дип жалоба биргән, имеш»,— дигән хәбәрне ишеткәч, әллә ничек бик авыр булып киткән иде. «Миңа нәрсә, сөйләрләр-сөйләрләр дә туктарлар. Тик менә бер дә юктан, бер тамчы да гаепсез кешенең семьясы җимерелүе мөмкин. Явыз гайбәт нәрсә генә эшләтмәс»,— дип хафаланган иде.

Ә менә Әзкиянең сүзләре бөтен күңелен айкап салды. Ничә еллар үзең белән бергә эшләгән, серләр уртаклашкан иптәшең йөзеңә шулай дисен әле. Белә бит ул минем гөнаһсызлыгымны, намусым сафлыкны белә... Җәрәхәтлим дип, юри шулай әйтә ул, ирен тоттырган ачудан. Эх, Әзкия, Әзкия... Син шундыйдыр дип һич уйламаган идем...

Бүтән вакытта һәм башка нәрсә турында сүз барса, картлар әйтмешли, болай әйтүченең иманын укыткан булыр иде Канитә, «мәңге алай әйтмәм»,— дип ант итү дәрәҗәсенә җиткерер иде. Уң яңагына сукканда сулын куеп тора торганнардан түгел ул. Ләкин бу юлы, әллә инде нахак гаепнең авырлыгыннан, Канитә телсез калгандай булды. Әйтергә дигән сүзләре тел очына ябышып калдылар, тамагына, бик нык авырттырып, төер тыгылды. Күзеннән мөлдерәп яшьләр атылып чыкты. Ул аларны тыярга теләсә дә, булдыра алмады. Шуңа күрә, кешеләр күрмәсен дип, тизрәк китеп барды. Аның бу халәтен Сәхипкамал апа гына сизеп калды.

— Алай ярамый, Әзкия, кеше күңелен җәрәхәтләү җиңел ул, бер тиенлек гаебе булмаса да. Нахакка рәнҗеттең Канитәне,— дип куйды.

* * *

Канитә фермадан туп-туры өенә китте.

Өенә кайткач, чишенмәгән килеш, караватка капланды. Бик озак, үксеп-үксеп елады. Бераз тынычлангач, күтәрелеп, иренең стенадагы рәсеменә карады. Чем кара

күе чәчле, таза җилкәле, тулы йөзле Гарифҗан аңа елмаеп тора иде. Бу караш Канитәне эретеп җибәрде һәм ул, рәсем белән сөйләшә-сөйләшә, тагын үксергә тотынды.

— Нигә шулай иртә ятим иттең син мине, бәгырь кисәгем. Мәңге бергә яшәр кебек идек бит. Бергә-бергә булганда җил-давылы да рәхәт икән. Ә хәзер миңа ничек авыр икәнен белсә идең син. Дүрт баланы үстерү авырлыгын әйтмим әле мин, анысына гына түзәр дә идем, җебеп калмас идем. Кайбер аңсызларының көлеп каравы, яль-яшь тол тик ятмыйдыр әле дип уйлавы, бер мәнсезе тараткан гайбәткә чын дип ышануы бигрәк тә авыр, Гарифҗанкаем. Менә ничә ел инде ялгызым, ә синнән башка кеше күңелемә дә килгәне юк бит, күңелемә дә... Нинди генә рәнҗеткеч гайбәтләр таратмыйлар. Председатель күңелен күрәм, имеш. Соң бит, бәгърем, башка кешене сине яраткан кебек ярата аламмыни мин. Үзең булмасаң да, күңелемдә син генә бит минем, бары син генә...

Әкренләп Канитә тынычланды. Гарифҗаны белән сөйләшү, аның белән бергә булган чакларын искә төшерү йөрәк сыкравын баса төште һәм аның хыяллары үткәннәргә, мәктәптә укып йөргән чакларына кайтты...

Күңелле дә иде соң ул чаклар. Әле бүгенгедәй хәтерендә: бер кайгысыз, шат күңелле чая кыз иде. Тугызынчы класста укып йөргән чаклары. Нәкъ шул елны бит абыйсы итеп йөргән күрше егете Гарифҗан Канитәгә ничектер сәеррәк карый башлады. Ул урта мәктәпне бетергән һәм МТСта тракторчы булып эшли иде инде. Гел бергә уйнап үскән малай хәзер күрше кызын күргәч, югалып кала, башын аска ия торган булып китте. Әле күптәнме соң кызның чәчләреннән тартуны, урамда очраганда карга төртеп егуны ул бернигә дә санамый иде. Хәзер нигә ояла икән? Хәер, озакламый моның сере ачыкланды. Гарифҗан, бик якын дус егете аркылы, Канитәгә хат җибәргән. Янәсе, үзенең вакыты юк, МТСта эшләр муеннан. Тиз генә Күбәккә дә кайта алмый икән. Ә ул хатта шигырь язылган иде. Үзе яздымы икән Гарифҗан моны, әллә берәр шагыйрьнекен күчердеме икән? Уратып-чуалтып маташса да, шигырьне укыгач, Канитә Гарифҗанның ни өчен эше тыгыз булуын да, нигә авылга кайтырга вакыты булмавын да аңлады. Үзе үк җибәргән хатның Канитәгә ничек тәэсир итүен белүдән курка ул. Шуңа боргалап маташа. Канитә дә усал инде. Хат китергән егет аша ук җавап та җибәрде. Шигырь өчен рәхмәт. Ләкин ул Гарифҗанның бу шигырьне ни өчен аңа җибәрүен аңламый, имеш...

Шулай да, бу шигырь-хат Канитәнең тынычлыгын җуйды, күңелендә уйлар өермәсе кузгатты. Балалык үтеп, җиткән кыз булып киләме икәнни инде? Үзеннән өлкәнрәк егетләр дә гыйшык хатлары яза башлагач... Әй, болай үртәп кенәдер әле. Авылның иң чибәр егете бит, мин кем дип масаюыдыр. Янәсе, теләсә кемне беренче сүздән үк үзенә карата. Каратмый тор әле. Канитәгә алай тиз генә төшең үтмәс...

Ләкин Гарифҗан да алай үз уеннан тиз генә кайта торганнардан түгел иде. Әле тугызынчыда гына укып йөргән күрше кызына хат язуы да шаярып кына түгел, ә төннәр буе шушы кызның күз алдыннан китмәве сәбәпле иде. (Гарифҗан боларны Канитәгә өйләнешкәч сөйләде.) Кызның шигырьгә җавабы аның йөрәгендәге утны дөрләтеп кенә җибәрде. Дус егете артыннан тагын берничә хат җибәрде. Дөрес, алары шигырь итеп язылмаганнар иде. Ләкин фикере шул ук. Тик һаман да яратуын ачыктан-ачык язарга курка иде әле. Канитә дә ул хатларга көлү-шаяру белән генә җавап кайтарды.

Шулай язышып җәй дә үтте, кыш җитте. Канитә унынчы класста укый иде инде. Шулай бер көнне, кинодан соң, дус кызларыннан аерылып үзе генә калган иде, янына Гарифҗан килде дә чыкты.

— Канитә, тукта әле бер генә минутка, сүзем бар иде,— диде.

— Я, сөйлә,— диде Канитә, шаянланып.

— Канитә, кайчаннан бирле янам инде, бер дә күрмисеңме?

— Нәрсәне? — дигән булды ул, гаҗәпләнгәндәй.

— Менә... ничек дип әйтим инде,— диде егет, газапланып. Ул әллә сүз таба алмый иде, әллә сүзләрен әйтергә кыюлыгы җитми иде.

Нинди шайтан котырткандыр, Канитә көлә-көлә әйтте дә салды:

— Ә мин белем ни әйтергә теләгәнеңне. Яратам, диярге телисең... Ә мин яратмыйм сине... Сине дә, бәркемне дә...

Шулай диде дә өйләренә таба йөгерде. Артына да әйләнеп карамады, Гарифҗан куып киләдер төсле тоелды аңа. Юләр, шунда куып тотса соң инде. Бу чакта Канитә дә аның турында еш уйлана иде бит, кызлар горурлыгы гына ачылып китүдән тыеп тора иде. Ә ул көнне куып тотса, бераз ялындырып булса да, серен ачар иде Канитә. Ә ул кумады. Икенче көнне, Канитәнең мәктәпкә баруын саклап торып, бер сүз дә әйтмичә генә, кулына хат тоттырып китте. Бу Гарифҗанның йөрәк түреннән чыккан сүзләре иде. Шуннан соң бит инде ул, икенче очрашканда, Гарифҗаннан качмады һәм кинодан озата килгәч, капка төбендә сөйләшеп торырга ризалашты. Рәтле сүзләр сөйләшенмәсә дә, алар бер-берләрен аңлаштылар...

Канитә, рәхәт елмаеп, Гарифҗан хатларын күкрәгенә кысты. Ул инде көндезге өрнүен дә, әле генә үксеп-үксеп елавын да оныткан, Гарифҗанның рәсеменә караган килеш, селкенергә дә куркып утыра, яшьлегенең якты хатирәләрен күз алдыннан җибәрмәскә тели...

Шулай унынчы класс та тәмамланды, өлгергәнлек аттестаты... Чыгарылыш кичәсе... Гарифҗан да килгән иде. Гел бергә булдылар. һәм кичәдән соң да бик озак йөрделәр әле. Шул чакта бит инде көзгә кавышырга дип вәгъдәләштеләр дә.

Урта мәктәпне тәмамлагач, Канитәнең классташлары кайсылары Бөгелмәгә, Әлмәткә, Казанга китеп урнашты. Канитә дә укырга керә алыр иде, билгеле, ләкин авылдан китәргә теләмәде. Ялгыз әнисен ташлыйсы килмәде. Уйлый торгач, Канитә тәвәккәлләде дә, комсомол путевкасы белән фермада эшли башлады. Ә 1957 елның көзендә туйлары булды. Бер ел үтүгә уллары туды. Рәмзил дип исем куштылар. Аннары бербер артлы ике кызлары дөньяга килде.

Шулай бер-берсенә сокланып туялмый, әле кичә генә кавышкан кебек гөрләп яшәгәндә һәм дүртенче нәнине көткәндә, алар семьясына коточкыч бәхетсезлек килде. Печән өсте иде. Гарифҗан тирләгән килеш салкын җиргә ятып йоклаган да, кинәт бик каты чирләгән, больницага ук алып киткәннәр. Канитәгә җәйләүгә килеп әйттеләр. Бу коточкыч хәлдән ничек район больницасына барып җиткәнен дә белми калды ул. Врачларның йөзеннән үк Канитә сөеклесенең хәле өметсез булуын аңлап алды...

Ике атнадан аның Гарифҗаны, мәңге шулай бергә-бергә яшәрбез дип уйлаган ире, дөнья куйды. Ә бер айдан дүртенче баласы Рушания дөньяга килде. Туганда ук ярым ятим булып, әтисез булып. Әй, ул авырлыкны, ул йөрәк әрнүен, ул көннәрдәге өметсезлекне әйтеп тә, сөйләп тә бетерә торган түгел инде. Гарифҗаннан башка яшәү юк һәм мөмкин дә түгел кебек тоелды аңа. Тирә-юньдәге бер нәрсәгә дә игътибар итмичә, дөньядан киткән кешедәй йөрде. Ләкин эшен ташламады: аның күңеле шунда гына, иптәшләре арасында гына беравыкка тынычлык таба иде... Ә вакыт үзенекен итте, үтә торды һәм бик әкрен булса да, йөрәктәге тау чаклы хәсрәтне әкренләп тарата бирде. Канитә бар күңелен эшкә баглады, ө кичләрен балалары белән юанды. Озакламый колхозда иң тырыш савучы булып танылды. 1966 ел аңа зур шатлык китерде: тырыш хезмәте өчен «Почет билгесе» ордены белән бүләкләделәр...

Ләкин ялгызлык, Гарифҗанын өзелеп-өзелеп сагыну юк-юк та һаман сиздерә килде. Андый чакларда йөрәге сулкылдап-сулкылдап әрнешә. Төшенкелеккә бирелгәндә ул үз бүлмәсенә бикләнеп, барлык хәсрәт-кайгыларын, рәнҗү-үпкәләрен Гарифҗанның рәсеме белән уртаклаша һәм аңа җиңел булып китә. Өч ел үтте инде, ләкин яшьлек дустына күңелендә генә булсын хыянәт иткәне юк, итәчәк тә түгел. Аның төсле булган дүрт баласы бар, аларны кеше итәргә кирәк. Ничек инде бүтән кешегә күңел салсын ул. Билгеле, ялгыз хатын дип сүз катучылар да, кул сузучылар да булыр, әгәр ирек куйсаң. Ләкин аның ниндилеген беләләр, һәм, шөкер, андый уйлар белән якын килгән кеше дә юк. Юк... Ләкин барыбер гайбәт тараталар. Пычрак сүзләр белән Гарифҗанына булган тугрылыгын, күңеленең пакьлеген тапламакчы булалар...

* * *

Тимергали фермадан куылды. Ләкин моның белән генә эшләр җайланмады әле. Элеккеге мөдирнең шешәдәшләре булган кайбер терлек караучылар «сәнәктән кирәк булган нәчәльник» белән исәпләшергә теләмәделәр. Үзләренең яңа мөдирне санга салмауларын раслау өчен хәтта кай көннәрдә эшкә дә хатыннарын гына җибәрделәр, ә үзләре кибет тирәсендә «өч борын»лап кәеф-сафа кордылар. Әгәр дә һаман-һаман шулай барса, эшнең һич тә җайга салынмаячагын Канитә бик яхшы аңлады. Башта ул

ләр белән иптәшләрчә сөйләшеп карады, ә инде барып чыкмагач, мәсьәләне кабыргасы белән куйды: «Я эшлисез, я әнә Тимергали язмышы сезгә дә. Авылда кешеләр юк түгел, табарбыз»,— диде. Бу ярыйсы гына тәэсир итте. «Ирлек горурлыкларын» саклап, Канитәгә саксыз караган булып кылансалар да, эшкә үз урыннарына хатыннарын җибәрми башладылар...

Авырлык белән булса да, фермада әкренләп тәртип урнашты, хезмәт дисциплинасы ныгыды.

Инде хәзер алда икенче мәсьәлә һәм иң читене — сыерларның савымын арттыру бурычы тора. Моңа һәр терлекче тырышып эшләгәндә генә ирешергә мөмкин. Бар көчне шуңа тупларга кирәк. Бер үк вакытта «сыерларның сөте — телләрендә» дигән мәкальне дә онытырга ярамый. Азык, яхшы, мул һәм сусыл азык, витаминлы һәм ақсымлы азык кирәк. Шунсыз савымны арттыру турында уйларга да мөмкин түгел.

Көн димәде Канитә, төн димәде, ял белмәде; көтүчеләргә дә тынгылык күрсәтмәде, председательнең дә теңкәсенә тиде. Барыбер үзенекен итте, һәм әкренләп савым күтәрелә башлады. Сөт арту белән терлек караучыларның хезмәт хакы да күтәрелде. Материаль кызыксындыру чараларын куллану терлекчеләр арасындагы ярышны тагын да көчәйтеп җибәрде. Хәзер инде берәү дә эленке-салынкы йөрми. Берәүнең дә иптәшләреннән калышасы, хезмәт хакын ким аласы килми. Фермага эшкә килергә теләүчеләр дә артты. Хәтта Тимергали Камалов та яңадан эшкә алуларын үтенде, үзенең хатасын аңлаганлыгын әйтте. Уйлашкач, киңәшкәч, аны яңадан фермага алдылар, сыерлар көтәргә билгеләделәр.

Ел ахырына күрсәткечләр матур гына булды, уртача һәр сыердан сөт савып алу беркадәр артты. Ләкин беренче уңышлар бик аз иде әле, алар тынгысыз мөдирне һич тә канәгатьләндерә алмадылар.

— Уртача савым өч мең килограмм да юк бит. Булмый болай, иптәшләр, уйлашырга, киңәшергә, алдагы елда кимендә өч меңгә күтәрергә кирәк,— диде ул терлекчеләргә.

Сыер савучылар да, терлек карауучылар да мөдирләренең уртак эш өчен януын, иптәшләренә гадел булуын аңлаганнар иде инде. Ачу саклый торган гадәте юк. Әнә, Тимергалине дә кире алды бит. Әзкия белән дә элеккедәгедәй дуслар, араларында бернәрсә дә булмаган кебек. Югыйсә, теге вакыттагы сүзләре өчен үпкәләрлеге дә бар иде инде. Эчендәге тышында шул аның, әйтәсен туп-туры әйтә дә, артыннан сүз куертып йөрми. Хәзер терлекчеләр дә, үзара сөйләшкәндә, Канитәгә карата тегендимондый сүз ычкындыручы булса: «Канитәгә сүз әйтмәгез, ул андый түгел»,— дип кенә әзеләр.

Ә сыер савучылар арасында ярыш кызганнан-кыза. Иң алда — Ханә Кәлимуллина. Аның артыннан Рита Шәяхметова белән Сәхипкамал апай. Аның кызы Фирдания дә, тугызынчы класстан соң, сыер сава башлады. Унынчыны кичен укып тәмамларга булды. Кемнең дә ялкау исеме аласы килми. Тырышкач, акчасын да мул аласың. Әнә Риталар, Сәхипкамаллар кайбер айларда 160 ар сум алалар.

Канитәнең мөдирлек иткән икенче елы зур уңыш китерде. Ферма колхоз күләмендә генә түгел, Мөслим районы буенча да беренче урынга чыкты. Һәр сыердан савым ул мөдирлек итә башлагандагыга караганда уртача 640 килограммга артты. Ханә Кәлимуллинага колхозның Куйбышев исемендәге премиясе бирелде. Башкалар да кыйммәтле бүләкләр алдылар — кайсына радиоалгыч, кайсына кер юу машинасы, тегү машинасы.

— Хәзер безнең бурыч — һәр сыердан 3300 килограмм сөт савуга ирешү,— диде Ганиева партия җыелышында...

Коммунистлар тырыш мөдиргә зур ышаныч күрсәттеләр, колхоз партвомының члены һәм район партия конференциясенә делегат итеп сайладылар. Ә район партия конференциясендә ул райком члены һәм партиянең өлкә конференциясенә делегат итеп сайланды. Бу Канитә Ганиеваның күңелен тагын да күтәрде. Ләкин ул үз өстенә тагын да зуррак җаваплылык өстәлүен дә аңлады. Партиянең өлкә конференциясендә булган чыгышларны тыңлау аны тирән уйланырга мәҗбүр итте. «Сөтне күп итеп җитештерү генә аз икән бит әле, аның нинди бәягә төшүе турында да уйларга кирәк икән. Ә бездә моңа җитәрлек игътибар бирелгәне юк әлегә. Кайту белән бу мәсьәләне күтәрергә туры килер».

* * *

Фермаларда эшләр шактый җайланды дигәч тә, барысы да ал да гөл инде дип булмый әле. Мәсьәләнең бер ягы уңай хәл ителсә, икенче ягы калкып чыга. Берәүләр белән булган үпкәләшләр хәл ителеп, алар белән мөнәсәбәтләр яхшырды дип кенә уйлыйсың, икенчеләре белән конфликтка керәсең һәм яңа гауга куба.

Җитештерелгән сөтнең үзкыйммәтен исәплəп карагач һәм аны узган еллардагы саннар белән чагыштыргач, Канитә гаҗәпкә калды. Савым арткан, ә менә сөтнең үзкыйммәте хәтта элеккегә караганда да күтәрелә төшкән. Бу инде бернинди рамкага да сыймый. Дөрес, аның фермасы буенча сөтнең үзкыйммәте колхозның башка фермаларындагыдан түбәнрәк. Логинов белән Мәрданов җитәкчелегендәге фермаларда сөтнең центнеры унҗиде сумнан алып унсигез сум илле тиенгә кадәр, колхоз буенча да унбиш сум алтмыш биш тиен. Ә аларда унөч сум кырык тиен генә. Шулай да югары әле бу. Аны киметү мөмкинлекләре булырга тиеш.

Ганиева, идарәгә килеп, колхозның баш бухгалтеры белән сөйләште, ни өчен сөтнең болай кыйбатка төшүе белән кызыксынды. Баш бухгалтер Хәниф Мирхаҗиянов моны бик ансат аңлатты:

— Терлек азыгы җитештерү кыйммәткә төшә, шул кыйбатландыра. Аннары, күпме силос бозыла, кибән төпләрендә күпме печән, салам череп кала. Алар бит барысы да сезнең өскә...

— Ничек инде безнең өскә,— диде Канитә, аңлый алмыйча.

— Ничек булсын, колхозның барлык азыгы җәйдән үк исәпкә алынган. Ел барышында күпмесе бозылуы, әрәм-шәрәм ителүе хисапланмый инде аның.

— Димәк, чересә дә, бер траншея силосың яраксызга чыгып, терлекләрнең теленә тимәсә дә, урлашсалар да — барысы да безнең малкайлар ашаганга санала?

— Шулай булып чыга...

— Бу дөрес түгел бит, иптәш бухгалтер, бөтенләй дөрес түгел.

— Соң, шулай килгән инде ул, шулай барачак. Бездән генә калмаган, дигәндәй. Аннары, үзең дә беләсең ич, колхозда хуҗалык исәбе. Димәк, сезнең фермага да кагыла.

— Хуҗалык исәбе булгач та, кулга кермәгән азыкны безнең өскә сипләргә димәгәннәр бит,— дип кызды Ганиева.— Юк, моны болай эшләүгә чик куярга кирәк. Кемнәрнеңдер җавапсызлыгы аркасында терлекчеләр зыян күрергә тиеш түгел...

— Сиңа гына дөнья тар инде, Канитә,— дип ризасызлык белдерде баш бухгалтер,— барысына да ярагач, синең генә күңеленә кая булып төшә һәрнәрсә...

Касыймов икенче колхозга күчерелгәч, аның урынына председатель булып калган Зәйнак Вәлиев тә бу мәсьәләдә Канитәне бик хупларга теләмәде. Партком секретаре чагында бүтәнчәрәк сөйләшә иде, әллә нишләп китте әле ул да. Хәер, председательнең дә эше читен инде. Бер ферма белән дә менә ничек тинтерәп бетәсең, ә бит ул бөтен хуҗалык өчен җавап бирергә, барысының да күңелен табарга тиеш. Шулай да, председатель:

— Син генә куертып йөрмә инде, Канитә, бу мәсьәләне, барыбер үзгәреш кертә алмассың,— дигәч, Ганиеваның җен ачулары чыкты.

— Ничек инде алай, Зәйнак абый? Бу бит һич кенә дә гадел булмый. Сыер савучыларның хезмәтен урлау була бит бу. Болай да тырышалар инде. Күпме сөйләнеп, төп эшләрне дә механикалаштыра алганыбыз юк. Ул да бит үзкыйммәткә суга. Әле бит йөз сиксән сыерның шул кадәр үк бозавы була, аны карарга кирәк. 1200 дән артык сарык безнең кулда. Кырыклап кеше эшлибез бит. Механизация булса, терлекчеләр санын әллә никадәр киметеп булыр иде. Сөт тә, йон да, ит тә арзанаер иде.

— Менә монсы хак,— диде председатель, сүзнең икенче юнәлешкәрәк борылуыннан канәгать булып.— Шуның өчен дә яңа сыерлар абзары өлгертергә тырышабыз бит. Анда күчкәч, эшегез бермә-бер җиңеләячәк...

Мөслим районы,
Куйбышев исемендәге колхоз

Шәйхи Маннур

# ҺАМАН ДА ИСТӘ[1]

## Күңел нечкәрүе



Сугыш утлары эчендә йөргән кешенең күңеле әллә ничә төрлегә төрләнеп китә. Бер карасаң, үз өстенә шашынып килгән дошманны, бик тыныч кына булырга тырышып, аяусыз каты күңел белән атып ега солдат. Икенче карасаң, сугыш кырында яткан үлекләр өстеннән аркылы сикереп, алга йөгерә, кинәт башка бер үле гәүдәгә ышыкланып ята да, мылтыгын аның өстенә салып, дошманга ут яудыруын дәвам итә. Кешене түгел, үз өстенә килә торган үлемне үтерәм дип ата ул. Үзенә калкан булган җансыз гәүдәнең дә адәм баласы икәнлеген бер мәлгә онытып тора. «Абау, нинди таш бәгырьле, нинди миһербансыз бу — кеше дигән зат!» — дип тә уйларга мөмкин...

Әмма инде өченче карасаң, каршында калкан булып аның башын саклап калган шул үлекнең үз иптәше икәнен күреп ала ул. Күреп ала да тетрәнеп китә, күңелендә чиксез кызгану туа, күзләреннән саран яшь тәгәри һәм, иплән кенә, ярасы авыртмасын дигәндәй генә кочтырып, шул мәетне хәвефсез урынгарак алып китә башлый. Шулай үле иптәшен уттан чыгарганда, тере солдат үзе дә һәлак була кайчакта... Моны ул айнык акыл белән белеп эшләми, моны аңа саф вөҗданы куша, моны аңа йомшак һәм нечкә күңеле куша...

Әйе, солдат күңеле, аяусыз сугышлар эчендә йөри-йөри, бик тә нечкәреп китә. Әз генә ут тынып тәмәке төрер арасы булдымы, аның күз алдына балалары килә. Ничәү генә булмасын, бөтенесе берьюлы йөгерешеп-чөкердәшеп килеп, аның муенына сарыла, күпмедер еллар гомер иткән хатыны ягымлы һәм сагышлы йөзе белән аның янына — траншеяга төшеп баса шикелле. Махорканың зәңгәр төтене, солдатның өзелеп сагынуын сөйли торган тавышсыз җыр сыман, салмак кына бөдрәләнеп өскә күтәрелә... Сөйгән кызы яки яшь кәләше булган егет, гимнастеркасының сул кесәсендә — әйе, нәкъ сул кесәсендә — үзенә чиксез кадерле булган кешенең бердәнбер карточкасын саклап йөртә. Ул аның йөрәк өстенә туры килгәнгәме, аны һәрвакыт рәхәт бер тойгы белән тибрәтеп тора, яшерен шатлык белән йөзен елмайта. Хәтта ниндидер эчке горурлык бирә аңа һәм шул ук вакытта хәвефле борчуга да дучар итә: «Нихәлләрдә яши икән?.. Онытмадымы?.. Көтә микән? Турылыклы ми-

---

[1] Ахыры Башы 5 нче санда.

кән? Исән калып, кавышырбыз микән?.. Дошман сүзләренә карап, ятка күз салмас микән?»

Вәдүт тә шундый ук нечкә күңелле иде. Шагыйрь күңеле, солдат күңеле — аларның уртак өлешләре шактый күп. Вәдүтнең дә өзелеп сөйгән һәм бик тә сагындыра торган кадерле кешесе бар иде...

Без Вәдүт белән кырык икенче елның яз башында Сороколетово авылында очрашып, өч-дүрт көн бергә булдык. Шул көннәрнең һәрберендә аның куанып сөйләгәне шул сөеклесе булды, бергә уздырган бәхетле көннәре хакында булды. Шундый яратуга лаеклы әйбәт иптәше булуга чиксез сөенә иде Вәдүт. Тик мин китәр алдыннан гына үзенең күңелен тырнап торган әчке бер зур хафасын аңлатты ул: сөеклесеннән хатлар бик сирәк, бик сагындырып кына килә икән — ничәмә айга бары ике хат! Анда да бик кыска һәм ярату сүзләре шактый саран языла икән... Ә солдат кешегә җылы сүзләр, юк, җылы гына түгел — яндырырлык кайнар сүзләр, «яратам, бәгърем!» дигән ялкынлы сүзләр кочак-кочак кирәк бит! Шунда гына ул тулы бәхетле.

Аның бу хафасыннан солдат һәм шагыйрь күңелен шик корты борчый башлавын аңладым мин. «Әллә боларның мәхәббәте тигез түгелме?..» дигән сорау һәм... үз хәлләрем... юл буе уйланырга мәҗбүр итте. Ә инде аның белән күрешәм дип икенче килүемдә яшь дустымның фаҗигале үлем хәбәрен ишеткәч, берьюлы ургылган бик күп хисләр белән бергә, кинәт мондый сораулар килеп туды: «Ә ничек, сөеклесеннән хатлар ешрак килә башлаган иде микән? Ул көткән ярату сүзләрен язды микән, солдат күңелендәге авыр төен чишелгән иде микән? Бәхетле хисләр эчендә үлде микән егерме алты яшьлек шагыйрь?..» Бу сорауларга ул чакта, әлбәттә, җавап табу мөмкин түгел иде. Вәдүткә багышланган кечкенә бер шигыремне Казанга җибәрдем. Ул журналдамы, китаптамы басылып чыккан. Вәдүт җәмәгатенең шул шигырьдән соң иске адрес белән язган хаты кырык икенче елның декабрь ахырында гына мине яңа урыннан — Калинин фронтыннан эзләп тапты. Ул хат бик борчулы, бик күп сораулы иде. Күрәсең, шигырь матбугатта күренгәнче, Вәдүтнең язмышы турында ул ханым һични белмәгән булса кирәк. Хәер, үлем хәбәре, бәлки, килгәндер дә, ләкин анда киң аңлатма бирелми ич... Ә таныш булмаган яшь ханымның бу хәсрәтле хатын мин үземчә юрадым: «Димәк, ул да Вәдүтне яраткан икән! Тик шуны анык белеп үлгән булса гына ярар иде! Ул чагында әлеге шик кортлары йөрәген кимермәгән булыр иде...»

Җиңү килде. Илгә кайттык... Инде 1948 елның яз башы иде. Безнең өйгә яшь бер ханым килеп керде. Урта буйлы, тулырак гәүдәле, мөлаем йөзле иде ул. Бу ханым миңа күптән үк таныш кешем шикелле тоелды. Уйлана торгач, төсмерләп алдым һәм:

— Сез Вәдүтнең җәмәгате буласызмы? — дип эндәштем.

Ул моңсу гына елмаеп куйды да:

— Каян беләсез, Шәйхи абый? — дип сорады.

— Вәдүт миңа сезнең рәсемегезне күрсәткән иде... Ул аны, юка кәгазьгә бик пөхтәләп кенә төреп, сул күкрәк кесәсендә, комсомол билеты эчендә йөртә иде,— дидем.

Ханым тагын да моңаярак төште. Күз төбендә елтыраган энҗе бөртеген яшермәкче булып, башын түбән иде... Байтак сүзсез утырганнан соң, кулындагы кәгазь төргәкне миңа сузды.

— Бу — Вәдүтнең кульязмалары һәм хатлары...— диде.

«Хатлары» дигән сүз миңа бер хәтле аңлашылып җитмәде:

— Фронттан язган хатларымы? Аларын да китердегезмени? — дип сорадым. Ханым озак кына эндәшми торды. Аннары, башын күтәрмичә генә, әкрен тавыш белән әйтеп куйды:

— Оныта алмыйм, Шәйхи абый... Менә алты ел инде шул хатларны укыйм да җылыйм, укыйм да җылыйм...

Без ул чакта тагын ниләр сөйләшкәнбездер, хәзер хәтердә ачык сакланмаган инде. Тик ул ханым киткәннән соң күпмедер вакыт узгач, икенче бер журналист иптәшем белән очрашу хәтердә калган.

— Кара әле, Мансур, син бит Мамадышта эшли идең шикелле, ә соңгы вакытларда Чаллыдан яза башладың, анда күчтеңмени?..— дип сорадым.

— Туры килде шул...— диде ул, авырсынып кына. Һәм сораштыра торгач, сөйләп бирде: тугыз классны бетергән бердәнбер малае май бәйрәме көнне, кояш дип, җылы дип, бер иптәше белән әле тонып та җитмәгән боздай сулы Вяткада су коенган. Кичкә үк каты авырып егылган, сәбәбен өйдәгеләргә әйтмәгән һәм үпкәсенә бик каты суык тиюдән дүрт-биш көн эчендә дөнья куйган. Гаҗиз булган ата-ана, бу коточкыч авыр кайгыдан качмакчы булып, урын алыштырырга мәҗбүр булганнар... Бу фаҗига миңа Вәдүт җәмәгатенең хәлен дә бер хәтле аңлатып бирде шикелле. Ул да шулай уйлагандыр инде: «Бу хатлар минем күз алдымда булмаса, аларны көн саен укып җыламасам, бәлки, җиңелрәк булыр... бәлки, мәңге кайтмаска киткән Вәдүт дә әкренләп онытылыр иде...» дигәндер...

И кадерле дусларым! Ә кайгыдан качып буламы соң? Ә сагынулар суынамы соң? Ә яраткан кешең онытыламы соң?

Мансурны аннан соң да күпме очраттым, ул һаман күз нурыдай шул улын искә ала иде. Яшь ханымны күптән очратканым юк, ләкин сизеп торам: әгәр ул исән булса, аның изге хисләре һаман да шулай саф көенчә сакланалардыр, якты сагынулары сүрелмидер, кайнар итеп сөя белгән яшь шагыйрь Вәдүт образы һаман шулай күз алдында басып торадыр!

...Вәдүтнең кульязма шигырьләрен актарырга тотындым, алар күп түгел. 39—40 елларда язылган шактый өйрәнчек язмалар, ләкин шулар арасында матур гына строфалар да очрый.

Вәдүт Мифтахов тормышка ятимлек сукмагыннан атлап килгән. Ул өч яшьтә чакта, әтисе үлгәч, әнисе аны Сарайлы авылындагы бабасына илтеп ташлап, үзе кияүгә киткән. Ул кешене «Кара мәзин» дип йөрткәннәр. Ятим малайның үзәгенә үткән ул һәм шигыренә дә рәхимшәфкатьсез җан булып кергән.

Киндер күлмәк киеп,
Урамыңны
Айкап йөргән ятим малайны
Хәтерлимсең?
Әллә бетенләйгә
Оныттыңмы, авылым, Сарайлы.
«Тәрбиячем» — «Кара мәзин» иде,
Сыек чыбык торды матчада.
Канлы эзләр, сызым-сызым булып,
Көн дә төшә иде аркама...
Ул гына да түгел,
Ашатмыйча,
Өй базына тотып ыргыта.
Авыр эштән, куйналудан арып,
Үз-үземне шунда онытам...
Кыен иде миңа:
Хыялга бай,
Бәхеткә бик ярлы идем мин.
Шуңа күрә ялгыз моңаюны
Бар нәрсәдән артык сөйдем мин.
Миңзәләнең[1] ярын каплап алган
Куе таллык иде бәллүем.
Таллар белән кайгы уртаклашып,
Баса идем йөрәк әрнүен.

---

[1] Миңзәлә суы.

Күңел тулгач,
Ятып үкси идем,
Тал төбенә — яшел чирәмгә.
Юатырга теләгәндәй мине,
Кошлар сайрый иде тирәмдә...—

дип яза шагыйрь ул көннәре турында.

Вәдүтнең хатлары да шигъри ялкын тулы, ялкынлы сөю тулы. Тормыш дусты аның 15 хатын һәм полк комсомол бюросыннан алган икс хатны бергә теркәп, бер почмагыннан бик нык итеп тегеп куйган. «Тар калмасын, югалмасын!» дигәч уй күренеп тора. Күбесе карандаш белән язылган ул хатлар шактый таушалганнар, күп урында хәрефләр, сүзләр танымаслык хәлгә килгән. Күрәсең, алты ел эчендә әз укылмаган дыр, ихтимал, ачы тамчылар да сүзләр өстенә томан җәйми калмагандыр...

Солдат тормышының беренче атналарыннан ук сагына башлый Вәдүт. Ул аны көн аралаш диярлек язылган хатларында сөеклесенә яудыра тора. Тегелү тәртибе буенча җиденче хатын менә мондый матур шигырь белән яза:

Әй, кайда син минем куанычым,
Шат йолдызы бәхет күгемнең?
Балкыдың да көлеп баш очымда,
Гомерлеккә сүндең түгелме?..
Кабатларга һич тә теләгем юк
Җәйге моңсу сагыш җырымны.
Чөнки, бәгърем, бергә атлый идем
Синең белән тормыш юлымны.
Чын сөюле көннәр кичердек без,
Чын бәхетле көннәр кичердек.
Бер ай ярым вакыт — кыска гомер,
Ә син күпме шатлык китердең!
Йөрәгемә минем, тормышыма,
Хыялыма канат бирдең син.
«Гомер буе шулай шатлык белән
Көннәр үтәр безнең», дидең син.
Бүгенгедәй күз алдымда менә:
Син, утырып өстәл буена,
Дәрес хәзерлисең,
Күзләреңне текәп китабыңа,
Белем җыйнап якты уеңа...
Ә мин ятам кырын — караватта
Һәм сокланып сиңе күзәтәм:
Күз алмыйча сиңа карыйм һаман
Һәм йөрәккә татлы сүз әйтәм:
«Әминәм!»
Их, нинди җылы исем!
Нинди якын, нинди кадерле!
...Ә соң, хәзер...
Кая син югалдың?..
Юк син... Юк син...
Ялгыз хәзер мин...

Ә яшь шагыйрьнең саф сөю тулы мондый хатларына җавап сүзләре тиз генә килеп җитмәгән икән шул. Инде алгы сызыкка килеп, сугышка керер алдыннан язган бер хатында Вәдүтнең сагыну хисләренә үпкә тойгылары да катыша башлый: «Кадерлем! Сиңа хат җибәрүемә нәкъ бер ай тулды, моның гаҗәпләнмәслек сәбәбе бар,— дип яза ул.— Мин сиңа юлдан һәм Кинель-Черкасстан бик күп озын-озын хатлар җибәреп, шуларга каршы бер җавап та алмадым. Әрнедем һәм йөрәгем жылады... Минем бит синең йөрәк тибешеңне ишетәсем килә, синең уй-кичерешләреңне беләсем килә... Без хәзер алгы кырыйга якынлаштык. Тизрәк сугышка кереп, фашистларны кыйный башлыйсы иде... Белеп булмый, әгәр бу соңгы хатым булса, мине начар итеп искә алмассың дип уйлыйм. Бик аз, бик аз яшәп калдым мин синең белән. Шундый матур сөюне, тулы канлы мәхәббәт белән аккан ай ярым вакытым бөтен кур-

гән авыр кичерешләремне юып, шатлыкка күмгән иде. Тик ул тормышның гомере кыска булды. Син тагын ялгыз, мин тагын аерым... Хуш, иркәм. Кил, сине күңелем белән алдыма утыртып кочыйм да туйганчы бер үбим!.. Сагынычлы сәлам! Хәзергә дөрес адрес юк әле. Булу белән хәбәр итәрмен. Ә бу соңгы хатым булса... Ватаным өчен һәм синең белән узган бәхетле көннәрем, мәхәббәтем өчен үләчәкмен. Шуны белеп ул — үзе бер дан!»

Бик югары ноталар. Бик тә үзәктән өзелеп чыккан сүзләр. Һәм барысы да барыбызга да бик таныш һәм бик уртак булган кичерешләр. Барыбыз да шулай өзелеп сагындык, барыбыз да хатларның еш килмәвенә, тиз йөрмәвенә шулай әрнедек. Муса да, әле Мәскәү резервында яткан чагында ук, Казаннан хат ала алмавына шулай борчылып яза (том III). Бу хисләр минем үземә дә таныш. «Хат көтәм» дигән шигырь дә үзәк өзмичә генә тумагандыр...

Ә хатлар, безнең шул түземсез хисләргә үч иткәндәй, тиз йөрмиләр иде шул. Фронт почтасының юллары әйләнеч һәм бүленешле иде, хәтта көн саен язылган хатларның да кайчакта әллә ничәсеннән бере генә барып ирешә. Фронт юлы өсләрендә элемтә транспортының тар-мар булып ятканын, почтарьның үле гәүдәсен, җиргә чәчелгән өчпочмаклы хатларның янып-көюдән калган мескен пачкалары җил белән кырга тәгәрәвен күп мәртәбәләр үз күзләрем белән күргәнем бар минем...

Чын солдат үлем турында бер уйлый һәм, шул ныклап бер уйлаган да, бу мәсьәләне үзе өчен хәл итеп куя. Вәдүт тә шулай. Алда китерелгән кайнар пафослы сүзләре белән бер карарга килгәч, ул һаман үзенең яшәү һәм сөю поэмасын дәвам итә. «Кадерлем! Сиңа мең мәртәбә сагыну сәламе. Сиңа, әйе, сиңа, сөеклем! Синең куе кара керфек арасыннан елмаеп карый торган зәңгәрсу күзләреңә! Алсу алма төсле битеңнең мәхәббәт нурларына сагыну сәламе, иркәм! Их, бер генә минут эчендә бер генә мәртәбә сиңа күзләремне тутырып карар идем. Тик бер генә минутка! Бер генә сүзеңне ишетер идем, кадерлем! Оныттың, ахры, бер генә хатыңны да күрә алмыйм, бер генә сүзеңне дә укый алмыйм! Кадерлем, нигә мине болай борчыйсың? Син уйлап кара, фронттагы солдат өчен яраткан кешесеннән бер җылы сүз ишетү дә көрәшкә омтылыш бирә, җиңү дәрте һәм яшәү өмете тудыра. Мин, сугышчан бурычымны үтәргә керешкәндә, сине күңелемдә саклап ут эченә керәм. Мәхәббәтем, өзелгән бәхетем өчен дошманга үч белән янып, җиңү дәрте белән канатланып керәм...»

Аннары шигырьгә күчеп киткән шагыйрь:

Яфракларның сары төсләрендә
Сагынуымны күрәм үземнең.
Ялгыз калган һәрбер минутымда
Рәсемеңнән алмыйм күземне:
Сагынсам да хәзер,
Саргайсам да
Ара ерак инде, алтыным.
Тик йөрәктә көн дә арта бара
Сиңа булган сөю ялкыным...

Шулай җыр тулы, сөю тулы, сагыну тулы бай күңел белән яшәгәндә, әле яңа гына ачыла килгән чәчәктәй яшь шагыйрьне фаҗигале үлем кинәт җиргә ега. Аның солдатча батыр үлеме турында бер язган идем. («Совет әдәбияты». 1948. № 6.) Саф йөрәкле шагыйрьнең олы мәхәббәте кинәт өзелә, күңел түрендәге олы җырлар туарга өлгерә алмый кала...

Бу көтелмәгән авыр югалтуны мин генә түгел, полк комсомоллары да (ул аларның җитәкчесе иде) бик авыр кичерделәр. Полк комиссары Фомин иптәш тә аны бик яратканын сөйләп бетерә алмый иде...

Икенче баруымда Вәдүтнең үзен түгел, Рыдань авылындагы каберен генә күргәч: «И дускаем, соң син өзелеп көткән хатлар килдеме?

Солдат һәм шагыйрьнең артык нечкәргән күңелендәге әрнүле төен чишелгән идеме?..» дип сорадым... (Көлмәгез, арттырмыйм, фронт жирендә кешеләр шундый сәерләккә әйләнәләр икән.) Кабер, әлбәттә, эндәшмәде... Фәкать алты елдан соң гына (җәмәгате китергән хатлардан гына) ул сорауларга җавап таптым мин. Өенә җибәргән иң соңгы хатында Вәдүт болай дип яза: «Кадерлем минем, йөрәк бәгърем? Бүген комиссар рөхсәте белән передовойдан тылга бер тәүлеккә кунакка кайткан идем. Икенче эшелон миңа хат алып кайткан, берьюлы ике хат! Син уйлап кара! Берьюлы ике хат! Ә мин кичә генә әле сиңа үпкәләп һәм ачуланып хат җибәргән идем... Барып кына җитмәсә ярар иде!.. Нишлим соң, ял итмәгән көннәр, йокламаган төннәр күп, нервылар киеренке, күңел кыллары артык нечкәргән... Комсомол эше буенча дивизия күләмендә беренче урынны алдык. Тиздән партия кандидатыннан членлыкка күчәчәкмен. Менә тормыш шулай ага, акыллым минем, иң кадерле кешем! Хатларыңдагы җәүһәр бөртекләредәй кадерле сүзләреңне ятлап, өмет белән юанып яшим: «Вәдүтем, җаным, синең хатының булган хәлемдә, минут саен исемнән чыгармыйча, сине көтеп торачакмын. Берәр җирең ранен булса да, йөри алмаслык дәрәҗәдә булсаң да, сине ташламам...» Менә шушы сүзләрең, әгәр син аларны йөрәгең каны белән саф күңелдән язган булсаң, мине канатландыралар, куандыралар, киләчәк тормышыма өмет яктысы булып балкыйлар...»

Бу юлларны укыгач, мин дә җиңел сулап куйдым. Шагыйрь-солдатның нечкә күңелен күпме вакытлар сызлатып килгән әрнүле төен калмаган икән — Вәдүт үзе сөеп кенә түгел, сөелә дә икәнен белеп үлгән... Ә сөю һәм сөелүдән дә бөек нинди куаныч бар, нинди бәхет бар?..

## Бай хыяллы иде ул

42 нең октябрь ахырларында мине Политик идарәгә чакыртып, Калинин фронтында чыгарыласы татар газетасына җибәрделәр. Татарча газета!.. Теге вакытта шуны сорап Әхмәт Фәйзи белән язып йөргәнебез келт итеп искә төште. «Әллә шуның берәр файдасы тиде микән?» дип уйлау табигый иде. Алай ук булмагандыр, әлбәттә. Милли газеталар чыгару турында югарыда бездән башка да һәм бездән алда да уйлаучылар булгандыр. Әмма ничек кенә булмасын, мин бу хәлгә сабыйларча куанып куйдым. Менә хәзер батырлык, кыюлыкның «кайнар эзләре» буенча язылган шигырь, хикәя, хәбәр, очеркларны солдатка ана телендә шул ук «кайнар» хәлендә җиткерергә мөмкин! Бергәләп куанырга Әхмәт Фәйзи генә булмады — ул әле теге вакытта «кайтып торырга» кушылганнан соң Казанда яши икән. Мусаның да июнь башыннан бирле хат-хәбәре булмавын ишеттем. Мәскәүдән бүтән иптәшләрдән берәүне дә күрә алмыйча, яңа урынга китеп бардым.

Фронт газетасын Калинин шәһәреннән байтак эчкәредәге бер зур гына авылдан эзләп таптым. «Вперед на врага» исемендә чыга икән ул. Бу сүзләрне татарча шома гына яңгыраулы итеп алу мәсьәләсе шактый кыен эш булып чыкты. Безнеңчә: «Дошманга каршы, алга!» яки «Алга, дошманга каршы һөҗүмгә!» дигән сыманрак кирәк шикелле. Ләкин барыбер тиешенчә матур яңгырамый, кытыршылык сизелә, артык сүз дә кереп китә. Ә солдат газетасының исеме кыска, шома һәм сугышчан яңгыраса әйбәт булачак. «Алга, дошман өстенә!» дисәк тә, калька килеп чыга һәм татарча яңгырамый кебек. Әмма төп текст мәгънәсен хәреф-бихәреф бирү кирәклеге белән эш иткәндә һәм бу ике җөмләне сугышчан команда сүзләре итеп аңлаганда, бу вариант кытыршылыгы белән колакны бик ул хәтле тырнамый шикелле. Шулай итеп, фронтта туган яшь балага «Алга, дошман өстенә!» дигән исем кушылды. Типографиягә җибәрелгән әз-мәз татарча хәрефләрдән баш-

ка һични булмаганлыктан, беренче саннарны чыгару шактый авырга килде. Ноябрьнең икенче яртыларында Казанга кайтып, хәреф җыючылар, шрифтлар, язу машинасы, китаплар һәм башка кирәк-яраклар алып килмичә булмады.

Казандагы бер генә эпизодка тукталасы килә. Фронтовик язучы кайткан бит, борынгыдан килгән йола буенча, кунак кешене сыйларга кирәк лабаса... Иптәшләр, үзара салышыпмы, әллә литфонд «кесәсен»нәнме, табын оештырганнар. Матбугат йортының бишенче каттагы боздай суык бер бүлмәсендә утырабыз. Өйдә булган язучылар барысы да диярлек килгән. Өс киемнәрен салырлык та түгел, болай да куллар күшегә, колак туңа...

Алдагы тәлинкәләрдә куш бармак иңлегендә юка-юка гына икешәр кисәк (аны телем дип әйтү мөмкин түгел) арыш ипие. Ул ипи ясмык кумачедәй кызгылт-кара, йомшагы ләчтә кайрак икәне авызга капканчы ук сизелеп тора. Шул кисәкләр өстенә юка гына ярка май куелган. Стаканнарда ак ябалак сөте һәм... вәссәлам! Ичмаса, закускага тозлы кәбестә дә юк иде бугай. Күреп торам, шул ике «мескен кисәк» — һәр борын башына тигән бик зур өлеш! Һәр борын аның чамасын белеп кенә кабарга тиеш. Әгәр дә мәгәр кем дә кем, үз өлешен «ике кабып-бер йотып», янадан ярты гына сынык икмәк сораса да, хуҗа (литфондның ул чактагы башлыгы мәрхүм Мөхәммәт Гали абзый иде бугай) аңа ипинең валчыгын да табып бирә алмаячак: һәм ул «кем» шундый «песмелсез»леге белән кунак алдында йөз кызарткaны өчен бөтен мәҗлес тарафыннан тиргәләчәк!..

Утырабыз. Алдыбызда кырлы стаканнар тулы... Һәркем үз хәлен үзе белә... каршымда гына мәрхүм Шәриф абзый. Ул мине кыстый да кыстый.

— Әйдәле, Шәйхи энекәш, күтәреп карыйк әле,— дигән була. Мин дә аны кыстыйм — чын күңелемнән сыйлыйсым килә. Әйтерсең, без сугышка киткәндә ясалган «каз итле», «тавык ботлы», «дөге бәлешле» чын банкет бу! Аннары сораулар китә. Күргән-белгәннәремнең барын да сөйләргә тырышам. Кайберәүләрнең бик тә инде фронтка китәсе килә. Күршемдә генә Риза Ишморат күзләрен елтыратып утыра. Ул хәрби киемнән, хәтта сержант булып киткән! Ай-һай, «зур» исем биргәннәр безнең танылган драматургка! Аның бигрәк тә китәсе килә. Аптырагач, монда оеша торган танк частена ул инде үзе барып керган... (Соңга табарак Риза агай үз максатына ирешкән, әлбәттә. Фронттагы татар газеталарының берендә редактор булып, Берлинны алып, майор булып кайтты ул! Алып дигән сүзне мин куштырнаксыз әйтәм, чөнки ул Берлин сугышларында корал тотып катнашкан һәм яра алган батыр ир бит!..)

Бу мәҗлестән мин мондагы иптәшләремнең нинди кыен һәм авыр тормыш алып баруларын ачык аңлап, бик моңаеп кайттым. Фронттагы хәлләр миңа бик билгеле, әмма мондагылар тормышы да «майлы ботка» түгел икән... Ихтимал, шуңа күрәдер, ул «банкет» бүген дә онытылмаган. Иптәшләремнең шундый кыен көннәрдә дә кунакчыл була белүләре өчен бүген дә рәхмәт укыйсым килә.

Кешеләр һәм кирәк-яраклар алып килгәч, редакция эшләре рәткә салынды, чыгарылган газеталар солдат кулына барып җитеп, аннан җавап хатлары, хәбәрләр, шигырь һәм башка материаллар килә башлады. Озакламый язучы Абдулла Әхмәттән дә хатлар килеп төште. Ул да Калинин фронтында икән. Кара син аны, әлеге «14» баланы ничек калдырып киткән ул! «Сәмәлүт»ләрнең баш очында гына очуларын бик куркыныч итеп яза, шулай да көлдерергә тырыша. Соңыннан ул редакциягә китерелде һәм безгә аның белән «Телеграмм баганасы олы юлга маяк ул»ны байтак вакыт бергә җырлап йөрергә туры килде...

Яшь шагыйрь Гаяз Мансурдан да шигырьләр килә башлады. Кыр почтасы, 11101-«Е». Фронт буйлап командировкада, татар солдатлары күбрәк булган частьларны эзләп йөргәндә, шул почтага юлыктым. 306 нчы дивизия иде бу. Мансурның шушындагы бер полкта хезмәт итүен әйттеләр. Тик аның янына көндез кереп булмый икән, немец снайперы күренгән бер кешене чүкеп кенә тора, ди... Төнлә киттек. Алгы кырыйның беренче сызык траншеясына үрмәләп килеп төштек. Кеше күмелерлек тирән итеп казылган тар гына борма юл буйлап барабыз. Бу инде кырык икенче ел башындагы кыш түгел, солдат хәзер кар өстендә ятмый икән. Ул инде бөтен буена жиргә «күмелгән», аны тиз генә урыныннан кубару яки ансат кына атып егу мөмкин түгел хәзер.

Брустверның махсус көйләнгән урынында — кул пулеметы. Ике ягына ике солдат баскан.

— Гаязов! К тебе пришли,— диде мине алып килгән сержант. Солдатларның озын буйлысы безгә таба борылды.

— Исәнме, Мансур! — мех бияләйне салып, кул суздым. Мин моны, танып-белеп түгел, чамача гына эшләдем. Казанда кайчандыр бер күргәнем булса да, артык танышлыгыбыз юк иде. Ул да, караңгыда мине таный алмыйча, шактый аптырап калды. Тик мин исемне әйткәннән соң гына җавап кайтарды. Һәм без, бик күптән күрешмәгән һәм бик сагынышкан якын дуслардай, кочаклашып калдык. Кырык өченче елның март башлары иде бу. Кышкы айсыз төн. Кар шәүләсе әз-мәз яктыртса да, шактый караңгы. Бруствергa таяндык та сөйләшеп киттек. Көнбатыштан җил исә. Аның сулышында аз гына җепшек-йомшак яз исе бар шикелле, шулай да кышкы җил әле ул, кырыс — битләргә әчесе тия...

Мансурны җентекләбрәк күздән кичерергә тырышам: озын буйлы, юка гәүдәле, моңсу чырайлы булып күренә ул. Төс-битен ачык аерып булмый, әлбәттә. Ләкин тавышының да ничектер йомшак, кече күңелле һәм юаш булып яңгыравы йөз чалымнарына барып кушыла шикелле.

Сугыш җирендә гади солдатның да, шагыйрь солдатның да иң кадерле уйлары һәм теләкләре бер төсле була икән: яшисе килә, ничек тә яшисе килә. Туган-үскән җирләргә исән кайтып, җинеп кайтып, гомерне яңадан дәвам иттерәсе килә.

Без дә шул хакта сөйләштек. Траншеяда чүгәләп тәмәке тарткан-да, язарга вакыт булмавыннан зарландык, сугыштан соң күтәрәсе зур темаларыбыз белән хыялландык. Ул әле өйләнмәгән егет, аның күңелендә Халидә дигән кадерле бер исем дә бар иде. Үзе генә белгән татлы һәм яшерен серләр пәрдәсен әз генә, аңа хас тыйнаклык белән генә ачып куйды ул...

Сәер булып чыкты безнең бу төнге диалог. Әйтерсең җиде төн уртасында бакча якта качып-посып кына күрешкән егет белән кыз! Иртәгесен яктыда кабат күрешеп сөйләшә алмыйча китеп барырга туры килде миңа... Соңыннан без хатлар аша сөйләшкәнбез. Аның миндә бары ике генә хаты сакланган. 1943 елның 25 маенда язган озын хатында мондый юллар бар: «...Сездән өч хат алдым. Тирән рәхмәт. Хат белән килгән кечкенә җыентыгыгыз миңа фронт истәлеге булыр инде... Шигырьләремнең газетада чыгуы бик зур куаныч. Аларны укыгач, минем йөрәгемә сыя алмыйча кайнаган ачу, көчле нәфрәт — дошман башында ярыла кебек тә, мин аны карап торып җаныма ләззәт, рәхәтлек табам кебек тоела, күңелем тынычлана.

Сезнең җыентыгыгызга тәнкыйть ясап тора алмыйм, аның өчен вакыт тар. Тик китапка булган карашымны кыскача әйтми уза алмыйм шунда да. Иң мөһиме, шигырьләрегездә туган илнең туфрагына баскан дошманга ачы нәфрәт, көчле ачу, бер хаксызга түгелгән

кан һәм күз яшен күреп йөрәгегез әрнүе, Бөек Ватан сугышында гомерләрен дә аямыйча көрәшүче батырларның чагылуы. Менә җыентык шул ягы белән кыйммәт, йөрәккә якын. Кайбер юлларның шигырь булып янгырап житә алмавы шикелле кимчелекләр дә бар...

Сөекле дустым Вәдүт Мифтаховның геройларча үлеме чагылдырылган шигыренезне укыгач, сүз әйтә алмас дәрәҗәдә калдым. Авыр, бик авыр булды минем өчен. Мин Вәдүт белән күп еллардан бирле хат алыша идем. Ачы-татлы яшьләрем комсомолецның батыр тәне яткан изге кабер өстенә тамсын. Хуш, хуш, сөекле дус, без синең гомеренне һәм миллионнар гомерен даулап, кулларга коралны нык кысып, алга, фашист юлбасарлар өстенә ташланабыз. Хуш, яшь шагыйрь, хуш, якын дустым!..

...Сезгә хат яза башлагач, почта белән очраклы рәвештә татарча газета кулга эләкте. Анда тагын минем Суворов турындагы шигырем бар. Укыдым. Газетада минем хакта искә алуыгыз куандырды. Тик инде минем талантыма карата әйткән сүзләрегезне, сезнең ышанычны акларга мин күп бурычлы. Ышаныгыз... Мин үз хезмәтемне чиксез дәрәҗәдә сөям. Иҗат эше миңа — көч тә, дәрт тә, бер рәхәтлек тә бирә. Мин иҗат эшем белән дә бөек сугышта да үземә булган ышанычны акларга тиеш. Моның өчен мин ил каршында җаваплы. Сез күрсәткән темаларга язу өчен бик тырышсам да, үземнең хезмәттән вакытсыз аерыла алмавым комачаулый. Сезгә бер мәкалә җибәргән идем, алсагыз кирәк, тагын шушы көннәрдә язармын. Бакиров, Рәхимовны күреп сөйләштем, аларның эше онытылып торган, хәзер яңадан документлаштырылды. Шушы көннәрдә орденнар бирелер, аннары мин алар турында язармын. Оештырасы материаллар күп булса да, вакыт булмавы уңайсыз. Ничек тә шушы арада тагын миннән материал көтегез — язармын.

...Үзем сау-сәламәт, шул бер частьта. Мин бу полкка февральдә генә килгән идем. Рядовой. Килгәч тә разведкада йөрдем. Һәр төнне, караңгы-салкыннарга, күз ачкысыз бураннарга карамый, дошман ныгытмаларын үтәргә, аның дзот һәм траншеялары буенча капшанырга туры килә иде. Бераздан соң үз теләгем белән батальонга күчерелдем, инде өч ай штабны саклау хезмәтендә мин. Соңгы көннәрдә дә берничә һөҗүмгә бардык, һаман да әле мин исән. Эх, яшәргә, яшәргә, яшәргә иде әле! Бу бөек сугыштан соңгы матур тормышны күрәсем, үземнең сөйгән иҗади хезмәтемнең чәчәк атуын күрәсем килә...

Узган ел Ржев сугышында ранен булдым, аннан — өч ай госпитальдә, тагын фронтта; декабрь-январь аенда тагын госпитальдә. Шуннан соң шушы бер частьта... Мин 36 нчы елдан бирле комсомолец, хәзер партия членлыгына кандидат. Үзем турында шул. Бу хатым белән тагын шигырьләр җибәрәм, басыгыз. Сездән хатлар көтәм, сәлам белән М. Гаязов».

Мансурның миңа 20 нче июльдә тапшырылган икенче хаты ярты битлек кәгазьгә гади карандаш белән генә язылып, «өчпочмак» итеп салынган. Ашыгыч арада гына сызгаланган булуы күренеп тора. Ул анда редакция җибәргән кәгазьне алуын, тагын да шигырь һәм башка материаллар җибәрәчәген хәбәр итә. Аннары «күптән инде «Фронттан Татарстан иленә хат» дигән зуррак нәрсә язып ятам. I, II һ. б. бүлекләр рәвешендә дәвам итәргә уйлыйм, әгәр исән булсам. Тик, вакыт житмәгәнлектән, бетереп кенә булмый...» дип яза...

Шуннан соң безнең арадагы элемтә өзелеп калганмы, әллә ул җибәргән башка хатлар миндә сакланмаганмы, хәзер инде ачык кына әйтүе бик кыен. Тик соңыннан, кырык дүртенче ел башларында гына, аның турындагы кайгылы хәбәрне ишеттем: инде дүрт тапкыр яраланып, дүрт тапкыр госпитальләрдә «ямалып» чыккан яшь шагыйрь

Витебск тирәсендәге каты сугышларда кырык өчнең ноябрь аенда батырларча һәлак булган...

Ә нинди бай хыяллар белән, шигъриятькә гашыйк булган иҗат ялкыны белән һәм тормышны чиксез яратып, аңа теш-тырнагы белән ябышып яши иде ул! Аның саф һәм нечкә күңел белән: «Эх, яшәргә, яшәргә, яшәргә иде әле!» дип кычкырган авазы Витебск урманнары төбендә әле дә яңгырыйдыр кебек тоела.

## Җилләр канатында

1944 ел. 23 июнь. Солдат язмышы аны төрле якларга ташлый. Мин дә, Калинин фронтындагы татар газетасыннан «җибәрелгәч», III нче Белоруссия фронтындагы бер дивизия газетасына барып төшкән идем инде...

Тулы сугышчан хәзерлек белән икенче эшелонда торган безнең дивизия ул көнне иртәнге дүрттән үк аякка басты. Зур юлга әзерләнүнең актык мәшәкатьләре төгәлләнеп килгәндә, «туплар туе» башланды. Юк, дивизия күләмендә генә түгел, армия, фронт, хәтта берничә фронт күләмендә иде бу. Артиллерия, миномет һәм «Катюша»ларның бөтен калибры берьюлы эшли. Җир өсте ниндидер чиксез олы ындыр табагы һәм шунда миллионлаган пәһлеван көчле кешеләр миллионнарча чуен чабагач белән ындыр сугалар төсле. Бөтен тирә-як бик киң торф мәйданы сыман салмак кына тибрәнә, җир уфылдап куя һәм без дә сизелер-сизелмәс кенә чайкалабыз төсле. Минем әле «сугыш алласы»ның бу кадәр көчләре берьюлы эшләвен беренче күрүем. Дәһшәтле дыңгылдап ярылган миллион снарядлардан җир ыңгырашуын беренче тапкыр шаккатып тыңлап торам, тән чымырдый... Озакламый биек күктән төркем-төркем авыр «бомбачылар» агыла башлады. Алар артыннан, кинәт әллә каян гына килеп чыккандай, киң канатлы штурмовик «ИЛ»лар баш очыннан гына ачы сызгырып, куркыныч гөрелдәп узып киттеләр. Алар койган йөкләрдән җир тагын да авыррак ыңгыраша башлады кебек. Бу ут ташкыны кимендә ике сәгать баргандыр, ә аннан бер мәлгә кинәт һични ишетелмәс булды. Әйтерсең дөньяны калын мамык белән төрделәр. Колаклар тонганын шунда гына белдек. Тик ул мамык тынлыкны бик тиз өзгәләп ташладылар. Аяк астыннан гына чыккан сыман, якын-тирәләрдән кузгалып, киң табаннары белән җирне үтүкли-үтүкли, танклар алга китте. Ирексездән 1941—1942 ел сугышлары искә төште. Күктә ишле бер төркем самолет, җирдә ишле бер төркем танк күрергә интизар була идек. Бердәнбер горурлыгыбыз «Катюша» иде ул чакта. Аз иде, шулай да горур идек. Немецларның аны «кара әҗәл» дип атавы безнең солдатка көч бирә шикелле иде, елмаю көче, өстенлек сизү көче!..

Безнең дивизия — гвардия исеме Городок булган (шәһәр исеме) һәм Суворов ордены йөрткән дивизия. Аның зур сугышчан юлы бар. Ләкин ул бер дә олы магистральләрдә, олы объектлар өчен барган сугышларда катнашмаган, һаман шул авыл араларында, чокыр-чакырлы юлларда, сазлыклар эчендә йөрергә туры килгән аңа. Шуңа күрә аның «Болотная дивизия» дигән исеме дә бар. Монысын солдат үзе кушкан, яратып, үз язмышын кушып әйткән. Менә бүген алар тагын зур юлга, кыен юлга әзер булып, соңгы приказны көтәләр. Барысы да күккә караган. Үзебезнең төркем-төркем агылып торган лачын кошларны сабыйларча горур елмаеп озаталар. Иртә белән көн болытлырак иде, хәзер күк ачылып китте, кояш балкый. Ә бер генә дошман самолеты да күренми. Бу ни гаҗәп? Хәтта ышанасы килми. Әллә немецның самолеты беткәнме, әллә берәр хәйлә корганмы? Һәрхәлдә, сәер бу! Кая соң әле безнең «мескен» бер «чайка»га немецның ун

«фокки»е, котырган шөпшәләрдәй, төрле яктан ташланып, аны ничек тә жиргә сылаган чаклары?.. Күкләр безнең кулга күчеп бара! Солдат жиргә карый. Кара төтеннәр чыгарып, кара тузаннар күтәреп, жир селкетеп алга узган авыр танкларны сабыйларча горур елмаю белән озатып кала ул. Пилоткасын салып болгар иде, күккә чөяр иде, тик ярамый — сафта тора, әмер көтә...

Ниһаять, ракета. Дивизия «кайный» башлый. Взводлар, роталар, батальоннар танк колонналары артыннан кузгала. Безгә юл ачылган иде инде. Иртәнге туплар туе, авиация һәм танклар үтүкләве үз эшен жиренә житкереп эшләгән. Жимерек дзотлар, актарылган бетон бункерлар, өзгәләнгән траншеялар аркылы бик аз каршылык белән үтеп, дошман тылына ябырылдык. Бездән суллараК — Орша, шунда таба юнәләбез. Ләкин безгә ул кала өчен сугышырга туры килмәде, аны шулай сулда калдырып, алга уздык һәм өченче көннең иртәсендә киң асфальт юлга чыктык. Мәскәү — Минск магистрале икән бу. Безнең «Сазламык дивизиясе» баш магистраль буйлап көнбатышка жилдерә. Чынлап та жилдерә! Чөнки бөтен гаскәр машинада! Шушы ике көнлек һөжүмдә дошман ташлап качкан техниканың төзек булганы бөтенесе эшкә жигелгән. Утырып баручы юк, кузовтагы һәм бронетранспортерлардагы бөтен солдат аягүрә баскан, автоматын ут ачарга әзер тота. Хәтта машиналарның алгы канатларында да ике яктан икешәр автоматчы басып бара.

Безнең редакция дә «һөжүм итә». Ник итмәсен! Үзе бәләкәй генә булса да, «Ватан бәхете өчен!» дигән зур исеме бар аның. Аның хәреф тартмаларын, басу станогын, дүрт-биш кешелек «гаскәр»ен һәм калган бөтен хужалыгын төягән бердәнбер авыр машинасы полклар, батальоннар белән бер сафта алга, көнбатышка чаба! Мин дә шул машинаның алгы канатына басып барам. Жәйнең иң матур чагы: дөнья саф, яшел, эссе, коры. Алдан килеп бәрелгән жылы рәхәт жил ачык күкрәкләрне иркәли, кытыклый, юл читләрендә бакыр стенадай торган нарат куелыгыннан китергән әчкелт чәер исен үпкәләргә тутыра ул жил. Жиңеләйтеп, ярсытып жибәрә. Машинада түгел, жилләр канатында очасың төсле. Күңел сабыйларча уенчак, мәхәббәттән бәхетле егетләрнекечә күтәренке! Минем әле фронтта йөри башлаганнан бирле мондый хисләрне беренче кичерүем һәм мондый давыл узышын үз күзләрем белән беренче күрүем иде.

Немецларның алгы кырыйдан качкан солдат ташкыны һәм бөтен интендантлык эшелоны шушы юлдан ашыгыч рәвештә Минскига табан агылган булса кирәк. Алар бит урман эчләреннән куркалар иде. Бездән алда хәрәкәт иткән танк армиясе шуңа күрә аларны бик тиз куып житеп, таптап, тар-мар итеп узган. Юлның ике читендә яньчелеп һәм чәнчелеп яткан йөк машиналары, төрле маркадагы, төрле төстәге жиңел автомобильләр, трактор, бронетранспортер, автобуслар һәм бүтән техника әллә ничә чакрымнарга сузылып бара. Кайберләре аумаган да, түнмәгән дә — шул көйгә туктап калган. «Эх! — дип куя солдат.— Утыр да кит!» Педальгә басып, «клиндерен» боргалап карый, кузгалмый — бензине юк икән. Шуңа күрә хужасы жәяүләп сыздырган, күрәсең. Каскалары читкә тәгәрәп яткан немец үләксәләре чутсыз, каршыга ак чүпрәк күтәреп, төркем-төркем килүчеләрнең дә исәп-хисабына чыкмалы түгел. Баштарак алар якындагы тапшырылу пунктына берәр солдат белән озатыла иде, ә соңрак арадан берсен башлык итеп, үзләрен генә жибәрергә туры килә башлады...

Барабыз, жилләр канатында көнбатышка житәбез, көнбатышка! Ил чигенә, дошман жиренә таба! Дошман жиренә таба! Күңелләр көр, кәефләр шәп! Инде сугышның, ахырын да шәйлибез шикелле, тиздән өйгә кайту юллары да, иртәнге яңгырдан соң чыккан салават күпере төсле, якын булып, бик матур булып күренә...

Юк, солдат юлы тоташ агым түгел. Тоткарлыклар туып кына тора: әледән-әле кыска-кыска сугышлар булып ала. Урман эченнән шомлы бер пуля сызгыра — тиз генә юлның ике читен кимендә ике йөз метр тирәнлектә «тарап» узарга туры килә. Юл өстендәге авыл яна, аны сүндерешмичә китеп булмый. Ниһаять, кич була, солдат арый, ачыга. Еракта калган «АХЧ»ның кайнар термослары сөйгән ярдай сагындыра башлый...

Шундый чакларда безнең «дредноудт» та юл читендәге берәр җәенке ботаклы юан нарат төбенә килеп туктый. Җил-яңгырларда уңып беткән дерматин белән тышланган фанер кәймәле авыр машина ул. Егетләр тиз генә кассаларны сүтәләр дә хәреф җыярга тотыналар. Без әле бүген генә күздән кичкән вакыйгаларны язып, газета хәбәренә әйләндерәбез. Шофер, су табып, корымлы чиләк асып, аш пешерергә тотына. Ул пешергән аш өреле була һәм һәрвакыт диярлек бензин тәме килә, шулай да ашамаслык түгел. Аштан соң урманга кереп йөрим, сирәк үләнле, кипкән ылыслы җир өстенә ятам. Күңел мөлдерәгән — шигырь язасы килә («Җиңү балдагы» исемле шигырь шунда башланган иде). Тик ул шигырь, туса да, тиз генә дөнья күрә алмыйча, сумкада йөриячәк, русчага тәрҗемә итәр кеше юк. Ә Казан моннан бик еракта хәзер!..

Шундый «моцион»нарның берсендә коточкыч бер хәлгә тап булдым. Урман кырыенда, шоссега чыга торган авыл юлы өстендә өч хатын-кыз гәүдәсе ята. Яшьләре егерме-утыз арасында булыр. Өсләрендәге авылча киемнәре ярым өзгәләнеп, каерылып ташланган. Билдән түбән гәүдәләре ялангач, битләренә кан чәчрәгән... Йөрәк «жуу» итеп, ни дияргә белмичә, иптәшләр янына йөгердем. Барыбыз бергәләп килеп карадык. Әлбәттә, фашистлар эше иде бу... Йөрәкне пешергән ачу утыннан битләр кызып, кан тамырлары бүртеп чыкты, сүз табып авыз ачу кыен иде. Күммәкче булган идек, соңрак килеп җиткән политбүлек начальнигы күмдермәде. «Белик, кайсы авылдан, кемнәр икән, ни өчен бу кабахәтлек эшләнде икән?» — диде. Соңгысы болай да ачык иде, һәрхәлдә, кешелек сыйфаты булган зат моны эшләмәс... Ул төнне бер эшкә дә кул бармады. Күңелгә тулган әйбәт хисләр, якты уйлар түгелеп-чәчелеп бетте...

...Инде Березина ярларына килеп җиттек. Березина! Күпме яуларны йоткан елга бу! Наполеон яулары, Мәскәүдән качып барышлый, шушы елгага батып һәлак булган, көнбатыш ярга чыга алган вак-төяк төркемнәрнең гаскәр дип әйтерлек мәгънәсе калмаган. Егерменче елны ак поляклар да шушында башларын җуйганнар. Гитлер армиясенең үзәк группасы да шушында тәмам тар-мар ителде...

Понтон күпере өлгергәнче һәм төп гаскәр, техника күчеп беткәнче, безгә бу ярда ике көн торырга туры килде. Ике көн буена, нидидер күксел-көрән дельфиннардай туңкаеп, немецлар гәүдәсе акты... Һава сугышларын тамаша кылдык. Дошманның бик биектән 12 авыр самолеты килеп чыкты. Понтон өсте тулы гаскәрне бомбаларга иде нияте. Ләкин безнең яңа тип җиңел, җәһәт истребительләр, үз ояларын карчыгадан саклаучы яр карлыгачлары төсле, күп булып бердәм ябырылып, аларны кире борды. Ничәседер мәгәлде, калганнары йөкләрен әллә кая читкә ташлый-ташлый ычкынырга мәҗбүр булды...

Менә шул көннәрдә немец гаскәренең кичәге психологиясен аңлый башладым шикелле: алар һәр җирдә җиңеп, тар-мар итеп, өелеп калган мал-байлык арасыннан юл ярып, асфальт һәм үлекләр, көлләр өстеннән атлап алга барганнар. Бары да җиңел булып тоелган, бары да күңелгә рәхәт булган. Корбаннар, югалтулар сизелмәгән дә аларга. Шуңа күрә авыз гармуннары уйнап кына килгәннәр. Кая хәтле барсалар да — барыбер. Фюрер кушса, җирне әйләнеп чыгарга да мөмкин, тик бар да майлагандай шома барсын! Үз итекләре астында калган

ләр һәм халыкларның бәхетсезлеге, күз яше, ут йотуы аңлашылмаган аларга. Нәфрәт күрсәтеп, карышып маташулары мыскыллы елмаю гына тудырган. Мыскыллы көлү — җиңүчегә хас сыйфат, көчлеләр кыланышы. Ә немец — «җиңүче», немец — «көчле». Шулай булгач, бүтәннәрдә ни эше бар аның!.. Ялгышсам да бик әз ялгышамдыр: немецның бөтен кыланышын, бөтен тырбайчыклыгын сөземтәләгәндә, бары тик шундый нәтиҗәгә генә килергә мөмкин.

Хәзер рольләр алмашынып килә: җиңүче булып без барабыз көнбатышка! Ә җиңеп бару һәм шундый көчле ташкын булып җиңеп бару — чынлап та бик рәхәт икән! Күңелләр җиденче күктә! Ләкин без баш әйләнүдән, масаюдан бик нык сакланабыз. Авызлар пешкән безнең. Шуңа күрә андый очраклар булган чакта бик тиз чик куела. Максат та җир шарын әйләнү түгел, үз чикләребезгә барып җитү! Немец анда да корал ташламаса, Берлингача бару һәм шунда корал ташлатып, бу каһәрле сугышны тизрәк бетерү! Тизрәк бетерү! Бик җитте, бик туйдырды, бер кабарлык урын да калмады...

...Березинаны кичкәч, Борисов аша Минскига юнәлдек. Инде бу зур калага без дә барып керәбез икән дип торганда гына, безне төньяк-көнбатышка таба — Молодечно юнәлешенә борып җибәрделәр. Аны алсак та ярый, өлкә шәһәре бит! Ләкин ул да булмады, тагын борылып-сарылып бара торгач, Литва җирләренә — Неман ярына килеп чыктык. Килешли үк, тегe ярда, плацдарм алдык. Немец анда шактый каршылык күрсәтә башлады: атна-ун көн яр буенда юанырга туры килде. Ниһаять, аннан да дошманны кубарып алып киттек. Волковыськи шәһәрен алдык — бәләкәй генә район шәһәре. Ул да ярый инде безнең «Сазламык дивизия»сенә. Аның каравы, алда Вильнюс, Каунаслар тора бит әле! Кайчан булса да берсен барыбер без алырбыз!

Юк шул, булмаса булмый икән ул. Без, Литва җирләрен аркылап, Польшаның Сувалки өлкәсеннән бер почмагын кисеп, кечкенә бер инешне кичтек тә Көнчыгыш Пруссиягә килеп кердек!

Бу — кырык дүртенче елның октябры иде. Көзге кояшлы көн матур һәм җылы, агачлар, гәрәбә яфракларын җиргә коярга теләмәгәндәй, тын утыралар. Немецның бәләкәй бер арьергард төркеме, инеш күпере тирәсенә бер-ике снаряд салды да, безнең батареяларның массив утыннан соң тынып калды. Пехота каршылыгы бөтенләй булмады. Күпер аша тегe якка агылдык. Һәм, ни өчендер, барыбыз да артка, үзебезнең якка таба борылып, бәхетле бер елмайган хәлдә тынып калдык.

— Я хода, бу көннәрне дә күрербез икән!..— Кемдер шулай кычкырып җибәрде. Барыбызның да бик тирәннән, күңел түрләреннән чыккан уртак тавыш иде бу. Шул бәхетле тавыш туган җиребезгә эндәшүебез шикелле булып ишетелде: әрнүле дә, чиксез татлы да булып яңгырады ул. Кинәт бөтен автоматчылар, сүз куешкан шикелле, күккә яшелле-зәңгәрле-кызыллы ут сиптереп җибәрделәр. Үзе дә бәхетле елмайган лейтенант кычкырып туктатырга мәҗбүр булды.

— Салют! Җолдас командир, — диде казакъ егете.

## Солдат бәхете

Без хәзер Көнчыгыш Пруссиянең Роментен урманнарында. Ап-ак кар яуган. Бездәге шикелле матур кыш башы. Көннәр кояшлы, җылы булып тора. Монда маршал Герингның аучылык заповедниги булган. Бик матур итеп челтәрләп эшләнгән яшел вилласы да бар. Яраннары белән шунда ауга килеп, сиптереп-типтереп йөргән ул. Ә бу кышта аучылык белән шөгыльләнергә, мөгаен, вакыты булмастыр инде аның. Бүтән мәшәкате күптер...

Хәер, аның ауга чыга алмавыннан бер күңелсезлек тә сизелми монда. Безнең солдатлар маршалның болыннарын, кыр кәҗәләрен, пошиларын, куяннарын аңардан да остарак аталар һәм итләрен бик яратып, бик мактап, котелок тутырып ашыйлар. Ау ашы гомумән тәмле була ич ул. Шул хәтле ерак араларны сугышып һәм җиңеп узып, бу җирләргә исән килеп җиткән солдатка бик тә кирәкле, ләкин бик тә кыска була торган ял вакытында, бик тә хәләл булган ризык бу! Деликатес! Гел генә концентрат чәйнәргә димәгән бит!

Шундый болан ашы, болан ите белән бер батальонда мине дә сыйладылар. Аннары болан аучысы һән болан ашын шулай тәмле итеп пешерүченең үзе белән дә таныштырдылар. Юк, ул боланнар иленда туып-үскән төньяк кешесе түгел, төп һөнәре буенча аучы да түгел — игенче ул, эшче ул, сугышчы ул. Әйе, аның икенче төп һөнәрен сугышчы дип атарга бик мөмкин.

Акъегет агай Галиев Башкортстанда туып-үскән (районын блокнотка язмый калдырганмын). Өлкән буйлы, таза-нык гәүдәле, үткен күзле һәм калын коңгырт кашлы кеше ул. Түшендә ике Дан ордены һәм медальләр чыңлый, уң ягында Кызыл Йолдыз ордены белән Гвардия билгесе дә күренә. Без аның белән озак сөйләшеп утырдык. Ул кичкән юлларны тулысы белән яза калсаң, үзе бер китап булырлык. Ул инде илледән узып киткән икән. 1916 елда патша сугышына алынып, өч ай ефрейторлыкка укыгач, фронтта отделение командиры булган. Уналтынчы елның августында Рига тирәсендә рус гаскәрләре һөҗүмгә күчә. Акъегет агай үз бүлекчәсе белән бер ай эчендә унөч тапкыр штык атакасына бара. Немецлар штыкка каршы барудан шүрлиләр, тик боларның җиденче атакасында гына штыкка штык киләләр.

— Әмма рус солдатының штыгына немец каршы тора алмый, — ди Акъегет агай. — Без аларның алгы сафын таптап-кадап чыккач, калганнары пленга бирелделәр.

Ул сөйли, мин уйланып утырам: күрәсең, бу бик борынгы заманнардан калган сөңгегә сөңге килү, кылычка кылыч килүнең актык мисалы булгандыр. Бу сугышта инде автомат, пулемет, гомумән, ут чәчә торган техника «патшалык» итте.

— Ул атакада безнең отделение байтак немецның башына житте, миңа да өчесен җиргә салырга туры килде. Хәер, ел ярым передовойда йөргән вакыт эчендә андый хәлләр шактый булды инде,— ди Галиев. — Хәтта миңа Гиурги крисен дә биргәннәр иде, тик тагып кына йөрмәдем...

Моның ул чак өчен мөһим сәбәпләре булган икән: «Патша өчен кан коючы» дип, «Козьма Крючков» дип караганнар. Ә Галиев патша өчен алай үлеп торучылардан булмаган. Февраль революциясеннән соң частьлары Петроградка кайтарылгач, алар Кызыл гвардия отрядына кергәннәр. Октябрь көннәрендә Керенскийны бәреп төшерүгә катнашканнар. 1918 ел башларында Уфага кайтып «III сугышчан дружина»га кергән. Ул дружина белән Дутовка каршы сугышка киткән. Троицк тирәсендә чехлар тылында «Стенька Разин» исемле отрядта партизанлыкта йөргәннәр. Соңыннан Кызыл Армиягә кушылып, Колчакка каршы сугышкан. Ижевскины алгандагы батырлыгы өчен исемле сәгать белән бүләкләнгән. Воткинскины алганда пленга эләгә. Анда егетнең ялангач аркасына илле шомпол чыжлап төшә. Канга баткан килеш мунчага биклиләр. Өзлексез яуган яңгырлы төндә, мунча астын казып чыгып, үзебезнең якка кайта һәм үз полкына кушыла. Колчактан Екатеринбургны азат иткәч, Царицынга китәләр. Деникинга каршы дүрт ай буе һөҗүм сугышлары алып баралар. Ниһаять, гражданнар сугышы бетә, Галиев басмачыларга каршы җибәрелә. Егерме өченче елны гына өенә кайтып керә ул. Ләкин Акъегет, ни өчендер, андагы тормыш эченә сеңеп кала алмый, Чиләбе ягына китеп черепица заво-

дына керә, аннары Мәскәү метросында проходчик була, аннары Донбасста шахта проходчигы...

Һәм... менә тагын сугыш... 1941 елның декабреннан бирле Акъегет тагын алгы кырыйда, тагын ул иске «танышлары» белән очраша башлый. Кышкы һөҗүм сугышлары бара. Алдагы авылга разведка китә. Галиев та шул төркемдә. Таң беленгәндә авылның бер читенә кереп, хатыннардан сорашып, аргы очтагы биш-алты йортта немец барлыгын беләләр. Разведка шунда китә, немецлар сизенеп уң яктан ут ачалар. Разведка тиз генә бакча кырыена ятып, ут белән җавап бирә. Шул чакта бер зур өйдән егермеләп ак халатлы немец чыгып, басуга таба йөгерә башлый. Берсе сыер җитәкләгән, икенчесе аны арттан таяк белән кыйнап чаптырырга тырыша. Разведка утны алар өстенә күчерә. Шул арада якындагы бер өйдән өч малай винтовка күтәреп чыгып, тегеләргә ата башлый.

— Абый, абый, безнең сыерны алып китәләр,— ди берсе, елардай булып. Ләкин аны алып китә алмыйлар, ташлап урманга кача немецлар. Ә малайлар куанышып сыер янына йөгерәләр һәм җитәкләп өйләренә алып кайталар. Сыерны урнаштыргач, алар тагын разведчиклар янына килеп, авыл аркылы узган сунын теге ягындагы өч-дүрт йортка немецлар җыелганын әйтәләр. Разведка бакча эченнән елга ярына якынлаша да, җимерек йортка ышыкланып, дошманга ут ача, малайлар да булышалар. Атыш кызгач кына патрон бетү куркынычы туа. Малайларның берсе шул ук бакчага күмеп куелган патрон ящигы урынын күрсәтә, аны тиз генә актарып алалар да «эшкә җигәләр». Озакламый бу алты кеше янына сержант Иванов отделениесе килеп чыга. Алар бергәләп немецларны авылдан куып чыгаралар. Алып китә алмаган 25 немец гәүдәсе авыл урамында аунап кала. Болар эчендә Акъегетнең дә «өлеше» шактый булса кирәк. Тик ул «фәлән хәтле немец үтердем» дигән сүзне бик үк әйтеп бетерми, «без...» дип сөйли. Шулай да бер урында «тел язып» куйды. Хәл болай булды: шул ук разведка төркеме яңа задание белән алдагы авылга барганда, калку җирдә миномет уты астында кала. Чанадан төшеп, үзәнгә йөгермәкче булалар. Якында гына ярылган мина атны һәм ездовойны харап итә, лейтенант Ивконың иптәше Клавдияне яралый. Аның ярасын ут астында Галиев белән бергәләп бәйләгәч, лейтенант үзәнгә таба алып китә, ләкин шунда үзе дә яралана, икенче солдатның муенына пуля керә, исән калган Кругликов аны тылга алып чыгарга китә, шулай итеп, Акъегет берүзе кала. Лейтенант белән Клавдия аңардан үзләрен ташламавын үтенәләр. Ә каршыларына җиде немец килә, автоматларын уйнаткандай гына сиптереп, аягүрә киләләр. Галиев лейтенант белән Клавдиягә үзәндәге иманлеккә шуышырга куша да үзе тегеләргә каршы ут ача. Менә шунда инде:

— Тырпаеп аягүрә килгән автоматчының берсен атып ектым,— диде ул, гади генә тыныч тавыш белән. Ә хәлләр ул минутта бик үк тынычлык саклардай булды микән? Немецлар үрмәләп килә башлыйлар, һаман якынаялар. Йөз метрдан кимрәк ара кала. Алты немецка бер татар. Тегеләрдә автомат, моңарда винтовка гына. Хәл — җитдинең теге ягында. Галиев нииндидер бер мизгел эчендә тирә-якны күзәтеп ала: сул якта, юл читендә, бер ватык немец машинасы күренә. Бердәнбер котылу урыны шул булыр сыман тоела. Ул үзән сыртына ышыкланып үрмәли-бөкрәя шунда ташлана. Уң ягыннан, арттан пуля ява, шулай да Галиев машина астына кереп өлгерә. Кереп өлгерүенә мина килеп төшә. Күрәсең, аны ничек тә бетерергә телиләр. Ләкин минаның зыяны тими.

— Солдат бәхете саклап калды,— ди Акъегет, елмаеп.

Ихтимал, машина астында ятканда да шулай уйлап сөенгәндер ул. Тик аның сөенүе озакка барды микән? Теге алты немец тагын аның

өстенә — машинага таба килә. Галиев зур, калын көпчәкле авыр йөк машинасы астыннан аларга каршы ут ача. Немецның тагы берсе егыла. Калганнары аның белән азапланган минутта, Галиев машина астыннан үрмәләп чыгып, юл буендагы утыртма наратлыкка кереп югала. Якындагы Заречный авылына барып керә. Анда үзебезнең артиллеристларны табып, хәлне сөйли, алар ул әйткән урынга ут ачалар. Ә Галиев ат һәм бер сугышчы сорап ала да үзән буенча әлеге имәнлеккә чаба. Лейтенант та, Клавдия дә исәннәр! Яшь ханым сөенеченнән аны кочаклап елап җибәрә. Шулай итеп, алар үлемнән котыла...

...Кырык икенче елның май ахыры. Фронт оборонада, солдатлар төн буе траншея казый, ныгытмалар ясый. Көндез эшләргә дошман комачау итә. Галиев тә ул төнне үз взводы белән блиндаж казу эшендә була. Иртәнге дүртләр тирәсендә күрше рота ягыннан әче бер тавыш яңгырый. Акъегет, моны ишеткәч:

— Немецлар! — дип кычкыра да шул якка ташлана. Үрне төшеп, әлеге ротаның алгы сак (боевое охранение) траншеясына якынлашса, ике кешенең тарткалашып ятканын күрә. Берсе аның үз танышы Кустов. Битләре канга баткан, гимнастеркасы ертылган. Икенчесе җирән чәчле, озын таза гәүдәле немец. Алар кулларын тотышып, берберсен чайкашып маташалар. Немец Кустовны алып китәргә тели, ә Кустов бирешми, теш-тырнагы белән каршылык күрсәтә. Немецның да бите ертылып беткән, кан саркыган. Галиев шундук Кустовка ярдәмгә ашыга. Дошман ягыннан автомат уты ачалар. Ут астында траншеяга үрмәләп килгәндә, әлеге немец аңа:

— Танклар килә! — дип кычкыра. Куркытмакчы була, янәсе. Акъегет икенче сикерүдә траншеяга килеп төшә дә автоматын төзәп: «Һәнди һоһ!» дип кычкыра. Немец кул күтәрергә мәҗбүр була. Галиев аны якалап траншеядан сөйри башлый, немец яман әшәке тавыш белән акырырга тотына, немецчалап ниләрдер әйтә,— артта, прикрытиедә, яткан иптәшләреннән ярдәм соравыдыр инде...

— Шунда мин аны культурный гына рәвештә бер-ике рәт селкеп алдым да автомат көпшәсен чигәсенә терәдем, — ди Галиев, көлемсерәп. Шул чакта безнең сугышчылар, арткы траншеядан килеп житеп, немец автоматчыларын куып җибәрәләр. Бу немецка шаулар урын калмый. «Тел» алырга килеп, үзе «тел»гә әйләнә. Галиев аны рота командирына илтеп тапшыра. Ничек илтә бит әле: ул аның чалбар төймәләрен кырып, ыштанын кулына тоттыра, каешын да салдырып ала. Менә шуннан соң инде немецың качып карасын! Ул «батыр» — оберефрейтор булып чыга, «тимер тәре» кавалеры икән, «тел» алырга үзе теләп килгән, янадан бер тәреле булырга теләгән, күрәсең...

...Җәяүле разведка һәрвакыт үз частенын алдыннан бара. Кайчакта тавыш-тынсыз гына, ә кайчакта ачык атака белән дә дошман траншеясына бәреп керергә кирәк була. Һәр очракта беренче куркыныч, беренче ут аның өстенә килә.

Ржев төбендә немецлар бик тирән казынып, бик озак утыралар. Аларны кубарып ташлауның хәйләсен табу өчен «җеп очы» кирәк. Разведка төркеме, төп сызыктан читтә булган бер кечкенә авыл тирәсендәге позициягә кинәт атака ясап, дошманның беренче траншеясына бәреп кермәкче була. Ләкин немецлар, шуны гына көтеп торгандай, чамасыз каты ут яудыра башлыйлар. Атака уңышсыз чыга. Төркем байтак югалтуларга очрый. Өч кенә кеше исән: старшина Курдюков, Галиев һәм Филипкин. Алар, максатларына ирешә алмыйча, чигенергә мәҗбүрләр. Шул чакта Акъегет, балтыры яраланып, егыла. Старшина белән Филипкин аны җитәкләп алалар. Болар өстенә автомат давылы гына түгел, миналар да чинап ява башлый хәзер. Галиевнең ике иптәше дә сафтан чыга, үзенең тагын кулы да яралана. Ул бер ялгызы кала. Ничек кенә булса да дошман кулына эләкмәскә,

үз иптәшләре янына кайтып житәргә кирәк. Яралы аягын өстери алмагач, жиргә ятып, ут астында бөтерелә-бөтерелә тәгәри башлый ул, танкка каршы казылган тирән чокырга житә. Немецлар аны тереләй элэктермәкче булалар. Акъегетнең кулы да яралы булганлыктан, ут белән каршы торыр мөмкинлеге юк. Ул, чокырга тәгәрәп, аның төбендәге суга ук барып төшә һәм сугыш башларында ук казылган бу чокырның сул кырыена үскән камышлар артына ышыклана. Чокыр кырыена килеп баскан өч немец аны күрми, суга карап нәрсәдер мыгырдашып торалар да түбәнгә китәләр, сусыз жирдән чыкмакчы булалар, күрәсең. Ләкин ул тирәдә алар безнекеләрнең утына эләгәләр. Акъегет, шуннан файдаланып, судан чыга да үз иптәшләре янына шуыша башлый. Аны ике арадагы зонадан санитарлар табып алып кайта. Дәваланып янадан сафка баса Акъегет агай.

Ул беренче бөтендөнья сугышында бер яра, бер контузия алган булса, Ватан сугышында өч яра һәм бер контузия алган... Дөньяны күп күргән, э сугышларның әчесен-төчесен кушучлап чөмерергә мәжбүр булган бу агайның, бу өлкән солдатның беренче ишетүгә сәер тоелган үз фәлсәфәсе бар: «Солдатка берни дә кирәкми, бай трофейлар да дан да, хәтта орден-медальләр дә артык кызыктырмый аны, — ди ул. — Солдатка бары тик бәхет кыйбат, солдат бәхете! Ә «Солдат бәхете нәрсәдә?» дип сорасагыз, солдат бәхете — үлмәүдә!.. Әйе, әйе — үлмәүдә!» — дип кабат өсти ул.

Аның бик гади әйтелгән бу фикеренә елмаеп куясың. Һәм аңа каршы бәхәсләшәсе килә.

— Алайса, бәхеткә ышанып, ут астында теләсә нишләп йөрергә буламы? Яки, үлмәскә теләп, окоп төбеннән баш та калкытмый посып кына ятарга кирәкме? — дип карыйм мин. Хәзер инде ул көлә.

— Икесе дә ялгыш! — дип сүзен дәвам итә. — Әгәр дә мәгәр бәхет дигән нәрсә, ходайның бер хикмәтле кошы булып, синең баш очында гына сайрап торса, син немецны ялан куллап кына уңлы-суллы яңаклап йөрер идең. Бөтен бәла шунда: ул кош синең күзгә күренми. Бармы ул, юкмы ул — син аны тиз генә белә алмыйсың. Ә инде окоп төбендәге «йомран» турында сөйләп торасы да юк. Андыйлар хәзер дә очрый һәм шул чокыр төбеннән баш калкытырга, якты дөньяга бер тапкыр күз салырга да өлгермичә, жан бирәләр. «Батыр бер үлгәнче, куркак мең үләр» дип, тикмәгә әйтмәгәндер халык...

Ул берхәтле тынып калды. Ашыкмый гына махоркасын чорнап кабызды. Аннары гына, сабыр елмаю белән миңа карап, дәвам итте:

— Хәер, бәхет турында үземнән чыгып әйтүем генә... Өч сугышта күргән хәлләрнең уннан берен генә диярлек сөйләдем мин сиңа, иптәш. Барын да сөйли китсәң, кеше ышанмастай мажаралар да бик күп. Ә кеше ышанмаслык сүзне дөрес булса да сөйләмә, дигәннәр түгелме. Әнә шул кеше ышанырдайларын гына кичергән булсам да — мин һаман исән! Хәтта менә немецның үз жиренә килеп кердек, аның болан итләреннән дә авыз иттек. Анысы чепуха, кәнишне, әмма жиңүче булып Берлинга барып житәргә өметләнү — бәләкәй эш түгел и барып та житәрбез, бәхет булса! Ә бәхет дигәнең бик үз холыклы кош ул: иң актыккы минутта гына баш түбәңнән очып югалса, нишләрсең?!.

Барыбыз да көлешеп алдык. Әлбәттә, баш очындагы ул кадерле кошны беребезнең дә очырып жибәрәсе килми иде. Акъегет агай белән хушлашып, редакциягә кайтканда, һаман шул «кош» турында уйлана бирдем: 1942 елның сентябре иде, безнең армиягә яңарак килеп сугышка кергән мотомехбригадага бардым. Биек нарат урманы эчендәге ачыклыкта яңа казылган блиндаж. Командирны да, замполитны да туры китерә алмагач, штаб начальнигы белән сөйләшәм. Шактый олы яшьтәге какча йөзле майор ул. Аңардан саннар, сводкалар алып була, ләкин батырлык эпизодлары алып булмый. Тәмәке тартырга чыктым.

Кат-кат накат өстенә тигезләп өелгән кызыл балчык арасыннан әле бер генә үлән кыягы да борын төртмәгән, яшел кәс белән дә капланмаган ул. Җиңел тәмәкене газета кәгазенә чорнап тартсаң, сары май тәмнәре килә инде! Ә тирә-якта атыш бара — артиллерия дуэле. Снарядлар як-яктан һәм урман өстеннән сызгырып узалар. Мондый атыш куркыныч түгел, һәр ике як бер-беренең якын тылын капшый, андагы ут нокталарын басарга тырыша. Мин, берни дә уйламыйча, нарат башларына карап, тарта бирәм. Шул чагында нәкъ блиндажның өстенә, миннән ике метр чамасы гына алга бер снаряд килеп төште дә, чыелдап, зыр-зыр әйләнә башлады. Борыны белән җиргә кадалмады, «түше» белән килеп төште ул. Мондый ук куркыныч хәлгә беренче юлыгуым — яртылаш җаным чыккандай булып, блиндаж эченә атылып кердем, почмакка постым, майорга сүз катарлык әмәлем дә калмады, «менә, ярыла да, икебез дә бетәбез инде!» дип көтәм. Тешләрнең тешкә шак-шок орынуын сиздермәс өчен иренне тешлим. «Ник бүтән җиргә йөгермәдем? Үлемнең астына килеп кердем...» дип үкенәм. Ә кая качасың?.. Көтәм, көтәм, ярылмый. Инде өч-дүрт минут узды булса кирәк, һаман шартлау юк. Әгәр ул соңыннан ярыла торган булса?.. Алайса, хәзер үк чарасын күрергә! Үземне көч-хәл белән кулга алып, телгә килдем:

— Иптәш майор, әйдәгез, карыйк әле, анда бер снаряд төшкән иде,— дидем. Ул мине аңлап бетермәде. Җиңеннән тотып, ашык-пошык алып чыктым да блиндаж өстендәге снарядны күрсәттем. Ул инде кайчандыр һәм ничектер төшеп калган снаряд шикелле тып-тын ята иде. Хәлнең ничек булганын кабаланып сөйләп биргәч, майор бер дә гаҗәпләнмәде.

— Нарат башына эләгеп, рикошет биргән һәм хәрәкәт тизлеген җуеп, монда яны белән килеп төшкән,— диде ул.— Юкса, немецлар монда атмыйлар, ул монда төшмәскә дә тиеш.

Бу «адашкан үлем» турында мондый тулы һәм салкын канлы анализны ишеткәч, мин дә суынып куйдым, баягы шүрләвем көлке сыман булып калды...

Нәкъ шушыннан ике ел соң, 1944 елның август ахырында, Польшаның Сувалки өлкәсеннән барабыз. Тип-тигез арыш басуы, бик матур кояшлы иртә. Тар гына авыл юлының ике читендә сузылып кала торган озын-озын «тасма» җирләрне күргәч, монда әле бик борынгы заман яшәвен хәтерлисең. Басу һәм урман чатларында биек-биек тәре баганалары. Аларның аркылысына беркетелгән Гайсә сыны хәсрәтле итеп ясаган карачкы төсле булып тоела. Шул тар гына юлдан барган бөтен полк атта. Немецлардан алган трофей атлар безне җәяү йөртми хәзер. Якында гына каршылык күрсәтүче дошман юк, безнең төнге тукталышта ул шактый ерак качып өлгергән. Шуңа күрә пулеметлар, ПТРлар да, солдат үзе дә арбаларга төялгән, разведчиклар атланып, алдан баралар.

Кайсыдыр арбада кемдер аккордеон уйный, шул ук тирәдән басынкы гына җыр авазы яңгырап кала. Бу куанычлы хәрәкәт нииндидер ягы белән гражданнар сугышын, тачанкалы, кавалерияле Кызыл гаскәрнең Украина далаларын кичкән көннәрен хәтерләтеп куя кебек. Матур. Романтикалы! Үзенең шундый әшәке дошманың җинеп барган гаскәр юлы һәрвакыт матур һәм тантаналы!

Ләкин бу идиллия күпкә сузылмады, бер авылга якынлашып килгәндә һавада немец «култыкса»сы күренде (ике кысалы разведка самолеты). Бер генә әйләнде дә китеп барды. Без сагаеп та өлгермәдек, аның артыннан ук биектән 12 самолет килеп чыкты, якында — бер агачы, урман заты, чокыр-чакыры булмаган тип-тигез басу өсте, озын сабаклы арыш дулкыны. Унда тик шул авыл гына. Бүтән беркая сыенып урын юк... Таралырга команда бирелде. Юлга тезелгән атлы

арбалар, күз ачып йомганчы, арыш арасына чәчелеп беттеләр, солдатлар да, төрле якка сибелеп, төрле җиргә сенделәр. Қайбер төркемнәр ундагы авылның бакча башларына йөгерде. Шулар арасында мин дә бар идем. Алдан чапкан яшь, егәрле солдатлар, каядыр таралышып, юк та булдылар. Берүзем калдым, кая сыенырга соң? Ә күктән инде, яман да ачы сызгырып, бомбалар ява. Ваграк булсалар кирәк, фугас кебек авыр гөрселдәмиләр.

Бакча киртәсе аша ничек сикергәнмендер, белмим; бәрәңге сабаклары арасыннан йөгереп килгәндә салам түбәле бер мунчага килеп төртелдем дә, стена буена сәке биеклегедәй генә өелгән такталар өстенә йөзтүбән капландым. Күзләрне чытырдатып йомып, шул стена, шул такталарга сеңеп керердәй булып ятам. Бала чакта бер олырак малай сиңа кизәнсә, башны корыштырып, күзне йомасың. Бу инстинкт соңыннан да бетми икән. Менә хәзер дә, күзләрне шулай чытырдатып йомгач, минем өчен гүя куркыныч азрак, бөтен дәһшәтне күзләрең белән күрмәгәч, гүя ки ул хәтле хәтәр түгел! Ләкин колаклар барыбер һәммәсен дә ишетеп, йөрәккә житкереп тора. Қарамыйча да күреп ятам: тирә-якның асты-өскә килә. Бомбалар гөрселди тора — кайдадыр атлар чыйнавы, озын итеп кул пулеметы тыкырдавы, «ПТР»дан аткан тавышлар бар да бергә кушыла. Менә кинәт бик яман чыйнап, бик якында гына бер бомба килеп төште, бакчага ук төште бугай ул, хәтта авыр тотен сасысы да борынга килеп сылангандай булды. Әмма бик зурдан түгелдер, ахры. Шартлавыннан җир тибрәнмәде.

Шуннан соң озакламый ниндидер шомлы тынлык урнашты, баш очында самолетлар уламый башлады. Бик тиз сикереп тордым да мунча сукмагы буйлап абзар-курага таба чаптым: шушы тын арада ышанычлырак урын табам, янәсе. Қаршыма, аяк астыннан гына дигәндәй, җиде-сигез солдат килеп чыкты.

— Кая йөгерәсез, иптәш капитан? — ди берсе.

— Укрытие эзлим...

— Бомбежка бетте бит инде! — диләр, тегеләр, көлеп.

Күккә карыйм — бер самолет та калмаган. Оялып кызарганымны үзем дә сизәм, аларга кушылып көлгән булам.

— Ә сез кайда идегез соң? — дип сорыйм.

— Әнә ич,— диләр,— иң шәп убежище!

Абзар артында гына тирән бәрәңге чокыры. Алар бары да шунда чумганнар икән. Солдат сәләтле һәм тапкыр шул. Мин җүләр, авылда үсеп тә, һәр абзар артында бәрәңге чокыры булуын искә дә алмаганмын.

Борылып мунча янына килеп җиттек.

— Мин шушы такталар өстендә яттым,— дим тегеләргә.

Алар аптырап калдылар. Мин үзем дә шаккаттым: мунчаның мин яткан урыннан бер генә метр биеклектәге бүрәнәләрен бомба кителәре уч төбедәй умырып алып киткән. Ә бомба мунча сукмагының сул ягына 4—5 метрга гына килеп төшкән. Чокыры тирән түгел — тубал сыярдай гына. Тирәсендәге яшел бәрәңге сабаклары кара корымга батып куырылганнар. Бу хәлләрне күргәч, йөрәгем «жу» итеп куйды. Ничек исән калганмын? Әллә күзләрне чытырдатып йому коткарганмы?.. Әллә Акъегет агай сөйләгән солдат бәхете иде микән бу?! Шулдыр, мөгаен, шул тылсымлы кошның корыч канатлары каплагандыр мине! Шуннан соң мин ул бәхеткә бик нык ышанып йөри башладым. Күңел түрендә ниндидер якты куаныч һәрвакыт балкып торучан булып китте...

Полк яңадан җыелды. Басуга таралган байтак кына атларыбыз шунда ятып калды. Ярый әле, солдатлардан үлүчеләр бераү дә юк, ике-өч егет кенә җиңел яра алганнар. Алар да сафтан китмәде. Юлны яңадан дәвам иттек.

Ә менә минем якын дусларым Шелховской белән Андреевны солдат бәхете ахырга кадәр саклый алмады. Кырык бишенче елның март уртасы иде бит, без инде Кенигсберг төбендә вакытлыча оборонада гына ята идек, алда бары бер генә сикереш калган иде. Юк, булмады, урта бармактай ир-егетләр әрәм булды. Алар икесе дә рядовойдан башлап майор дәрәҗәсенә җиткән офицерлар иде. Мәскәү егете Шелховской — батальон командиры, Курск егете Андреев исә аның замполиты иде. Елдан артык бергә хәрәкәт итеп, бер-берең белән тәмам үзләшеп беткән дуслар! Дивизиянең 52 нче полкына килгән саен мин алар батальонына сугылмый калмый идем. Чөнки Шелховской батальоны әйбәт сугыша, операцияләре грамотный уздырыла. Шунлыктан, газетада язарлык кыю егетләре дә күп була, командирның үзе белән бергә шул уңышлы операцияләр хакында мәкалә-фәлән оештырырга мөмкинлек тә туа. Аннары Шелховской белән Андреевның үзара мыек кабартышмыйча матур итеп тату яшәүләре дә, бер-беренә ихтирам һәм кече күңел белән эш итүләре дә миңа бик ошый иде. Аларның сугыш юлларында кала торган ничәмә-ничә блиндажларында күпме көннәрем, күпме төннәрем узганы бар иде. Күпме сүзләр сөйләшенгән, күпме көленгән, күпме хыяллар кичерелгән иде... Менә шул алтын егетләрне миңа соңгы тапкыр немец хуторының кирпеч сараенда ике тәгәрмәчле арба әрҗәсендә күрергә туры килде. Бүгенгедәй күз алдымда: икесе бер-беренә карап кулларын салып кочаклашкандай булып ятканнар. Әйтерсең һаман алга күчү юлындагы вакытлы землянканың аннан-моннан гына әмәлләнгән тар сәкесендә төн куналар: талчыгып килеп, каты йокыга талганнар. Каты йокыга... Әйе, сугыш башыннан бирле җәяүләп, көнбатыш чикләрдән Мәскәү, Сталинградкача чигенгән, аннары кире борылып Кенигсберг капкасынача барып җиткән бу асыл егетләр, егылсалар да, ял сорауны белмичә һаман алга ыргылган бу давыл йөрәклеләр инде мәңгелек йокыда тынганнар... Аларның сакаллы битләренә иреннәрем тия, битләре суык, куллары да суык, гәүдәләре дә боз кук — туңганнар, мескенкәйләрем. Ихтыяр көченә буйсынмый тамган яшьләрем, кайнар булса да, аларны җылыта алмый инде.

Теге снаряд тагын искә төште: 1942 нең сентябрендә блиндаж өстендә ярылмый калган снаряд әйтерсең монда килеп ярылган. Тирән төн уртасында ниндидер котырган немец кулы белән җибәрелгән авыр снаряд, нәкъ блиндаж өстенә туры килеп, актарып ташлаган... Шелховскойның да, Андреевның да йөзләре тыныч, бер генә дә кичереш билгесе сызылып калмаган, яра да юк ул йөзләрдә... Күрәсең, алар йокыда булганнар, уяна да алмыйча, сабыйларча тынычлык белән үлеп киткәннәр... Алар һаман күз алдымда минем... Кайда идең син, тылсымлы кош — солдат бәхете?..

Безнең тагын бер якын иптәшебезне саклый алмый калдың син... Подполковник Зәки иптәш Басыйров иде ул. Мин аның белән 1942 елның апрелендә Брянск фронтында, Сороколетово авылында танышкан идем. Ике ярым елдан соң Роментен урманнарында тагын очраштык. Ул инде безнең дивизиядә полк командиры иде. Бик тыйнак, тыныч холыклы, акыл белән уйлап эш итүче бу иптәш бик түбәннән күтәрелгән халык улы иде. Чит авылда, үги ата кулында, чит балалар арасында интегеп үскән Зәки 14—15 яшенә җиткәч, авыл көтүе көтеп тамак туйдыра башлаган. Кичләрен клуб, ликбезда уку, комсомол җыелышлары, спектакль кую, ә соңыннан үзе избач булып китү — яшь батракның күңел күзен көннән-көн киңрәк ача барган... «Укырга, укырга! Кеше булырга!» — дигән омтылыш аның төп максатына әйләнеп киткән. Ләкин кая барып укырга соң? Ул бит ликбездан гына башлаган кеше. Кантон калаларында техникумнар, төрле курслар барлыгын, Уфа белән Казанда рабфаклар булуын ишетә, чарасын

да күреп карый — тик белеме җитми, дүрт класс та юк — алмыйлар. Ниһаять, өмет өзми тырыша торгач, 1928 елны Казандагы хәрби училище курсанты булу бәхетенә ирешкән ул. 17 яшьлек Зәки Басыйров шул көннән башлап хәрби кеше булып киткән. Курслардагы отделение командирыннан тотынып, бөтен баскычларны әкренләп уза-уза, полк командирлыгына килеп җиткән, сугышның беренче көннәреннән алып ут эчендә кайнаган кеше иде ул.

Башкортстан шагыйре Хәниф Кәрим Унберенче армия газетасында эшли иде. Ул безнең дивизиягә килеп чыкса, һәрвакыт бергәләп Басыйров янына китәбез. Алар якташлар, икесе дә җыр сөючән кешеләр. Иркенрәк ара табып, кич утырырга туры килгәндә, сагынып сөйләнә торган истәлекләрдән соң, Хәниф үзенең моңга бай йомшак тавышы белән «Һандугас»ны сузып җибәрә. Басыйров калынрак басынкы тавыш белән «Ирәмәлекәй»не әйтеп бирә, «Ком бураны»н җырлый һәм ул чакта фронтта популяр булган «Синий платочек», «Огонек», «До смерти четыре шага» һәм бүтән күп кенә рус җырларын да оста башкара иде. Гомумән, ул дистәләрчә җырларны күңелдән белә, шуның өстенә җыр язып тутырылган калын бер кесә дәфтәре дә йөртә иде. Хәер, Башкортстан кешеләре, гомумән, җырчан егетләр бит алар...

Сугышның актык көннәре килеп җиткәндә генә без әнә шундый кадерле дустыбызны, 17 ел өзлексез армия сафында хезмәт итеп, аның өлкән кадрына әйләнгән яхшы бер иптәшебезне югалттык. Миңа аны күмешергә туры килде. Сугыш җирендәгечә гади ясалып, карага буялган табут эчендә, йоклагандай тыныч йөз белән якын иптәш ята... Баш очы тирәсен, әле мартның 24 е генә булса да, солдатлары, каяндыр табып, яшел үсентеләр белән бизәгәннәр. Көн дә кия торган кителенең түшендә орденнар, медальләр һәм Гвардия билгесе балкый. Әле моннан өч кенә көн элек бергә сөйләшеп йөргән иптәшемә хәзер бер сүз дә эндәшеп булмый, җавабын да ишетү мөмкин түгел. Күңел сыкрый, йөрәк елый... И солдат бәхете, ник син үзеңнең тылсымлы канатларың астына яшермәдең аны? Ник әрәм булды ул яхшы кеше? Кече күңелле солдат, турылыклы бер командир ник сугышның соңгы көннәрендә генә сафтан чыкты?..

Шагыйрь Хәниф Кәрим үзенең «Якты йолдыз» исемле талантлы поэмасын Зәки Басыйров истәлегенә багышлаган. Үги ата, үги йорт тарлыкларыннан котылып, тормыш юлын ялан аяклы көтүче буларак башлап җибәргән халык улына, бөтен авырлыкларны егетләрчә күтәрә белгән тыйнак һәм батыр Ватан солдатына гүзәл бер һәйкәл бу. «Егетнең егетләре җырга күчеп яшиләр» дигәннең мисалы менә шулдыр инде.

Сүзне «Солдат бәхете» дип башлаган идек бугай. Солдат бәхете... Әйе, солдат бәхете — үлмәүдә. Солдатның тау тарттырудан да авыр хезмәтен егетләрчә үтәп, хәтта ничәдер тапкыр яраланып яки контузия алып булса да, туган-үскән йортына сау-сәламәт килеш кайтып керүдә ул бәхет...

Исән микән Акъегет агай? Кызганычка каршы, без аның белән яңадан туры килешмәдек. Өч сугышның ут-суларын кичеп, үлемне алдауда остарып беткән Акъегет агай, үзе генә түгел, иптәшләрен дә коткарып йөргән, ә дошманына һәрвакыт аяусыз булган Ил солдаты, түшенә тезелгән орден һәм медальләрне бик хаклык горурлык белән горур чыңлатып, туган-үскән җирләренә исән-аман кайтып җитте микән? Ахыргача саклап йөртте микән аны тылсымлы кош — солдат бәхете? Бик беләсем килә минем шуны.

Апрельнең беренче атнасы да узмаган әле. Табигать яшел күзләрен ачып килә. Безнең фронт Кенигсбергка һөҗүм башлады. Көнчыгыш Пруссиянең үзәк һәм ныгытылган ноктасы бу. Немецлар моны теш-тырнаклары белән сакларга җыеналар.

Безнең «Сазламык дивизиясе» дә, ниһаять, зур калага һөҗүм итә! Хәер, уйнап кына әйтү. Үзебезнең Суворов орденлы, Городок исемле 83 нче укчы гвардия дивизиябезне бер дә кимсетеп сөйлисем килми. Мин анда хәзер 14 ай хезмәт итәм, сугышчан көннәремнең иң матурын шунда кичердем. Аның шушы исемнәре генә дә узган юлының бер дә башкалардан ким булмавын күрсәтеп тормыймыни? Ә монда килешли без әле дошманның Гумбенин, Тильзит һ. б. калаларын да алып үттек. Юк, олы юлда ул, аның шаян кушаматы онытылып бара хәзер.

Әнә күз алдында тевтоннарның бик борынгы шәһәре Кенигсберг. Аның борынгы соборлары, күп катлы биек йортлары, озын моржалы завод корпуслары, шәһәр боҗрасындагы бетон фортлары ерактан ук күренеп тора. Алар барысы да ныгытмага әйләндерелгән. Безнең зур калибрлы артиллерия һәм авиация аларны утка тота. Кара төтен баганалары һәм алар аслап күккә сузылган кызыл ялкыннар коточкыч һәлакәтне аңлаталар. Кайчандыр ярты дөньяны кара һәм соры төтенгә батырган әшәке дошман, хәзер, үз башына шул афәтләр ява башлагач, нинди хисләр кичерә икән?.. Яна Кенигсберг, яна... Беребез күңелендә дә кызгану һәм аяу тойгысы тудырмыйча яна. Инде безнең алгы частьлар шәһәрнең беренче кварталларында сугыш алып баралар. Аерым взвод һәм төркемнәр аның юл читендәге аерым йортларны, вак хуторларны снайпер калдыкларыннан, идән асты «убыр»ларыннан тазарталар. Иген җирен саранча ояларыннан әрчү шикелле вак һәм мәшәкатьле эш инде бу. Андый чакта төрле хәлләргә тап килә солдат. Аяк астына поскан бәла сине һәр минут бәреп ташлавы мөмкин. Шундыйрак бер эпизод һаман хәтердән чыкмый әле.

Безнең бер ротада Галета фамилияле автоматчы егетебез бар иде. Ерак Көнчыгыш казагы. Кайчандыр бабалары Украинадан күчеп, шунда төпләнгәннәр. Озын буйлы, нечкә гәүдәле, сары чәчле, сары мыеклы, җор телле, бик гади һәм ачык күңелле бер солдат иде ул. Аның украинча йомшак сөйләм белән тезә торган мәзәк сүзләрен землянкада төн буе көлә-көлә үземнең дә тыңлаган чакларым булды. Менә шул Галетабыз, «әрчү» эшендә йөргәндә, кызу гына йөгереп, бер коттеджга килеп керә. Автоматы белән ике-өч бүлмәне чайкап уза да, шул ук кызулык белән тагын бер бүлмәне ачып җибәрсә, бүлмә түрендә аңа автомат төзәгән сары мыеклы, озын буйлы сары немец басып тора! Кинәт булган бу хәлдән Галетабыз аптырап китә. Тиз генә ишекне яба да: «Тукта, бу үзе генә түгелдер, хәйлә кирәк», дигән уй белән иптәшләре янына йөгереп чыга. Алар килеп йортны камап алалар, аннары эчкә кереп эзли башлыйлар — берәү дә юк! Галета аптырый: «Неужели шул арада чыгып качтылар микән?..» Һәм йөгереп килә дә тагын теге ишекне ачып җибәрә. Тагын аның каршында әлеге автоматлы немец басып тора. Галета тиз генә аңа автоматын төзи, теге дә Галетага төзи... Ләкин Галета, шул ук кызулыгы белән алданрак өлгерергә тырышып, автоматыннан озын бер «чират» сиптереп җибәрә. Каршыда нәрсәдер «чылтыр-р-р!» итеп коелып төшә... Иптәшләре килеп карауга бот чабып көләргә тотыналар: ике тәрәзә арасына буйдан-буйга куелган көзге булган икән ул. Әңгер-меңгердә Галетаның үзен үзенә немец итеп күрсәтеп, шул бутаган икән башын. Әй, көлделәр дә соң ул көнне ротада. Ә Галета, мескенем, оятыннан комачтай кызарып, моңлы бер елмаю белән башын иеп йөрде. «От

дурень, чорт попутав...» дип пышылдый иде ул. Ләкин берәү дә куркаклыкта гаепләмәде аны, чөнки Галетаның чын мәгънәсендә йөрәкле солдат икәнен иптәшләре бары да белә иде.

Икенче көнне Галетадан тагын бер көлеп, һәм тагын аңа бер сокланып алдылар әле. Җиденче апрель иде бугай бу. Кенигсберг өстендә туплар гөрелтесе тына төште, шәһәр урамнары бер-бер артлы алына тора, анда хәзер күбрәк мылтык, автомат, пулемет сугышы бара. Шәһәр эченнән безнең тылга таба халык чыга башлады. Болар фашист коллыгында җәфа чиккән хәрби әсирләр икән. Советлар Союзы, Бельгия, Франция, Югославия, Чехословакия, Польша һәм тагын әллә кайсы илләрнең әсирләре, гади чүпрәкләрдән әмәлләнгән үз милли флагларын күтәреп, төркем-төркем әкрен генә, хәлсез генә, юл буйлап атлыйлар. Аларның төс-битләрен, өсләрендәге сәламәләрен күрү йөрәкләрне кысып ала, тамак төбенә төер утыра. Шәүләләр. Үлем авызыннан йолкып алынган шәүләләр... Ләкин алар гына түгел икән әле, алар артыннан «цивильни» немецлар төркеме килеп чыкты. Икеөч йөз кеше булыр: яше-карты, бала-чагасы...

Асфальт юлдан читтәрәк булган шактый зур бер күл буена килеп туктады алар. Монда ашыгыч кына оештырылган «билгеләү пункты» — кайсы төркем кая юнәлә — шушында әйтелә. Җыелганнар арасында тәртип саклау, һәрхәлдә, күз-колак булу өчен бездән дә бер төркем солдат билгеләнгән. Ә тәртип кирәк: юкса, чуалыш-буталыш, теләсә кайда укмашып гаскәр хәрәкәтенә комачау итүләр тулып ята. Немецлар күл буена килеп туктагач, озак та үтмәстән, сәер бер хәл булып алды:

— Бата! Фрау бата! — дип, кемдер русча кычкырып җибәрде. Бу тавыш шаяртып-көлеп кычкыргандайрак булып ишетелде. Шулай да күл өстенә карасак, гаҗәпкә калдык: дүрт-биш яшьлек малай күтәргән бер хатын җәһәт-җәһәт су эченә кереп бара! Ә бит апрель башы, су — боз кебек. Нишли ул? Күкрәк тиңенте кергәч, баласын кысып кочаклады да кинәт чүгеп, суга чумды ул. Ә малай, шыр кычкырып, анасының җилкә башына үрмәләде. Немка кире калкынды — әйтерсең, чиркәнчек алып карый иде. Суык суга чыланган малай, бик әче чырылдап, еларга тотынды. Галета минем янда иде, тәмәке суыра идек, һәм нииндидер бик матур мәзәген сөйли иде. Кинәт сүзен бүлеп:

— Оть дурка, оть скаженна! — дип кычкырды ул.— Малыську-то чи топыть хоче?

Килеп туктаган немецларның да моңа кайберсе гаҗәпләнеп карый шикелле. Ләкин күпчелегенең артык исе китмәгән сыман күренә. Үз хәлләре хәл булса кирәк: берәү дә фрауны коткаруга ташланмый. Галета тагын нидер сукранды да, мин авыз ачарга өлгергәнче, автоматын салып, минем муенга элде дә яр буена йөгерде. Шул уңайга плащ-палаткасын җиргә ыргытты һәм теге фрау артыннан кереп тә китте. Беравык эчендә куып җитте ул аны. Малайны нәрсәдер әреплләшкән немка кулыннан тартып алды да муенына атландырды, малай нәни куллары белән аның яңакларына чытырдап ябышты, аннары хатынны култык астыннан эләктереп ярга алып чыкты. Немка һаман тыпырчына, кычкырына һәм истерик тавыш белән елый иде. Галета аны яр өстенә бастыруы булды, ул тагын шул зәһәр тавышы белән илаулап, куллары белән чәчләрен йолыккандай итеп, күл эченә малайсыз гына кереп китте. Онытмы ул аны, җәлләдеме, әллә бу коткаручы «дошман» кулыннан тартып алырга курыктымы? Моны белү кыен иде. Галета исә бу юлы аның артыннан ташланмады.

— Топысь, дурка, топысь...— дип көлеп кенә торды ул. Аның гимнастерка һәм чалбарларыннан чебердәп су ага, җилкәсендәге малайның да юеш киемнәре арык тәненә ябышкан, ул суга керә барган әнисенә караган, ләкин кычкырмый да, еламый да иде.

Фрау батмады, кире әйләнеп чыкты. Яр буена байтак кеше җыелган, бар да аңа кызыксынып карый иде. Безнең политбүлек тәрҗемәчесе капитан Эдельштейн немкага сораулар бирде. Кайгыдан ярсыган фрау «тел яшереп» тормады, кызу-кызу сөйләп китте. Барын да туп-туры әйтеп бирде ул, «кызыл дошман»нан куркып тормаган: ире эсэс офицеры булган икән, Кенигсберг сугышында әле кичә генә үлгән. «Мин үлсәм, син дә, балабыз да үләргә тиеш! — дигән. — Бу кызыл шайтаннар сезне тереләй тотып ашаячаклар,— дигән.— Германия үлә, немец халкы бетә...» — дигән. Фрау иренә һәм фюрергә турылыклы булып үләргә ант иткән. Коткарган булып маташмагыз, барыбер мин сезгә ышанмыйм, барыбер үләчәкмен, дигән...

Калтырана башлаган юеш малайны инде үзенең плащ-палаткасына төреп кулына тоткан Галета кинәт «философ»ка әйләнеп китте:

— Нишли бу немчина? — дип башлады ул.— Дөньяны кара канга, кара трагедиягә батырып, җир күтәрмәс кабахәтлек эшләделәр дә, хәзер үч чукмары үз башларына төшә башлагач, кәмит уйнап маташкан булалар. Корбан булалар, имеш, суга баталар, атылалар, асылыналар, агу эчкән булалар! Ник башладыгыз соң? Мин — солдат Галета, бары тик әйбәт мәзәк сүзләрне, уен-көлкене, бер-береңә яхшылыкны һәм җир сөреп тамак туйдыруны гына яраткан крестьян малае Галета, җир уртасына басып сорыйм сездән: ник башладыгыз бу явызлыкны? Ник башладыгыз? Башлагансыз икән — җавап та бирегез инде! Кәмит уйнап маташмагыз!..

9 апрельдә Кенигсбергның калдык-постык гарнизоны капитуляция ясады. Урамнарда, ерак почмакларда соңгы атыш тавышлары тынды. Шул көнне безнең дивизия өчен сугыш бетте. Солдат, автоматын җилкәсенә аскан килеш, тыныч тормышка күчте... Тик бер «үкенеч» калды: Берлинны күрә алмадык без. Рейхстагның юан колонналарына үзебезнең имзаларны куя алмадык, ә бик тә анда буласы килгән иде, югыйсә...

*1970*

# ШӘКЕРТ ДӘФТӘРЕ— ҖЫРЛАР БИШТӘРЕ

**Казан университеты каршында эшләп килүче Археографик экспедиция табышлары хакында журнал укучыларына «Тарихтагы тирән эзләрдән» исемле язмада беркадәрә мәгълүмат бирелгән иде инде. («Казан утлары», 1970, сан 5.) Соңгы елларда фольклор һәм аноним язма поэзия әсәрләрен эченә алган эреле-ваклы кульязмалар дистәләп табылды.**

Билгеле, мондый әсәрләрнең бер өлеше әдәби-гыйльми кыйммәткә ия булмаган саф дини мөнәҗәтләр яисә түбән сыйфатлы такмазалардан гыйбарәт. Икенче төркем исә фольклористикада күптәннән мәгълүм текстларны эченә ала. Дөрес, болар арасында сыйфатлары белән моңарчы басыла килгәннәреннән югары торганнары да шактый. Әмма төп өлешне әлегә кадәр фольклор белемендә, димәк, укучыларга да, мәгълүм булмаганнары тәшкил итә дисәк, әллә ни арттыру булмастыр. Һәм андыйларның саны бик күп. Бүген без журнал укучыларына заманында шәкертләр арасында популяр булган әнә шундый фольклор һәм аноним язма поэзия әсәрләреннән берничә үрнәк тәкъдим итәбез.

Ләкин шигъри текстларның үзләренә күчкәнгә хәтле шул истәлекләр теркәлеп калган язма чыганаклар хакында да берничә сүз әйтәсе килә.

Татарлар арасында киң таралган кульязмалар турында сөйләгән чакта күләмнәре белән хәзерге гади дәфтәр форматындагы калынлы-юкалы, таушалган тышлы язма китаплар күз алдына килеп баса. Менә шундый кульязмаларның да (төп эчтәлеген дини-фәлсәфи, гыйльми-әдәби текстлар тәшкил иткән хәлдә дә) артып калган буш битләрендә берән-сәрән шигъри әсәр, җыр-бәет очратырга мөмкин. Күрәсең, кәгазь кытлыгын һаман татып яшәгән шәкертләр җае килгән саен күңеле хуш күргән әдәби әсәрне кәгазьгә теркәп барырга тырышканнар. Шуңа күрә дә төп эчтәлегә буенча кәтып калган догмага яисә искереп өлгергән берәр «рисаләгә» багышланган кульязма да бүгенге көндә яңадан кыйммәткә ия була: шәкерт бабаңның кайчандыр узып барышлый гына теркәп куйган бер җыр-шигыре «ашын ашап, яшен яшәгән» иске, эчтәлеге белән әһәмиятсез кульязмага икенче мәртәбә җан өрә — әдәбиятчылар, фольклорчылар күзләрен талдыра-талдыра «өстәмә» язуны укыячаклар.

Мәгәр шәкерт дөньясының әдәби репертуары белән чын-чынлап танышырга теләбез икән, ул чакта инде безгә тагы да чуар һәм формасы, эшләнеше белән тагы да ярлырак кульязмалар — шәкертләрнең «җырлар биштәре» белән эш итәргә кала. Бу инде үзенең зурлыгы белән дәфтәр форматының яртысы кадәр генә бер «кеч кенәгәләре». Ул 10—15 биттән 500 биткә хәтле була ала.

Ә эчендә ниләр генә юк аларның! Бисмилласы белән никах догасы дисеңме, сәлам хаты үрнәге белән шаян җырлары дисеңме, бәете белән мәет куму «кагыйдәсе»нме, гыйшык моңнары белән бәхетсез ананың зарларын тыңларга телисеңме, уку, аң-белем, мәгърифәтне мактаган ялкынлы шигырьләр белән тарихи хикәятләр, гыйбрәтле риваятьләр эзлисеңме — барысы да, барысы да бар мондый дәфтәрләрдә. Кеткәнең берсеннән килеп чыкмаса, аптырама — икенчесен, өченчесен карь — табарсың, әлә генә!

Ә ул җырлар, бәетләрнең ниндиләре генә юк!.. Түбәндә китереләчәк үрнәкләр шәкерт дәфтәре — җырлар биштәренең бер почмагыннан гына алынган өч-дүрт бәртек кенә. Ул «биштәрне» ачарга, аның эчендә хәзерге көндә кыен укыла торган гарәп хәрефләренә «төренеп» яткан элекке язма әдәбият һәм шәкерт дәфтәрләрендә теркәлеп калган халык авыз иҗаты энҗеләрен әдәби-гыйльми хәрәкәткә кертеп, гамәлдәге хәзинәбезгә кушарга кирәк. Ләкин болар киләчәктәге бурычлар. Шәкерт әдәбияты репертуарына гомум күзәтү ясау да, ул репертуарның кайбер якларын, зәгыйфь урыннарын билгеләү дә, шәкертләрнең дөньяга карашларындагы каршылыклы мәсьәләләргә тукталу да[1] шулай ук алда торган актуаль проблемаларга керә. Бу өлкәдә кыенлыклар да аз булмас. Аларның да иң мөшкеле — шәкерт поэзиясе репертуарының иксез-чиксез булуы: күпме шәкерт булган, шулхәтле дәфтәр язылган — бар, җыештырып кара шуларның һәммәсен!.. Бәлкем, бу мәсьәләдә — шәкерт бабаларыбыздан калган «куен кенәгәсе» исемле «җырлар биштәрен» җыеп өйрәнүдә — безгә җәмәгатьчелек тә якыннан ярдәм күрсәтер?!. Чөнки бу төр чыганакларны җыеп өйрәнүнең әдәбият-фольклор, мәктәп-мәгариф, иҗтимагый фикер һәм гомумән культура тарихын тикшерү өчен гаять мөһим икәнлеге беркемдә дә шик уятмастыр...[2]

Мәсьәләгә якынрак килик. Форсаттан файдаланып, түбәндәге әсәрләр теркәлгән дәфтәрләрне безгә бүләк итүче агаларга, апаларга (монда исемнәре аталмаганнарына да) тагы бер кат күп-күп рәхмәтләр әйтәсе килә. «Казан егетләренә» бирел җибәргән дәфтәрләренең язмышы өчен кайгырмасыннар иде алар: ул дәфтәрләр хәзер Казан дәүләт университеты каршындагы гыйльми китапханәдә һәрберсенә хас махсус номер белән сакланалар һәм шул рәвешчә киләчәк буыннарга да барып җитәрләр.

**М. ГОСМАНОВ.**

# Су агадыр, барадыр...

Егерме-егерме биш ел «падиша хезмәтендә» гомер уздыруга хөкем ителгән бәхетсез егетләрнең бу лирик җырлары Буа районы Чәчкап авылында яшәүче Мөнирә апа Шәрәфетдинова тапшырган кульъязмада сакланган. (1968 ел. КДУ китапханәсе, № Т. 2368.) Дәфтәр XX йөз башында Афзалетдин Шәрәфетдинов тарафыннан мәдрәсәдә укып йөргән чакта төзелгән.

Идел суы агадыр,
Әчтерханга барадыр,
Егламас идем бу кадәр,
Үз илләрем каладыр.

Инде безнең барасы
Падишаның жат җире,
Безнең солдат булуыбыз
Бер алланың тәкъдире.

Билемдәге чын путам
Өч әйләнми билемә:
Насыйп булса кайтырмын
Туган-үскән илемә.

Мендем тауның башына,
Карадым бән каерылып,
Туган-үскән илләрем
Калды бәндин аерылып.

Самавырга су салдым,
Кайнамыйдыр күмерсез.
Бән киткәнгә сәүенгән
Үзе булсын гомерсез.

Аккош очып барадыр,
Аны кемнәр куадыр;
Без китә дип куанмагыз,
Сезгә шупшы (?) каладыр.

---

[1] Мәсәлән, суфилардан йөз чөергәне хәлдә, дингә карата иллюзия саклау,— «Гыйлем кирәк!» шигыренә карагыз.

[2] Материаллар җибәрергә теләүчеләр өчен адрес: Казань, Университет, исторический факультет, кафедра истории СССР.

Алма берлән бал ашадым,
Бал татлырак алмадин;
Исән булсам кайтырмын,
Өмет итәм алладин.

Иртә торып карасам,
Нурлы кояш җалтырый.
Бу хәлләрем исемә төшкәч,
Яшь йөрәгем калтырый.

Алты мыскал көмеш йөзек
Бән киямен кулыма;
Алла үзе ярдәм бирсен
Бән бичара колына.

Күк күгәрчен җон кояр,
Аның җонын кем җыяр;
Бәнем күргән хәлләрем —
Кеме еглап, кем көяр.

Әй, сәүекле газиз әнкәм,
Бәндин бәхил улсанә,
Һәр намазның соңында
Хәер-дога кылсана.

Кояш [чыгар] әйләнеп,
Алмагачка бәйләнеп;
Алла эшен һичкем белмәс,—
Шәт кайтырмын әйләнеп.

Су агадыр, барадыр,
Суның өсте карадыр...
Егламас идем бу кадәр,
[Үз] илләрем каладыр!..

# Тырышаек без шәкертләр

*Шәкерт садасы*

Шәкерт дәфтәрләрендә элгәрге татар яшьләренең аң-белемгә, мәгърифәткә омтылуларын чагылдыра торган махсус шәкерт җырлары — садалар, шигырьләр дә шактый күп очрыйлар. «Тырышаек без шәкертләр» дип исемләнгән бу җыр да шундыйларын берсе. Текст берничә кульязма нигезендә бирелә (КДУ. №№ Т. 1943, Т. 1952, Т. 2384 һ. б.).

Без шәкертләр укып сабак,
Кальбемезне кылаек ак,
Ярдәм бирсен безләргә хак,—
Тырышаек без шәкертләр!

Сабак уку шәкерт эше,
Кирәк олуг, кирәк кече,
Сабак укыр [һәр] яшь кеше,—
Тырышаек без шәкертләр!

Безләр кердек яхшы юлга,
Гыйлемлекне алыйк кулга,
Дикъкать итеп уңга-сулга,—
Тырышаек без шәкертләр.

Язу танып язаек без,
Алга таба узаек без,
Эшкә лаек булаек без,—
Тырышаек без шәкертләр!

Гүзәл йирдер безем мәктәп,
Һәр бер төрле китаплар күп,
Файда алаек безләр укып,—
Тырышаек без шәкертләр!

Башка милләт балалары,
Мәктәпләрдә укып бары,
Чыгып китте бик югары,—
Тырышаек без шәкертләр!

Без алардан һич ким түгел,
Укыйк сабак биреп күңел,
Һәрнәрсәне бик ачык бел,—
Тырышаек без шәкертләр!

Милләт хезмәт көтәр бездән,
Төшсен бурыч үземездән,
Файда юктыр коры сүздән,—
Тырышаек без шәкертләр!

## Гыйлем кирәк!

Миңлегани Шакир улы һәм Хәлиулла Хәйрулла улы дигән шәкертләр күчереп язган (1907 ел) ике дәфтәрне бергә төпләгән бу 65 кәгазьле кулъязманы 1969 елда мәрхүм Гани абзый Фәләхов бүләк иткән иде (Багыш авылы, Апас районы. КДУ. № Т. 2365). Шигырь авторы кем булуы хәзергә ачыкланмады.

Вакыт житте, күземезне ачмак кирәк,
Җәһаләт тәкъсиредән[1] качмак кирәк.
Гел җәһаләт, тәгассеблә[2] яшәү булмас,
Һөнәр-гыйлем орлыгыны сачмак кирәк!

Төрле-төрле гыйлем-һөнәр белмәк кирәк,
Һөнәр-гыйлем мәктәбенә кермәк кирәк.
Мич башына гыйлемлекләр килеп кермәс —
Гыйлем өчен аһ-ваһ итеп йөрмәк кирәк!

Үземез наданлыкны сизмәк кирәк,
Шул наданлык — дошманны измәк кирәк.
Өйдә ятып эш тугмады һәм тугмайдыр.—
Гыйлем өчен Аурупаны гизмәк кирәк!

Наданлыкны асрамаек,— ташлау кирәк,
Милләт, диннең йыгачларын[3] ашлау кирәк,
Наданлык — дөнья ахирәт йөз карасы,—
Ихлас илә гыйлемлеккә башлау кирәк!

Безне жиңгән японга күз салмак кирәк,
Күзне салып, шуннан гыйбрәт алмак кирәк,
Анлар кеби булырга кирәк нәрсә —
Гыйлем-һөнәр юлларында калмак кирәк.

Бик карамыз, безгә бик тә гыйлем кирәк,
Һәм сәнаигъ[4], һәм мәгариф белем кирәк,
Барчамыз да төрле жиргә тузып беттек,—
Үз арада берләшергә җилем кирәк!

Гыйлемлекне остаз итеп санлау кирәк,
Дин тамырын гыйлем илә жанлау кирәк,
Дин вә милләт җәһаләтлә үләчәктер,—
Белек илә милләт, динне жанлау кирәк!

Гыйлем өчен көн-төн җәһәд итмәк кирәк,
Аурупа, Амрика(га) йитмәк кирәк,
Укымыйча харап улдык, беләсезме? —
Уку өчен төрле йиргә китмәк кирәк.

Һәр авылга олуг мәктәп салмак кирәк,
Укытырга жанлы хәлфә алмак кирәк,
Ярты-йорты уку илә эш чыкмыйдыр —
Ихлас куеп дәреслектә калмак кирәк!

---

[1] Наданлык кимчелегеннән.
[2] Фанатизм белән
[3] Йыгач — агач.
[4] Сәнаигъ — сәнгать.

Күңлемезне гыйлем илә нурлау кирәк,
Укыган адәмләрне зурлау кирәк,
Гыйлемләрне күп хурладык, йитәр инде!—
Суфи сыман наданнарны хурлау кирәк!

Кальбемезне белек илә пакьлау кирәк,
Фикеремезне, юлымызны хаклау кирәк,
Наданлык, каралыкта череп беттек,—
Гыйлем илә үземезне саклау кирәк!

## Сәйфетдин мәрсиясе

Иске язма поэзиябездә мәрсия — вафат булган кешеләр истәлегенә багышланган элегия — жанры күренекле урын биләп тора. Түбәндә үрнәк сыйфатында китерелгән мәрсияне без 1968 елны Аллабирде авылында (Тәтеш районы) Мәхүбҗамал әби Мөхәммәтшинадан алган XVIII йөз ахыры кулъязмасыннан күчердек (КДУ. № Т. 2380).

..а алып хәлал алган [1],
Мәгыйшәттән хәбәр алган,
Хәбәр алып сабыр кылган,—
Сабыр биргел, кадыйр мәүлям.

Ходая, хәсрәтем авыр,
Нәчүк итим икән сабыр?
Көеп яна йөрәк-бәгырь —
Үлеп китте газиз балам.

Ганимәт дәүләте балам,
Җанымның зиннәте балам,
Бу дөнья рәхәте балам,—
Күзем нуры, йөрәк парәм!..

Ганимәт дәүләте балам,
Мәхәлләм куәте балам,
Дәхи кул канаты балам,
Газиз балам, йөрәк парәм!..

Сәнең киемең кияр булсам,
Сәнең күвең [2] күләр булсам,
Атың тотып сыйлар булсам,—
Тәкатем китәдер, балам!..

Сәнең киемең кияр булсам,
Торып карап йөрәр булсам,
Әгәр Сәфетдинем дисәм,—
Йөрәкем өзеләдер, балам!..

[Сәне] сагынадыр әнкәң,
Балакаем [3] диеп, кәгъбәм,
[Саргаядыр] [4] дәхи атаң,
Газиз балам, йөрәк парәм!..

Карендәше, агасындин,
Анасындин, атасындин,
Фатыймакай тутасындин
Аерылды газиз балам.

Бу дөньядин әлүн [5] тарткан,
Әҗәл хәстәсенә яткан,
Башым авырый дәюп әйткән
Газиз балам, йөрәк парәм!..

## Кызлар киндер агарта

Кызларның хезмәте, гадәт һәм фигыльләре турындагы бу шаян җырлар Г. Фәләхов кулъязмасыннан күчерелде.

Кызлар киндер агарта
Тау буенда бакчада,
Матур кызлар алданадыр
Көмеш дигән акчага.

Кызлар киндер агарта
Агым суның буенда,
Матур егет кайдадыр? —
Матур кызлар куйнында.

---

[1] Юл башындагы бер сүз укылмаудан «хәлал» сүзенең төгәл мәгънәсен тәгаен белеп булмады.
[2] К ү — көй.
[3] Бу сүзне «бәләкәем» дип укырга да мөмкин.
[4] Укылыш шартлы; сакланып калган хәреф койрыкларына карагында, аны «зар еглыйдыр» дип укырга да юл кала.
[5] Әл — кул.

Кызлар киндер суккачтын
Сандыгына куймыйдыр,
Матур егет кызлар күрсә,
Карый-карый туймыйдыр.

Кызлар киндер суккачтын
Агым суда агарта,
Матур кызлар ак йөзләрен
Егет сагышы саргайта.

Кызлар суккан киндерләрен
Кисеп алдым сөлгегә,
Таңнар ата, китим, җаный,
Үбеп калыйм бер генә!

Кызлар суккан киндерләрен
Чыбылдыкка кистеләр,
Ике матур чытлы кызны
Егет белән тоттылар.

Кызлар чигү чигәрләр
Яшел-кызыл яулыкка,
Бән сәнең хәсрәтеңдин
Туя алмадым саулыкка.

Кызлар яка чигәрләр
Уң бармагын хуш тотып,
Матур кызлар һич тә тормый
Гомерләрен буш тотып.

Кызлар бизәү бизәгәчтин
Тулган ай тик балкадыр,
Кызлар унбишкә йиткәч[тин],
Түшләре дә калкадыр.

Кызларның яулыклары
Кызыл микән, ал микән?
Ошбу матур кызларның
Сөймәгәне бар микән?

Чытлы кызның кершәне
Акбур микән, таш микән?
Матур кызның сәүгәннәре
Халаекка фаш микән?

Кызлар кайда? — аулакта,
Өч почмаклы чарлакта,
Матур кызлар хур булыптыр
Гомере буе ардакта [1].

Кызлар яка чигәдер
Аппак-аппак бүзләргә,
Кызлар урамга чыгадыр
Егетләрне күзләргә.

Кызлар сачын тарарлар,
Ука берлән үрерләр,
Матур кызлар сәүгәннәрен
Көн дә ике күрерләр (...)

Кызлар көлмәк юарлар,
Егетләрне сорарлар.
Начар егетне күрсәләр,
Күз кысышып көләрләр.

Кызлар әйтер ал яулык,
Ал яулык та гөл яулык,
Сәүгәнемә барыр идем,
Ходай бирсә бер саулык.

## «Әй гүзәлем, барма картка...»

Шигырь югарыда телгә алынган Афзалетдин Шәрәфетдинов кульъязмасыннан күчерелде. (КДУ. № Т. 2368.)

Егет тә кеше гашыйк булыр,
Менеп йөрер яхшы атларга;
Рыялы кызлар шул булыр —
Гашыйк булыр маллы картларга.

Әй гүзәлем, барма картка,
Әй җанымның кисәге!
Карт кешенең мисле шулдыр:
Артка чыгар терсәге.

...Әй гүзәлем, бакмаясың
Карт кешенең малына:

[1] Ардак — мактау; биредә «матур кызларны мактау боза» диган мәгънәдә.

Та гомерлек хәсрәт алма
Сән үзеңнең җаныңа!

Карт кешегә гашыйк булсаң,
Йөргәнен күр бөкрәеп.
Сәңа хаҗәт карар ирсә,
Күзе торыр чекрәеп.

Гәрчә аны кабул итсән,
Инанып сән сүзенә,—
Гашыйк улып малы өчен
Барыр кызлар үзенә.

Әй гүзәлем, заигъ итмә,
Карт кеше илә гомереӊ[н]е,
Яшьлегеӊ[н]е заигъ итмә —
Үз-үзеңдин кадереӊ[н]е.

Нәфсеӊә әүварә булып
Бакма аның малына,
Бу сүзләрдән аңлаясың,
Кара үзең хәлеңә.

Карт кешегә гашыйк булсаң,
Гәрчә булса ул надан,—
Яшьлегеңнең кадре китеп,
Барчасы булыр яман!..

## Бу эшләрдән кайт, жаный

Җыр Афзалетдин Шәрәфетдинов дәфтәреннән күчерелде (КДУ. № Т. 2368).

Биек тә биек баскычтин
Менеп кенә булмый тоткасыз:
Ике дә гашыйк бергә килсә,
Һич булмайдыр, жаный, үпкәсез.

Беләзекләрең бөгелмә,
Бөгелмәдин килгән түгелме?..
Сөямен диеп әйтәсең,
Сөюләрең хәйлә түгелме?

Сикереп атка менгәндә
Камчыларым төште, ал, жаный,
Сәнең хафаңдин офтанамын,
Бу эшләрдин инде кайт, жаный!

Бу чагында талир тәңкә
Бер сум егерме биш тиен;
Үз дигәнем булмагач,
Җатлар берлән нишлием?!.

# Төрле җырлар

Төрле кулъязмалардан чүпләнгән дүртьюллыклардан кайбер үрнәкләр (КДУ. №№ Т. 2375, Т. 2385, Т. 2368 һ. б.).

* * *

Агач та башы ак мамык,
Нинди генә кошның оясы?
Ике дә гашыйк кавышса —
Оҗмах булыр, җаный, дөньясы.

Агач та башы каләнфер,
Җанкай, сәңа сәламдер.
Бу сәламләремне алмасаң,
Гыйшык тотуларың хәрамдер.

Атланган атым Дөлдел тик [1],
Бохардин килгән былбыл тик;
Сән җанкәй исемә төшкәч,
Бер сәгате була бер ел тик.

Биек тауның башында
Алтын багана урыны бар.
Сән җанкәем йөзендә
Йосыф пәйгамбәр нуры бар.

Ишек алдында яшел чирәм,—
Каз бәбкәсенең азыгы.
Үз китабымда үзем күрдем —
Гыйшык тотуның юктыр языгы.

Йосыф илән Зөләйха
Кавыштылар Мисыр илендә,
Сән җанкәемне бән телимен
Сәҗдәләргә киткән йиремдә.

Каз канатлары — хат, җаный,
Ир канатлары — ат, җаный.
Сәнең дә күңелең әллә ничек,
Бәнем сәүгәнләрем — хак, җаный.

Кара савыты ясадым
Фиргавен дигән тирәктин,
Әй, җанкәем, гыйшкың каты,—
Мәхшәр көнсез китми йөрәктин.

Кашың да кара Зөлфөкар [2]
Керпек асларындин гөл тама.
Гөл тамган керпек асларындин
Ихлас күңелең илән бер кара!

---

[1] Дөлдел — хәзрәт Гали атының исеме.
[2] Зөлфөкар — хәзрәт Гали кылычы.

Кызарып кояш чыкканда
Шәүләләре төшә дингезгә.
Ике жиңең сызганып
Кайчан хезмәт итәсең безгә?..

Мәдрәсәдә язу язганда
Кояш кына төште битемә.
Бал-шикәр каптым — йоталмадым,
Шул жанкәй төште исемә.

Мәдрәсәләрнең почмагы —
Бу дөньяларның оҗмагы.
Икенче оҗмах шул булыр —
Шул жанкәйнең кочагы.

Су буйларында ике сал,
Берсе генә каен, берсе тал,
Бән әйткәнгә, жаный, ышанмасаң,
Йосыф китабиндин гыйбрәт ал.

Талиблар[1] алтын табыптыр,
Ак кәгазьләргә салыптыр,
Гыйшык та тоту гаеп түгел,—
Йосыф-Зөләйхадин калыптыр.

Укый торган китабымның
Бит кенә саен фасылы.
Безнең жанкәйне сорасаңыз —
Йосыф-Зөләйханең нәселе.

Чыктым былбыл тотарга,
Былбылым очты Бохарга.
Сыйфатың язып алыр идем
Күз алдымда гына тотарга.

Жефәктин түмә түәрмен,
Хак бирсә лә жефәк киярмен.
Ходай ла язып ала калсам,
Яшь угландин артык сүәрмен.

Һилалә охшый кашларың,
Инжүя охшый дешләрең...[2]
Алла разый булсын, жанкәем,
Мин дигәнчә булган эшләрең.

Һавадин очкан аккошның
Тамагы ла туймый сайрамый.
Шушы авылларда бер матур бар —
Никах укымыйча ярамый!

[1] Талиб — шәкерт, студент.
[2] Бу ике юл «Йосыф китабы»ннан үзгәртеп алынган. Һилал — ай, инжу — энже.

**Камил Дәүләтшин**

# ЧОРЛАР АША

**Мәүла Колый әсәрләренең язылуына 300 ел тулды. Аның шигырьләре татар халкы арасында гасырлар буе кулдан кулга, мәҗмугадан мәҗмугага күчә килгән. Шагыйрь хикмәтләренең күчермә нөсхәләре халыкта әле дә саклана.**

**Хикмәтләрнең кайда һәм кайчан иҗат ителүе турында шагыйрь болай ди:**

Мөхиб[1] дуслар, бу хикмәтне әймеш көндә
Сиксән ел ирде ул көн тарих мең дә[2].
Әйтелде шәһри Болгар кәндләрендә[3],
Гасый[4] җаны Мәүла Колый сүзли, дуслар.

**Шагыйрьнең йөзгә якын хикмәте (3700 шигъри юл) тупланган кулъязма җыентыкны 1925 елда Татарстанның Зәй-Каратай авылыннан Фазыл Туйкә тапкан иде. 1969 елның җәендә исә Мәүла Колый хикмәтләре теркәлгән, әлегә кадәр билгесез яңа бер мәҗмуга табылды[5]. Аны СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына Мөгаззәмә Гатауллина тапшырды. М. Колыйның берничә шигыре теркәлгән өченче бер кулъязма китап Ленинградның Көнчыгышны өйрәнү институты китапханәсендә саклана. Бу мәҗмуганың да Татарстанда төзелгән булуы мәгълүм.**

**Мәүла Колый хикмәтләренең XVII йөз татар әдәбияты тарихын өйрәнү өчен бердәнбер әдәби истәлек, «иң кыйммәтле тарихи-әдәби материал» булуын беренче тапкыр проф. Г. Сәгъди билгеле[6]. Шул еллардан башлап шагыйрьнең хикмәтләре төрле әдәби җыентыкларда, урта мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен чыгарылган дәреслекләрдә басыла килә. Алар шулай ук рус теленә дә тәрҗемә ителделәр.**

**Мәүла Колый әсәрләренең табылуы татар әдәбияты тарихында яңа сәхифә ачты. Шагыйрьнең бай поэтик мирасы тулы бер дәвер әдәбияты турында фикер йөртү мөмкинлеген бирде. Ул — XVII гасыр татар әдәби хәрәкәтенең тарихи-иҗтимагый эчтәлеген, әдәбиятның үсеш юлын билгеләүдә кыйммәтле чыганак. Мәүла Колый иҗатына, табигый, җитди каршылыклар хас. Аның әсәрләрендә дөньяви, прогрессив идея-**

[1] Мөхиб — кадерле, якын.

[2] Миладн ел исәбе белән 1670 елга туры килә. Язылу елы күрсәтелгән юллар Ленинград нөсхәсеннән алынды. Башка мисаллар Ф. Туйкә тапкан кулъязмадан китереләчәк.

[3] Кәнд — ныгытма, крепость.

[4] Гасый — гөнаһлы.

[5] Мәҗмугага теркәлгән хикмәтләрнең М. Колыйныкы булуын Ш. Абилов билгеләде.

[6] Кара: «Вестник научного общества татароведения» журналы. 1927 ел. 7 сан. «Новый материал по истории татарской литературы» исемле мәкалә.

лар белән дини-мистик, реакцион тәгълиматлар каршылыгын күрү читен түгел. Шагыйрьнең каршылыкларын ул яшәгән чордагы иҗтимагый тормышның катлаулы каршылыклары белән бәйләп караганда гына дөрес аңлатырга мөмкин.

В. И. Ленин Лев Толстой турындагы хезмәтендә болай дигән иде: «...Толстойның карашларындагы һәм тәгълиматларындагы каршылыклар очраклы күренеш түгел, бәлки XIX йөзнең соңгы 30 елында рус тормышындагы каршылыклы шартларның чагылышы»[1]. «Толстой әсәрләрендә нәкъ шул крестьян масса хәрәкәтенең көче дә, йомшаклыгы да, куәте дә, чикләнгәнлеге дә гәүдәләнде»[2].

Россия тарихында XVII йөзне буйдан-буйга халык кузгалышлары тутырып тора: И. Болотников җитәкчелегендәге 1606 елгы восстаниегә Зея күтәрелеше ялгана. 1609 елда вотяклар һәм чебоксарлылар күтәрелә. 1648—1660 елларда Мәскәү, Псков, Новгород кебек шәһәрләрдә әледән-әле һөнәрчеләр кузгалышы булып тора. 1662 елда башкортлар корал ала. Бу кузгалышларның кульминацион ноктасы булып Степан Разин җитәкчелегендәге крестьян восстаниесе тора (1669—1671 еллар). Сакланып калган тарихи документларга караганда, Идел буе халыклары XVII йөздәге крестьян восстаниеләренә актив катнашканнар. Әлбәттә, татарлар да бу вакыйгалардан читтә калмаганнар. Мәүлә Колыйның крестьян күтәрелешләренә булган мөнәсәбәтен төгәл билгеләү кыен. Ләкин аның урыны шул заман татар укымышлылары арасында булган дип уйларга кирәк. Аларның «укымышлы» дигәне дә хәзерге мәгънәдә түгел, ә «дини өйрәтмәләрне яхшы белүче» дигән мәгънәдә. Бу төркемнең иҗтимагый даирәсе тар, зур тарихи вакыйгаларга мөнәсәбәте, күбесенчә, пассив. Шулай да болар милек-мөлкәт һәм конкрет биләгән урыннары, башкарган эшләре ягыннан барысы да бертигез булмаган. Аларның иң түбән торганнары халык арасында, гади тормыш-көнкүреш белән яшәгән, халыкка якын торган. Мәүлә Колый да шушындыйларның берсе булса кирәк. «Укымышлы» буларак, аның дөньяга карашы дини-мистик өйрәтмәләрдән азык алса, тормышның үз шартлары аңарда бүтән тойгылар, бүтән уйлар тудырган. Аның каршына дөньяви мәсьәләләрне китереп куйган. Күңелендә туган сорауларга җавап эзләп, ул суфичылыкка мөрәҗәгать итә. Бусы да бик чуалчык өйрәтмә, ул да хорафат, мистика белән тулган. Мәсьәләләрне ул да хәл итеп, чишеп бирми.

Белмән үзем — канда мән;
Юл таба алмаз чүлдә мән,—

ди шагыйрь.

Болар шагыйрь күңеленең тынгысызлыгын, хакыйкать эзләүдә тукталамавын күрсәтәләр. Суфичылык өйрәтмәсе белән тормыш таләпләре арасындагы конфликтны ул яхшы ук ачык чамалый.

Нәфсе дөнья гыйшкы белән әвәрәдер[3],
Бу күңел йиңә алмыйдыр, нә чарадыр...
Нәфсе юлы берлә йөреп булдым хәстә,
Нәтәк[4] аны уңартаем?[5] — дару юктыр.

«Күңел» — илаһи як, «нәфсе» — дөньяви як, шагыйрьнең рухи дөньясында шул ике көч көрәшә. Шушы аның үзен һәм иҗатын каршылыклы ясый. Хәзерге укучы өчен, әлбәттә, аның иҗатында дөньявилык тенденциясе өстенлек алган моментлар әһәмиятле. Шагыйрьнең хикмәтләр җыелмасыннан шәхес күңелендәге катлаулы психологик кичерешләрне һәм аның рухи дөньясындагы кайбер үзгәрешләрне күрә алабыз. Мәсәлән, шагыйрьнең бер хикмәтендә әле уянып та җитмәгән мәхәббәт хисләре турында әйтелә. Икенчесендә исә бу хисләрнең өлгергән булуын тоябыз. Ә өченчесендә инде шагыйрьнең лирик герое — мәгъшукасы белән күрешү турында уйлап яшәүче зат, «мәхәббәт бәхеренә» чумган дәрвиш, мәҗнүн. Моңардан безнең алга, гади генә булса да, кеше рухиятенең эволюциясе, үсү һәм үзгәрү картинасы килеп баса. Ша-

---

[1] Ленин әдәбият турында. Казан. 1960 ел. 13 бит.
[2] Шунда ук, 18 бит.
[3] Әвәрә — бер нәрсәгә бирелеп китү.
[4] Нәтәк — ничек.
[5] Уңартаем — сафлыйм, төзәтим.

хес күңелендәге төрле рухи халәтне тасвирлаган хикмәтләрне бер җепкә тезеп бирү нәтиҗәсендә шагыйрь зур полотно тудыра алган.

Мәула Колый әсәрләренең идея эчтәлеге турында фикер йөрткәндә, аның иҗатыннан аерым бер хикмәтне алып анализлау һәрчакта да көтелгән нәтиҗәне бирмәскә мөмкин. Чөнки алар, аерым-аерым мөстәкыйль әсәр булсалар да, үзара тыгыз үрелгәннәр һәм органик бәйләнештә киләләр. М. Колый хикмәтләренең үзәгендә килешә алмас каршылыкка нигезләнгән конфликт тора. Аның әсәрләрендәге тормышчанлык, дөньявилык мотивлары дини-суфичыл идеяләр белән үзара бәрелешәләр. Шушы нигездә лирик герой күңелендә дөньявилык һәм илаһият, ягъни тормыш таләпләре һәм дини идеаллар арасында кискен конфликт туа. Безнең өчен шунысы кызыклы: күңел көрәшендә еш кына дөньяви таләпләр — нәфсе җиңеп чыга. Мәсәлән:

Бу нәфсе шомлыгындин тикде зарар,
Хак эшендин ерак кылды, хәсрәтем чук[1].
Нәчә әйтсәм, хак эшендин алмаз хәбәр,
Нәтәен, нә кылаен, гыйлем юкдыр.
Нәфсе кяһил[2] хак эшендин биздерүбдер,
Хак юлындин үз юлына яздырубдыр.
Дөнья гыйшкын куа-куа аздырубдыр,
Нәтәен, нә кылаен, гыйлем юктыр.

Җирдә яшәп, тормыштан, дөнья мәшәкатьләреннән аерылып булмый. Киресенчә, тормыш көннән-көн кеше алдына яңа таләпләр куя. Шагыйрь үзе дә моны танырга мәҗбүр.

Гөнаһ тагы күкрәкдә тулукланды,
Тәкәбберлек ботаклары олукланды,
Көне-көндин бу дөньяга гашыйкланды,
Бу күңелдә хакны эстәр[3] чынлык юкдыр,—

дип яза Мәула Колый.

Шагыйрьнең нәфсе һәм күңел көрәшен чагылдырган хикмәтләрендә лирик геройның рухи дөньясы ачыла. Аның уй һәм кичерешләре, фикер, тойгылары күп төрле каршылыклары белән күрсәтелә. Алар шул чорның билгеле иҗтимагый төркеменә характерлы да. Шагыйрь бу каршылыкларның иҗтимагый асылын, әлбәттә, аңлый алмаган. Ул шәхес күңелендәге каршылыкларны кешенең табигатенә, «яратылганда» үк бирелгән сыйфатларына бәйләп аңлата. Мәсәлән, нәрсә ул күңел һәм нәфсе! Шагыйрь болай дип җавап бирә:

Бу күңел бер егетдур, бер нур торур,
Нәфсе гөлдур, туфрак булып йирдә черүр.

Суфилар уенча, нур һәм туфрак — табигатьләре белән һич тә үзара килешә алмаслык матди нәрсәләр. Нур һаман югарыга омтылса, туфрак һәрвакыт түбәнгә, җиргә тартыла һ. б. Гомумән, кеше дүрт төрле капма-каршы сыйфатлы матди элементтан төзелгән дип уйлый Мәула Колый.

Бу адәмне хак туфракдин төзеде, бел,
Ут билә суны кушды һәм тәкый йил.
Бу дүртедин адәм булдың, гакылга кил,
Бу дүрте төзекдә эш кыла күргел.

Күренә ки, шагыйрь фикеренчә, кеше күп төрле сыйфатларны берләштергән. Аның күңелендәге бәхәс һәм каршылыклар, эзләнүләр һәм тынычсызлык әнә шул дүрт элементның капма-каршылыклы үзенчәлекләренә бәйләнешле дә инде:

Бер көн булып, аерылмак вәгъдә тиккәй,
Уты утка, суы суга янә киткәй.

---

[1] Чук — күп.
[2] Кяһил — ялкау.
[3] Эстәү — эзләү.

Йиле йилгә китеп, бу тән каушап яткай,
Тән төзекдә яраклыг эш кыла күргел.

Бу юллар аерата кызыклы: шагыйрьнең әсәрләрендә ерак-еракларданbик борынгы заманнардан ук килгән фикер һәм шигърият традицияләре аваз бирә. Деньяның нигезе дүрт элементтан тора дигән өйрәтмә безнең эрадан күп йөз еллар элек барлыкка килгән. Аның ул заманнарда бигрәк тә Һиндстанда популяр булуы мәгълүм. Соңрак ул борынгы грек философиясенә дә кергән. Без аны урта гасырлардагы прогрессив фикер ияләрендә, Гомәр Хәйям, Низами, Әбуғалисина әсәрләрендә очратабыз. Һәм менә, ниһаять, ул XVII гасырда М. Колый шигырьләреннән яңгырый. Моны шагыйрь карашындагы бер уңай момент димичә мөмкин түгел. Монда стихияле материализмга тартымлы тенденция бар.

Мәүла Колыйның тормышта хакыйкать эзләве еш кына ачы нәфрәт тойгысы аша ачыла. Ул хакыйкать көткән нәрсәләрдә, гаделлек иясе дип инанган затларда кинәт ялган, алдау, икейөзлелек булуын ачып ташлый, рәхим-шәфкать, мәрхәмәт, кечелеклелек иясе дип уйланган кешеләрдән ачкүзлелек, бозыклык, канга сусаган ерткычлык ярсып торуын фаш итә. Бу сыйфаты аның бигрәк тә кыйммәтле. Ул йөзенә диндарлык битлеген каплаган суфи-ишанның портретын, рәхимсез детальләр кулланып, бер-ике авыз сүз белән онытылмаслык төстә рәсемләп ташлый:

Габа[1] кияр, үз-үзени суфи белур,
Тешен көүләр[2], янларына мисвәк[3] өйләр.
Фәкыйрь-мескен мөэминнәргә зарар кылур,
Рәхим кылмаз, башын куйса печәр[4] ирде.

Мондый ханжаларга карата аның ярсулы нәфрәте ташып тора:

Башларына таҗ күтәрмеш, суфи мән тир,
Тәнләрени симерткәнчә хәрам йияр[5],
Ихласы юк, галәм халкын алдаю, күр,
Күңле туймаз, бу галәмне йотар ирде.

Әлбәттә, шагыйрьнең теләге — «ихлассыз», алдар суфиларны гына тәнкыйтьләү. Әмма авторның субъектив карашына чынбарлык шундый нык тәэсир иткән ки, нәтиҗәдә шагыйрь комсыз, кеше хакын ашап симерүче суфи образын койган да куйган. М. Колый иҗатының кызыклы һәм үзенчәлекле ягы да шунда: ул, суфи шагыйрь булып, суфизм поэзиясенең традицион темаларына мөрәҗәгать итә һәм үз карашларын үткәрергә омтыла, ләкин аның талант көче коры тәгълиматлар, вәгазь-нәсихәтләр чигеннән чыгып китә. Аның хикмәтләре тормыштан алынган күренешләр, җанлы кичерешләр белән сугарыла. Мәсьәләгә бу яктан якын килеп карaганда, шагыйрьнең игенче хезмәтенә дан җырлаган шигырьләре аеруча әһәмиятле. Игенче хезмәте өлгерткән һәр кавым ипинең әһәмияте бер колны азат итү хәтле, ди шагыйрь:

Игенчеләр туфрак үзә[6] иген иксә,
Кош-корт, хәйван, адәм-һәркем андин йисә;
Игенчегә андаг сәвап, белүр ирсә,
Һәр локмәгә бер кол азат кылур булсаң.

Әгәр кеше игенчелек белән шөгыльләнә икән, бу хезмәтнең кыйммәте бөтен дөнья күләмендә үлчәнә, хәтта дини аерымлыклар да бу очракта беренче планда тормый, ди автор. Мәүла Колыйның гади кешеләргә булган мөнәсәбәтен «гарипләргә» багышлап язган хикмәтендә дә күрәбез. Шагыйрь бу хикмәтне: «Хак бирмәсен һичбер кемгә гариплекне»,— дип башлап җибәрә. Хикмәтнең шушы фикер белән башлануы ук бу шигырьнең суфичылык тәгълиматыннән шактый аермалы булуы турында сөйли.

---

[1] Габа — өске йон кием.
[2] Тешен көүләр — тешен кара төскә буяр.
[3] Мисвәк — теш чистарту өчен үзенә бер төр агачтан ясалган таякчык.
[4] Печәр — кисәр.
[5] Йияр — ашар.
[6] Туфрак үзә — туфрак өстендә.

Мәүла Колый гарибе конкрет җирлеккә бәйләнгән һәм аның мондый хәлгә төшүе шәхси ихтыярдан да, кешенең табигатеннән дә түгел. Моңа рәхимсез тормыш гаепле. Без аның иҗтимагый хәлен дә хикмәтләрдән ачык тоя алабыз:

Гарипләрне һичбер адәм алмаз санга,
Аш йиярсә, ләззәт бармаз һәргиз[1] җанга;
Мәканлылар миһманлашыр[2] тиңле тиңгә,
Гарипләр моң-зар булып торур иркән.

Шагыйрь хәерчеләрнең көнкүрешләре искиткеч авыр булуын, хәтта башларына әҗәл килсә, тыныч кына ятып үләрлек урыннары да юклыкны тирән теләктәшлек, үкенеч тойгысы белән тасвирлый. Бу мескеннең дөньяда бер ялгызлыгын, миһербансыз заманада аңар ярдәм кулы сузарга бер генә затның да булмавын ачынып яза:

Гарипләргә тормага йорт — мәкан кани?
Баш агырса әҗәл йитәр, куркар җани.
Оруг-кардәш кыла алмаз сәне гани[3],
Гариплектә үлүм килсә дөшвар[4] иркән.

Мәүла Колый, үзенә мөрәҗәгать итү формасында хикмәтенә йомгак ясап, болай ди:

Мәүла Колый, гарипләрнең халэн сорсаң,
Хален сорап, гарипләргә шәфкать кылсаң,
Кулда барын биреп күңлен хушнуд[5] кылсаң,
Изем рәхман[6] сәндин хушнуд булыр иркән,

Мәүла Колыйның гарипләр турындагы хикмәтенә таянып шуны әйтергә була: шагыйрь бу әсәрендә кыерсытылган ярлы халык вәкилләренең канлы яшь түгүен чагылдыра алган. Чөнки шагыйрь үзе дә тормыштан аерылган ниндидер дәрвиш-аскет булмыйча, ватандашларының аһ-зарын күреп, тоеп яшәрлек актив шәхес булган.

Мәүла Колыйның кыерсытылган-кимсетелгәннәрне яклавы аеруча аның этик карашларында ачык сизелә. «Үзе бирми, үзгәләрдән тамигъ итү»[7]челәрне шагыйрь тәнкыйтьли:

Алма кеше малыни тартып-орып,
Чәйнәмә аны агзыңа алып, тултырып,—

ди ул.

Мәүла Колыйның этик карашлары бары тик дини өйрәтмәләргә генә нигезләнгән дип карау да берьяклы булыр иде. Чөнки әхлак нормалары кешелек җәмгыятенең аерылмас өлеше һәм халык тормышына бәйле рәвештә үсә-үзгәрә тора. Мәүла Колыйның әдәп-әхлакка булган мөнәсәбәте, дини-аскетизм буявына манчылган булса да, асыл эчтәлеге белән тормышчан. Мәсәлән, ул «укымышлы» кешеләрне, «галимнәрне» мактый. Әмма галим булуның төп шарты итеп гыйлемлекне генә куймый. Галим булган кешедә иң беренче чиратта кешелекле сыйфатлар булырга тиеш, ди ул. Шагыйрь аеруча мин-минлекне рәхимсез тәнкыйтьли, үзен-үзе генә яратучы тыйнаксыз, мактанчык кешеләрнең «галим» булу ихтималын шик астына ала. Галим кешенең иң зарури сыйфаты итеп, башка кешеләргә ярдәмчел булуны саный:

Галим мән тип, дәһер ара[8] күксен[9] кирүр,
Хакны белмәз, мәэминнәргә зарар тикрүр,

---

[1] Һәргиз — һәрвакыт, һичбер вакыт.
[2] Миһманлашыр — кунак булышыр.
[3] Гани — бай.
[4] Дөшвар — авыр, кыен.
[5] Хушнуд — шат.
[6] Изем рәхман — рәхимле тәңрем.
[7] Тамигъ итү — кешедән өмет итү, ачкүзлелек.
[8] Дәһер ара — заман, матди дөнья.
[9] Күксе — күкрәк.

Галәм халкын күзгә алмаз, мән-мән тиүр,
Кани[1] галим? Ихсан кылур[2] кулы юкдыр.

Шагыйрь иҗатында дуслык һәм иптәшлек, кардәшлек һәм ярдәмчеллек, юмартлык һәм киң күңеллелек кебек сыйфатларга аерым игътибар итеЛә. Ул кешедә шундый якларның җиңүен тели. Бик борынгы чорлардан ук билгеле булган традицион кардәшлек төшенчәсен шагыйрь үз заманы күзлегеннән үткәрә, аңар бөртек-бөртек яңалык өсти. Ул икейөзлелек, комсызлык, дәрәҗә сөю кебек сыйфатларны әхлакый бозыклык дип саный.

Гәрчә аның иҗатында капма-каршы фикерләр, дини-суфичылык догмалары урын алган булса да, бу хәл шагыйрь әсәрләренең әдәби-тарихи кыйммәтен юкка чыгара алмый. Чөнки Мәүла Колый гасырлар буе кеше акылын борчыган мәсьәләләргә мөрәҗәгать итә, аларны гуманистик планда хәл итәргә омтыла. Заман өчен алдынгы саналган әхлак нормаларын алга сөрә, борынгыдан ук килгән мәңгелек проблемаларны күтәрә, аларны үзенчә поэтик эшкәртеп, замандашларына җиткерә.

Мәүла Колый иҗатының татар әдәбияты тарихында тоткан урынын билгеләү ул күтәргән әһәмиятле дөньяви тормыш мәсьәләләренә, этик проблемаларга гына кайтып калмый. Ул төрки халыклар әдәбиятының гасырлар буе туплана килгән шигъри хәзинәсенә дә өлеш кертә алган. Мәүла Колыйның шигъри осталыгы аеруча аның лирикасында күренә. Шигырьләрнең форма ягыннан төгәл эшләнгәнлеге һәм эчтәлек белән ярашуы шагыйрьнең зур художник булуын дәлилли. Шагыйрь сурәт чараларын бик уйлап сайлый: һәр сүзнең, һәр бизәкнең күп төрле төсмерләрен тирән аңлап эш итә. Мәсәлән, «мәхәббәт» хисләре белән тулы күңелнең ярсып ташуын градация ярдәмендә түбәндәгечә тасвирлый:

Мәхәббәт гыйшкы берлә күңелә ташса,
Гыйшкъ уты илә көеп, янып, кайнап пешсә,
Җәзебә улып[3], үзен белмәй җандин кичсә,
Хак зикерен әйтмаклыкта агзы талмас.

Мәүла Колый чагыштыруларны төрле мәгънәви функцияләрә һәм мөмкинлекләреннән чыгып куллана:

Яз көнендә болыты аз, чуак[4] була,
Егет кеше кайгусы юк, даим көлә.
Карый кеше[5] мисле[6] һаман кыш тик була,
Шул сыйфатлы гомре кечәр кодрәт берлә...
Кыз вә углан рәушан торур якты көндин
Ата-ана ләззәтлектер шәкәр-балдин...

Күренә ки, шагыйрь чагыштыруларны тышкы охшашлыкларга нигезләп тә, эчке сыйфатлар берлегенә таянып та таба белә. Бер очракта бу охшашлыклар күзгә күренерлек булсалар, икенче шигырьдә алар чагыштырыла торган күренешләрнең функцияләрендәге эчке берлеккә кайтып кала. Аның әсәрләрендә эчке һәм тышкы сыйфатлар тәңгәллегенә нигезләнгән чагыштырулар шактый күп. Мәүла Колый бу шигъри чараның тасвир мөмкинлеген тирән сиземли һәм символларга бай чагыштыруларны бик теләп куллана. Мәсәлән, былбыл кош, гәүһәр символлары. «Былбыл кош» моңлы шагыйрь мәгънәсендә кулланыла, ә «гәүһәр» сүзе чынлык, хакыйкать төшенчәсен бирә. Әлбәттә, мондый символларның еш очравы шагыйрьнең суфичылык поэзиясе үрнәкләре белән якыннан таныш булуыннан килә. Кайбер очракта тегe яки бу чагыштыруның нинди уртак билгеләргә нигезләнгәнлеген табу да кыен. Шагыйрь күңелне — егет, гыйлемне — күк, нәфсене — гөл, галимне — кояш, шәкертне ай белән тиңли. Ул монда беренче карашка һич тә уртаклыклары, тәңгәл сыйфатлары булмаган, бер-берсеннән гаять ерак торган күренешләрне ча-

---

[1] Кани — кая.
[2] Ихсан кылу — ярдәм итү.
[3] Җәзебә улу — гыйбадәттә шашу дәрәҗәсенә җитү.
[4] Чуак — аяз.
[5] Карый кеше — карт кеше.
[6] Мисле — кебек, төсле.

гыштыра сыман. Шагыйрьнең сурәт тудыру һәм тасвир чарапарын җентекләп күзәткәндә генә бу чагыштыруларның очраклы булмавы ачыклана. Алар искиткеч төгәл, киң мәгънә сыйдырышлы:

Гыйлемлек күккә охшар тәхсил кыйлсаң,
Наданлык дөнья кебек гакыйл ирсәң...

Шагыйрьнең образлы фикерләве белән дөньяга карашы тыгыз бәйләнештә булуы бу хикмәт мисалында бигрәк тә ачык күренә. «Гыйлемлек» күккә охшый. Чөнки ул җир кешесенә «илаһи рәхмәт кебек үк кирәкле». Галим исә шул күкнең кояшы, нур сибүчесе:

Галимнәр күк йөзендә көнәш яңлыйг [1],
Шәкертләр тулып торган айга яңлыйг...

Мәүла Колыйның шигъри бизәк чараларыннан оста файдалануы үгет-нәсихәткә багышланган риторик юлларны да эмоциягә бай, тәэсирле итә алган. Шагыйрь халык иҗатында гасырлар буе шомартыла килгән бизәк чараларын, даими метафораларны да бик урынлы куллана:

Нәфсе хакны танумаз, гөнаһ кылур арымаз,
Нәфсе шомың хәҗәләтдин [2] хәсрәт утын йотарум.

Кайбер метафоралар әдәбиятта бик еш кабатланалар, шуның нәтиҗәсендә аларның эмоциональ тәэсире кими. Мәүла Колый мондый поэтик бизәкләрнең кулланыш сферасын киңәйтә, үзгәртә. Бер очракта ул халык авыз иҗатындагы әзер сурәт мөмкинлекләреннән файдалана. Мәсәлән, комсыз суфиның мал өчен теләсә нинди кабахәтлектән дә тартынмавын күрсәткәндә:

Үзе бирмәс, үзгәләрдин тамигъ итәр,
Мал өчен канын суча эчәр ирде,—

ди.

Ә инде гашыйк кешенең йөрәгендәге ялкын куәтен күрсәтү өчен әзер мөмкинлекләр белән генә чикләнми:

Гашыйк кеше хакга лаек булса кәрәк,
Мәхәббәтдин күңле аның тулса кәрәк.
Зөләйха тик йөрәгендә ут янса кәрәк,
Аһ итмәктә җиһан милке көяр улур.

Мәгълүм булганча, Кол Гали әсәрендә Зөләйханың сөю ялкыныннан Йосыфның камчысына гына ут каба:

Йосыф аңа камчысын сону вирде,
Бер аһ кылды, Йосыфә киру вирде.
Камчысына ут тоташмыш янар улды,
Чүбеннән [3] Йосыф әлен көйдерер имди [4].

Мәүла Колый хикмәтендә исә сөю ялкынының кызуы бөтен җиһан милкен көйдерер дәрәҗәгә үстерелгән. Монда да шагыйрьнең дөнья милкенә булган мөнәсәбәтендә суфичылык йогынтысы ачык сизелә, сурәтләү чараларының очраклы гына сайланмаган булуы күренә. Шагыйрь төрле әдәби жанр белән иркен эш итә. Аның иҗатында: хикмәт [5], мәдхия [6] һәм мәрсия [7] кебек төрләрнең шактый кызыклы үрнәкләре бар. Мәүла Колыйның әдәби традицияләрне иҗади үзләштерүе, җиңел аңлаешлы телдә язуы — XVII йөз әдәбияты өчен гаять әһәмиятле күренеш. Мисал өчен Мәүла Колыйның әлегә кадәр матбугатта басылмаган бер шигыре тәкъдим ителә.

---

[1] Көнәш яңлыйг — кояш кебек.
[2] Хәҗәләт — оялу.
[3] Чүбеннән — сабыннан.
[4] Борынгы татар әдәбияты. Казан. 1963. 139 бит.
[5] Хикмәт — дидактик поэзиянең бер төре. Акыллы сүз, акыллы сөйләм. Бу урында: шигъри сөйләм, шигырь мәгънәсендә.
[6] Мәдхия — лирик поэзиянең бер төре. Мактаулы шигырь, ода.
[7] Мәрсия — үлгән кешенең яхшы сыйфатларын күрсәтеп сөйләгән сүз яки шигырь (элегия).

Монча еллар көттем ярны килгәйму тип,
Мән аныклә, ул мәнемлә булгайму тип.
Әсиргәп[1], мәнем халем соргайму тип,
Имде белдем мәндин качар хыялый яр.
Яр миңа килмәк идең, килмәдең сән,
Хәсрәтеңдә кәбаб[2] булдым, белмәйсен сән,
Дәрдең берлә ахыр чыкар бу газиз җан,
Имде белдем: мәндә сәнең шөбһәң бар.
Күңел сәндин аерылмайдур, нә кылаен?
Сәнең миңа ни хыялың, нә белаен?
Кабул кылгыл, әшгалыңда[3] кол булаем,
Белмәз эшем күрерсең, куәтең бар.
Мәне кабул әйлә, ярым, булмаз бизар[4].
Бу көн узмаз, гомер бездин имде узар.
Эчем-тышым хәсрәт уты, еглаймын зар,
Имде тәндин газиз җаным чыкары бар.
Мәүлә Колый, зарланасың имде монча,
Хезмәтеңдә тормадың сән, яр дигәнчә,
Ни әсигъ[5] бар, буш зарланып гомер кичә,
Рәхим әйләп, ярың сәне кылмасын зар.

Мәүла Колый әсәрләренең чорлар аша үтеп, безнең әдәбиятка килеп кушылган ноктасы — дөньяви тормыш турында уйлануларда, поэтик әсәрнең үзәгендә торган героеның тормыш кешесе булуында, ул геройның катлаулы һәм гаять каршылыклы кичерешләрен, рухи дөньясын сурәтләүгә омтылуда. Бигрәк тә материаль байлыкның чын хуҗасы һәм аны тудыручы хезмәт кешесе — игенче хезмәтенә мәдех әйтүендә.

Моннан өч гасыр элек яшәгән шагыйрьнең поэтик мирасын нәкъ шушы сыйфатлары өчен зур ихтирам белән искә алабыз да.


Шакир Абилов

# МӘҮЛА КОЛЫЙ ХИКМӘТЛӘРЕНЕҢ ЯҢА КУЛЪЯЗМАСЫ

1969 елның җәендә пенсионерка Мөгаззәмә ханым Гатауллина әтисеннән калган борынгы кулъязма китапларны Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына бүләк итте. Ул тапшырган китаплар арасында, башка кыйммәтле әсәрләр белән бергә, Мәүла Колый хикмәтләре теркәлгән бер мәҗмуга да бар иде. М. Гатауллинаның сөйләвенә караганда, әлеге мәҗмуга аның әтисе Кизләү мәдрәсәсендә укыган вакытлардан ук сакланып калган икән. Шуңа күрә, уңайлык өчен, без аны «Кизләү кулъязмасы» дип йөртергә булдык[6].

Кулъязма китап 42 кәгазьдән, ягъни 84 биттән тора. Кайбер битләре аксыл көрән, икенчеләре күк көрән төстәге кара белән язылган. Ул нигездә дүрт кеше тарафыннан

[1] Әсиргәп — кызганып.
[2] Кәбаб — куырдык, куырма.
[3] Әшгалыңда — йомышларыңда, эшләреңдә.
[4] Бизар — алтыраучы, интегүче.
[5] Әсигъ — файда.
[6] СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты архивы. 39 коллекция, 48 саклау берәмлеге.



*Мәүла Колый хикмәтләренең Кизләү кулъязмасыннан үрнәк, 15 бит кәгазь.*

күчерелгән. Башкача әйткәндә, аерым-аерым язылган дүрт китапны ахырдан кемдер бергә тупланган. Моның шулай икәнлеге кәгазьнең төрле сыйфатлы булуы да һәм бер үк хикмәт юллары язылган битләрнең төрле урыннарда тегелүе дә күрсәтеп тора. Төпләм өч кат алача киндер белән һәм иң өстән чәчкә бизәкле иске ситсы белән тышланган. Күчерелгән вакыты яки урыны күрсәтелмәгән, моны кәгазь буенча да белү кыен. Су билгеләре юк. Җыентыкның гомуми күләме 12×19,5 см зурлыгында, текст язылган өлеше төрле зурлыкта.

Җыентыкта Шәмсе Кәминә (Шәмсе Гасый, Шәмсетдин Үзгәнди), Кол Сөләйман (Бакыргани), Солтан Хөббн (Сөләйман Бакырганиның улы), Кол Габиди (Кол Гобәйди) хикмәтләре, Әшраф углы Руми шигырьләре һәм Локман исемле берәүнең «Хикмәте Мәҗнүн» исемле кейле әсәре бар. Боларның Локман исемлесеннән башкалары төрки әдәбиятларда исемнәре билгеле шагыйрьләр. Габиди (Гобәйди)нең шигырьләре элек татарлар арасында күп таралган булган, аның теле дә татарныкына бик якын. Шуларны искә алып булса кирәк, Г. Сәгъди аны татар шагыйрьләреннән түгелме икән, дип яза [1]. Безнең уйлавыбызча, ул — үзбәкнең XVI йөздә яшәгән билгеле суфи шагыйре Гобәйдулла (Гобәйди) булырга тиеш. Үзенә күрә тәзкирә (антология) булып хисапланган бу җыентыкта күп урынны Мәүла Колый шигырьләре били. Барысы 13 хикмәт, 364 шигъри юл. Ун хикмәттә шагыйрьнең үзенә кабул иткән Мәүла Колы («алла колы») дигән әдәби кушаматы үк язылган, калган өч хикмәттә авторы күрсәтелмәсә дә, аларның да Мәүла Колыйныкы икәнлеге җиңел билгеләнә. Димәк, безнең алда шагыйрь хикмәтләренең моңа кадәр билгеле булмаган яңа бер күчермәсе.

Шулай итеп, хәзер безгә М. Колый хикмәтләренең өч күчермәсе билгеле. Яңа күчермә Ф. Туйкә күчермәсе һәм Ленинград нөсхәсе белән чагыштырулар ясарга, аерым урыннарны ачыкларга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, М. Колыйның төп җыентыгында «Мелла Мамай» турындагы хикмәт нигездә дүртәр юллы строфалардан тора. Арада:

---

[1] «Вестник научного общества татароведения» журналы. 1927 ел. 7 сан.

Остадым[1] хак гыйшкында тормыш иде,
Берничә көн ул мәҗлестә тордым, дустлар,—

диган ике юллысы да бар. Ләкин бу юллар арасында эчке бәйләнеш җитеп бетми, чөнки алдарак «ул мәҗлестә» дигәнне аңлатып килгән сүзләр булырга тиешлеге сизелә. Кизләү җыентыгында әлеге куплет дүрт юлдан тора.

Остадым хак гыйшкында тормыш ирди,
Мәдрәсә, мәктүпханә[2] кормыш ирди,
Җөмлә мөрит табигында[3] йөз ормыш ирди,
Берничә көн ул мәҗлестә тордым, дустлар.

Монда инде мәсьәлә шактый ачыклана төшә. Остазының мәдрәсә, мәктүпханә каршында мөритләр җыйнала торган булган; безнең шагыйрь дә шул мәҗлесләрнең кайберләрендә үзенең беркадәр вакытын уздырган икән.

Ф. Туйкә М. Колыйның 95 нче хикмәтеннән бер куплетны түбәндәгечә — беренче юлның яртысына һәм өченче юлга күп нокталар куеп киткән:

Юкдыр явыз (. . . . . . . . . . . . . .
Золым берлән языкымга һәм ниһайәт.
(. . . . . . . . . . . . . . . . . . . .)
Соруг булса, мән кол анда нә айгай мән.

Ул сүзләр җуелган булгандыр яисә, таушалганлыктан, аңлашылмагандыр. Кизләү кульязмасында юллар тулы сакланган:

Юкдыр явыз эшләремгә хәдде-гайәт[4],
Золым берлән языкымга һәм ниһайәт;
Садыр[5] булып һәр көн мәндин күп хыянәт,
Соруг булса, мән кол анда нә айгай мән.

Шагыйрь диванында юллары буталып яки яртылаш кына язылган куплетлар бер югарыдагы хикмәт белән генә чикләнми. Кизләү нөсхәсе андый урыннарны ачыкларга да өстәмә материал булып тора.

Үзенең 29 нчы хикмәтендә Мәүла Колый кеше гомеренең төрле вакытларын елның аерым фасылларына охшатып сурәтли. Анда шундый юллар бар.

Бу кыш көнне карыйлыкка[6] охшатадыр,
Тәмуг кебек суык кыйлур кодрәт берлә;
Мәхлүкатны ризык биреп кышлатадыр,
Бу галәмдин нигъмәтләрен бушатадыр.

Хикмәттәге калган куплетларда баштагы һәр өч юл үзара рифмалашып киләләр һәм дүртенче юл «...кодрәт берлә» дигән сүз белән тәмамлана. Өстәге мисалда исә, күргәнегезчә, шагыйрь кулланган алым бозылган, «кодрәт берлә» сүзе икенче юлның ахырында килгән. Кизләү кульязмасында бу юллар шигырьнең башка строфаларындагы шикелле үк:

Бу кыш көнне карыйлыкка охшатадыр,
Бу галәмдин нигъмәтләрне бушатадыр,
Мәхлүкатны ризык биреп кышлатадыр,
Тәмуг кебек суык кыйлур кодрәт берлә.

Кизләү нөсхәсе буенча шагыйрь хикмәтләрендәге аерым сүзләргә карата да ачыклыклар кертергә мөмкин. Мәсәлән, «Мелла Мамай» турындагы алда телгә алынган хикмәтнең беренче строфасына күз салыйк:

---

[1] Остад — остаз, өйрәтүче.
[2] Мәктүпханә — китаплар күчереп яза торган бина, үзенә күрә китап күчереп язучылар мастерское, мәктәп.
[3] Табигында — карамагында, аңа ияреп, буйсынып.
[4] Хәдде — гайәт — чиге-кырые.
[5] Садыр булып — барлыкка килеп.
[6] Карыйлык — картлык.

Рәхман изем[1] остаз **кулгын** ачмыш иркән,
Бернәчә көн анда җәүлан[2] кылдым, дустлар,
Гафиллектә[3] күзем сукыр карамакта
Остазымдин җеда[4] булып калдым, дустлар.

**Беренче юлдагы «кулгын» формасында язылган сүзне «кулмак»тан (сорауын, үтенечен) яисә «кулук»тан-«кулугын» дип тә укырга була. «Кулук» — баш уравыч, чалма. Ничек кенә уйласаң да, бу сүз тексттагы мәгънә серешенә бәйләнеп җитми. Ә хикмәтнең Кизләү һәм Ленинград нөсхәләрендә бу урында «капугын» сүзе тора. Капуг (капу) — капка (ишек) мәгънәсеннән тыш, сарай, мәҗлес (киңәш) урыны дигән төшенчәләрне дә аңлата. Болай булса, мәсьәлә аңлашыла төшә: остазының хозур сарайлары капкасы (ишекләре) ачылган да, шагыйрь шунда гизеп йөргән булган.**

**Мәүла Колыйның 20 хикмәтен тикшерик. Шагыйрь аны үзенең рухани һәм рухи җитәкчесенә — пиренә багышлаган. Һәр строфаның соңгы дүртенче юлы: «пирем углы Мәхдүми җан хәзрәте ишан» дигән сүзләр белән тәмамлана.**

Кытай, Кыпчак, Ясәү, Сауран[5] әүлядләре[6],
Даире[7] Болгар, Кирмин[8], Казан фәрзәндләре[9]
Булыр барча пиремезнең мөритләре,
Пирем углы Мәхдүми җан хәзрәте ишан.

**Соңгы юлдагы «углы» сүзе бөтен шигырьнең мәгънәсен үзгәртә. Сүз шагыйрьнең пире — җитәкчесе турында булмыйча, пирнең улы хакында бара булып чыга. Һәм «Мәхдүми»не аның исеме дип тә аңлап була... Чынлыкта исә шагыйрь үзенең пирен мактый һәм шигырь аңа багышланган да. Эш нәрсәдә соң? Кизләү нөсхәсендә «углы» сүзе «әгъля» формасында язылган. Шулай булса, ул «югары», «бөек», «яхшы», «затлы» дигән мәгънәне аңлата[10].**

**Кизләү кулъязмасының әһәмияте шагыйрь диванындагы авыр яисә төрлечә укырга мөмкин булган сүзләрне ачыклау белән генә чикләнми. Ул аерым хикмәтләрнең үзләре турында да сүз йөртергә нигез бирә. Без бирәдә Кизләү җыентыгындагы 9 хикмәтне күз алдә тотабыз. Анда 12 юл гына. Ул:**

Иреннәр мөхфилендә нур ягар сөхбәтендә[11],
Ни теләсә — ул булыр дәрвишләр сөхбәтендә,—

**дип башлана һәм:**

Мәүла Колый, тәүбә кыл, хикмәт әйтмәй хәлең бел,
Кол Гобәйди хикмәтен җандин гаҗиз тотарым[12],—

**дигән юл белән тәмамлана.**

---

[1] Рәхман изем — рәхимле аллам (таңрем).
[2] Җәүлан кылдым — гизеп йөрдем.
[3] Гафиллектә — гамьсезлектә.
[4] Җеда булып — аерылып.
[5] Өлкә исемнәре: Ясәү — Яссы, Сауран — Сайран.
[6] Әүлядләре — нәселләре.
[7] Бу сүз гарәпчә «дабды» формасында язылган, даире (даирә) дип укыйм: тирә, өлкә.
[8] Кирмин — хан Кирмән (Касыйм шәһәре).
[9] Фәрзәндләре — уллары.
[10] Мәхдүми Әгъзам — Бохара мәдрәсәләрендә тәрбияләнеп, суфичылык карашларын таратуда исеме бик билгеле булган тарихи шәхес. XVI нчы йөз башларында ул Кашгарга күчеп килә һәм үзенең күп санлы мөритләрен бөтен Төркстанга һәм Идел—Урал буйларына кадәр тарата. Мәүла Колыйның рухи җитәкчесе—пире әнә шул суфи Мәхдүми Әгъзамның нәселләреннән берсе булганлыгы аңлашыла, чөнки шагыйрь шул ук хикмәтендә «пиремнең Мәхдүми Әгъзам бабалары» дип бик ачык яза.
Урта Азиядә күп рухани аталар үзләренә карата Мәхдүми хәзрәт, Мәхдүми җан кебек исем белән эндәшүне яратканнар. Хәтта аерым шагыйрьләр дә үзләрен шундый кушамат белән йөрткәннәр. Мәхдүми җан исеме белән йөртелгән нинди рухани безнең шагыйрьнең җитәкчесе булган — хәзергә әйтүе кыен.
[11] Юлның мәгънәсе: ир-егетләр киңәшкәндә, нурлар ява диярсең.
[12] Гаҗиз тотарым — якын күрермен.

Бу шигырь Мәүла Колыйның хикмәтләр диванында тулысынча юк, тик аның соңгы ике юлы гына бар. Әмма бу ике юлны эченә алган хикмәт бирeдә һәм формасы һәм эчтәлеге белән бөтенләй башка. Кизләү җыентыгындагы хикмәт «Бакырган» китабына һәм Ясәвинең «Диваны хикмәт»енә дә кергән. Ләкин ул аларның берсендә Кол Сөләйман, икенчесендә Хуҗа Әхмәт (Ясәви) исеменнән сөйләнә. Күрәсез, бер үк әсәр өч җыентыкта өч төрле авторныкы итеп бирелгән. Бу — әсәрне күчерүчеләр хатасымы! Әллә бер шагыйрь икенче бер каләмдәшенең шигъри юлларыннан шулай файдаланамы! Чынлыкта аны кайсысы иҗат иткән! — Хәзергә билгеләве читен. Моны ачыклау өчен, авторы күрсәтелгән шигырьнең борынгырак күчермәсен табарга кирәк. Әмма шунысы билгеле, Көнчыгышны өйрәнү галиме А. К. Боровковның тикшерүенчә, Әхмәт Ясәвинең үз заманында иҗат иткән хикмәтләре бик аз сакланган. Ясәвинеке дип йөртелгәннәренең дә күбесе, соңгы дәверләрдә аның юлыннан баручылар тарафыннан иҗат ителеп, Ясәвигә нисбәтләнгәннәр. Фактлар шуны раслый: берничә дистәләгән суфи шагыйрьнең әсәрләрен эченә алган «Бакырган» китабы да, Идел — Урал буйларында яшәгән татар һәм башкорт укымышлылары арасында таралган хикмәтләрдән җыйналып, Ясәвинең «Диваны хикмәт»е шикелле, беренче мәртәбә Казанда басылган.

Җыйнап әйткәндә, Кизләү кульязмасы Мәүла Колый шигырьләренең кайбер якларын ачыклау өчен әнә шулай ярдәмгә килү белән бергә, ул алар турында киңрәк сүз йөртергә дә мөмкинлек бирә.

Без биредә Мәүла Колый хикмәтләрендәге аерым урыннарны Кизләү кулъязмасы белән чагыштырып, аларны мисалларда күрсәттек. Димәк, берничә кулъязмасы булуы әсәрнең төп текстындагы аерым мәсьәләләрне чишүдә ярдәмгә килә. Мәсәлән, шагыйрьнең «Мелла Мамай» турындагы хикмәтенең Ленинград кулъязмасы табылуы әсәрнең иҗат ителү вакытына һәм урынына карата аерым ачыклаулар алып килүе, хәтта шагыйрьнең чын исеме Меллагол икәнлеген күрсәтүе турында матбугатта инде язылды. Бу яктан алганда, Кизләү кулъязмасының да әһәмияте бар. Беренчедән, ул шагыйрь әсәрләренең халык арасында төрле урыннарда укылып йөргәнлеген күрсәтсә, икенчедән, әсәрнең тексты өстендә тикшеренүләр ясарга шарт тудыра. Шул нигездә без әсәрнең моңа кадәр сер булып кала килгән якларын, аерым сүзләрне яисә юлларны дөрес ача алабыз. Шик юк ки, борынгы әсәрләр кулдан кулга күчерелеп языла торгач, алар төрле хаталарга дучар булалар. М. Колый хикмәтләренең 1925 елгы Ф. Туйкә күчермәсе дә андый хаталардан азат түгел. Ул анда укый алмаслык таушалган урыннарга күп нокталар куеп киткән, яисә, үзенең әйтүенчә, төрлечә укырга һәм аңларга мөмкин булган сүзләрне формаларына охшатып язган. Мондый хәл борынгы әсәрләр текстына карата бик сак килүне, җентекләп тикшеренүне сорый.

...Мәүла Колый — урта гасыр татар әдәбияты, бигрәк тә аның поэзиясе тарихында ныклы урын алган һәм үзенең эзен калдырган билгеле шагыйрьләрдән. Аның әсәрләре, тел һәм әдәбият ядкарьлары буларак, хәзер киң күләмдә өйрәнелә башлады. Ә халыкның исә иҗтимагый-политик, социаль-философик фикерләү тарихын өйрәнүдә бу иҗатка философларыбызның кулы тигәне юк әле. Бу яктан да ул — өйрәнелергә тиешле һәм шуңа лаеклы иҗат. Киләчәктә бу чирәм дә күтәрелер дигән өметтә каласы килә.

# НИЧӘ «КАРА» БАР?

Омонимнарны (аваз-хәреф составы бер, мәгънәсе башка булган сүзләрне) белү — телнең нечкәлегенә төшенү дигән сүз. Мондый сүзләр бездә байтак.

Элегрәк, омонимнар барысы да бертуган кардәшләр, дигән фикер бар иде. Имеш, соңыннан гына бу сүзләр төрле мәгънә алганнар. Бу теория буенча фикер йөртсәң, егыла язу, яз (ел фасылы), язу язу, аяк язу дип әйткәндәге һәм башка язлар, имештер, бер чыганактан булып чыга. Бер автор хәтта Идел-Ител сүзе белән «иту»не бер тамырдан дип чыкты.

Хәзер галимнәр омонимнарның килеп чыгышы хакында башкарак фикердә. Алар — төрле җирдә, төрле шартларда бер-берсен белмичә туган сүзләр.

Күп мәгънәле «кара» сүзен тикшереп карыйк. Безнеңчә, еш куллану ягыннан ул омонимнар арасында иң алда тора. Түбәндәге таблицага карагыз — нинди генә мәгънәләрдә кулланылмый бу сүз:

1. **Иң әүвәл төсне** аңлата:

Кара кашлы, кара күзле
Бала бәхетсез була.

(Борынгы халык җыры.)

2. **Гади, простой** мәгънәсендә:

Кара халык; кара эш; кара эшче; кара кул. Төрекләр сукаһы «кара сапан» диләр.

3. **Явыз, шомлы, усал, шәфкатьсез** дип әйтер җирдә:

Эче кара, тышы ак (усал кеше); кара йөз; кара уй; кара хәбәр; кара көз; кара кыш.

4. **Бәхетсез** мәгънәсендә:

Кара төн, кара язмыш.

5. «Күзгә-күз» очрашу, килү мәгънәсендәге **«кара-каршы»** сүзендә.

6. **Зур, дәү, олы** мәгънәсендә:

Каракош (бөркет); «Кара тау»; Каридел (Кама, Уфа иделләре); кара урман; кара яу (бик ишле яу); кара болыт.

7. **Бөек** дигән сүзне алмаштыра:

Кара диңгез; «Кара корым» (борынгы Себердәге империянең башкаласы); «Караханнар» (тарихта ханнар династиясе); кара хан (бөек хан).

8. **Чит кеше** дигәндә:

«Кеше-кара белә күрмәсен» (Ә. Мирзаһитов. **Гөл** бакчасы).

9. **Сихер, бозымга** бәйләнешле мәгънәдә:

Кара китап, кара китапчы. (Кара: С. Руденко. Башкортлар. 332 бит.)

10. **Шикләнгәндә, шомланганда:**

Алдың-артың шәйләп йөре, берәр кара-фәлән булмасын. (Күмертау районы Калта авылында ишеткән сүз.) Ягъни, яман хәлгә очрама.

11. **Җирдән чыккан су — чишмә яки күл:**

Кара су (кар суын «ак су» диләр. Урта Азиядә Кара су, Ак су исемле элгәләр күп). Чишмәне күп җирдә «каран» дип әйтәләр. «Каран» — кара сүзенең борынгырак формасы.

12. **Шәүлә** урынына:
«Еракта бер кара күренде» (Ә. Вәли).
13. **Язу карасы** мәгънәсендә:
Кызыл кара; яшел кара.
14. **«Язу»** дияр төштә:
«Акка кара төшсә, алтын була» (мәкаль).
15. **Җир** дигән сүзне алмаштыра:
Яз житте — карага бастык (ягъни, кара җиргә).
16. **Карау,** күз салу мәгънәсендә:
«Кара син алга!» (М. Гафури).
17. **Багу,** хәстәрлек күрсәтүне аңлата:
Бала карау; авыруны карау; карап үстерү.
18. **Тою, белү** мәгънәсендә:
Тәмләп кара; үзең кара анысын.
19. **Искәрткән, янаган** чакта:
Килеп кара! Эшләмирәк кара.
20. **Чагыштыру** өчен:
«Апасына караганда сеңлесе чибәр бугай?» (Җыр.)
21. **Игътибарга алу-алмауны** аңлатып:
Аның сүзенә карама, эшеңдә бул. Аңа кара, ул ни әйтсә, шуны эшлә.
22. **Буйсыну, кул астында торуны** аңлатканда:
«Килем авылы халкы Тәфкилевләргә караган» (Д. Юлтый)[1]. Амурның уң ягы Кытайга карар икән, сул ягы — безнеке.
23. Борын заманда «кара» эре терлек (сыер) һәм гомумән терлек-мал (ат, сыер, сарык һ. б.) мәгънәсендә кулланылган. Орхон-Енисей язмаларыннан Кижилиг-Хобу эпитафиясендә:

**Сездән, җирем, суым,**
**...Сездән, угланым,**
**Сездән, агым, карам,**
**Адырылдым,—**

диелгән (ягъни, аерылдым).

Академик Радлов «агым» сүзен — елкым, «карам» сүзен — сыер көтүем дип тәрҗемә иткән (икесе бергә байлыгы була). Филология докторы Җәлил Киекбаев әйтүенчә, аларның ягында, Табын башкортларында, терлек-туар дигән төшенчәне «мал-кара» диләр икән. «Кара» сүзе шул мәгънәдә казакъ телендә дә йөри. «Колхоздың неше карасы бар?» (Ягъни, «Колхозның ничә баш малы бар?»)
24. **Әйбер, кыйммәт** нәрсә мәгънәсендә:
«Карап йөре, әйбер-караң югалмасын» (Хәниф Кәрим).
25. **Начар, эшләнеп бетмәгән,** таза түгел дигән мәгънәдә:
Каралама (әсәрнең тәүге, эшкәртелүе җитмәгән нөсхәсе).
26. **Төньяк** мәгънәсендә:
Казан арты татарлары үзләренең ягын «ак як», ә үзләреннән төньякта мари, удмурт арасында яшәгән татарлар ягын «кара як» дигәннәр (Татары Среднего Поволжья и Приуралья. Мәскәү. «Наука» нәшрияты. 1967. 40 бит).

Шулай итеп, хәзергә бу сүзнең 26 мәгънәсен таптык. Әмма сүз серешендә «кара» да, «ак» та бер генә мәгънә алалар: «акка кара төшергән», ягъни язган кеше дә, сөйләүче дә һәр сүзнең иң килешле урынын тоя.

Омонимнар телнең ярлылыгын күрсәтә дигән ялгыш сүз ишетергә туры килә. Ләкин, тирәнрәк уйласаң, алар телнең бик киң мөмкинлекле, бай, үткен икәнен күрсәтәләр. Әгәр галимнәребез омонимнарның сүзлеген төзеп чыгарсалар, билгеле, мондый карашларга урын да калмас иде.

**ЯОСЫФ ГӘРӘЙ**

---

[1] Бүздәк районы Килем авылы крестьяннары помещик Тәфкилевнең крепостнойлары булганнар. Д. Юлтый бу авылга барып, танышып, зур очерк язган иде.

# СӘЙФЕЛГАБИТ МӘҖИТОВ

**(1865—1938)**

Фәкыйрьлек, бәлгенлектән иза чиккән татар халкы, бәхет һәм тук тормыш эзләп, иске Россиянең төрле почмакларына таралган. Юзовка шахталарында, Баку нефть промыселларында, Мәскәү, Екатеринбург, Астрахань шәһәрләренең завод-фабрикаларында меңәрләгән татар эшчеләре эшләгән. Сәйфелгабит Мәҗитов та шундый язмышка дучар булган кешеләрнең берсе.

Ул 1865 елда Казан артындагы Өртәм[1] исемле бер авылда ярлы крестьян гаиләсендә туа. Әтисе Мәҗит Габделрәкыйп улы тормыш авырлыгына түзә алмый, туган авылын ташлап, читкә китәргә мәҗбүр була. 1875 елда алар Казагыстанның Актүбә шәһәренә күчеп киләләр. Бирегә килүгә Мәҗит ага үзе кәрваннарга йөк төяп озату хезмәтенә керә. Улы Сәйфелгабитне исә, авылда башлаган белемен дәвам иттерү өчен, Актүбәдәге мәктәпләрнең берсенә укырга урнаштыра. Монда ике-өч ел яшәгәч, кәрваннарга ияреп, Мәҗит ага тагын да ераграк, тагын да караңгырак җирләргә сәфәр кыла. 1877 елда алар Арал диңгезенең көньягындагы Таллык елгасы буена барып урнашалар. Бу гаиләнең шуннан соңгы тормышы анык билгеле түгел.

Каракалпак телендә чыккан «Ватан әдәбияты»[2] дигән китаптагы мәгълүматларга караганда, Сәйфелгабит кече яшьтән матур әдәбият белән кызыксына. Аның «Инаят булышка» дигән беренче әсәре 1907 елда ук дөнья күрә. Ләкин авыр тормыш, кыен шартлар аңа матур әдәбият өлкәсендә иркенләп канат җәяргә мөмкинлек бирми. Бары Совет власте елларында гына ул җиң сызганып иҗат эшенә тотына. Сәйфелгабит Мәҗитов Октябрь революциясен шатлык хисләре белән тулы шигырьләр язып каршылый;

Агарып таң туды, иркенлек таңы,
Омтылды мазлумнар җиткәнгә чагы.
Табигать шаулады җиткәнгә язы,
Уянды бар халык, безгә ни булды!

С. Мәҗитов «Ильяның улы» (1924), «Кызлар» (1926), «Маркс бабай» (1928), «Кыз киткән» (1934) кебек дистәләрчә поэмалар авторы. Моннан тыш, ул күп кенә пьесалар яза, каракалпак мәктәпләре өчен беренче «Әлифба» һәм «Уку китап»лары төзи. 1927 елда Сәйфелгабит Мәҗитов Каракалпак автономияле республикасының ул вакыттагы башкаласы Дүрткүл шәһәренә күчеп килә һәм «Азат Каракалпак» (хәзерге «Совет Каракалпакстаны») газетасының җаваплы секретаре булып эшли.

«Ватан әдәбияты» авторларының язуына караганда, С. Мәҗитов үзенең бөтен гомерен һәм иҗат көчен каракалпак халкының мәдәнияттән һәм әдәбиятын үстерү эшенә багышлый. Ул каракалпак совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе санала.

Журналның бу санында укучыларга якташыбызның 1924 елда язылган «Ильяның улы» дигән әсәрен тәкъдим итәм.

**ӘХМӘТ БУЛАТОВ**

## Ильяның улы

Үлчәүгә салсаң барлык җиһанны,
Авыррак килгән Ильяның улы.
Кешелек, азатлык, бәхет юлына
Омтыла белгән Ильяның улы.

[1] Күлле Киме куршесендә Рус Өртеме исемле бер авыл булуы мәгълүм.— Ә. Б.
[2] Ватан әдәбияты. 8 класслар өчен хрестоматия. Нөкес-Казан. 1966 ел. 85—88 битләр

Карт тарих күрмәде мондый нык хрие,
Үткәннәр күп булды, я, әйт, ни бирде!
Батып хыянәткә тулган бу юлны,
Әр-яңадан юл салды Ильяның улы.

Ул яңа юл гаҗәп: үзе төз, үзе киң,
Гарипкә, гаҗизгә кулайлы, җайлы, тиң.
Халыкны туплады, мазлумнан китте моң,
Тәләгең шул иде, Ильяның улы.

Бу дөнья яшәүгә күп миллион ел үтте,
Ничә йөз мең акыл кәсе юл үтте.
Булдымы тик мондый туры юл табучы!
Ал байрак күтәрде Ильяның улы.

Кай философ дөрес күрсәтте үз юлын,
Кай дана[1] сузды кол-мескенгә үз кулын!
Владимир Ильич Ульянов-Ленин ул
Барчасыннан бөек — Ильяның улы...

Теләгән гаҗизгә бирдең син кулыңны,
Җәфасын син чиктең, татыдык без балын.
Киң, якты юл булып, шул салган юлың
Безгә мирас булды, Ильяның улы.

Үтәлде җиһанда синең васыятең,
Булыр коммунизм дигән моратың,
Телдә хөрмәт белән сөйләнә атың,
Мәңгегә яшисең, Ильяның улы.

# КИТАБЕННАС ФИ ХАККЫЛХАВАС

Башкорт һәм татар халыкларының зур горурлану белән макталып телгә ала торган көчле шагыйре Шәйхзадә Бабич үзенең кыска гына иҗат гомерендә бай мирас калдырып китте. Ул иҗат иткән күп санлы әсәрләр арасыннан үзенең әдәби һәм тарихи-иҗтимагый әһәмияте белән «Китабеннас фи хаккылхавас» («Атаклы кешеләр турында китап») дигән эпиграммалар циклы аерылып тора. Үткен сүзле, очлы каләмле зур шагыйрьнең бу сатирик юллары шул замандагы «милләт хадимнәр»ьнә — язучыларга, журналистларга, укытучыларга һәм башка җәмгать эшлеклеләренә адресланган. Тегеяки бу конкрет тарихи шәхестән көлү белән бергә, аларда шул чактагы татар һәм башкорт халыкларының реаль тормыш күренешләре, андагы кызыклы һәм үзенчәлекле вакыйгалар да чагылып калган.

---

[1] Дана — данлыклы кеше.

Ләкин мәсьәләнең бер кыен ягы бар. Ш. Бабичның теге яки бу эпиграммасы кем турында, нинди вакыйга уңае белән язылган?.. Бүгенге укучыларның күбесе әнә шуларны белми. Нәтиҗәдә эпиграммаларның келдерү көче кирәк ноктага бәрып житмәскә, аларны укудан алган тәэсир нык кимергә мөмкин. Берьяктан, шуны игътибарга алып, икенче яктан, ул чордагы кешеләр, аларның кем булулары, кайда, ни эшләүләре онытылып, еллар тузаны астында күмелеп калу ихтималын күздә тотып, ул эпиграммаларга кыскача аңлатмалар биреп калдыруны үземнең бурычым дип санадым.

Мондый зур язманы журнал битләрендә тулысынча бастыру мөмкин булмаганга, монда бер төркем әеруча кызыклы яки бүгенге укучыларга бөтенләй таныш булмаган кайбер исемнәр белән генә чикләнергә туры килде.

**МӘХМҮД ҺАДИ.**

**Әхмәдел Урманчи, урманга ник бер бармыйсың!**
**Көн буе кырда ятып, буп-бушка чыпчык аулыйсың.**

Әхмәт Шәрәфетдин улы Урманчиев — татар халкының уяну чорында мәйданга чыгып шактый роль уйнаган мәгърифәтчеләрнең берсе. Ул Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Фатих Әмирханнарны якыннан белгән кеше, «Ялт-йолт» исемле көлке журналының мөхәррире һәм нашире.

Габдулла Тукай исән чакта «Ялт-йолт» укучыларның тирән мәхәббәтен казанган иң көчле сатира-юмор журналы була. Әмма ул үлгәннән соң, бигрәк тә 1915—1916 елларда, журнал үзенең әһәмиятен югалтыр дәрәҗәдә вакланып кала. Ш. Бабич Әхмәт Урманчиевның, чын «көлке урманына» барырга иренүеннән, җыен вак-төяк нәрсәләр язып, чыпчык аулап ятуыннан көлә.

---

**Төхфәтуллин җырчы, бакыручы, «мефәссир кибрия»!**
**Үпкәләсәң үпкә ашарсың: һәммә эшләрең рия!..**

Бу эпиграммада сүз Камил Мотыйгый турында бара. Мөхәммәткамил Мотыйгулла улы Төхфәтуллин 1884 елда Уральск шәһәрендә мулла гаиләсендә туган. Гарәбстанда укып кайтканнан соң, Уральскида «Әлгасрел җәдит» һәм «Уклар» исемле журналлар, «Фикер» исемле газета чыгара. Камил Мотыйгыйның яхшы ук көчле тавышы бар иде. Ул — татар һәм башкорт җырларын сәхнәгә күтәргән кешеләрнең берсе.

Бирәдә шуны да әйтми үтеп булмый: үзенең холкы, кыланышлары белән ул фельетончыларга, көлке журналларына иң күп азык биргән кеше. Әйтик, үз эшен әйбәт кенә башкарып килгәндә, тота да концертлар биреп йөри башлый, ул да түгел, рестораннарга кереп җырлый, циркта көрәшче булып эшли, мәчетләрдә коръән укый. Г. Тукайның «Сибгатуллин» исемле сатирик шигыре дә аның кыланышларын күздә тотып язылган.

---

**Әлҗәлалев чын вакыйф булды әсирлек халенә,**
**Ул, ахырсы, тончыгып үләр фәган вә зарына.**

Эпиграммада сүз заманында, бик күп көлке нәрсәләр язып, шагыйрь исемен күтәреп йөргән Вакыйф Җәлал турында бара. Байлыгына кызыгып, Казандагы Апанаева дигән бер бай карчыкка өйләнә. Шуның аркасында Г. Тукай каләменә эләктә:

Күңелләр саф чагында шәп, матур кыз сайлыйлар аңлар:
«Булыр безнең хатын, булса, йөзе айдай»,— диләр аңлар.
Әгәр басса дөнья һәм муеннарда бурыч тулса,
Убырлы карчыгыңны да алырлар, акчасы булса.

Ш. Бабич эпиграммасындагы «Вакыйф булды әсирлек халенә» дигән юллар шул ук нәрсәгә ишарә итә.

Дәрдмәнд, дәрт шәп чагында «Дәрдмәнд» дип алдың ат,
Исте җилләр.., күчте комнар... бетте дәрман, сүнде дәрт.

Сүз татарның мәшһүр шагыйре Дәрдмәнд турында бара. Заманында вакытлы матбугатта басылган шигырьләрен укучылар кызыксынып, дәрт һәм рухлану белән укыйлар иде. Ләкин революциядән соң никтер көчле әсәрләр бирә алмады. Ш. Бабич Дәрдмәнднең шул чорда ук сүрелә башлавына ишарәли.

---

Шарлатан Шакир юрист, ай-һай, горурлы фиргавен!
Фиргавеннәр бик күбәйде, таңрем, үзең бир гавен...

Шакир Зариф улы Мөхәммәдъяров (1883—1967) — Тукай Петербургка барган чакта аны җитәкләп докторларга йөрткән кеше. 1910 елда башкалада университет бетереп юрист булып эшли. «Таң», «Мөхбир», «Әхбәр», «Йолдыз» һәм «Вакыт» газеталарына язышa, милли хәрәкәтнең уң флангысында барган журналист була.

Революциягә чаклы Ш. Мөхәммәдъяров Оренбургта губернатор канцеляриясендә чиновник булып та эшләп йөргән. Күрәсең, үзен эре тоткандыр. Ш. Бабичның бу эпиграммасы шул уңай белән язылган булыр.

Революциядән соң Ш. Мөхәммәдъяров Эчке эшләр министрлыгында укытучы булып эшләде. Язган әсәрләре бар.

---

Юк, сафа бетте, Сафа менгәч татарның тәхтенә,
Якты күрмәссең, татар, Иблис төкергәч бәхтеңә!..

Сафа заманында зур түрәләрнең берсе иде. Соңыннан әтисе Гатаулла Баязитов тарафыннан чыгарыла башлаган «Нур» газетасының мөхәррире булды. Революция алдыннан Бөтенроссия мөселманнарының рухани башлыгы — мөфти итеп куелды. Ш. Бабичның бу эпиграммасы Сафа Баязитов мөфти булгач язылган.

Сафа һәм аның Петербургтагы иптәшләре карагруһлар идеологиясен таратучы «Сыйраты мөстәкыйм» исемле реакцион оешма төзеделәр. Дәүләт думасының унга якын депутаты, «Аң» журналының 1914 елгы 5 санына протест хаты язып, ул җәмгыятьнең кара йөзен фаш итте.

Революциядән соң табылган архив документлары буенча Сафа Баязитовның провокатор булганлыгы беленде.

Фатих Урманчеев

# ХАЛЫКНЫҢ КҮҢЕЛ КӨЗГЕСЕ

*Фольклор җыентыкларын төзү һәм матбугатка чыгару мәсьәләләренә карата*

Бездә халык иҗаты җыентыклары еш чыгып тора. Сугыштан соңгы елларда гына да 30 дан артык яңа китап дөнья күргән. Шул китапларның барысын бергә җыеп, бер-бер артлы карый башласаң, күңелдә төрле сораулар туа. Халык иҗаты әсәрләрен ничек чыгарырга? Аларны төзәтергә, ничек тә булса үзгәртергә яки редакцияләргә ярыймы? Халык иҗаты әсәрләре тупланган җыентык нинди булырга тиеш?..

Төп мәсьәләгә керешкәнче башта фольклор җыентыкларының төрләре турында бер-ике сүз әйтеп үтәргә кирәктер кебек. Алар гадәттә өч төркемгә бүленеп йөртеләләр: фәнни җыентыклар, фәнни-популяр һәм популяр җыентыклар. Популяр китаплар нигездә балалар, укучы яшьләр өчен чыгарыла. Мондый җыентыкларда махсус кереш сүз яки киң аңлатмалар бирү мәҗбүри түгел. Әмма күләме белән зур булмаган, күңелне тартырлык һәм балаларга да аңлаешлы итеп язылган кереш сүз комачауламый, әлбәттә. Элегрәк балалар өчен төзелгән халык иҗаты җыентыклары ешрак чыга торган иде. Гомәр ага Бәширов белән Хәмит ага Ярми тарафыннан төзелгән «Татар халык әкиятләре» (1949), «Гөлчәчәк (1947)[1], Афзал ага Шамов белән Хәмит ага Ярминең «Халык җырлары» (1948), Г. Тохфәт төзегән «СССР халыклары әкиятләре» (1953) әнә шул хакта сөйли.

Соңгы елларда исә балаларга багышланган фольклор җыентыклары сирәгрәк күренә башлады. Халыкның күңел көзгесенә балачактан ук ихтирам, туган илгә һәм туган телгә мәхәббәт тәрбияләүдә мондый җыентыклар искиткеч зур роль уйный. Шуңа күрә киләчәктә аларны ешрак һәм күбрәк чыгару турында уйлашырга кирәк.

Фольклор китапларының кайберсе популяр һәм фәнни-популяр җыентыкларның һәр икесенә хас сыйфатларны берләштерә. Мәсәлән, 1967 елда Нәкый ага Исәнбәтнең «Нәниләр шатлана» дигән китабы чыкты. Ул кече яшьтәге мәктәп балалары өчен төзелгән. Ләкин анда «Уеннар турында» дигән тирән эчтәлекле, чын мәгънәсендә фәнни кереш мәкалә, уеннарның кайберсенә карата төрле характердагы киң аңлатмалар бирелгән. Аннан соң китапта, кече яшьтәге мәктәп балалары арасында таралган уеннар һәм такмак-такмазалар белән бергә, яшүсмерләр, яшь егетләр һәм кызлар арасында таралган җырлар һәм такмаклар да китерелгән. Шулай булгач, бу басманы без популяр җыентык дисәк тә, фәнни-популяр китап дисәк тә, ялгышмыйбыз. Күптән түгел Н. Исәнбәт «Балалар дөньясы» исемле тагын бер китап чыгарды.

Фольклор китаплары арасында чагыштырмача киң таралганы — фәнни-популяр җыентыклар. Мондыйлар рәтенә Гомәр ага Бәшировның «Туксан тугыз мәзәк» (1960)

[1] Бу китап соңыннан рус, украин һәм кытай телләрендә дә басылып чыкты.

һәм «Мең дә бер мәзәк» [1963], Хәмит ага Ярми тарафыннан төзелгән «Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре» [1960], Абдулла ага Әхмәт чыгарган «Хуҗа Насретдин мәзәкләре» [1962 һәм 1966 еллар] кебек китапларны кертергә мөмкин. Мондый җыентыкларда киң фәнни аңлатмалар булуы шулай ук мәҗбүри түгел. Ләкин китапка кергән әсәрләрнең чыганаклары күрсәтелергә тиеш. Фәнни-популяр җыентыкларда кереш мәкаләләр дә була. Алар жанрның тарихын һәм теориясен төрле яклап ачыклауны дәгъва итми. Шулай да китапка кергән әсәрләрнең кайбер үзенчәлекләре, соңгы заманнарда, бигрәк тә безнең көннәрдә яшәү формалары, тәрбияви әһәмияте һәм эстетик кыйммәте турында җитди мәгълүматлар булуы мөмкин.

Соңгы елларда дөнья күргән фольклор китаплары арасында төп урынны фәнни җыентыклар алып тора. Аларның иң матур үрнәкләре төсендә Нәкый ага Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре»н [1959, 1963 һәм 1967 еллар] яки Ильбарис Надировның «Татар халык җырлары»н [1965] күрсәтергә мөмкин.

Фәнни җыентыклар турында сүз баргандә нигә соң бу ике җыентык кына үрнәк итеп алынды әле! Бу сорауга, кыска гына итеп, түбәндәгечә җавап бирергә мөмкин: күрсәтелгән ике җыентык безнең көннәрдә әзерләнгән фольклор китапларына куела торган таләпләргә т у л ы с ы н ч а  җ а в а п  б и р ә л ә р. Кайбер аермалары булуга карамастан, әлеге җыентыкларның икесе дә бүгенге фольклор фәне казанышлары, халык иҗаты әсәрләрен бастырып чыгаруның чын фәнни принциплары нигезендә төзелгән. Хәтта бу китапларны соңгы елларда чыккан җыентыкларның иң яхшылары дисәм дә ялгышмам кебек.

«Татар халык мәкальләре» белән «Татар халык җырлары» — икесе ике типтагы җыентык. Бу аларның аерым бүлекләренә игътибар иткәндә үк күзгә ташлана. «Татар халык җырлары»ның ахырында «Искәрмәләр» дигән махсус бүлек урнаштырылган. «Татар халык мәкальләре»ндә исә мондый бүлек юк. Андагы аңлатмалар аерым мәкальләр белән рәттән урнаштырылган. Гомум фольклор фәнендә аерым әсәрләргә бирелгән аңлатмаларны, махсус бүлек итеп бер тирәгә туплап, җыентыкның ахырында урнаштыру кулайрак санала. Әмма Исәнбәт томнарындагы искәрмәләрнең эчтәлегенә, никадәр тирән һәм киң булуына игътибар итсәк, аларның «бармак башыдай





## *А. Шамуковка*

Безнең Шамун Абдулласы язып тора,
Бер образдан иненчегә азып тора.
Археолог булмаса да, эрмый-талмый
Борынгының хикмәтләрен казып тора.

Н. АРСЛАНОВ эпиграммасы.



## *Салих Батталга*

Баттал абзаң Чирмешәнгә
Тагын да китәр әле.
Роман бетте, дип алданма,
Бер дәвам итәр әле...

Н. АРСЛАНОВ эпиграммасы.

вак» әсәрләр белән бәйләнгәнлеген дә истә тотсак, тәзүче, һичшиксез, дөрес юл сайлаган дип әйтәсе килә. Өстәвенә, аңлатмаларның мәкальләр белән рәттән урнаштырылуы китапны укуны, аның искиткеч бай һәм катлаулы эчтәлеген үзләштерүне җиңеләйтә.

Инде әйтелгәнчә, соңгы елларда басылып чыккан фольклор китапларының гомуми саны шактый. һәрбер фольклор китабы турында махсус сөйләү зур урын таләп итәр иде. Шуңа күрә биредә гадәттә фольклор китапларында очрый торган төп бүлекләргә генә тукталу отышлырак булыр шикелле.

Фәнни җыентыклар гадәттә өч бүлектән тора: кереш мәкалә, халык иҗаты әсәрләре тупланган төп бүлек һәм искәрмәләр яки аңлатмалар. Бу бүлекләргә безнең көннәрдә нинди таләпләр куела! Фольклор җыентыклары бу таләпләргә ничек җавап бирә!..

Сүзне кереш мәкаләдән башлыйк. Аның күләме гадәттә яхшы ук зур була. Фәнни тирәнлеге дә шуңа беркадәр тәңгәл булырга тиеш, әлбәттә. һәрхәлдә, кереш мәкаләдә китапка кергән материалның асыл сыйфаты, эстетик әһәмияте тикшерелә. Әгәр җыентык аерым бер жанрга гына багышланган булса, аның специфик үзенчәлекләрен һәм тарихын ачыклау да таләп ителә. Мөмкин дәрәҗәдә, билгеле. Менә шул принциплар ноктасыннан карап, яңадан Н. Исәнбәтнең мәкаль томнарына һәм И. Надировның җырлар җыентыгына игътибар итик. Нәкый аганың «Мәкальләребез турында» дигән хезмәтендә теоретик яктан җентекләп тикшерелгән төп мәсьәләләрне санап үтү генә дә аның никадәр киң мәгънәле булуын күрсәтә (жанрның билгеләмәсе; идея эчтәлеге; алынмачылык, ягъни мәкальләрнең бер халыктан икенче халыкка күчеп йөрүе; мәкальләрне төрләргә бүлү; татар халык мәкальләренең килеп чыгышы; тарихы; милли үзенчәлекләре; безнең мәкальләрне җыю һәм өйрәнү тарихы һ. б.). Нәкый ага тарафыннан чыгарылган башка җыентыклар һәм аларның керешләре дә фольклорчылар алдына яңа җитди проблемалар куя. Чөнки алар кирәк дәрәҗәдә киң һәм фәнни яктан тирән язылган. 1941 елда басылып чыккан «Табышмаклар» белән «Балалар фольклоры»н, 1967 елда дөнья күргән «Нәниләр шатлана» һәм 1970 елда чыккан «Татар халык табышмаклары» китапларын искә төшерик. Шуләй ук И. Надировның «Татар халык җырлары»на һәм Х. Гатина төзегән «Татар халкының җырлы-биюле уеннары»на (1968) язган кереш мәкаләләрендә халык җырларының төп төрләре, тарихи үсеш-үзгәреш процессы, шигъри үзенчәлекләре турында киң мәгълүматлар бирелгән, җитди фәнни фикерләр әйтелгән.

Әмма соңгы еллардагы фольклор китапларының кайберсендә урнаштырылган керешләр безнең заман фольклор фәне таләпләреннән шактый түбән тора. Мисалга 1964 елда Мәскәүдә басылып чыккан «Татар халык көйләре» исемле музыкаль җыентыкны алырга мөмкин. Бу китапның кереше бөтенсоюз укучысына татар халык җырларының асыл табигатен, шигъри гүзәллеген һәм матурлыгын күрсәтергә тиеш иде. Чынлыкта нәрсә килеп чыккан соң! Иң элек, җыентыкның исеме дөрес түгел. Анда көйләр генә түгел, бәлки җырлар, ягъни халык лирикасы әсәрләренең көйләре дә, сүзләре дә урнаштырылган. Димәк, сүз татар халык җырлары турында бара. Күләм ягыннан кереш мәкалә зур түгел. Аннан татар халык көйләре, аларның төрләре турында кайбер кызыклы мәгълүматлар табарга мөмкин. Әмма, шуның белән бергә үк, мәкаләдә төрле бәхәсле фикерләр дә җитәрлек. Кереш сүздә, җыентыкның төп өлеше әлегә кадәр беркайда да басылмаган материаллардан тора, дип язылган. Чынлыкта исә китапта нибары биш-ун гына яңа җыр бар. Җыентыкның төп өлеше А. Ключарев, Җ. Фәйзи һәм башкаларның китапларында кабат-кабат басылган, «Уел», «Кара урман», «Галиябану» кебек, әллә кайчаннан бирле киң җәмәгатьчелеккә яхшы таныш җырлардан тора. Фәнни дөреслеккә туры килми торган моңдый урыннарны бу мәкаләдән тагы да табарга мөмкин. Әйтик, кереш мәкалә авторы фикеренчә, революциягә кадәр татар халкында хор белән җырлау практикасы бөтенләй булмый, халык җырларын башкаруның бу яңа формасы тик революциядән соң гына тарала икән. И. Надиров үзенең бер мәкаләсендә бу фикернең дөрес түгеллеген фактларга таянып исбат иткән иде инде («Совет әдәбияты» журналы. 1957 ел. 6 сан). Шуңа карамастан, объектив дөреслеккә туры килмәгән фикер Мәскәүдә басылып чыккан китапта тагын бер тапкыр кабатланган. һәм ул татар халык лирикасының яшәү формалары турында бөтенләй ялгыш фикер уята. Чыннан да, татар халкының сабан туйларын, җыен бәйрәмнәрен, туйларны, аулак өйләрне, тула басу һәм каз өмәләрен, халкыбыз арасында киң таралган түгәрәк һәм әйлән-бәйлән уеннарын

ничек инде кумәк җырсыз күз алдына китерергә мөмкин!.

Кереш мәкаләдән соң гадәттә җыентыкның төп өлеше — халык иҗаты әсәрләренең үзләреннән торган бүлеге башлана. Халык иҗаты җыентыкларын чын мәгънәсендә сәнгатьчә яңгыраган әсәрләрдән генә төзү өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар. һәм әнә шундый әсәрләр генә халык күңелендә гасырлар буена яши, олы һәм урта буын вәкилләре аңа ата-бабалардан калган кыйммәтле мирас дип карый, бөтен матурлыгын саклап яки тагы да камилләштереп, аны яшь буынга тапшыра. Нәкъ әнә шуңа күрә Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов кебек олы әдипләребез халык иҗатының гүзәллегенә сокланып караганнар. Халыкның күңел көзгесенә тирән ихтирам — безгә алардан калган васыять.

Соңгы елларда чыккан китапларның төп өлеше татар халык иҗатының иң яхшы, чын мәгънәсендә матур әсәрләреннән тора. Кабатлап булса да әйтим: Нәкый ага Исәнбәтнең мәкаль томнарына, табышмаклар һәм балалар фольклорына багышланган китапларына, Гомәр ага Бәширов белән Хәмит ага Ярминең әкият җыентыкларына, Гомәр аганың мәзәк китапларына, Ильбарис Надировның җырлар җыентыгына нигездә югары сыйфатлы әсәрләр тупланган. Бу китапларның һәркайсы татар фольклор фәне тарихында әһәмиятле роль уйнады һәм халык иҗатының иң матур үрнәкләрен яңадан халыкка таратырга ярдәм итте. Ниндидер сихри бер көчкә ия булган әкиятләр, кайгы-хәсрәт дәрьясыдай бәетләр, гасырлар моңын туплаган җырлар, үткен телле мәзәк-мәсәлләр, хикмәтле мәкаль-әйтемнәр һәм шат күңелле такмак-такмазалар — әлеге китаплардан боларның барысын да табарга мөмкин. Алар белән танышкач, халык шигъриятенә булган мәхәббәт һәм ихтирам хисең тагы да көчәя тагы да тирәнәя...

Саналган китаплардагы әсәрләр киң катлау укучыларга, фәнни һәм иҗади җәмәгатьчелеккә яхшы таныш булганга, мин аларга озак туктапып тормыйм, игътибарны фольклор китапларында очрый торган кайбер җитешсезлекләргә юнәлтәсе килә. Аерым очракларда без халык иҗаты әсәрләренең әһәмиятенә, аларның эстетик кыйммәте һәм шигъри үзенчәлекләренә тиешле игътибар бирел җиткермибез шикелле. Шуңа күрә кайбер җыентыкларда әдәби яктан начар эшләнгән, түбән сыйфатлы



*Марс Шабаевка*

«Әби-апа», әти, әни...
Туганнарын сөя Шабай.
Имеш, хәзер яза ди ул
Шигъри роман «Абый-бабай».

Р. ВӘЛИЕВ эпиграммасы.



*Галимҗан Латыйпка*

Чаба поезд белмим кая,
Аваз чыга: «Тып-тып, ла-тыйп»...
Әй, тәгәри тәгәрмәчләр,
Һәм шигырьләр кала ятып.

Р. ВӘЛИЕВ эпиграммасы

әсәрләр урын ала. Мәсәлән, «Татар халык иҗаты» (1954 ел) антологиясендә «Чапай турында», «Ничек без утыз биш фашистны плен алдык» кебек истәлекләргә махсус бүлек бирелгән иде. Аларны хәтта совет чоры халык иҗатының яңа бер эпик жанры дип бәяләгәннәр иде. Яңа, мөстәкыйль жанр булгач, аңа исем дә кирәк бит инде. Анысы да табыла: сөйләк, имеш. 1954 елдан бирле уннан артык фольклор җыентыгы чыкты. Ә менә «яңа эпик жанр» дип игълан ителгән сөйләкләр халык тарафыннан кабул ителмәде һәм аларның соңгы җыентыкларда, халык иҗаты әсәре буларак, басылганы да юк. Бу аңлашыла да. Үзенең төп сыйфатлары белән сөйләк фольклор әсәрләреннән ерак тора. Хәзер инде фольклорчылар мондый истәлекләрне мөстәкыйль әдәби әсәр дип тә исәпләмиләр.

Басылып чыккан бәетләр арасында да әдәби яктан шактый йомшаклары очрый. Үз вакытында берничә тапкыр тәнкыйть ителгән, шуңа карамастан, кат-кат басылып чыккан «Гаптиева бәете», шуннан әллә ни ерак тормаган «Сернокислотный цех бәете», «Балтай бәете» кебек әсәрләрне әнә шундыйлар рәтеннән санарга мөмкин.

Фольклор җыентыкларындагы аерым әсәрләрнең шактый йомшак, беркадәр ясалма булуы күзгә бәрелеп тора. Мәсәлән, «Татар халык иҗаты»нда басылган «Тудыкайлар» дигән туй җырында шундый юллар бар:

Ирең сиңа баш була,
Аңа каршы сүз әйтмә;
Каты-каты кыйнаса да,
Тудыкайлар,
Аны һич тә рәнҗетмә.

Ирең булыр баш сиңа,
Ә син хатын — муенсың,
Яратмасаң да иреңдә тор,
Тудыкайлар,
Иреңә тик син буйсын.

Бу юллар кулга алмаслык начар түгел. Идея эчтәлеге дә ярыйсы гына. Шулай да аларда ниндидер ясалмалык сизелә. Һәрхәлдә, үз тормышындагы зур вакыйга алдында торган кызга, әлеге җырдагыча, ямьсез киләчәк вәгъдә итү, элеккеге гаилә тормышының иң әшәке якларын гына күрсәтү шактый ясалма яңгырый, ышандырмый. Җырның теле, стиле дә ярыйсы ук кытыршы.

Шулай да, төрле характердагы җитешсезлекләре, аерым кимчелекләре булуга карамастан, соңгы елларда чыккан филологик җыентыклар тулаем уңай тәэсир калдыра, аларга кертелгән әсәрләр яхшы сайланган, тиешле дәрәҗәдә редакцияләнгән була. Ә менә музыкаль җыентыклар турында, кызганычка каршы, болай әйтеп булмый. Аларның байтагында без халык иҗаты әсәрләренә, конкрет әйткәндә, җыр һәм бәетләрнең текстларына искиткеч игътибарсызлык күрәбез. Музыкаль ягы, ягъни ноталары ярыйсы гына төзелгән җыентыкларның да текстларында күп төрле кимчелекләр очрый. Аларда таралган типик күренешләрнең берсе — җырның көен, музыкасын тулысынча урнаштырып, сүзләрен ярты-йорты килеш бирү. Әйтик, «Уел», «Нурия», «Галиябану» 4—5 куплеттан торган җырлар булса, җыентыкта аларның 1—2 куплеты гына урнаштырыла. Нәтиҗәдә бик күп җырларның текстлары өзек-өзек булып чыга. Киң таралган бу күренешкә аерым мисаллар китереп тормаска да мөмкин. Чөнки кинди генә музыкаль китапны алсаң та, мондый кимчелекләрне теләгән кадәр табарга мөмкин.

Шулай да музыкаль җыентыкларның төп кимчелеге бу түгел әле. Шундый өзекләр генә адәм рәтле булса да, шөкер итәргә ярар иде. Кызганычка каршы, болай түгел шул. Музыкаль җыентыклардагы җыр текстларының шактый өлеше примитив яңгырый. Югарыда телгә алынган 1964 елгы «Татар халык көйләре»ннән мондый җырларның үрнәкләрен байтак табарга мөмкин. Мәсәлән, күптән билгеле «Әтнә» җыры анда болай бирелгән:

Кактым-суктым ачылды,
Таңкәләре чәчелде,
Эте чыкты өрмәгә,
Кызы чыкты күрмәгә.
Этен алдым пычакка,
Кызын алдым кочакка.

Иң элек бу без аңлаган мәгънәдәге җыр түгел, ә такмаза. Беренче тапкыр ул 1875 елда Габор Балинтның Будапештта чыккан китабында берниндн исемсез басыла. Аның 1964 елда чыккан китапка «Әтнә» көе буларак керүе шактый сәер. Чөнки «Әтнә» революциягә кадәр туган җыр түгел, ә бәлки безнең заманның популяр җырларыннан берсе. Һәм аның сүзләре белән әлеге такмаза арасында берниндн уртаклык юк. Халык арасында таралган, күп мәртәбәләр басылып чыккан «Әтнә» көе түбәндәге сүзләр белән башлана:

Җырлыйк Әтнә көйләренә
Җырчыларга таралсын;
Мул уңышлар үстерүдә
Безнең Әтнә дан алсын.

Моны әлеге җыентыктагы текстларны әзерләүче З. Хәйруллина да бик яхшы белә. Ул төзегән «Халык җырлый» (1962) җыентыгында җырның сүзләре дөрес бирелгән. Ә менә 1964 елгы «Татар халык көйләре»нә кайдандыр бөтенләй башка текст килеп кергән. Яисә шул ук китаптан «Сәфәр» җырын алыйк:

Урам аша киртә үтә,
Киртә буе гөл үсә шул.
Эшче, игенче гел бергә,
Аерыла алмый бер күрсә.

Строфаның идеясе матур. Биредә сүз эшче һәм крестьяннарның сыйнфый дуслыгы турында бара. Ләкин мондый бөек идея турында халык болай ямьсез җырламый бит. Биредә исә «аерыла алмый бер күрсә» тәгъбире халыкның мәхәббәт лирикасыннан алынып, социаль-политик характердагы җырга ябыштырылган. Аннан соң «урам аша үтә» торган киртәләр нинди авылларда була икән! — дип тә уйлап куясың... Әнә шундый примитив текст бөтенсоюз укучысына татар халык җыры дип тәкъдим ителә. Мондый мисаллар әлеге җыентыкта, кызганычка каршы, аз түгел. Менә «Асиләсе, Василәсе» җырыннан бер куплет:

Авылларда тудыңмы,
Фабрикларда үстеңме?
Беләкләрең тимер кебек,
Машиналар, динамолар,
Станоклар техникасын
Белер өчен үстеңме?

Хатын-кызлар турындагы җырлар халык лирикасының зур һәм гүзәл бер өлешен тәшкил итә. Гадәттә, алар турында сүз барганда алма, чия, бөрлегән, сандугач, былбыл кебек нәфис сурәтләр, искиткеч матур чагыштырулар, ягымлы сүзләр кулланыла. Биредәге «беләкләрең тимер кебек» чагыштыруы исә колакка ятмый. Һәрхәлдә, андый кызлардан ераграк йөрүең хәерле... Кыскасы, әлеге җыентык белән танышып чыккач: «Кайдан килгән соң мондый начар җырлар!» — дип аптырарга гына кала. Андыйларны халык арасыннан табуы да җиңел түгел бит. Хәер, җыентыкның керешендә редактор А. Абдуллин бик җитди рәвештә: «Җырларның текстлары музыка белгече



## *Равил Фәйзуллинга*

Батыр яуда сынала.
Мин беләм.
Луноход Айда сынала.
Мин беләм.
Шагыйрь кайда сынала?
(Шагыйрь дустым авыр гына тын ала.)
Премия алганнан соң сынала.
ЮЗИЛ эпиграммасы.



## *Гөлшат Зәйнашевага*

Танкыйть ителгән җырларның
Авторы Гөлшат түгел,
Җырларым да бик популяр,
Нигә соң мин шат түгел?
ЮЗИЛ эпиграммасы.

З. Ш. Хәйруллина тарафыннан тәкъдим ителде».— дип яза. Шулай булгач, музыка белгеченнән филолог та булуны таләп итеп булмый инде. Тик җыентыкны төзүчеләр белән редактор гына моны истән чыгарганнар, күрәсең...

Югарыда конкрет әсәрләрне бәяләүдәге җитешсезлекләр күрсәтелде. Моннан кала, кайбер китапларда җыентыкны төзү принципларына, халык иҗаты әсәрләрен урнаштыру тәртибенә караган кимчелекләр дә очрап куя. Соңгы елларда дөнья күргән җыентыклар арасында төрле принциплар нигезендә төзелгәннәре бар. И. Надировның «Татар халык җырлары», мәсәлән, тематик принцип нигезендә төзелгән. «Борынгы татар әдәбияты»ндагы (1963) фольклор материаллары, хронологик тәртип буенча, аерым чорларга бүленеп бирелгән. Фольклор әсәрләренең күп төрләрен үз эченә алган «Татар халык иҗаты» китабының нигезендә жанрларга бүлү принцибы ята.

Халык иҗаты әсәрләрен жанрларга бүлү фольклор фәненең гомуми торышы, үсеш дәрәҗәсе белән бәйләнгән. Бездә исә татар халык иҗатының гомуми эчтәлеге, аның жанрлары, төрләре турында соңгы елларда нинди дә булса махсус мәкалә, җитди фәнни тикшеренү язылганы юк. Күрәсең, шуңа күрәдер кайвакыт бер жанрга караган җыентыкка бөтенләй икенче жанр әсәрләре кереп китә. Мәсәлән, үзеннән-үзе җырлап торган «Тали», «Ташкай» кебек тарихи җырлар, лирик җыр икәнлеге шиксез булган «Ялчылар хәле» Хәмит ага Ярми төзегән «Бәетләр» китабына кереп киткән:

Алыста ла җирдән, әй, күренә
Җемелдәгән Чаный күлкәе.
Кыйгылдашып очкан акчарлаклар
Җемелдәгән күлнең гөлкәе.

(«Ялчылар хәле»)

Бик күптәннән бирле җыр булуы бәхәссез «Карьят батыр» 1964 елгы «Татар халык көйләре»ндә бәетләр бүлегенә кергән. Шул ук китапта кульъязма поэзия йогынтысында туган, шуңа күрә халкыбызның традицион лирикасыннан шактый ерак торган агитацион-публицистик садалар (гимннар) исә тарихи җыр дип бирелгән. Мәзәк булуы шиксез әсәрләр еш кына әкиятләр рәтендә йөри. Андый әсәрләрне «Татар халык иҗаты»ннан да, әкият томнарыннан да табарга мөмкин. «Кәкре каен терәткән», «Атланма, билен сындырырсың», «Үткен кияү» кебек әсәрләр Эдуард Касыймовның «Абага чәчәге. Татар халкының сатирик әкиятләре» (1962 ел) исемле китабында да, Гомәр ага Бәшировның «Мең дә бер мәзәк» җыентыгында да бар. Э. Касыймов аларны әкият дип исәпли, Г. Бәширов исә мәзәкләр рәтенә кертә. Димәк, татар халык иҗатының жанрларын ачыклау, аларны мөмкин кадәр төгәл итеп төрләргә бүлү бүгенге фольклор фәненең мөһим практик бурычларыннан санала икән.

Фольклор китапларының күпчелеге тематик классификация нигезендә төзелгән. Бу — безнең фольклор фәнендә халык иҗаты әсәрләрен билгеле бер тәртип белән урнаштыруның беркадәр камилләшкән ысулы.

Башка принциплардан халык иҗаты әсәрләрен хронологик яктан икегә — Октябрьга кадәрге дәвергә һәм совет чорына бүлеп йөртү киң таралган. Октябрьга кадәрге чор дигәннән, бу бүлеккә гадәттә IX—X йөзләрдә барлыкка килүе ихтимал булган әсәрләр дә, XIX һәм XX йөз башында туган әсәрләр дә керә. Бу хронологиягә нигезләнгән җыентыкларда бик тә сәер күренешләр очраштыргалый. «Татар халык иҗаты» китабының беренче бүлегендә XX йөздәге әсәрләр, икенче бүлегендә исә X—XIX йөзләрдә туган әсәрләр урнаштырылган. Ягъни хронологик принцип киресенчә килеп чыккан. Фольклорчылар мондый принциптан акрынлап арыналар. Ә менә З. Хәйруллина «Халык җырлый»ның 1962 елгы басмасында шул ук искергән принцип нигезендә эшләгән. Китапның баш өлешендә нигездә безнең заман, ягъни XX гасыр җырлары, ахырда борынгы җырлар урнаштырылган. Тагын мисалларга мөрәҗәгать итик. «Татар халык иҗаты» китабында мәкаль һәм әйтемнәр, табышмакларга багышланган бүлекләр совет чорына кергән. Таныша башлагач исә аларның нигездә традицион, ягъни революциягә кадәр туган әсәрләр булуы ачыклана. Төзүчеләр борынгы мәкаль, әйтем, табышмакларның совет чорында да яшәү фактына таянганнар, күрәсең. Әмма бу турыда искәрмәләрдә бер нәрсә дә әйтелмәгән. Хәтта, киресенчә, андагы әсәрләр нигездә революциягә кадәр чыккан китаплардан алынды дип язылган. Шул ук вакытта китапның «Октябрьга кадәрге чор» дигән өлешендә мәкаль, әйтем, табышмаклар бөтенләй юк. Әйтерсең алар безнең халык иҗатында революциягә кадәр гомумән булмаган.

Фольклор әсәрләрен хронологик тәртипкә салу шактый катлаулы эш. Чөнки фольклор әсәрләре халык телендә гасырлар буе, мең еллар буе яши. Безнең заманда язып алынган әсәрләрнең дә кайберсе моннан 2—3 йөз, яки хәтта мең ел элек туган булуы мөмкин. Шуңа күрә халык иҗатының күп кенә борынгы әсәрләренең кайсы гасырда туганын билгеләп тә булмый. Шулай да бу юнәлештә аерым эзләнүләр бар. Мәсәлән, «Борынгы татар әдәбиятында»гы легенда, риваять һәм бәетләр билгеле чорларга бүленеп урнаштырылган. Халыкның риваять һәм легендаларын башка телләрдән тәрҗемә итеп, әдәбият китабына кертү никадәр нигезледер, мәсьәләнең бу ягына мин кагылмыйм. Ә менә нишләп «Кыйссан ике былбыл» белән «Нәүрүз бәете» VIII—XIII йөзләр әдәбиятына кергән икән! — дип уйланырга урын бар. Бу әсәрләрдә сүз егетләр киеме киеп, мәдрәсәдә укыган һәм аннан чыгып китәргә мәҗбүр булган кызлар турында бара. Эчтәлеге ягыннан алар XIX йөзнең беренче яртысында туган «Җиде кыз бәете»нә бик якын. Бу бәеттә дә егетләр киеме киеп укырга керәән кызлар язмышы гәүдәләнә. Кыз икәнлекләре сизелгәч, аларны мәдрәсәдән куып чыгаралар. Димәк, «Нәүрүз бәете» VIII—XIII йөзләрдә туган дисәк, әле Болгар чорында ук кызларга мәдрәсәдә укырга рөхсәт ителмәгән булып чыга. Әмма археологик тикшеренүләргә һәм гарәп сәяхәтчеләренең язмаларына карагында, Болгар социаль-политик яктан прогрессив ил саналган. Уку-укыту эшләре дә анда шактый алга киткән булырга тиеш дип уйларга кирәк. Ислам диненең реакцион законнары Идел буенда нигездә XVII—XIX йөзләрдә генә тирән тамыр җәя. Моңа кадәр исә «Нәүрүз бәете»ндәге кебек реакцион күренешләр сәнгать әсәренә куәу дәрәҗәсенә җиткән типик хәл була алмый. Китапны төзүчеләр Ш. Мәрҗаниның Болгар чорында «Нәүрүз бәете» һәм «Шәһре Болгар газыйлары бәете» булуы турындагы сүзләренә таянганнар, күрәсең. Әмма, минемчә, Мәрҗани XIX йөз азагында басылып чыккан «Нәүрүз бәете» турында түгел, ниндидер башка бер әсәр хакында сөйли булса кирәк.

Халык иҗаты җыентыклары арасында берниндм принципка, берниндн классификациягә нигезләнмәгәннәре дә бар. Шундыйлар рәтенә халык әкиятләреннән торган төрле җыентыкларны кертергә мөмкин. Әкиятләрнең нигездә өч төркемгә бүленүе



*Зәкия Туфайловага*

Союзга алынмаган,
Зинһар, дип ялынмаган,
Рецензия күрмәгән,
Языгыз дип йөрмәгән,
Унлап китап авторы
Кем ул, я, әйт, туп-туры?!

ЮЗИЛ эпиграммасы.



*Мәхмүт Хөсәенгә*

«Күпме сукканны вә какканны
күтәрдем мин ятим».
Г. Тукай.

Ис тә китми бит минем. Холкым
шулай шул, нишләтим.
М. Хөсәен.

ЮЗИЛ эпиграммасы.

күптән ачыкланган факт: хайваннар турындагы әкиятләр, тылсымлы һәм тормыш-көнкүреш әкиятләре. Әкият томнары киләчәктә дә чыга торыр. Һәм аларны әнә шул бүленеш нигезендә чыгару хәерлерәк булыр шикелле.

Халык иҗаты китабының төп өлешен алып торган әдәби текстлардан соң фәнни җыентыкларда (ә кайвакыт фәнни-популяр басмаларда да) «Искәрмәләр» яки «Аңлатмалар» бүлеге урнаштырыла. Аларның сыйфатын ачыклау өчен, югарыда телгә алынган кайбер китапларның соңгы битләрен актарып карыйк. «Аңлатмалар»да сүз гадәттә әсәрне кайчан, кайда, кем язып алганлыгы яки нинди башка төр чыганактан (китап, кулъязма) алынганлыгы күрсәтелә. Бу мәгълүматлар нинди әсәрләрнең кайсы якларда һәм ничек таралганлыгын, татар халкының төрле этник төркемнәре фольклорының эчтәлеген, шигъри үзенчәлекләрен, аерым җырчы-әкиятчеләрнең репертуарын, татар фольклорының географик чикләрен ачыкларга ярдәм итә. Мондый искәрмәләрнең әһәмияте бәхәссез. Кайбер китапларның искәрмәләре югарыда телгә алынган мәгълүматлар белән генә дә чикләнми. Андый аңлатмаларда аерым әсәрләрнең үзенчәлекле сыйфатлары, барлыкка килү чоры, халыкның борынгы ышанулары һәм карашлары белән бәйләнеше, талантлы җырчы-әкиятчеләрнең репертуары, халык иҗаты әсәрләренең яшәү формалары турында киң мәгълүматлар бирелә. Бу очракта искәрмәләр яки аңлатмалар мөстәкыйль әһәмияткә ия булган җитди фәнни хезмәт булып әверелә. Әнә шундый искәрмәләр белән тәэмин ителгән җыентыклар рәтенә мин иң элек Нәкый ага Исәнбәтнең «Балалар фольклоры», «Табышмаклар», «Татар халык мәкальләре» китапларын кертер идем. Бу җыентыклар үзләренең кереш мәкаләләре һәм конкрет материаллары белән генә түгел, ә бәлки искиткеч бай һәм җитди аңлатмалары белән дә кыйммәтле чыганак булып тора. Мондый киң һәм җитди аңлатмалар белән чыккан җыентыклар бездә әллә ни күп түгел. Ләкин бар. Биредә мин тагы да И. Надировның «Татар халык җырлары»н күрсәтер идем. Андагы искәрмәләр нигезендә җырларның чыганакларын гына түгел, аларның кайсы якларда ничек таралганлыгын, эчтәлеге һәм формасына караган үзенчәлекләрен, аерым җырчыларның репертуарын күз алдына китерергә мөмкин. Үз гомерендә күп санлы әкият, бәет вә җырлар җыйган һәм төрле җыентыклар төзеп чыгарган Хәмит ага Ярминең «Бәетләр»ендә һәм «Татар халык әкиятләре»нең 1—2 китапларында да киң генә аңлатмалар бирелгән.

Шулай да, безнең көннәрдә татар фольклор фәненең шактый алга китүенә карамастан, кайвакыт аңлатмалар шактый түбән сыйфатлы була. Югарыда кат-кат телгә алынган «Татар халык көйләре» җыентыгына тагы бер тапкыр тукталыйк. Бу китаптагы Ю. Виноградов тарафыннан төзелгән аңлатмаларда сүз бик күп төрле әйберләр турында бара. Кайбер искәрмәләрнең бөтенләй кирәге юк. «Сикереп төштем» җыры турында, мәсәлән, мондый аңлатма бирелгән: «Хатын-кызларның элеккеге замандагы авыр язмышын чагылдырган күп җырларның берсе». Моның шулай икәнлеге җырның сүзләреннән дә күренеп тора лабаса. Янсә менә «Анам кабере янында» әсәрен «ятимнәр җыры» дип аңлату нәрсәгә кирәк булды икән! Аңлатмалар арасында бөтенләй аңлашылмаганнары да бар. Мәсәлән, «Яшә, республикам!» җырына бирелгән аңлатмада мондый юллар бар: «Батырлык һәм көч символы булган арысланнарны телгә алу татар фольклорында еш очрый». Ә җырның текстында берниндн арыслан юк...

1964 елгы «Татар халык көйләре»нә мин шактый киң тукталдым. Чөнки ул халык иҗатына, аның идея-эстетик әһәмиятенә игътибарсызлыкның «классик» үрнәге булып санала ала. Моны мин күп мисаллар белән исбат итәргә тырыштым. Җыентыкның күп төрле кимчелекләре булуга карамастан, А. Юсфин исә аңа югары бәя биреп, «замечательный сборник» дип язып чыкты («Советская Татария» газетасы, 1965 ел, 24 март).

Югарыда сөйләгәннәрдән фольклор җыентыгының нинди булырга тиешлеге беркадәр аңлашылса кирәк. Яхшы әзерләнгән фәнни китапларда тирән эчтәлекле һәм киң мәгънәле кереш мәкаләләр, халык иҗаты әсәрләренең чын мәгънәсендә сәнгатьчә яңгыраганнары, аларның чыганакларын һәм җитди үзенчәлекләрен ачып бирердәй аңлатмалар була. Фәнни җыентыкның һәркайсы әнә шул таләпләргә җавап бирергә тиеш.

Китапка кергәнче халык иҗаты әсәре редакцияләнә, әлбәттә. Әмма редакцияләү әсәрнең асыл табигатенә — сюжетына, төп образларына, композициясенә кагылмаска тиеш. Ләкин телен, әгәр ул диалекталь сүзләр белән артык чуарланган булса, беркадәр редакцияләү кирәк шикелле. Алай да

бу турыда махсус әйтелгән булырга тиеш. Диалекталь сүзләргә килгәндә, фольклор әсәрендәге үзенчәлекле тәгъбирләр, билгеле бер этник төркемнең көнкүреше, йолалары, ышанулары, ягъни этнографиясе белән бәйләнгән сүзләр һәм җөмләләр сакланганда яхшырак була, әлбәттә.

Халык иҗаты әсәрләрен бастырып чыгару турында сүз кузгалгач, тагы бер-ике җитди мәсьәләгә кагылып үтәргә кирәк шикелле. Иң элек безгә татар фольклоры әсәрләрен русчага тәрҗемә итеп чыгару турында уйланырга кирәк. Дөрес, кайбер әсәрләр бездә русчага яхшы гына тәрҗемә ителгән һәм басылып та чыккан. «Татар поэзиясе антологиясе»нең русчасында халык җырлары белән бәетләрнең шигъри тәрҗемәләре бирелгән. Аерым китаплар да бар. Татар халык әкиятләреннән Х. Ярми тарафыннан балалар өчен русча төзелгән берничә җыентык басылып чыкты. Әмма әлегә кадәр татар халык поэзиясе әсәрләрен туплап рус телендә чыккан бер генә җитди фәнни җыентык та юк. Бу яктан без тугандаш төрки халыклардан һәм үзебезнең күршеләрдән шактый артта калдык. Моңа кадәр мәгълүм булган эпосларның иң зурысы — кыргызларның «Манас»ыннан аерым күренешләр, үзбәкләрнең «Алпамыш»ы, буряtларның «Гәсәр»е, казакъларның төрле дастаннары, кыргыз, үзбәк, казакъ, каракалпак һәм якутларның әкиятләре, мәкаль-әйтемнәре һәм башкалар рус телендә кат-кат басылып чыкты. Хәзер рус телендә мордва халык иҗатының 8 томлыгы чыга. Ә безнең халык иҗатының милли-оригиналь төре булган бәетләр дә әлегә кадәр русча чыга алганы юк! Һәм бу гына да түгел! Безнең халык иҗатының кайбер жанрларын тәшкил иткән классик әсәрләр әлегә кадәр татарча да рәтләп басылганы юк. Димәк, басылып чыккан китаплар нигезендә генә татар халык иҗатының бөтен байлыгын күз алдына китереп булмый. Сүз биредә аерым әсәрләр турында гына бармый, билгеле. Аларның һәрвакыт яңалары иҗат ителер, язып алыныр һәм иң матурлары басыла торыр. Сүз аерым жанрлар турында бара. Биредә без иң элек татар халык эпосы турында уйланырга тиеш булабыз. Аның бездә гомумән акрын өйрәнелүе һәркемгә мәгълүм факт. Һәрхәлдә, татар халык иҗаты буенча вуз программаларында һәм лекцияләрдә милли эпос турында бернәрсә дә әйтелми. Һәм моңа гаҗәпләнерлек тә түгел. Чөнки безнең бар дастаннарыбыз да XX йөздә бер тирәгә тупланып басылганы юк. Хәзер Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор фондында «Кузы-Көрпәч белән Баян-сылу» дастанының 16 варианты бар. Бер вариант В. В. Радловның мәгълүм китабында басылган. Киләчәктә әнә шул 17 вариант нигезендә дастанның ике-өч зур җыелма вариантларын төзеп бастырганда, гаять яхшы булыр иде. Болардан кала төрле чорларда, төрле җирләрдә язылып алынган, кайберсе басылып та чыккан дастаннардан «Алпамша»ның әкияткә якын торган вариантын, казакъ халкында зур эпик поэма буларак мәгълүм булган, бездә шулай ук әкият формасында сакланган «Дутан батыр»ны, «Ак Күбек», «Кара Куккел», «Гүруглы» кебек әсәрләрне күрсәтергә кирәк. Тел, әдәбият һәм тарих институтында «Йосыф-Зөләйха», «Таһир-Зөһрә», ««Сәйфелмөлек», «Буз егет» кебек китаби дастаннарның соңгы елларда халыктан язып алынган вариантлары да бар. Аңлашыла ки, татар халык эпосы буенча да конкрет материал юк түгел. Аларның барысын бер тирәгә туплап, кирәк дәрәҗәдә редакцияләп, киң фәнни аңлатмалар белән бастырып чыгару — безнең эпосны өйрәнүдә беренче җитди адым булыр иде.

Риваять-легендалар һәм мәзәк-мәсәлләр буенча да ярыйсы ук бай конкрет материал тупланган. Киләчәктә халык иҗатының моңа кадәр рәтләп өйрәнелмәгән бу төрләренә багышлап та махсус академик томнар әзерләнер дип ышанырга кирәк.

Димәк, татар халык эпосы, риваять һәм легендалар буенча махсус җыентыклар әзерләү белән бергә, тугандаш халыклардан үрнәк алып, татар халык әкиятләреннән, җырлардан, афористик әсәрләрдән, бәетләрдән торган русча зур-зур фәнни томнар ясә татар халык иҗатының төп жанрларын эченә алган күләмле антология чыгару — безнең бүгенге филологиянең актуаль бурычы.

# БӘЛӘКӘЙ РЕЦЕНЗИЯЛӘР [1]

**Г. СӘГЫЙРОВ. Тормыш җиле. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел**

Тормыш җиле... Кайчагында ул кешене үз кочагына бөтереп ала да яңадан тора алмаслык итеп аягыннан ега. Ләкин кеше бирешми, мәрхәмәтсез язмыш иркенә буйсынырга теләми. Җиргә, кешеләргә булган мәхәббәте аңа, табигать корып куйган киртәләрне җимереп, көрәшчеләр сафында атлап барырлык рухи көч бирә. Бернинди авырлыклар, тормышта очрый торган күп санлы каршылыклар алдында баш имәгән шундый егетләрнең берсе булган Гакыйль Сәгыйров белән укучы инде байтактан таныш. Аяк-куллары хәрәкәтсез калып, урынга егылгач та ул башкалар бәхете хакына көрәшүче кыю солдат булып кала. Илгә, халыкка хезмәт итү өчен үзенең беркайчан да хыянәт итмәс коралы, якын киңәшчесе, тугрылыклы дусты һәм аерылмас юлдашы итеп Гакыйль поэзияне сайлый...

Бу яшь шагыйрьнең беренче иҗат үрнәкләре белән укучы «Ялкын», «Казан утлары», «Азат хатын» журналлары, «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре» һәм «Социалистик Татарстан» газеталары аша таныш. Узган ел аның шигырьләре, аерым җыентык булып, Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты. Анда сайлап алынган шигырьләрнең күбесендә тормышка, үзенең ил-җиренә бөтен барлыгы белән гашыйк егетнең эчкерсез уйлары, иң матур хыяллары, якты өметләре гәүдәләнә.

Топольләрем, уйчан топольләрем —
Кошларымның яшел бишеге.
Топольләрем җирне ямьләндереп,
Мәңге аумый яшәр шикелле.
...Көне нинди якты, күге нинди,
Самолетлар юллар ясаган!
Берәр меңне яшәп, тагын берне
Җибәрәмсең башлап яңадан...

«Аяз иртәләрдә...» дип башланган бу шигырьдәге тирән мәгънәле фикерләр «Кирәк түгел андый-мондый бәхет», «Күл буенда имән белән каен», «Карлар бүген», «Больницада», «Яшерим мин кемнән яшьләремне» шигырьләрендә тагын да көчлерәк, образлырак итеп әйтелә. Кайбер шагыйрьләр шикелле төшенкелеккә бирелү, укучыны «кызгандыра» торган шигырьләр язарга тырышу Гакыйль Сәгыйров иҗатына бөтенләй ят нәрсә. Нинди генә темага, нинди генә вакыйгага нигезләнеп язылган булмасыннар, аның шигырьләре укучы күңелендә оптимистик хисләр, саф тойгылар уяталар. Менә шуңа ул шигырьләрдәге лирик герой шагыйрьнең генә түгел, бүтәннәрнең дә рухи туганына әверелә. Менә шуңа күрә дә Гакыйль кешеләрне шатландыра, канатландыра, биеклеккә омтылдыра торган шигырьләр тудыруны үзенең төп иҗат принцибы дип саный. Ләкин бу әле шагыйрь җирдәге һәм кешеләр йөрәгендәге борчуларны, сагыш-моңнарны читләп үтә икән дигән сүз түгел. Тормыштагы шатлык-кайгылар да, сөенеч-көенечләр дә Гакыйльнең нечкә хисле күңеленә бер үк дәрәҗәдә тәэсир итә, аны бер үк дәрәҗәдә дулкынландыра. Әмма шунысы куанычлы: теләсә нинди очракта да аның шигырьләрендә рухи күтәренкелек, кешенең үз көченә ышануы, һәртөрле кыенлыкларны җиңәргә сәләтле булуын тоюы өстенлек ала. Моның шулай икәнлеге «Яшерим мин кемнән яшьләремне» дип башланган шигырьдә дә бик ачык күренә:

Яшерим мин кемнән яшьләремне —
Мескен диеп
Җәлләр өчен акмый яшьләрем.
Бу көнгәчә дуслар күңеләнә
Мин кызгану хисе чәчмәдем.
...Ирләр еш еламый...
Еласа да
Көчсезлектән түгел елавы:
Яше аның текә ярларыннан
Ташып чыккан дәрья сулары.

«Тормыш җиле» җыентыгының «Нәни дусларга» дип аталган бүлегенә яшь шагыйрьнең балалар өчен язган шигырьләре урнаштырылган. Алар киләчәктә Гакыйль-

[1] Бу сандагы рецензияләрне Рәшит Гәрәй һәм Ренат Галәвиннар әзерләде.

нең кечкенәләр өчен дә әйбәт шигырьләр яза алачагына ышаныч тудыралар.

Китапның эчендә табигать, шулай ук авыл күренешләрен сурәтләгән һәм бер карау белән күңелне үзенә җәлеп итәрлек матур-матур рәсемнәр бар. Ул рәсемнәрне дә Гакыйль үзе ясаган. Аларны караганда күз алдына нечкә хисле, киң табигатьле яп-яшь егет — туган җирен, замандашларын сөеп туя алмаучы шагыйрь һәм рәссам килеп баса. Җыентыкны төзегән һәм аңа сүз башы язган шагыйрь Илдар Юзеев әйткәнчә, язмыш Гакыйль Сәгыйровның тормыш кылларын өзәргә уйлаган. Ләкин бернигә тә егетнең күңел кылын өзә алмаган. Ул әнә шул өзелмәс нечкә кылда тагы да матуррак уйнар әле.

**М. ФӘЙЗУЛЛИНА. Энҗе чәчәк. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел**

Шагыйрә Марзия Фәйзуллина кече яшьтәге мәктәп балаларына багышлап чыгарган яңа җыентыгын «Энҗе чәчәк» дип атаган. Китапның беренче битен ачу белән, кулларына чәчәк бәйләмнәре тоткан көләч йөзле шат балалар күзгә ташлана. Мәктәп бусагасын беренче тапкыр атлап кергән бу бәхетле сабыйлар хуш исле әлеге чәчәкләрне укытучы апаларына бүләк итеп бирер өчен алып килгәннәр. «Беренче дәрес» шигырендә автор әнә шул хакта сөйли. Һәркем түземсезлек белән көтеп ала торган олы бәйрәмнәргә карата язылган мондый шигырьләр җыентыкта шактый күп. Ул шигырьләрнең берсе «Май бәйрәме» дип атала. Юрий Гагарин булып киенеп, әбисе белән бергәләп урамга демонстрация карарга чыккан кечкенә малай турында шагыйрә менә болай дип яза:

Ул ракетага утырган,
Кигән күзлекле бүрек.
Барлык балалар сокланып
Яшь космонавтны күреп.

Нәниләр күңеленә кереп калырлык мондый җыйнак һәм гади строфаларны «Ике көрәк», «Электр уты кабынгач», «Өлкән группага күчкәч», «Атлар эчерткәндә», «Суган турагандa», «Кырда», «Чебиләр», «Камыш уены», «Мырауҗан», «Үрмәкүч», «Миләш», «Көз», «Күләгә» кебек шигырьләрдә дә очратырга мөмкин. Үзенең шигырьләрендә Марзия Фәйзуллина укучыларны бәләкәйдән үк эш сөеп үсәргә, өлкәннәрнең сүзеннән чыкмаска, зирәк һәм акыллы булырга өнди. «Аннан-моннан» дип аталган бүлеккә тупланган кайбер шигырьләрне укыганда, шагыйрәнең балалар телен яхшы белеп, кыска һәм аңлаешлы итеп язарга сәләте барлыгын тоясың. Моны бигрәк тә «Чәче», «Мендәре», «Ник яңа дәфтәр алган», «Таш диеп җавап биргән», «Аннан-моннан акланган», «Горчицаны бал диеп» шигырьләренә карата әйтергә була. Әлеге шигырьләрендә шагыйрә балалар холкын, аларның бер-берләренә һәм үзләрен чолгап алган мохитка булган мөнәсәбәтләрен табигый, ышандырырлык итеп тасвирларга тырыша. «Мендәре» шигырендә ул, мәсәлән, дәрескә соңга калып килгән укучы хакында түбәндәгечә яза:

Мәктәбенә соңга калса,
Ул болай дип аңлата:
Имеш, ул түгел... Мендәре
Йоклатырга ярата.

Укучыны елмаерга мәҗбүр итә торган мондый юмористик юллар җыентыктагы башка шигъри парчаларда да байтак.

Ләкин, шуңа да карамастан, китаптагы аерым шигырьләрне укып чыкканнан соң күңелдә канәгатьсезлек хисе туа. Моны раслау өчен, барыннан да элек, «Флаг йөртүчеләр», Язгы чәчүдә», «Кызык тәлинкә», «Күз өстендә каш нигә», «Нәни булышчы», «Туган көн юкка чыккан», «Тузаннар», «Үтәли җил», «Салават күпере» шигырьләрен күрсәтеп үтәргә кирәк. Саналып кителгән әлеге шигырьләр ясалма сюжетка корылганнар һәм чын поэзия әсәрләре булудан шактый ерак торалар. Ул шигырьләрнең төп кимчелеге шунда: автор аларда үз-үзен кабатлый, укучыга бер үк нәрсәләрне кат-кат тәкъдим итә, алынган теманы шигъриятькә хас булган үтемле алымнар ярдәмендә чишеп бирү турында кирәгенчә уйланмый. «Эш сөям», «Озату кичәсе», «Нәни булышчы», «Аумас курчак», «Ял көнендә», «Скрипач курчак», «Сиздермичә», «Поезд», «Кем ул», «Тузаннар», «Яңа квартирада» шигырьләренең һәркайсында курчаклар турында сөйләнә. Әмма ул шигырьләр бер-берләренә ике тамчы су кебек охшаганнар һәм поэзиягә әллә ни яңалык алып килмиләр. Җыентыкның ахырына урнаштырылган табышмак-шигырьләр дә халык телендә элек-электән йөргән һәм һәркемгә таныш булган нәрсәләрне рифмалы юлларга тезеп чыгудан узмаган. Кайбер шигырьләрдә исә тел кытыршылыгы үзен нык сиздерә. «Кабат килдек тагын да», «урманга рәхмәт әйтергә бар авазны тупладык», «кулын яфракка илтте», «башбаштак кылып йөрдек» шикелле сүз тезмәләре кечкенәләргә түгел, олыларга да авыр аңлашыла. Әгәр автор язганнарын дөньяга чыгарганда талымсызлык күрсәтмәгән булса, тиешенчә эшләнеп бет-

мәгән шигырьләргә җыентыкта, әлбәттә, урын бирелмәгән булыр иде. Яңа әсәрләрен матбугатта бастырырга әзерләгәндә киләчәктә шагыйрә бу хакта да ныклап уйланырга тиеш.

**ЗӘКИ НУРИ. Озын сүзнең кыскасы. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел**

Укучылар шагыйрь Зәки Нурины нигездә кыска шигырьләр авторы буларак беләләр. Шигырь язганда ул һәр очракта диярлек тормышта үзе күргән, үзе кичергән яки башкалардан ишетеп белгән вакыйгаларга, гыйбрәтле һәм мәзәк күренешләргә мөрәҗәгать итә. Аның узган ел Татарстан китап нәшриятында басылган «Озын сүзнең кыскасы» исемле яңа җыентыгы да әнә шундый кыска шигырьләрдән, җырлардан, этюд һәм шигъри репортажлардан, төрле сурәтләргә карап язылган эскизлардан, мәзәкләрдән тора. Аларны шагыйрь тематик яктан өч бәйләмгә бүлеп урнаштырган. Беренче бәйләм «Ярату сүзе» дип атала. «Мәхәббәт бетсә әгәр...» шигыре белән ачылган бу бәйләмгә шагыйрь күбесенчә яшьлек, мәхәббәт һәм дуслык турындагы шигырьләрен туплаган. «Яфрак яуган бер чакта», «Ут күземә дүрт сүзем», «Су буенда яшел куак», «Килерсең әле, килерсең», «Ышан», «Таң чаңы» дигән җырларга да шул ук шигырьләр арасында урын бирелгән.

Соңгы вакытта Зәки Нури иҗатында кешенең эчке кичерешләрен, табигать күренешләрен үз йөрәге аша үткәреп, белеп тасвирлаган яңа поэтик картиналар, шигъри детальләр шактый еш очрый башлады. Моның матур мисалларын без «Озын сүзнең кыскасы» җыентыгында да күрәбез. Югарыда телгә алынган бүлектәге «Торналар» шигыренең соңгы юлларын укыганда, мәсәлән, күңелне олы бер хис — туган җиргә булган мәхәббәт хисе били:

Җирне кошлар ике якка бүлә —
Берсе җылы, берсе салкын як.
Ә уйлары нәкъ безнеке кебек:
Тик туган як җирдә — алтын як.
Маяк булып, кояш, күтәрел син,
Тарал юлда тизрәк, күк томан!
...Тезелгәннәр кошлар җылы якны
Салкын якка тоткан җеп сыман.

Тормышында тынгылык белмәгән һәм күп вакытын юлда үткәрергә, һәр җирдә кешеләр белән якыннан аралашырга яраткан шагыйрь илебезнең төрле почмакларына әледән-әле сәяхәт кыла, ерак Польша җирләренә барып чыга. Үзе булган урыннардан татар укучыларына ул әр-яңа шигырьләр алып кайта. Шул шигырьләрнең бер өлеше җыентыкның «Бәйрәм бәйләме» н тәшкил иткән. Андагы «Җыр белән очрашу», «Шушь елгасы буенда», «Тауларга менү», «Сулар төшә таш алып», «Диңгез күзе» шигырьләрендә Зәки Нури сөекле юлбашчыбыз Ленинның Казанда, Себердә һәм Польшада яшәгән еллары турында сөйли. «Салют-букет» шигырендә ул даһи Ильич тарафыннан төзелгән туган республикабызның уңышларын күреп сөенә, «Чавай чишмәсе» шигырен мари халкының әкиятләрендә һәм легендаларында сөйләнгән Чавай батыр исемен үзенә әдәби псевдоним итеп алган күренекле язучы һәм культура эшлеклесе Сергей Григорьевның якты истәлегенә багышлый. «Кәләпүш», «Арарат», «Вислада су кергәндә», «Күкрәүле яңгыр» шигырьләрендә без төрле милләт вәкилләре — җирдә бер үк теләк, бер үк идеал белән янып яшәүче якын дусларыбыз белән очрашабыз. Илен, туган җирен, дусларын яңа бәхетләр белән куандырыр өчен көрәшле, авыр юлдан атлаучы һәм максатына карап барганда ару-талуларын онытткан юлчының уй-теләкләрен шагыйрь «Офык» шигырендә менә болай тасвирлый:

Кеше — юлда. Кеше һаман ашыга.
Җәяүләп тә, самолетта очып та.
Шунда гүя аның бөтен бәхете,
Бар шатлыгы гүя шушы офыкта.

Сине һаман алга чакырып, еракка дәшеп торган киң офык сызыгын кем сызган соң, дигән сорауга автор бик матур итеп җавап бирә:

Ленин сызган барчабызның офыгын
Уч төбендә кояш тоткан кул белән!
Җитеп булга аңа бары көрәштә
Һәм хезмәттә җиңеп узган юл белән.

Зәки Нури — татар совет поэзиясендә сатира-юмор жанрын үстерүгә үзеннән шактый зур өлеш керткән шагыйрьләребезнең берсе. Аның бу жанрда язылган кайбер яңа шигырьләре белән җыентыкның «Чәнечкеле бәйләм» бүлегендә танышабыз. Ул шигырьләрнең күбесе «Бу уклар кемгә тияр», «Таныш затлар түгелме», «Озын сүзнең кыскасы», «Ут чәчеп һәм ук чәнчеп», «Нәни Күпбелмеш сөйли» дип исемләнгән аерым циклларга тупланып басылганнар. Бер яки ике генә строфадан торган сатирик диалогларда, аерым типларга аталып язылган шигъри фельетоннарда, хроника һәм мәзәк-ирониялардә шагыйрь тормышыбызның алга таба үсешен тоткарларга маташучы хорәсәннәрне, кире фикерле, ваемсыз кешеләрне тәнкыйть уты астына ала, алардан

ачып итеп килә. Ләкин биредә шуны да әйтеп үтәргә кирәк: әлеге циклларда үзләренә йөкләтелгән вазифаны тәгәл үтәгән «Гыйбрәт өчен», «Хушлашканда», «Кәтелмәгән», «Кем кемне кыса», «Бәйләнчек ир», «Кыйммәтле кияү» шикелле шигырьләр арасында авторның әйтергә теләгән фикерен ахырынача ачып бирә алмаган, поэтик яктан йомшак эшләнгән дуртьюллыклар да очрый.

Ә гомумән җыентыкка карата булган төп фикеребез, шагыйрь үзе әйтмешли, озын сүзнең кыскасы... шул: андагы шигырьләр белән танышып чыккан укучы көндәлек тормышыбыздагы вакыйгаларга битараф кала алмый. Ул шигырьләр кешедә Ватан-анага мәхәббәт, туган туфракка, бергә-бергә гомер иткән дус-ишләргә мәхәббәт, алга китешебезгә комачаулык ясарга тырышучыларга — бюрократларга, ялагайларга, ялкауларга, икейөзлеләргә тирән нәфрәт хисе тәрбияли. Китапның уңай ягы барыннан да элек әнә шунда.

**А. СӘЛАХЕТДИНОВ. Туган җирем — Татарстан. Очерклар һәм юльязмалар. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел**

Узган ел республикабыз хезмәт ияләре Татарстан АССРның төзелүенә 50 ел тулуны тантаналы тәстә билгеләп үттеләр. Шушы олы юбилейга әзерлек көннәрендә язучыларыбыз һәм журналистларыбыз Татарстанның узганы һәм бүгенгесе, аның атаклы кешеләре, социаль һәм культура тормышындагы үзгәрешләр турында күп кенә яңа әсәрләр тудырдылар. Ул әсәрләр арасында Абдулла Сәлахетдиновның очерклар һәм юлъязмалар җыелмасыннан торган «Туган җирем — Татарстан» дигән китабын да күрәбез.

Җыентыкның сүз башында автор укучыны үзе белән бергә республика буйлап сәяхәткә чыгарга чакыра. Шактый озынга сузылган бу сәяхәт дәвамында ул тугыз урында тукталыш ясый. Аның беренче тукталышында язган очеркы «Тимеркәй оныклары» дип атала. Очеркның баштагы өлешендә моннан күп еллар элек Казан губернасының Тау ягында яшәгән Тимеркәй исемле кешенең авыр язмышы, ә икенче бүлегендә аның оныкларының нур белән бизәлгән якты тормышы, искиткеч матур эшләре тасвирлана.

А. Сәлахетдинов үзенең әлеге очеркында «КПСС тарихы»ннан менә мондый бер җөмлә китерә: «Днепростройда һәм Магнитостройда алдынгы бригадалар бетон салу буенча дөнья рекордлары куйдылар...» Аннан соң автор партия тарихында әйтелгән дөнья рекордын Тау ягы кешеләре — яшьләре белән Тимеркәйгә онык тиешле Хәбибулла Галиуллин бригадасы егетләре куйганлыгын әйтеп үтә.

Исеме бөтен илгә таралган һәм бетон салу буенча дөнья күләмендә рекорд яулау дәрәҗәсенә ирешкән Хәбибулла Галиуллин илнең югары бүләге — Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. Үзек газеталар үзләрен эштә аямаган Татарстан егетләренең героик хезмәтләре турында күп тапкырлар язып чыгалар. Күренекле рус язучысы Валентин Катаев «Вакыт, алга!» романында Галиуллин бригадасының дөнья рекорды яулауга ирешкән көнен сурәтли. Шагыйрь Александр Ворошилов, аларга багышлап, «Дөнья рекорды турында җыр» исемле поэма иҗат итә.

Җыентыктагы башка очерклар да якташларыбызның эштәге фидакарьлеге турында сөйләгән гаять бай фактик материалларга нигезләнеп язылганнар. Ул очеркларның күбесендә элекке тормыштан алынган кайгылы вакыйгаларны Октябрь кояшы балкыганнан соң халкыбызның тормышка ашкан уй-теләкләрен чагылдырган якты күренешләр алыштыра. «Язмышларны замана яза» очеркын укып чыккач, авылдан ерак калага сатарга алып барылучы яшь кызларны күз алдына китереп әрнисең. Шул очеркның ахырында Апас районының Дәвеш авылында туып-үскән һәм терлекчелек фермасында эшләгән алдынгы сеңелләрнең колхоз биргән путевка белән Кавказга ял итәргә китүләрен ишетеп, куанып бетә алмыйсың.

Язучының алдагы тукталышы — Бөгелмәдә. Бу тукталышта язылган сәхифәләр укучыны Бөгелмәнең революциягә кадәрге хәле, интервенция елларында ул тирәләрдә барган сугышлар, шул сугышларда халык бәхете өчен гомерләрен биргән үлемсез каһарманнар, шәһәрнең хәрби комендантны ярдәмчесе вазифаларын башкарган күренекле чех язучысы Ярослав Гашекның Бөгелмәдә яшәгән дәвердәге эшчәнлеге, Татарстанда Совет власте урнашкач, бу якларның йөзен үзгәрткән яңарышлар, нефть фәнни-тикшеренү институты галимнәренең тынгысыз хезмәтләре белән таныштыра. «Урал тау итәгендә» очеркында республикабызда беренче булып «кара алтын» эзләп табучылар, танылган монтажчылар, бораулаучылар, тозучелар, «Индустрия бастионнары» дип исемләнгән язмаларда Миңлебай

газ заводын коручылар белән очрашабыз.

Җыентыктагы кайсы гына очерк яки юлъязманы укыма, анда синең күз алдыңа Татарстан җирендә калкып чыккан әр-яңа гигантлар һәм аларга тормыш сулышы өргән баһадир йөрәкле кешеләр килеп баса. «Йолдызларны Зәй кабыза», «Яшьлек каласы өмәдә», «Кама буйларында яңарыш», «Кояшлы кырлар киңлеге» язмаларында республикабыз тормышындагы үзгәрешләр аеруча калку итеп сурәтләнә. Татарстанның данын еракларга тараткан Зәй ГРЭСы, Түбән Камадагы химия комбинаты, елгачылар һәм тукучылар, бетон ясаучылар һәм нефтьчеләр, төзүчеләр һәм энергетиклар шәһәре — Чаллы, андагы иң зур төзелеш — автомобиль заводларының гигант комплексы, киләчәккә карап, ишекләрен киң итеп ачкан Менделеевск, Чистай районының «Татарстан» колхозы... Югарыда телгә алынган юлъязмаларны укыганда, гүя без үзебез дә әнә шул җирләрдә йөрибез. Андагы зур эшләр, җирне яшәртү өчен үзләреннән лаеклы өлеш кертүче кешеләр күңелдә горурлык хисе уяталар.

Сәяхәтнең ахырында автор яңадан Казанга әйләнеп кайта һәм туган башкалабызның киләчәге турында укучы белән җанлы әңгәмә алып бара. Китапның соңгы битен ябып куяр алдыннан ул әйткән сүзләрне син дә үз сүзләрең итеп кабатлыйсың:

— Якты өметләр һәм зур ышанычларны юлдаш итеп, шәһәр буйлап атлыйм. Казанымның киләчәгенә, Татарстан башкаласының тиздән туачак яңа таңнарына барам...

Җыентыкка кергән очеркларны язу өчен материал туплауга автор бик күп хезмәт куйган һәм үзе күреп белгәннәрне, башкалардан ишеткәннәрне гади итеп, җиңел тел белән хикәяләп бирә алган. Озак эзләнүдән соң табылган күп санлы архив документларын очеркларда оста файдалану, республика тормышындагы төрле вакыйгаларны һәм күренешләрне чагылдырган фоторәсемнәр урнаштыру исә китапның эчтәлеген тагын да баета төшкән. Мондый характердагы китаплар алдагы көндә дә даими рәвештә чыгарылып барсын иде. Укучы әнә шуны тели.

**Р. ХАФИЗОВА. Кирлемән. Әкиятләр һәм хикәяләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел**

Роза Хафизованың кече яшьтәге мәктәп укучыларына атап чыгарылган яңа китабы «Кирлемән» дип атала. Китап ике бүлектән тора. Беренчесенә әкиятләр, икенчесенә хикәяләр тупланган.

Комда чокыр казып уйнаганда Салихның көрәге ниндидер каты әйбергә тиеп китә. Казып чыгарса, ни күзе белән күрсен, ком өстендә — нәни генә бер малай. Күзләренең берсе бер якка, икенчесе икенче якка караган. Бер кулы озын, икенчесе кыска. Башы тап-такыр. «Кем малае син?» — дип сорагач, ул: «Беркемнеке түгел. Мин — Кирлемән!» — дип җавап бирә. Һәм шунда ук саф күңелле, тиз ышанучан малайларны һәм кызларны алдый башлый, киреләнергә, сүз тыңламаска өйрәтә.

Җыентыктагы «Кирлемән» дигән әкият әнә шулай башланып китә. Әсәрне, Кирлемән тагын нинди начарлыклар эшләр, тагы кемне юлдан яздырыр икән дип, борчылып һәм дулкынланып укыйсың. «Ник сайрамый сандугач» дигән бүлек Кирлемәнгә карата бигрәк тә нык ачу тудыра. Аннан әшәкелеккә өйрәнгән бер малай оядан ике сандугач баласын тотып ала һәм һавага очыртып уйный башлый. Алар җиргә егылып, бәрелеп үләләр, билгеле...

Кирлемәннең кыланышлары чамадан ашып китә һәм бервакыт ул сизгерлеген югалта. Шунда аны эләктереп алалар. Пионерларның карары нык була: балаларга зыян китергәне, аларны начарлыкка өйрәткәне өчен, аны капчыкка салып җиргә күмәләр.

«Мияубикә сые» да мавыгып укырлык итеп язылган. Бу әкияттә бер явыз песи турында сөйләнелә. Кунакка чакырган булып, ул кошларны тотып ашарга уйлый. Ләкин теләгенә ирешә алмый кала. Өйалды астыннан Сарбай килеп чыккач, эләктергән кошларны да ычкындырып, тиз генә качарга мәҗбүр була. «Мәк чәчәкләренең сере» дигән әкият убырлы карчыкны һәм аның ялчыларын җиңгән тимерче карт турында. Борын-борын заманда биек таулар артында бер убырлы карчык яшәгән. Гомер буе кешеләрне рәнҗеткән, аларга гел начарлык эшләп килгән. Ул әнә яхшы күңелле Миңсылуга да куптән теш кайрап йөри икән. Шулай бервакыт убырлы карчык каз бәбкәсенә әверелә дә кызны, алдалап, кара урман эченә алып кереп адаштыра. Кая барырга, нишләргә белмәгән Миңсылу челтәрләп-сырлап ясалган күпер күрә, теге якка чыгу өчен күпер өстенә менүе була — күпер мәче башлы зур ябалакка әверелә һәм кызны упкынга илтеп ташлый. Ләкин убырлы карчык озак тантана итә алмый. Сөекле оныгының һәлак булуын белгән

тимерче карт урман артындагы шәрә кыяны убырлы карчык белән бергә упкынга олактыра.

Икенче бүлеккә биш хикәя кертелгән. «Рекс нигә үпкәләде?» исемлесе күңелдә веруча җылы тәэсир калдыра. Рекс кушаматлы озын сыйраклы эт Нияз белән бик дус була. Ул малайны көн саен күрше авылдагы мәктәпкә озата бара, дәресләре беткәнче аны көтеп утыра, мәктәптән чыгуга, Ниязның сумкасын күтәреп кайта.

Көннәрнең берендә бу дуслык бозыла да куя. «Ни өчен?» — дисезме. Бу хәл болай була. Нияз үз авылына кайтырга чыккач, күз ачкысыз буран куба. Чаңгыда була торып та Нияз карга батып-батып китә. Әтккә бигрәк тә кыен. Җитмәсә, аның авызында сумка бар. Шулай да көч-хәл белән исән-сау кайтып җитәләр болар. Өйгә кергәч, Нияз туйганчы ашый да җылынып, төшләр күрә-күрә йокыга тала. Рекс та бик ачыккан, арган һәм туңган була. Ләкин малай аны исенә дә алып карамый. Иртәгесен мәктәпкә барырга чыккач, Нияз этен бик озак чакыра. Ләкин Рекс аңа иярми. Нишлисең бит, кунак ашы кара-каршы. Үз җаен гына кайгырткан, башкалар хәлен онытканы өчен, Нияз дустын югалта.

«Яңа курчак», «Юлда» хикәяләре дә матур язылган, ләкин аларның ахыры табылып җитмәгән, тәмамланулары уңышлы түгел. Шуңа күрә бу хикәяләрнең тәэсир итү көче азрак. «Электрлы чалбар» хикәясенең дә ни өчен язылуы, авторның нәрсә әйтергә теләве аңлашылып җитми.

Ахыр килеп, Р. Хафизова әсәрләренең теле турында берничә сүз. «Кирләмән» әкиятенең беренче бүлеге һәм «Электрлы чалбар» хикәясе, «Ялкын» журналында басылган вариантлары белән чагыштырганда, бик нык эшкәртелгән. Кабатланып килгән сүзләр киметелгән, кайбер җөмлә төзелешләре тәртипкә китерелгән. Ләкин ялгыш төзелгән җөмләләр, урынсыз кулланылган сүзләр һәм сүз тезмәләре һаман да калган. Болар исә әкиятләрнең һәм хикәяләрнең тәэсир көчен шактый киметәләр. Авторның сүз байлыгы да әллә ни зур түгел шикелле.

Моңарчы чыккан китапларына карап хөкем иткәндә, Роза Хафизованы өметле һәм үсеп килүче язучы диярга була. «Курай-малай маҗаралары» да, «Кыңгыраулар җыры» да мавыгып укырлык итеп, кызык язылганнар иде. Укучылар авторның бу яңа китабын да нигездә яратып укырлар, дип ышанасы килә.

Ренат Гаязвин

**З. ТУФАЙЛОВА. Нәни капитаннар. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел**

Зәкия Туфайлова — кече яшьтәге балалар өчен актив иҗат итүче өлкән шагыйрәләребезнең берсе. Аның газета һәм журнал битләрендә басыла торган шигырьләрен укучылар һәрвакыт көтеп алалар һәм яратып укыйлар. Узган ел ул, үз шигырьләренең иң уңышлы дигәннәрен бергә туплап, «Нәни капитаннар» исемле яңа китабын бастырып чыгарды. Җыентыкка кергән шигырьләр, эчтәлекләренә карап, «Менә ич мин», «Без мәктәпкә барабыз» һәм «Табышмаклар» дигән бүлекләргә бүленеп урнаштырылган.

Беренче бүлекне нигездә мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен язылган шигырьләр тәшкил итә. Ул шигырьләрдә нәниләрнең үзләренә генә хас булган кызыклы тормышлары, үзара мөнәсәбәтләре, тегe яки бу вакыйганы үзләренчә кабул итүләре шагыйрә тарафыннан шактый оста тасвирлана. «Мин яңа сүз өйрәндем», «Мин этинең зур улы», «Бакчада», «Кем җитәкли», «Иртәнге кояш», «Кечкенә тамчылар», «Рәсем сөючеләр», «Озын телле Гөлүсә» шигырьләрендә автор балаларның бөек Ленинга мәхәббәтен, өлкәннәргә карата булган ихтирам-хөрмәтен, бәләкәй яшьтән үк эш сөючән булып үсүен уңышлы тотып алынган поэтик детальләр аша күз алдына китереп бастыра. Әлеге бүлектәге башка шигырьләр турында да җылы сүз әйтәсе килә. Мисал өчен «Тормыйм елап та» шигырен китерергә була. Шигырьдә сүз кечкенә кызчык исеменнән алып барыла. Тау шуар өчен абыйсыннан ул аның тимер чанасын сорый. Абыйсы бирмәгәч, әбисе янына килеп еларга тотына. Әбисе аны: «Тышта бик суык, кызым, суык тышта абыең шусын, әйдә»,— дип юата. Кызчык бераз тынычлана төшә һәм, абыйсын үчекләргә теләгәндәй итеп, болай ди:

— Кышын абый шусын, тормыйм елап та,
Җәй җиткәч, мин тормам аннан сорап та.

Зәкия Туфайлованың күпчелек шигырьләре әнә шул рәвешле балаларга хас булган гади һәм аңлаешлы телдә язылган. Ул шигырьләрнең бөтенесенә дә диярлек җиңелчә юмор хас.

Җыентыкның «Без мәктәпкә барабыз» дип аталган бүлегендә дә уңышлы эшләнгән шигырьләр байтак. Аларны укыганда вакыты-вакыты белән ирексездән елмаеп куясың. «Безләмәгез колакта» шигырендә уку-

чы дәресләрендә өлгермәүче һәм классны артка сөйрәүче Вәли белән танышa. Иптәшләре аңа тырышыбрак укырга, дәресләрне игътибар беләнрәк тыңларга киңәш бирәләр. Әмма Вәлинең үз сүзе сүз, аның җавабы бер:

— Башта үзегез әйттегез:
«Вәлигә бер шеф кирәк».
Үз башымны эшләткәч,
Ул шеф миңа ник кирәк!
Тәмам черки булдыгыз,
Бизләмәгез колакта.
Сездән котылыр өчен
Күчмим, калам класста!

Автор бирeдә укучыга уйланырга урын калдыра. Кем белә, Вәлигә, бәлки, чыннан да бернинди шеф та кирәкмидер, алдынгы укучылар сафына басарга, бәлки, аның үзенең дә көче-ихтыяры җитәрлектер.

«Безнең китапханәдә», «Локман», «Нурсанә», «Самат», «Мохтар» шигырьләрен шагыйрә китапның кадерен белүче яки аның «канатларын каеручы» балаларга багышлаган. Безнеңчә, җыентыкка кертү өчен бу шигырьләрнең бер-икесе бик җиткән иде. «Табышмаклар» бүлегендәге кайбер шигырьләр турында да шуны ук әйтергә кирәк: анда да китаптагы шигырьләрнең санын арттыру өчен генә китерелгән шигъри табышмаклар юк түгел. Аннан соң һәр табышмакның астына җавапларын биреп бару кирәк иде микән?

**П. АПУШЕВ. Сукмагым. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1971 ел**

Яшь шагыйрь Павел Апушевның шигырьләре моңарчы әле вакытлы матбугат битләрендә генә күренгәләп килә иде. Быел укучыларга ул үзенең беренче китабын тәкъдим итте. Җыентык авторның матур-матур хисләрен, яшьлек фәлсәфәсен, дөньяга карашын чагылдырган лирик парчалардан, авыл тормышына багышланган шигырьләрдән тора. П. Апушев шигырьләрен укыганда яшел чирәмле борма сукмаклар, ярсу толпарларга атланып чапканда «олы юлга кул сузган» малайлар, шул малайларга хәерле юл теләп калган авыл картлары күз алдына килеп баса. Күңелне дулкынландыра торган шундый шигырьләрнең берсе «Юл уңсын» дип атала. Анда яшь әдип лирик геройның әчке кичерешләрен, кешеләрнең үзенә карата булган игътибарлылыгын әйтеп бирү өчен гади һәм җылы сүзләр эзләп тапкан:

Веләм, беләм, изге теләк иде,
Шулай диде күрше картлары.
Җиңел уз дип, җиңел арбаларга
Җикте алар чаптар атларны.

Табигать күренешләрен тасвирлап язган шигырьләрендә дә П. Апушев үзен кешеләр янында итеп тоя. Менә шуңа күрә дә аның табигать турындагы «Беренче күкрәү», «Маяклар», «Карыш җирем», «Урман», «Төнбоеклар» шигырьләрен яратып укыйсың, хәтергә алар бик тиз сеңеп калалар.

Яшь шагыйрьнең тагын бер отышлы ягы шунда: ул озын язарга яратмый, тупланган фикерен дүрт-биш строфада әйтеп бирергә омтыла. Аз сүзлелек исә үз чиратында шигырьнең эчке динамикасын көчәйтә, кирәкмәгән нагрузка йөкли. Моны бигрәк тә җыентыктагы «Ятлар мине үз иттеләр», «Кайтып киләм», «Дөнья матур, дуслар», «Күке тавышы», «Көзге сагыш», «Кайда туса кеше» һәм башка шигырьләргә карата әйтергә кирәк. «Телләр өйрәнәсем бар» шигыре дә яшь шагыйрьнең алынган теманы үзенчә чишәргә сәләтле икәнлеге турында сөйли:

Ике телне белсәң җиткән диләр,
Килә алай түгел диясем.
Бар бит әле җир астыннан аккан
Чишмәләрнең телен беләсем.
Беләсем бар: ни дип сөйли икән
Җил искәндә яшел камышлар.
Йолдызларның телен белмим әле,
Ә үзләре күптән танышлар.

Җыентыкта, билгеле, тормышчан булмаган вакыйга-күренешләргә корылган яисә башкалар тарафыннан әйтелгән фикерләрне тагын бер тапкыр кабатлаган шигырьләр дә юк түгел. Ләкин алар китапка гомуми тон бирә алмыйлар. Шуңа күрә киләчәктә андый шигырьләрдән акрынлап-акрынлап арына барырга П. Апушевның көче җитәр дип ышанасы килә.

## Фәнис Яруллин

### Бәйрәмдә



Бер кеше өйләнмәсә дә,
Авылыбызда туй бүген.
Кемгә кермә — коймак пешкән,
Кемгә барма — сый бүген.
Без дә алай буш йөрмибез,
Үйламагыз юләр, дип.
Кесә тулы конфет безнең,
Чабу тулы — прәнник.
Узышабыз, чабышабыз
Булмаса да атыбыз.
Ат соң безгә нигә кирәк,
Алыштырдык аны без.
Таяк атларга атланып
Шәп тә соң урам урау!
Авызыбыз — гармун безнең,
Тавышыбыз — кыңгырау.

### Шигырьләр сөйли Марат



Башын бераз кыңгыр салып,
Телләрен ялап-ялап,
Чын күңелдән, илһамланып
Шигырьләр сөйли Марат.
Кулларын селтәп җибәрә,
Борынын тотып карый,
Колакларын капшап ала,
Кесә төпләрен кармый...
Ирексездән елмаясың
Ул сөйләп киткәч кызып.
Әллә шигырьләре кызык,
Әллә ул үзе кызык?!



## Искәндәрнең киңәше

Яңа пальто сатып алды
Искәндәрнең бабасы.
Эчләре дә атлас кына,
Каракүлдән якасы.
Бабай әйтә: — Туны шәп тә,
Бераз зуррак икән, — ди. —
Сатар идем дә, мондыйны
Табып булмас бүтән, — ди.
Искәндәр тыңлап тора да
Бирә үзенең киңәшен:
— Аптырама, бабакаем,
Бераз үскәч киярсең.

## Мәхмүт Газизов

### Балан

Җимеш кирәк бәлешкә,
барыйк икән кай төшкә?

— Җимеш, җимеш, син кайда?
— Баланда мин, баланда.
— Балан, балан, син кайда?
— Болында мин, болында.
— Болын, болын, син кайда?
— Түгәрәк күл буенда.
— Түгәрәк күл, син кайда?
— Бирерәк кил, мин монда.

Түгәрәк күлне күреп,
болын эченә кереп,
кып-кызыл балан табып,
җыеп кайттык бер савыт.

Баллы икән җимеше —
тәмле булды бәлеше.



### Тап әле

*Табышмак*

Кеше белән дустыр бу,
Үзе тәти коштыр бу,
Гөлдер-гөлдер-гөлдергү!
Әйбәт булды җимең дип,
Рәхмәт әйтеп йөрер бу.
Чем-чемекәй өсләре,
Елык-елык итә түшләре.
Нинди кошкай булыр бу?

**Расих Ханнанов**

# ИНСАФЛЫ КИЛЕН



Хәдичә апа базардан кайтып килә. Бер кулына авыр сетка, икенчесенә зур сумка күтәргән. Аның болай да бөкрәя төшкән карт гәүдәсе йөк авырлыгыннан бөтенләй җиргә чүккән сыман. Ул тишелгән иске гармун күреге шикелле уфылдап тын ала-ала берәз бара да хәл җыярга туктала, кулларын алмаштыра.

— Исәнмесез, Хәдичә апа? — дим мин аңа, әйберләрен алып. Карчыкның шатлыгы эченә сыймый:

— Ходайга шөкер, улым. Кулың-аягың сызлаусыз булсын инде, рәхмәт яугыры!

— Килен алырга кирәк, Хәдичә апа! Карт көнегездә болай интегеп йөрмәгез.

Хәдичә апа ниндидер бер изге серен чишкәндәй пышылдап кына җавап бирә:

— Шуңа әзерләнәбез инде, улым.

— Ә килен кем?

— Кем дип, үзебез кебек мөселман баласы инде. Дөнья күтәргә бик әвәс күренә. Өченче көн килгән иде. Без бергә яшисе кешеләр, мин дип әллә ни мәшәкатьләнмәгез, ди. Үземә кирәк әйберләрне генә алыгыз. Җылы итегем бар, мамык шәл дә кирәкми. Тун белән ак йон күлмәк шикелле модалы нәрсәләр алсагыз, бик житкән, соңыннан акча тотмаска яхшы булыр, ди. Телкәйләре шундый тәмле-татлы, күңелләр эреп кенә китә инде. Бу йортыбызны сатып, кaператифтан кухнәле, ванналы фатир алып җибәргәч, өч бүлмәнең берсендә үзең генә торырсың, өрмәгән җиргә дә утыртмабыз, дип өзелеп тора.

— Сез ризамы соң?

— Йорт саттырыргамы?

— Әйе. Алмагачларыгыз әрәм була бит.

— Килен әйтә: өйне барыбер сүтәчәкләр, сатып калырга кирәк, ди. Алмагачларны картымның төсе итеп кенә саклый идем дә соң. Барыбер бетәрләр, ахры.

Без, сөйләшә-сөйләшә тыкрыкны үтеп, Хәдичә апаларның өенә таба борылабыз. Урамда яз. Кешеләр дә язгыча киенгәннәр, йөзләрендә нур

уйнап тора. Әле яңа гына мин дә шундый идем. Ләкин Хәдичә апа белән очрашкач, әллә ничек күңелгә ямансу, күкнә болыт баскандай булып китте. Хәдичә апа моны сизенгәндерме, юкмы — белмим. Тик ул һаман үзенен «йорт җанлы» килене турында бертуктаусыз сөйләнүен белде:

— Беркөн Галинурым белән туйга кемнәрне чакырырга икән, дип баш ватып утыра идек, анау очлы туфлиләре белән тып-тып басып кына килеп керде дә уйлап та тапты: «Син Галинурның сүзенә карама, ди. Ул — бозау бит, шулай булмаса, утызы җиткәнче буйдак булып йөрмәс ие, ди. Мин үзебезнен яктан туйга чакырдым инде, бүләкләр турында да әйттем», ди.

Галинурым гаҗәпләнеп калды: «Нинди бүләкләр ул? Кешегә, бүләк алып кил, дип әйтәләрмени?..»

Килен тегенә тезеп китә:

— Белмисең, чөнки уҗым бозавы бит син. Йоласы шундый аның: туйга килә — бүләк китерә. Өйгә юк-бар белән чүп-чар җыелмасын өчен нинди бүләк кирәклеге турында алдан әйтеп кую бер дә начар түгел. Менә син кемнәрне чакырасың? Имамов киләме? (Монысы улымның начальнигы була инде, бик әйбәт кеше.) Әйдә, акча күп ала, бүләккә берәр телевизор китерсен, һич югында, магнитафун да ярый, дөнья көткәч эчне тишми ул. Өч абыен, апаң, җизнән бар. Акчаларын җәлләмәсеннәр, җыйнаулашып халадилник китерсәләр дә, харам булмас, ди.

Тәки сүзендә торды, кешеләрен дә таптырды, әткриткәләрен дә җибәрттерде. Туебыз бик шаулы, зур булмакчы.

— Кайчанга тәвәккәлләдегез соң?

— Берсекөнгә инде. Шуна тыз-быз йөгергән мәл.

— Моннан соң түр башында гына яшәргә язсын, Хәдичә апа, үзенә.

— Сүзләрен фәрештәнен амин дигәненә рас килсен, балакаем.— Хәдичә апа, ничектер, моңсу гына көрсенеп куйды.— Ярый, улым, рәхмәт. Мин ашыгыйм әле. Бүген талчукка да чыгып керәсем бар. Мәшәкатьле чак бит... Аннары Хәдичә апа, үзенчә шәп атларга тырышып, ләкин бөгелә-сыгыла, капкасыз зур өйгә таба юнәлде.

# ГЫЙЛЬМИ НӘТИҖӘ

*(Жилинскайтечарак итеп)*

Кеше ничек фән кандидаты була, беләсезме? Белмәсәгез, аңлатып бирим: тикшеренеп, ягъни нинди дә булса гыйльми ачыш ясап һәм нәтиҗә чыгарып. Менә күптән түгел, мәсәлән, минем бер якын дустым «Шөпшәләр нигә жуылдап оча» дигән темага диссертация яклап кандидат булды. Хәзер инде «Шөпшәләр нигә бал җыймый» дигән хезмәт өстендә эшли. Димәк, доктор булачак.

Мин үзем дә, билгеле, төшеп калганнардан түгелмен. Әлегә кадәр кандидат яки доктор булмаганмын икән, бу бары дошманнарымның күп булуы аркасында гына. Аяк чалалар. Гыйльми дөнья шулай ул — гел үчлеккә корылган. Ә бит, фән күзлегеннән чыгып караганда, минем

кадәр күп һәм катлаулы тикшеренү алып барган берәр кеше бармы безнекеләр арасында? Юк, әлбәттә. Буыннары сыек. Мин бит кайберәүләр кебек ат ботының, аның адымының уртача озынлыгын исбатларга тырышып йөрмим. Мин психологик тикшеренүләр алып барам.

Кеше — җан иясе. Аның һәр хәрәкәтен, әшен, психология күзлегеннән карап, күңеленең нечкәлегенә бик тирәнтен үтеп кереп тикшерәм һәм шуннан гыйльми нәтиҗә чыгарам. Әле күптән түгел генә бер малай, үз күз алдымда таш атып, безнең тәрәзәне челпәрәмә китерде. Дөрес, мин аны туктатып та кала алган булыр идем. Ләкин туктатмадым. Чөнки мәсьәләгә фәнни карашның бөтен сере дә әнә шунда. Тикшерергә, ачыкларга кирәк: ни өчен ул нәкъ әнә шул төбәктә яткан ташны иелеп алды? Һәм ни өчен аны безнең өйнең тәрәзәсенә томдырды, ә башка кешенекенә түгел?

Психологик тикшеренүләремне мин бер генә минутка да туктатмыйм. Ятсам да, торсам да, бакчада яки урамда йөрсәм дә — һәркайда да дәвам иттерәм. Әле дә менә урам буйлап бара идем, шунда бик кызык бер тикшерү объектына тап булдым. Алдымнан, көчле җилгә чайкалган тал чыбыгыдай бер тегеләй, бер болай селкенеп, әзмәвердәй ир бара. Киң урам тәмам тараеп калган аңа. Кешеләр аның янына килеп җитү белән читкә өркелешәләр. Чөнки алар өчен ул гади бер исерек. Ә миңа алай түгел. Минем өчен ул — серле йомгак, психологик җепләр төйнәлеше. Нигә ул шулай чайкала? Чайкалган саен аның башына нинди уйлар килә? Ара-тирә абынып китүләре аның миендәге яки характерындагы серле үзенчәлекләр турында сөйләмиме? Һәм, ахыр килеп, аны аракы шаукымымы яки икенче бер психологик көч шулай хәрәкәт иттерәме? Мин, шулай уйлап, тегенәрдән бер тотам да калмыйча атлыйм.

Кинәт каршыдагы капкадан бер көчек йөгереп чыкты да тегенең аяк астына ук килеп керде. Шуны гына көткән кебек, минем психологик объектым, киерелә биребрәк, аны тибеп очырмасынмы?! Теге мескенкәй, әллә нинди ямьсез хәрәкәтләр ясап, бөгәрләнеп-тәгәрәп әллә кая барып төште. Ә абзыйга берни булмады кебек, хәтта чайкалуыннан да туктап торды. Мин тизрәк мәсьәләнең тамырына ук карарга тырышам. Бу психологик момент ничек туды? Тибү рефлексы аның аңында, аерып әйткәндә, аның кайсы җирендә барлыкка килде дә һәм нинди космик тизлек белән, баш миеннән гәүдә аша үтеп, гаҗәеп бер сихри көч сыйфатында аякларына күчте икән? Нинди психологик бәйләнеше бар боларның?

Кинәт ачы итеп сүгенгән тавыштан сискәнеп куйдым. Башта бу тавышның каян килгәнен дә төшенеп булмады. Тирә-якта бүтән кешеләр күренми. Каршыга таба бер ханым гына якынлашып килә килүен, әмма аның тавышы андый калын булмас. Өстәвенә, хатын-кыз урамда сүгенеп тә йөрми. Димәк, теге тавышны минем тикшерү объектым биргән булып чыга. Менә кызык! Нигә кирәк булды соң әле менә бу сүгенү? Сүгәр кешесе дә юк лабаса. Монысы нинди психологик сер тагын? Моны рефлекс дип атарга мөмкинме?

Мин шулай уйларга өлгермәдем, объектым каршыга килүче ханымны туктатып, аңа бәйләнә, акча таптыра башлады. Ханымның йөзе куркудан күм-күк булды, үзе сүзен дә әйтә алмый. Калтыранган куллары белән сумкасын ачып, бер сум акча чыгара. Ә тегенә бу хәтле генә аз. Ул аның артыннан:

— Убырлы карчык, баш төзәтерлек тә бирмәде,— дип, ачы сүзләр белән тиргәнеп калды. Ул тиргәнә, ә мин аның таныш булмаган ханымны туктатып, акча таләп итәргә мәҗбүр иткән тойгылар көчен фәнни нигезләргә тырышам. Бу тойгыларны нинди сигнал системасы барлыкка китерде икән — беренчесеме, әллә икенчесеме? Гомумән, аның

адым саен диярлек шулай яңадан-яңа нәрсәләр уйлап табуы нәрсәгә бәйләнгән: табигый талантками, әллә дөньяны бик тиз танып белү сәләтенәме?

Бераздан ул кибеткә керде. Аннан чыгып азрак баргач, миңа әйләнеп күз кыскандай итте һәм, кабарып торган кесәсен кулы белән сыйпаштыра-сыйпаштыра, шәп-шәп атлап янә урам буйлап китеп барды. Бу вакытта аның давылдагы кораб төсле ихтыярсыз чайкалуы да бөтенләй кимегән төсле булды. Мин дә, адымымны тизләтеп, аңа якынлаша төштем. Һәм шул чак... Оригиналь объектым, җәһәт кенә борылды да, изүемнән эләктереп алып, бала башы кадәр йодрыгын күз төпләремдә, казнам өстендә биетергә тотынды. Башым чатнап, зиһенем томаланып китте...

Ә коелган тешләремне җыйнап аякка басканда, объект дигәнем каядыр китеп югалган иде инде. Ләкин миңа анысы мөһим түгел иде. Мөһиме — психологик ситуация. Күрәсең, аның да үз төенләнеше, кульминацион ноктасы һәм чишелеше буладыр. Һәм моны һич кичекмәстән фәнни яктан исбатларга, гыйльми нәтиҗә ясарга кирәк. Фәнни ачышлар шулай нечкә тикшеренүләр, авыр кичерешләр аша килсә генә шатлыклы булалар бит алар. Кем-кем, моны мин яхшы беләм инде. Чөнки диссертациям дә шул хакта булачак.

## Әхәт Фазылҗанов

# БЕЗ КЕМНӘН КИМ?

ЮМОРЕСКА



Малайны әйтәм әле, туганнан бирле авызына атлан май каптыра алганыбыз юк иде, беркөнне уеннан хәлсерәп кайтып керде дә:

— Ипигә май ягып бирегез, — дип куыра башлады.

— Нишләден? — без әйтәбез. — Белеп соравың түгелдер бу?

— Әнә урамда Рәшит ашап йөри, миңа да кирәк, — ди.

Сабый түгел диген син аны. Кешедән кызыгып кына соравы, имеш. Ә Рәшит дигәне безнең күрше малае була инде. Йортлары безгә каршы гына.

— Нәфесең бар икән, бик аша,— дидек, бу кителмәгән хәлгә куанып. — Күптән шулай кирәк иде. Майга аптырау түгел. Синнән кызганган юк. Тәненә ит кунар әзрәк.

Әнисе малайның кулына дәү ипи сыныгы тоттырды, калын итеп май сылады. Түземсезлек белән ашаганын көтеп торабыз. Кайда ул ашау, ай күрде, кояш алды малайны. Сыныкны эләктерүгә ишеккә атылды.

— Алай тәртипсезлеккә өйрәнмә, улым, — мин әйтәм.

— Өйдә генә утырып аша әле, — дип кычкырды әнисе. Колагына да элми малай.

— Рәшит кебек минем дә урамда йөреп ашыйсым килә, — ди.

Тәки жиңә алмадык бот буе җан иясен.

Сыныгын ашап бетергәндерме,. юктырмы, кичкә кырын мороженое сорап кергән бу.

— Анысы кайдан исенә төште әле шушы салкында? — дибез.

— Рәшиткә әтисе алып кайткан, миңа да кирәк менә.

Бүген инде соң, мороженое сата торган ларек та ябылгандыр, иртәгә алып кайтырбыз, дип карыйм. Юк, тәгәрәп кенә китә малай. Менә шушы минутында ук булсын аңа, иртәгә хәтле көтәр-түзәр чамасы юк. Эссе табага бастыра. Ахыр чиктә олы башымны кече итеп мороженое артыннан чаптым. Буш кул белән кайтып кергәч, олы мәхшәр купты өйдә. Көч-хәл белән юмалап йоклаттык малайны.

Иртәгесен тагын яңалык. Кайтты да апельсин даулый башлады бу.

— Дөньяда юк әйберне сорап йөдәтмә, зинһар, — дибез. — Үзебезнең дә апельсиннан авыз итмәгәнгә бер ел була бугай инде. Кайдан табыйк?

Син әйбәтләп әйткәнне аңлыймы соң ул бала! Күз яше белән елый.

— Рәшиткә тапканнар ич әле. Миңа да табыгыз менә, — ди.

Бөтенесен урамга ташып ашый торган нинди әдәпсез Рәшит булды соң бу? Ник бала котыртып йөри ул? Өендә тамагыннан үтми микән әллә, югыйсә? Әти-әнисен әйтер идем...

Ачу да килә, көнчелек тә кузгалган кебек. Анысы, сәбәбенә керешсәм, апельсинын да табам инде мин аның. Җиде кат җир астыннан булса да. Әллә мин Рәшитнең әтисеннән аз аламмы акчаны? Без кемнән ким?.. Тукта әле, әдәп саклыйм дип һаман саен малайны нәүмизләндерү дә әйбәт түгел бит. Кичә мороженое диде, ул дигәнчә булмады, бүген апельсинга күзе төшкән, анысы юк. Кеше баласы янында малайның кимсенеп үсүе бар бит. Ярамый болай. Юеш борынлы Рәшит ашаган ризык безнең малайга да хәрам булмас. Анда гына түгел ич авыз. Ашаулары белән мактанып йөрмәсеннәр әле.

Тәки үземнекен иттем. Шәһәргә чыгып киттем. Җәтмә тутырып апельсинын, мандаринын алып кайттым.

— Аша рәхәтләнеп, улым, — мин әйтәм. — Бүселгәнче аша. Һише җитәрлек. Монысы беткәч, тагын алып кайтырбыз. Тик өйдә ашыйсы түгел, кара аны. Урамга алып чык әнә. Урланган нәрсә түгел, курыкмый аша. Күреп торсыннар...

Кыскасы, сынаткан юк хәзер. Күрше малае кәгазьле конфет тотып чыкса, безнекендә — укалы тартма белән, «Күгәрчен сөте» дип аталганы. Колбаса сорап керсә (шул Рәшиттән күреп инде), килосы белән диярлек тоттырабыз. Күршенеке алма шытырдатса, безнеке — груша кимерә. Кайберсен үзебез ашамасак та, малай авызыннан өзгән юк. Безнең белән табын янына утырып ашамый да хәзер. Ашаганы-эчкәне урамда. Узыштан китте эшләр. Күршеләр белән, дим.

Бервакыт малаебыз тагын авызын турсайтып кайтты.

— Нәрсә кирәк тагын? — без әйтәбез.

— Рәшит ашаган әйбер.

— Нәрсә соң ул?

— Белмим. Исемен оныттым.

Инде малайның ашамаган нәрсәсе калмаган шикелле иде. Ул белмәгән тагын ни булыр икән? Кызыксынуым чиктән ашты, ишек алдына атылдым. Рәшит дигәннәрен эзләп таптым. Каһәр генә суксын, бәрәңге төя торган тукмактан да зуррак ананас кимереп утыра теге. Нишләргә инде? Анысын кайдан таптылар икән дә мин кайдан юнәтим икән? Аптырагач, Рәшитне юмалап карыйм:

— Бераз гына дустына да бирер идең. Үзен генә барыбер ашап бетермәссең бу кадәрне.

Дәшкәнемә үкендем. Телен чыгарып күрсәтте дә китеп барды малай актыгы. Үләрсең килешеннән.

Ачуым ачу, табам ананасын да. Дөньясын актарам...

Бүтәннәрнең төшенә дә кермәгән нәрсәләр юнәттем. Күршене әйтәм, ачудан шартларга җитешер инде...

Тыныч кына гомер итәргә түгелдер, ахры, миңа, хәзер инде малайны алмаштырып куйган кебек. Кулына әйбер тоттырып һич урамга чыгара торган түгел. Урамда йөреп ашау — гадәтсезлек, дип остарган була. Кайсысы котыртып кертте икән инде тагын? Әмма шушы күршеләрне! Гел безгә каршы килеп торалар, әй.

## Юзил

### Сонет турында сонет

Бик борынгы жанр сонет мин,
Классиклар коеп куйдылар,
Сыйфат түгел инде, сан бит мин,
Очты җилгә фикер, тойгылар...
Мондый фаҗигагә кем түзгән,
Таладылар рухым-җанымны.
Елар идем, яшь чыкмый күздән,
Эзләп китәр идем данымны,—
Акылым зәгыйфь, күзем сукыр ла...
Елый алмыйм шул мин, көлмим дә,
Коткаралмый хәтта докторлар,
Терелмим дә хәзер, үлмим дә.

Уян, Маршак, уян, Мөдәррис,
Коткарыгыз, дуслар, сүнәм ич!

### Илһам килгәндә һәм киткәндә

Үтенәм, китегез ялгызым калдырып,
Кулларым каләмгә үреләә.
Алдымда беркем дә белмәгән,
Тоймаган Матурлык күренә.
Үтенәм, китегез ялгызым калдырып,
Нур тама каләмем очыннан,
Күңелемнән аккошлар очырам,
Шашынам, тилерәм, очынам.
Үтенәм, китегез ялгызым калдырып,
Мин — күкнең җиденче катында.
Бу мәлдә кирәкми берсе дә:
Сөйгән яр, дусларым, алтын да...

. . . . . . . . . . . .

Күңел буш. Эч поша. Мин йөрим
Үләрдәй моңаеп, каңгырып.
Кил, акча, кил, дача, кил, хатын,
Үтенәм, китмәгез ялгызым калдырып...

### Яңа җырчы

Халык җырын ул яңача ача:
Бик искергән «Сарман» һәм «Арча»...
Җитешмәгән ягы бик кечкенә:
Моңы юк һәм... белми татарча.

## Төкле аягың белән!

Язмый кайда йөрден моңарчы,
Пьесаң әйбәт, бик шәп, Бомарше!

## Мәсәл геройларының сөенече

Якын бара күрмә, Шәмукка, дип,
Тәки олактырыр тәмугка, дип.
Кайгырмагыз, мәсәл язмый торып,
Шатландырды соңгы вакытта.

## Ариозо

Очып йөргән бер җыр күрдем мин,
Аңа текст язып бирдем мин,
Шул кош канатына тагылып,
Союзга да барып кердем мин.

## «Идел»гә

Бер номерын гына күреп калдык,
Төрле уйлар килә күңелгә:
Суы бик күп булып, яшь авторлар
Батты микән әллә «Идел»гә?

## Вера Минкинага

Көн дә барыр идем мин кинога,
Роль бирсәләр Вера Минкинага.

## Идрис Туктар

### Җөмләләр

* * *

Гамьсезнең тормышы ямьсез.

* *

Балаларга дөрес тәрбия бирим дисәң, башта син үзең алардан өйрән.

* * *

Таякка таянып аяк таймый, аякка таянып таяк таймый.

* * *

Язучы беркем дә кызыксынмаган иң кызыксыз кешеләр белән дә кызыксына.

* * *

Бер кешенең хәтерен саклау өчен бүтән берәүнең хәтерен калдырма.

* * *

Кайчак: күрдем, дип бер шатлансаң, аерылдым, дип ике шатланасың.

* * *

Яшьләрдән гыйбрәт алу — акыл-хикмәт; картлардан гыйбрәт алу да бик кирәк!

* * *

Никадәр күп белсәң, шулкадәр аз белгәнеңне беләсең; никадәр аз белсәң, шулкадәр «күп» беләсең.

* * о

Бирәчәгеңне кайгырт, алачагың качмас.

## Зиннур Насыйбуллин

### Йомычка

— Дингез кичтем. Давылларны җиңдем!
Мин барын да беләм тормышта! —
Дип мактана кайчак
Дулкын белән
Ярга чыккан гади йомычка.

### Озынборын

Филләр бит ул безнең нәселдән.
Мактансаң да була. Урынлы.
Исбат кирәк? Рәхим итегез:
Фил дә, мин дә озын борынлы.

### Карачкы

«Эшем тыгыз, эшем тынгысыз бик,
Поста торам төнен-көндезен;
Чөнки мин бит алыштыргысыз»,— дип,
Карачкы да мактый ди үзен.

### Турылык

Турылыклы булды:
— Хуҗам үлсә,
Мин дә җирдән китәм,— диде ул.
Һәм үз сүзен җилгә җибәрмәде...
— Кем? — дисезме?
Шәүлә иде ул.

### Мин-минлек

Берәү юлда сарык куа,
Ә сарыгы уйлап бара:
«Мин алдан юл күрсәтмәсәм,
Кая барсын бу бичара».

## Ике килми...

— Гомер ике килми бит ул,
Мә, туган, син дә чөмер!
— Абзый, миңа сала күрмә,
Ике килми бит гомер.

## Саран

Саран әйткән: «Бакчамнан чык,
Җитәр, житәр!
Күп иснәсәң, чәчәкләрнең
Исе бетәр».

## Бала «гаебе»

Тыңлыйсың да хәйран каласың,
Уйлыйсың да гыйбрәт аласың:
Хайваннар да кайчак, хайван, диеп
Әрли икән үзенең баласын!

## Ике фикер

— Урман гүя уйга чумган,
Нинди сафлык һәм нинди тын!
— Әйе, урман начар түгел,
Бер агачы — бер йөк утын.

## Бүкән

— Бөгелмим мин, сыгылмыйм мин,
Давылда да егылмыйм мин.
Кем бар шундый миннән бүтән?! —
Дип мактанып яши Бүкән.

## Алтын сүз

— Сүзең — көмеш, эндәшмәвең — алтын...
— Акыллы сүз тыңлау күңелле,
Тик ул алтын эндәшмәгән өчен
Бирә торган ришвәт түгелме?

## Битараф

Дөньялыкта беркем өчен
Көймәде дә, пошмады да.
Хәзер үзен хәтерләргә
Дусы да юк, дошманы да.

# УҢЫШЛЫ ӘСӘР

Нурихан Фәттахның «Әтил суы ака торур» исемле тарихи романын бик яратып укып бардым. Халкыбызның моннан мең еллар элгәре тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, иҗтимагый һәм культура үсеш дәрәҗәләрен өйрәнүдә һәм аны укучыларга җиткерүдә автор гаять зур эш башкарган. Бу әсәрне игътибар белән укып чыккан кеше борынгы бабаларыбыз хакында тирәнрәк, нигезлерәк фикергә килер дип уйлыйм.

Автор татар халкының борынгы бабалары нинди шартларда һәм ничек итеп яшәүләрен сәнгатьчә шактый осталык белән күз алдыбызга китереп бастыра алган.

Әсәрдә халкыбызның төп тамыры булган хөр күңелле, ирек-хезмәт сөючә, тынычлык белән көн күрергә омтылучы бер кабиләсенең тормышы сурәтләнә. Бу халык күрше һәм ерак юлбасарлар тарафыннан күп тапкыр кыерсытылган, таланган, рухи һәм материал зыян күрә килгән. Әмма берниңди изү дә, җәбер-золым да аны мескен хәлгә төшерә алмаган. Ил тулы канлы, иркен сулышлы тормыш белән яши бирә: һөнәрчеләр үз эшләре белән мәшгуль, төзүчеләр төзи, игенчеләр иген игә, сунарчылар җәнлек аулый, балык тота, баһадир уллар илне саклый һ. б. Икенчедән, халык үзенә генә хас йолаларын тота, гореф-гадәтләрен изге саклый, сәнгатен үстерә. Романнан укып без борынгы әби-бабаларыбызның горур да, сәләтле дә, тыйнак та булуын белеп куанабыз. Аларның бәйрәм итүләре, күңел ачулары да романда уңышлы тасвирланган. Яз бәйрәмен гаҗәп күңелле һәм бердәм итеп үткәрәләр алар. Төрле ырымнар башкарудан, күңел ачудан һәм аш-судан бирәү дә читтә калмый бу илдә.

Романда шул заманга хас кырыйлык, беркатлылык, сәер гадәтләр дә ышанырлык детальләр, конкрет персонажлар аша уңышлы күрсәтелгән. Бу җәһәттән йола сакчысы мәкерле һәм алдакчы Утташ кам образы игътибарга лаек. Халыкның теләсә нәрсәгә әчкерсез һәм гөнаһсыз ышанырга, табынырга әзер торуыннан бу мәкер иясе бик оста файдалана: алдый, әшәке уйларын гамәлгә ашырырга омтыла һәм аңа ияреүчеләргә карата үч саклый. Ул Тотышның яраткан Йолдыз кашкасын суйдыра, Күрән бинең властена, байлыгына, ганләсенә хуҗа булырга омсынып, төрле мәкерләр эшли. Ләкин ул күп очракта көчсез кала. Халык аңа түгел, дереслек, гаделлек ягында торучы ил хуҗасына иярә. Әсәрдә хәзерге атеистларны да гаҗәпкә калдырырлык кыю фикерләр бар. Аны моннан мең еллар элек Күрән би әйтә. Капка төбенә яу килгәндә йолык (корбан) бирү белән генә котылып булырмы! Аңа карап дошман кире кайтып китәрме! Юк-бар белән шөгыльләнгәнче үзебезгә хәрәкәт итәргә кирәк. Сугышабызмы, Алмыш ханның шартына күнәбезме, ди ул.

Романда бер кабилә тормышы гына тасвирланса, бу әсәр тулы булмас иде. Чөнки борынгы төрки халыклар үзара да, күршеләр белән дә бик якын мөнәсәбәттә торганнар. Аларның хәтта Багдад, Византия, Испания һәм башка ерак илләр белән иҗтимагый, экономик культура һәм сәүдә бәйләнешләрендә торуы тарихта мәгълүм. Әсәрен язганда автор бу фактларны да искә алып бик яхшы иткән.

Әсәрнең борынгы тел үзенчәлекләрен саклап язылуын да уңай яктан бәяләргә кирәк. Күп кенә архаик сүзләрнең кулланылуы фикер агышын бер дә төссезләндерми, мәгънәсен югалтмый, киресенчә, вакыйгаларны, персонажларны ачыграк, тулырак һәм гадәтирәк итеп тасвирларга ярдәм итә. Ул сүзләрнең хәтта безнең сөйләштә дә кулланылырга хаклылары бар. Боркай — масаючы, базарган — базарда сатучы, ым — пароль, битек — донесение, сөлтәр — скелет һ. б. Болардан тыш шул заманда гына кулланылган хезмәт һәм сугыш кораллары, кием-салым, аш-су төрләре, урын-җирләрнең үз исемнәре белән бирелүен дә хуплыйсы килә. Кеше исемнәре дә гап-гади (Аппак, Тотыш, Бәкәч, Тәңкә). Шул заманнан сакланып килгән бәетләрнең, такмазаларның, мәкаль һәм әйтемнәрнең урынлы китерелүен дә әсәрнең отышлы ягы дияргә була. Кыскача әйткәндә, «Әтил суы ака торур» романы бик кирәкле, файдалы әсәр.

ШӘЙХИ ШӘЯХМӘТОВ,

Башкортстанның Стәрлебаш авылы.

# *ӘДӘБИЯТ һӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ*

## ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

Шушы елның 16—17 мартында Татарстан язучыларының зур җыелышы үткәрелде. Узган әдәби елга йомгак ясауга багышланган ул җыелышта әдәбиятыбыз үсешенең төп тенденцияләре турындагы беренче докладны Язучылар союзының җаваплы секретаре Гариф Ахунов сөйләде. Узган елда басылып чыккан поэзия әсәрләре турында Нәби Дәүли һәм Гамил Афзал, проза әсәрләре турында Барлас Камалов һәм Атилла Расих, драма әсәрләре турында Баян Гыйззәт, тәнкыйть турында Хәсән Хәйри һәм Татарстанда яшәүче рус язучыларының әсәрләре хакында Юрий Белостоцкий иптәшләр доклад ясадылар. Докладчыларның барысы да узган елда басылып чыккан һәм сәхнәгә куелган әсәрләргә зур, җитди таләпләр күзлегеннән карап бәя бирделәр. Үткән елгы әсәрләр арасында күп кенә уңышлылары белән беррәттән, йомшаклары да дөнья күрүен искәрттеләр. Ә тулаем алганда әдәбиятыбызның һаман үсүен, алга баруын билгеләп үттеләр.

Докладлардан соң үткәрелгән фикер алышуларда язучылардан Аяз Гыйләҗев, Фатих Хөсни, Туфан Миңнуллин, Зәки Нури, Марс Шабаев, Рафаэль Мостафин, филология фәннәре докторы Гали Халит, Татарстан китап нәшриятының балалар һәм яшьләр редакциясе мөдире Шамил Рәкыйпов, «Азат хатын» журналының җаваплы секретаре Габдулла Шәрәфетдинов, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының әдәби бүлек мөдире Зәмирә Садикова катнаштылар. Алар докладчыларның фикерләрен тулыландырдылар, шулай итеп, үткән елгы әдәби әсәрләргә һәр яклап анализ ясалды.

Ел йомгаклары җыелышында «Спартак» аяк киеме берләшмәсе эшчесе Д. Илалова, Горбунов исемендәге авиация заводы эшчесе Х. Вәлиев, Саба районыннан М. Гаялиев иптәшләр дә чыгыш ясап, язучыларыбызның әсәрләрен үз предприятиеләрендә эшләүчеләр яратып укуын әйттеләр һәм эшчеләр тормышын чагылдырган китаплар күбрәк язылсын иде, диделәр.

Җыелышта КПСС Үзәк Комитетының матур әдәбият секторы мөдире А. А. Беляев, КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, РСФСР язучылары союзы идарәсе члены шагыйрь Кайсын Кулиев, «Наш современник» журналының баш редакторы шагыйрь Сергей Викулов, СССР язучылар союзыннан Виль Ганиев, РСФСР язучылар союзы әдәби консультанты Җәмил Мостафин иптәшләр дә катнашты. Сергей Викулов үзенең чыгышында татар әдипләрен киләчәктә активрак булып, «Наш современник» журналы белән якыннанрак элемтә тотарга өндәде. «Юность» журналының редколлегия члены шагыйрь Кайсын Кулиев та татар әдипләренең әсәрләрен «Юность» журналы битләрендә күрергә теләвен әйтте һәм ел йомгаклары җыелышы бик эшлекле булуын билгеләп үтте.

— Мин,— диде ул аннары,— татар әдәбиятына бик зур хөрмәт белән карыйм. Урта Азия һәм Кавказ халыклары әдәбиятларының үсүенә татар әдәбияты бик зур йогынты ясады. Бу өлкәдә Габдулла Тукай һәм Галимҗан Ибраһимов аеруча зур роль уйнадылар. Татар язучылары шул зур әдипләрнең традициясен уңышлы дәвам итәрләр дип ышанам һәм аларга уңышлар телим.

Ел йомгакларына җыйналган язучылар СССР язучыларының V съездына делегатлар сайладылар. Делегат итеп Гази Кашшаф, Нәби Дәүли, Гариф Гобәй, Сибгат Хәким, Геннадий Паушкин, Шәүкәт Галиев, Зәки Нури, Гариф Ахунов һәм Равил Фәйзуллин сайланды.

## ӘДӘБИЯТ АТНАЛЫКЛАРЫ

Соңгы елларда язучыларыбызның республикабыз хезмәт ияләре белән бәйләнеше аеруча ныгый бара. Республикабыз районнарында үткәрелә торган әдәбият атналыклары — шул элемтәнең ачык мисалы. Бу елның март аенда Арча һәм Саба районнарында да әдәбият атналыклары үткәрелде. КПССның XXIV съездына багышлап үткәрелгән ул атналык көннәрендә Арча районына язучыларыбыздан Самат Шакир, Гөлшат Зәйнашева, Вакыйф Нуруллин, Рәдиф Гатауллин; Саба районына Сибгат Хәким, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Туфан Миңнуллин, Зөлфәт Маликов, композиторлар Исмай Шәмсетдинов, Фасил Әхмәтов, Мәсгут Имашев һәм җырчы Флера Сөләйманова иптәшләр барды. Арча группасы шул районның Күпербаш, Мәңгәр, Бәрәскә һәм Күәм авыллары клубларында колхозчылар белән, мәктәпләрдә укучылар һәм укытучылар белән очрашулар үткәрде. Саба группасындагы иптәшләр район үзәгендә, лесхоз поселогында, Тимершык һәм Нырты авылларында һәм мәктәпләрендә колхозчылар, эшчеләр һәм укучылар белән тугыз очрашу үткәрделәр. Әдипләребез бүгенге татар әдәбиятының торышы турында сөйләделәр, үзләренең әсәрләрен укыдылар, иҗат планнары белән уртаклаштылар.

## МӘСКӘҮДӘ, КҮРГӘЗМӘДӘ

Шушы елның апрель ахырында һәм май башларында Мәскәүдә уналты автономияле республика художникларының әсәрләрен эченә алган күргәзмә булып үтте. Анда Татарстан художниклары иҗат иткән әсәрләргә дә шактый зур урын бирелгән иде. Сынлы сәнгать, графика, скульптура, плакат, сатира, монументаль әсәрләрдән торган һәм 400 дән артык экспонатны тәшкил иткән Татарстан художниклары әсәрләре бүлеген Мәскәү тамашачылары яратып карадылар.

## БАКУДА УЗДЫРЫЛГАН КИҢӘШМӘ

«Бердәм хәрәкәт һәм үзара тәэсир итешү — әдәбиятта һәм сәнгатьтә милли традицияләрне яңарту һәм үстерү факторы» дигән темага Баку шәһәрендә киңәшмә булды. «Литературная газета» һәм Әзербәйҗан язучылары союзы инициативасы белән үткәрелгән ул зур киңәшмәдә Мәскәү, Ленинград шәһәрләреннән, Урта Азия, Казагыстан, Балтик буе республикаларыннан һәм күп кенә автономияле республикалардан җыелган шагыйрьләр, тәнкыйтьчеләр, әдәбият һәм сәнгать белгечләре катнашты. Татарстан язучылар союзыннан барган тәнкыйтьче Р. Мостафин да ул киңәшмәдә чыгыш ясады һәм тугандаш әдәбиятларының үзара тәэсире һәм үзара баетылуларына кагылышлы актуаль мәсьәләләр турында сөйләде.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ТУГАН КӨНЕНӘ БАГЫШЛАП

Февраль аенда, герой шагыйребез Муса Җәлилнең тууына 65 ел тулуга багышлап, Оренбург шәһәрендәге «Россия» культура сараенда зур кичә үткәрелде. Кичәдә М. Җәлилнең тормышы һәм иҗаты турындагы докладны журналист Н. Альтов ясады. Махсус чакыру буенча Казаннан барган язучы Р. Мостафин кичәгә җыелган халыкны Җәлилнең иҗатына һәм батырлыгына бәйләнешле яңа материаллар белән таныштырды. Шагыйрьнең сеңелесе Хәдичә Җәлилова абыйсы Муса турында истәлекләр сөйләде. Шулай ук Казаннан барган шагыйрь Ренат Харисов үзенең Муса Җәлилгә багышлап язылган яңа шигырьләрен укыды.

Кичәдә республикабызның күренекле композиторы Александр Ключарев та катнашты һәм татар музыка культурасын тудыруда һәм үстерүдә Муса Җәлилнең бик күп хезмәт куюы турында сөйләде.

Соңыннан Оренбург шәһәре үзешчәннәре Муса Җәлилнең шигырьләрен укыдылар, аның сүзләренә язылган җырларны башкардылар һәм «Моабит дәфтәре» исемле нәфис фильм күрсәтелде.

* * *

Пермь шәһәренең Свердлов исемендәге культура сараенда да Муса Җәлилнең тууына 65 ел тулуга багышлап кичә үткәрелде. Күп санлы интеллигенция вәкилләре, укытучылар, эшчеләр катнашында үткәрелгән ул кичәдә «Белем» җәмгыяте члены Б. Кадыйрова Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗаты турында сөйләде. Барда районының «Таң» газетасы каршындагы әдәби берләшмә членнары Р. Габтукаев, Д. Сарманаева һәм Г. Исмәгыйлова М. Җәлил шигырьләрен һәм үзләренең шагыйрьгә багышланган әсәрләрен укыдылар.

Казаннан чакырылган кунаклардан шагыйрь Илдар Юзеев һәм композитор-җырчы Мәсгут Имашевларның М. Җәлилгә багышланган әсәрләрен тамашачылар аеруча кызыксынып тыңладылар. Свердлов исемендәге культура сараеның татар-башкорт сәнгать коллективы көче белән куелган һәм Муса Җәлил әсәрләреннән төзелгән концерт та кичәдә катнашучыларның күңеленә хуш килде.

## ТАМАШАЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Драматург, актер, тамашачы. Шушылардан башка театр яши алмый. Болар арасында тамашачы аеруча әһәмиятле урын тота, чөнки театрның төп максаты — тамашачыга рухи азык бирү, аны безнең коммунистик идеал яктылыгында тәрбияләү. Шуңлыктан тамашачының фикере театр өчен аеруча әһәмиятле.

15 мартта үткәрелгән тамашачылар конференциясен Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театры директоры Рәшидә Җиһаншина әнә шундый фикерләр белән ачып җибәрде.

Театрның баш режиссеры, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Марсель Сәлимҗановның кереш сүзеннән соң тамашачылар үзләре чыгышлар ясадылар. «Спартак» аяк киемнәре берләшмәсе эшчесе Зиннәтов, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты студентлары Галиев, Ситдыйков, театр белгече, филология фәннәре кандидаты Б. Гыйззәт һәм башка иптәшләр театрның ирешкән уңышларына сөенеп сөйләделәр, теләк-фикерләрен әйттеләр.

Соңыннан спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде.

## ҖӘЛИЛ ТУРЫНДА ЯҢА КИТАП

Муса Җәлил... Бу исемне хәзер бөтен дөнья халкы белә. Бу исем — батырлык һәм илгә турылык символына әверелде. Муса Җәлилнең иҗаты, тормышы һәм фашизмга каршы көрәше турында төрле илләрдә, төрле телләрдә шактый күп китаплар басылып чыкты инде. Һәм хәзер дә басылып тора. Бу өлкәдә рус язучысы Юрий Корольков аеруча тырышып эшли. Аның Муса Җәлил турындагы «Через сорок смертей» («Кырык үлем аша») исемле китабы укучыларга яхшы таныш. Ул китапның укучылар соравы буенча чыгарылган икенче басмасы да бик тиз таралып беткән иде. Әле күптән түгел генә Ю. Корольковның Муса Җәлилгә багышланган тагын бер китабы басылып чыкты. Мәскәүдәге Политиздат нәшрияты тарафыннан «Совет иленең Геройлары» сериясендә чыгарылган «Не пропавший без вести» («Хәбәрсез югалмаган») исемле бу китапта М. Җәлилнең дошман белән тигезсез көрәш алып барган вакытындагы тормышы һәм шул чорларда иҗат иткән шигырьләре турында сөйләнә.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Әлмәт бүлеге язучылары нефть районнарындагы нефтехимия промышленносте житәкчеләре, шәһәр партия оешмасы вәкилләре белән әледән-әле очрашып торалар. Соңгы очрашуларның берсендә КПСС Әлмәт шәһәр комитетының икенче секретаре С. Х. Закиров чыгыш ясады. Ул язучыларга шәһәр һәм район промышленносте предприятиеләренең бу бишьеллыкта үсү перспективалары һәм район халык хуҗалыгы алдында торган бурычлар турында сөйләде, сорауларга җаваплар бирде.

* * *

Бүлек утырышында КПССның Мөслим райкомында консультант вазифасын башкаручы, яшь язучы Фоат Садриевның хикәяләре укып тикшерелде. Әлмәт язучылары хөкеменә яшь авторның 10 лап хикәясе куелган иде. Чыгыш ясаучы иптәшләр һәммәсе Ф. Садриевның каләме үткен, юморга бай икәнлеген әйтеп уздылар. «Ал да гөл», «Башым кем ашый», «Ялгышлык», «Елга ага да ага» хикәяләре чагыштырмача яхшы дип билгеләп үтелде. Авторга әсәрләренең йомшак яклары да күрсәтелде.

Шул ук җыелышта шагыйрә К. Булатова каләмдәшләренә үзенең иҗат планнарын да сөйләде.

* * *

Әлмәт шәһәре янындагы «Юность» ял базасында район комсомол оешмасы секретарьларының ике көнлек семинары булды. Семинарда катнашучылар алдында шагыйрь Р. Фәйзуллин, драматург С. Кальметов иптәшләр чыгып ясап, үзләренең әсәрләрен укыдылар.

* * *

Соңгы айларда Әлмәт бүлеге язучыларының Татарстан китап нәшриятында байтак әсәрләре аерым китап булып басылып чыкты. Алар арасында Г. Афзалның «Ышаныгыз» исемле сайланма шигырьләр китабы, Р. Фәйзуллинның «Гадиләргә гимн», С. Сөләйманованың «Елмаеп тора Ильич» исемле шигъри җыентыклары, проза әсәрләреннән Р. Төхфәтуллинның «Давыл чәчәге», Ә. Маликовның «Кембригә юл салучылар», М. Хәсәновның «Көн җылынды», «Юллар, юллар» исемле китаплары бар.

## ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР СЕКЦИЯСЕНДӘ

Татарстан язучылар союзы каршындагы тәнкыйтьчеләр секциясенең чираттагы утырышы «Казан утлары» журналында әдәби тәнкыйтьнең торышын тикшерүгә багышланды. Күп кенә тәнкыйтьчеләр һәм язучылар катнашкан ул утырышта филология фәннәре докторы Ибраһим Нуруллин көн тәртибенә куелган мәсьәлә буенча доклад ясады.

Аның доклады буенча фикер алышуда шагыйрьләребездән Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур, өлкән әдибебез, драматург Нәкый Исәнбәт, тәнкыйтьчеләрдән Гали Халит, Гази Кашшаф, Рафаэль Мостафин, әдәбият белгече Азат Әхмәдуллин, «Казан утлары»ның тәнкыйть бүлеге мөдире Фәрваз Миңнуллин һәм башка иптәшләр катнашты. Алар бердәм рәвештә журналда басылган тәнкыйть материалларының сыйфаты нигездә канәгатьләнерлек булуын билгеләп үттеләр һәм шул ук вакытта тәнкыйтьчеләребезнең бүгенге әдәби әсәрләргә тиешенчә игътибар бирeп җиткермәүләрен, күп кенә китапларның рецензиясез калып килүен дә әйттеләр. Утырышта өлкән әдипләребез иҗаты турында кызыксынып укырлык монографияләрнең аз булуы, тәнкыйтьчеләребезнең үз әдәбиятыбыздагы уңышлы һәм уңышсыз әсәрләр хакында союз матбугатында бөтенләй сүз алып бармаулары, ә бу нәрсәнең бик кирәк икәнлеге әйтелде.

## МӘСКӘҮГӘ, ШИГЫРЬ УКЫРГА

СССР язучылар союзының әдәбиятны пропагандалау бюросы илебезнең төрле милләт әдәбиятлары вәкилләрен әледән-әле Мәскәүгә чакырып, әдәби кичәләрдә аларның иҗат отчетларын үткәреп килә. Шундый кичәләрнең берсе күптән түгел генә Мәскәүдәге Союзлар йортында булды. РСФСР язучылар союзы секретаре Сергей Наровчатов председательлегендә уздырылган ул кичәдә украин язучылары Микола Бажан, Дмитро Павлычко, Владимир Попов, грузин шагыйре Ираклий Абашидзе, Дагыстаннан Рәсүл Гамзатов һәм Фазу Алиева, Белоруссиядән Аркадий Кулешов, татар шагыйре Зәки Нури һәм күп кенә Мәскәү язучылары катнашып, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ КОНСУЛЬТАЦИЯ БҮЛЕГЕНДӘ

Кукмара районы Лубян урман техникумы студенты Энәс Ибәтуллин һәм Башкортстанның Авыргазы районыннан укытучы Салават Рәхмәтуллин Язучылар союзының консультация бүлегенә чакырылдылар. Аларның шигырьләрен тикшерүгә багышланган семинарда шагыйрьләрдән Хәсән Туфан, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Рәдиф Гатауллиннар катнашты.

Ике яшь шагыйрьнең иң яхшы дип табылган шигырьләре «Казан утлары» журналына тәкъдим ителде.

* * *

Саба район газетасы каршында оештырылган әдәби берләшмәнең чираттагы утырышында шагыйрьләрдән Сибгат Хәким, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Зөлфәт Маликов һәм драматург Туфан Миңнуллин катнаштылар һәм башлап язучыларның әсәрләре турында фикерләрен әйттеләр, әдәбият алдында торган бурычлар турында сөйләделәр.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Казанның 2 нче производство-техник училищесы укучылары, Муса Җәлил иҗатына һәм тормышына багышлап, тематик кичә үткәрделәр. Ул кичәдә тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин да катнашып, үзенең М. Җәлил турындагы китабын («Җәлил эзләре буйлап») ничек язуы турында сөйлә-

де, укучыларның бик күп сорауларына җавап бирде.

Казанның оргсинтез заводы эшчеләре дә Рафаэль Мостафинны үзләре белән очрашуга чакырдылар. Р. Мостафин аларга герой шагыйрьнең тормышы һәм иҗатына бәйле булган яңа материалларны ничек эзләве һәм табуы турында сөйләде.

* * *

Ерак Казагыстан даласында «Казан» совхозы бар. Бу совхозны чирәм җирләрне күтәрү чорында — 1954 елда Татарстаннан килгән кешеләр төзегәннәр иде.

Совхоз елдан-ел үсә. Ул — Павлодар өлкәсендә алдынгы совхозларның берсе. Совхозның таштан салынган ике катлы культура йортына да «Казан» исеме бирелгән.

Совхозга Татарстан язучылары да баргалап торалар. Күптән түгел язучы Самат Шакир шул совхозга барып, якташлар белән очрашты. Ул совхоз эшчеләренә үзенең яңа әсәрләрен укыды, татар әдәбияты турында сөйләде һәм совхоз эшчеләре турында очерк язу өчен материал туплап кайтты.

## «ТАТАР АШЛАРЫ»НЫҢ ЯҢА БАСМАСЫ

РСФСР сәүдә министрлыгы карамагындагы Үзәк кулинария советы члены, Ленин орденлы пешекче-оста Юныс Әхмәтҗановның «Татар ашлары» исемле китабы моннан бернична ел элек татар телендә ике тапкыр, рус телендә бер тапкыр басылып чыккан иде. Ул китаплар йортта аш-су пешерү белән шөгыльләнүчеләр арасында




тиз арада популярлашып киттеләр. һәм сатылып та беткәннәр иде инде. Бу китапны тагын бер мәртәбә бастырып чыгаруны үтенеп, Ю. Әхмәтҗановка бик күп хатлар килде. Әнә шул иптәшләрнең үтенечләрен искә алып, автор «Татар ашлары»ның кенә яңа мәгълүматлар белән тулыландырылган яңа басмасын рус телендә бастырып чыгарды. Китап төсле рәсемнәр белән иллюстрацияләнгән һәм ледирин тышлык белән басылган.

## ТАТАР ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ

Мәскәүдәге Бөтенсоюз «Совет композиторы» нәшрияты татар халык [illegible] аерым китап итеп бастырып чыга[illegible] халкыбызның ике йөз утыз җырын эче[illegible]ган бу җыентыкны сәнгать фәннәре кандидаты, музыка белгече Мәхмүт Әхмәтҗанов төзегән. Редакторы — ТАССРның атказанган композиторы Александр Сергеевич Ключарев.



Бу китаптан татарлар гына түгел, башка милләт вәкилләре дә файдалана алачаклар: җыентыкка кертелгән җырларның барысының да русча сүзгә-сүз тәрҗемәсе һәм ноталары бирелгән. Төзүче тарафыннан җыентыкта бирелгән сүз башы да рус телендә язылган.


Җырлар китапка тематик яктан хезмәт җырлары, мәҗлес җырлары, туй җырлары, уен җырлары, бәетләр, лирик җырлар, рекрутлар һәм көнкүреш җырлары диган бүлекләргә аерып урнаштырылган.

Җыентык зур формат белән, яхшы кәгазь һәм ледирин тыш белән чыгарылган.

# ТАТАРСТАН ТАҢНАРЫ

М. МАКАРОВ музыкасы

Г. АФЗАЛ сүзләре




Дулкынланып тирбәлә җыр:
«Сандугач кунмас инде;
Ямьле булса да торган җир
Туган җир булмас инде».

Санта торам ил чигендә,
Басмаган җир калмады;
Кайда йөрсәм дә күңелдә
Татарстан таңнары.

Таныш чәчәкләр җыясың
Болынга чыгасың да.
Әллә ничек үз тоясың
Аен да, кояшын да.

Кошлары сайрый тирәктә,
Сыгылып үсә таллары.
Кайда йөрсәм дә йөрәктә
Татарстан таңнары.

Зәңгәр тәрәзә каршында
Урмәле гөлләр үсә.
Чишмә буе тау астында
Фирүзә җилләр исә.

Басуларда эшләп үсә
Кызларның уңганнары;
Сагындырып искә төшә
Татарстан таңнары.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210